# КАЗАН УТЛАРЫ

12
ДЕКАБР
1980

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**12**
ДЕКАБРЬ
1980

## *Бу санда*

Х. ТУФАН. Мә, партия, мине! Шигырьләр . . . 3
Р. ТӨХФӘТУЛЛИН. Ике каен, бер карама. Хикәяләр . . . . . . . . . . . . . . . . 7
Ф. ХӨСНИ. Кем гаепле! Хикәя . . . . . . . . 29
М. ГАЛИЕВ. Сиңа мин кирәк. Хикәя . . . . . . 35

ЧАЛЛЫ ШАГЫЙРЬЛӘРЕ

К. СИБГАТУЛЛИН. Халык җыры. Шигырьләр . . 47
Х. ХӨСНУЛЛИН. Чаллым яктысы. Шигырьләр . . 51
Н. МАДЬЯРОВ. Күзгә кояш. Шигырьләр . . . . 53

М. ХӘБИБУЛЛИН. Яңа өй. Хикәя . . . . . . . 54
А. ГАНИЕВ. Иман. Хикәя . . . . . . . . . . . . 69
З. МАНСУРОВ. Уйлый белгән йөрәк. Шигырьләр 75
М. ХУҖИН. Кара күл. Хикәят . . . . . . . . 78
А. ХӘСӘНОВ. Фәндәм фонды. Хикәя . . . . . . 86
М. МАЛИКОВА. Сары тюльпаннар. Хикәя . . . 104

КПССның XXVI СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

М. ЗАРИПОВ. Мәңгелек шәһәр. Очерк . . . . 116
Г. ГОМӘРОВ. Кызлар үзәнендә. Очерк . . . . 126

ДУСЛАР ИҖАТЫ

Бездә кунакта: коми шагыйрьләре . . . . . . 131

ХӘСӘН ТУФАНГА 80 ЯШЬ

Х. ТУФАН. Ул — безнеке, без аныкы идек. Истәлек . . . . . . . . . . . . . . . . 139
Г. БӘШИРОВ. Шагыйрь бакчасында . . . . . . 140
С. ХӘКИМ. Туфан — күпер . . . . . . . . . 144
Т. МИҢНУЛЛИН. Шаянлык һәм җитдилек . . . 146

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

**А. ЯХИН, Ф. НИЗАМОВА. Кайсыгызның кулы җылы** . . . . . . . . . . . . . . . . . 146
**Р. КУТУЙ. Аккош күлендә. Шигырь** . . . . . 152

САЛИХ СӘЙДӘШЕВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

**З. СӘЙДӘШЕВА. Җыр бишеге янында** . . . . 153
**Ф. САЛИТОВА. Чорга аваздаш** . . . . . . . . 156
**Ә. БАКИРОВ. Соңгы очрашу. Истәлек** . . . . 158
**М. ХӨСӘЕН. Тукае син көйле дөньяның** . . . . 159

ТӨРЛЕСЕННӘН

**А. ЮСФИН. Аның күңел гөлбакчасында** . . . . 162

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**И. АХУНҖАНОВ. Тәрҗемәче ачкан тәрәзәләр** 165
**Безнең сафка** . . . . . . . . . . . . . . . . 170

НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

**Ш. ГАЛИЕВ. Тургайлар министрына хат. Шигырьләр** . . . . . . . . . . . . . . . . 172

СӘНГАТЬ

**М. ГЛУХОВ. Бәхетле иҗат** . . . . . . . . . 176

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

**В. ЕНЕШ. Классиклар эзеннән** . . . . . . . . 179

**1980 елда журналда басылган әсәрләр исемлеге** 181

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары** . . . . . . 190

**Баш редактор: ЗӘКИ НУРИ**

**Редколлегия: ӘХСӘН БАЯНОВ** (баш редактор урынбасары), **ШАМИЛ БИКЧУРИН, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, КОЯШ ТИМБИКОВА** (җаваплы секретарь), **СИБГАТ ХӘКИМ, НИЛ ЮЗИЕВ**

---

Техник редакторы *Р. Сөләйманова*
Корректорлары *Ф. Кадыйрова, Т. Шакирҗанова*

---

**Редакциянең адресы.** Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.
**Телефоннар:** баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-63, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Производствога бирелде 30/VIII-1980 ел. Басарга кул куелды 19/XI-1980 ел. ПФ 09040. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 92600 экз. Заказ У-372. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1980 ел.

## Хәсән Туфан

### Мә, партия, мине!

*Ленин үлгәч, юксынып*

Күңел — ярсу елга,
Күкрәгемдә — уйлар ташкыны,
Авыр, дуслар,
Бу йөрәк бит чуерташ түгел!

Безнең яклар — «бүре оясында»,
Әнә теге
Ак чикмәнле болыт турында,
Таш калалар — ерак,
Михнәт сукмагында
Юлаучы без
Борын-борыннан.

Җи-ир!
Кайгыда тагын ярлы явың,
Күңеле китек
Безнең тирәнең.
Җилкәләрдә гүя уйлар тавы,
Ә башларда — сагыш кибәне...

Ленин...
Кайда соң ул —
Безнең киң күңел?..
Әллә ничек авыр, моңсу
Ансыз ил көне...

Инде
Кемдә, кемнең йөрәгендә
Безнең ише илләр кайгысы?
Әй сез, батыр ирләр,
Юксылларга әти кайсыгыз?

Йөрәк таш түгел дә...
Кайгыдан да безгә файда юк.
Ленин,
Ленин кирәк безгә,
Кайда ул?..

Әй, партия!
Синме алмаш хәзер,
Әй, синдәме

Ятим ил ире?
Синме
Кояш кебек
Барыбызга уртак — тиң Ленин?!.

Ялгыз да мин, моңлы да мин,
Мә, партия, мине:
Иш кирәк миңа.
Синдә бит ул, синдә:
Безнең Ленин бүген
Син бит, партия!

*1926*

## Сиңа

Тагын бер яз саубуллашып китте,
Ядкарь итеп чәчәкләр биреп...
Син дә киттең,
Төсеңне тик миңа
Гомерлек бер истәлек итеп.

— Ут эчендә йөргән чакларында
Җуйгандыр ул мине,— дисеңме?
Юк,
Җаным белән ышыклап алып чыктым
Һәлакәтләр аша мин сине.

Ничә тапкыр гизеп үттем инде
Җир шарының орбитасын мин;
Тик беркайда очратмадым сине,
Табалмадым, табылмадың син.

Очрашып бер тагын вокзалларда
Саубуллашып үтәсе иде;
Йөрәгемдә синең иреннәрнең
Җылысын алып китәсе иде!..

Әйт булмаса,
Озак истәлеккә
Бер җылы сүз әйт син булмаса.
Бу чиге юк озын мәңгелектә
Бер генә кат яшибез ласа.

*1952*

## Эстафета

Тугры улың хәлдә, Русиям,
Кичтем барлык авыр елларны.
Бу — Тукаең биргән васыять
Юлларымны минем нурлады.

Азмы синнән җылылар алдым
Салкыннарга тарыган чагымда:
Ленин биргән кояш бардыр күк
Синең изге, җылы җаныңда!

Иңнәремдә азмы, Русиям,
Җылысын тойдым изге кулыңның...
Йөз кат, мең кат бурычлы сиңа
Минем бүген исән булуым.

Сиңа тугры бала буллуны
Байрак итеп йөрткән шикелле,
Дәвам итә минем тормышым
Каралтмаган хәлдә исемеңне.

Бүген Казан мәйданында мин
Сәлам биреп
Сиңа
Баш иям,
Тукай биргән эстафетаны
Югалтмаган хәлдә, Русиям.

*1956*

## Гомерем юлы

Зирәк илем, кыю, чая илем,
Сиңа бит бер сүзем бар минем,—
Йә үлемемдә шуны, йә теремдә
Искә ал идең:

Һәр эшне мин
Башкардым тик бары
Синең өчен кирәккә күрә;
Кирәк төштә утка-суга кердем
Бата-чума һәм яна-көя.

Йөрәгемне, илем,
Кул кылмаган
Саф рәхмәтең синең иркәли,
Дулкынланып шулай, канатланып
Үтеп барам гомер үтәли.

Һәлакәтләр юлда очрый калса,
Кирәк булса корбан булуым,
Дөнья, сиңа әйтә алыр идем:
— Үзең кебек иде бу улың!

Сиңа, илем, антым бу минем.
Мин тик шуны әйтмәкче идем.

*1956*

●

...Байтак көнең юлда үтә, ир-ат,
Илдән — өйдән ерак җирләрдә.
Гаиләнең, өйнең иминлеге,
И, хатын-кыз, синең иңнәрдә.

Бураннарда искә төшәсез дә,
Җылынып китә безнең күңелләр! —
Сагындырган өчен рәхмәт Сезгә,
Юксындырган өчен, сеңелләр!

Яздан хәбәр булып алтын нурлар
Тәрәзләрдән түргә кергәндә,
Үбеп-кочып сезне, и, җаныйлар,
Сәлам әйтеп чыксын бездән дә.

## Кайтып килә идек

...Үткән чордан кайтып килә идек
Илебезнең Киләчәгенә.
Киңәшләшеп утырып алдык бераз
Кипарислар күләгәсендә.

Ә чал Диңгез, никтер дулкынланып,
Яр читенә якын килгәләп,
Безнең гәпне тыңлаштыра бугай,
Ара-тирә «хуп, хуп!..» дигәләп.

Чинарлар да
Тыңлап тора сыман
Диңгезне дә, безнең гәпне дә,
Башкорт, татар һәм дә балкар гәбен
Төшенәләр, ахыры, әле дә.

*1970*

●

...Гөлчәчәкләр сискәнәләр кебек
Гаҗәпләнеп, сеңелем, бу эшкә:
Атып түгел, асып үтәргәннәр,
Асып сине, асып бу төштә [1].

Сөеп-сыйпап узып киткән сыман,
Җилләр бәреләә уйчан йөзеңә.
Изүләрең — түшеңә сыланганнар,
Итәкләрең — бронза тезеңә.

Керфектәге яшьне сөртер идең,
Һәм битемнән — юллар тузанын...
Артка каерып бәйләп куелган шул
Синең, сеңелем, кайнар кулларың.

Сискәнә җан — кырда төнге җилләр,
Куе җилләр искән мәлләрдә:
Син бит, сеңелем, япа-ялгыз анда,
Төннәр уртасында, һәйкәлдә...

---

[1] Зоя Космодемьянская үтерелгән кырда, аның һәйкәле янында.

## Рафаил Төхфәтуллин

# ИКЕ КАЕН, БЕР КАРАМА...

ДҮРТ ХИКӘЯ

## ЮЛДАШ



Без аның белән «Казан» санаториенда таныштык. Бу шифаханә шәһәр уртасында урнашса да, урмандай карт парк артына сыенып утырганлыктан, кала шау-шуы, кала ыгы-зыгысы сизелми дә — бөтенләе белән дәва-ял дөньясы монда. Янәшә генә шифалы чишмәсе бар, ләм белән дә дәвалыйлар, һәр көн әллә нинди сихәтле суларында коенып чыгасың. Сихәтле су дигәннән, танышлык шуннан башланды да.

Шулай бер көнне «Энҗе су» дип аталган ваннада коенып чыгарга нәүбәтемне көтеп утырганда, йомшак кәнәфиләр теземе тирәсендә үзенә урын таба алмагандай тәкатьсезләнеп әрле-бирле йөренеп торган берәү игътибарымны җәлеп итте. «Алып батырдай...» дисәм, күз алдыгызга пәһлеван гәүдәле кеше килеп басар да, дөреслеккә бик туры килеп бетмәс. Буйга уртачадан чак кына тәбәнәгрәк үзе, әмма иңнәренә бер кәрниз буе күгәрченнәр кунарлык. Ул имән төбедәй муен, ишелеп тә уңган җитендәй куе чәч! «Шушы кадәр тазалыкны да дәваларга кирәк микәнни?» — дип уйлап куйдым. Уйлавым булды — санаторий-ял йорты ишеләрдә шук-шаян уйларның тел очына килеп җиткәнен сизми дә каласың — ярып та салдым.

— Ул чир дигәннәре, сезгә килеп кагылганда, бу арка-җилкәләрне абайламый калды микәнни соң? Юкса, тияргә җөрьәт итә алмас иде.

— Үзем дә дөнья куып йөри-йөри күрми калганмын шул. Күземә чалынса, арт сабагын укыта белер идем хаинның,— диде теге авызны алай бик ермыйча гына.

— Безгә әүвәл дөньяга килгән иң олы чир-хаинның арт сабагын укытырга туры килде шул. Үзеңә тигән вак-төяген ничек абайлыйсың!— дидем мин дә моның күкрәгендәге рәт-рәт тезелеп киткән орден-медальләр колодкасына ымлап.

— Анысы, сугыш яралары бер хәл. Сөякләр сына торды, яшьлек аларны ни арада ялгый торды. Ә менә сугыштан соң... Еллар буе вакытында ашау юк, туйганчы бер йокы күрмә. Шулары какшатты.

— Шулкадәр тынгысыз, нинди хезмәт ул?
— Егерме алты ел колхоз председателе булдым мин, парин.
— Уһу! Бу кадәр стажлы председательләр сирәктер ул. «Булдым» дисез...
— Хәзер, минә кулыма путевка тоттырдылар да, пенсиягә куып чыгардылар.
— Шулай пенсия яше дә җитте мени әле? Кыяфәтегезгә караганда һич бирмәс идем.
— Яшь җитеп тә бетмәгән иде дә... Янәсе. миңа персональный пенсия. Әй, эш яшьтә мени! Райком секретареннан алып, кичә генә рульгә утырган тракторчы малайга кадәр: «Ял кирәк сезгә, дәваланырга кирәк»,— ди башлагач...— Ул кискен генә кулын селтәп куйды да, миннән сигарет алды.— Тартуны ташлаганга да ун елдан арткан иде инде. Картаймыш көнемдә, кешедән теләнеп булса да, суыргалый башладым.
Танышып киттек. Еш кына карт юкәләр, каен, усаклар арасындагы сукмаклар буйлап, ашыкмый гына сөйләшеп йөрибез. Апрель урталары иде бу, яз соңлабрак килсә дә, бөреләр инде уянган, каеннар бөтен ботакчыкларын тутырып, саргылт-көрән алкаларын тагып алганнар, юкәләрдән бал исе бөркелеп киткәндәй була, ә сизгер усаклар инде йөзек кашыдай нәп-нәни, ялтыр-яшен яфракчыклар да ярып өлгергән. Сабый чагы, яңарыш чоры табигатьнең — ихтимал, шуңадыр безнең аңгәмә дә алай өлкән-җитди сөрергә ашыкмый, язның үзе күк шукшаян төстәрәк ага иде.
Газим Галиевичны алай, телендә сандугач сайратучылар исәбенә үк кертеп булмастыр, әмма гомер юлын тормышның үзәгеннән ерып үткән кеше буларак, сөйләр сүзе, кичергән чәкәлеш-вакыйгалары бетмәс-төкәнмәс иде аның. Шуңадыр, вәземләбрәк сөйләсәң озын кич буена җитәрлек вакыйганы, Газим абыең, сукмакны бер әйләнүдә түгәрәкләп тә куя, аның каравы, икенче әйләнүгә, яңа хикәятен башлап җибәрә иде.
Шулай язгы сукмаклар буйлап берәр көн әйләнгәч, мин шуны сизеп алдым: сөйләгән бар гыйбрәтле-мәзәкле хәлләре фронт истәлекләреннән дә, малай-егет чакларыннан алына Газим Галиевичның, ә менә чирек гасырлык председательлек дәвереннән ник кенә берәр хәл сөйләсен! Мин бу турыда аның үзенә дә сиздермәкче идем, ярый, вакытында тыелып кала алдым. Соң, «пенсиягә куып» чыгаруларына никадәр кәефе кырылганын беренче сөйләшүдә үк аңлатты ич.
Шулай да, ул чордан да бер вакыйга сөйләп алды. Һаман да, шул тазалык-саулыктан чыкты сүз.
— Таза-нык чаклар бар иде, парин,— диде ул гадәтенчә тавышына һичнинди офтану да, мактану да төсмере салмыйча гына.— Бер вакыт шулай, алтмышынчы елларда, берәүне акылга утыртырга туры килде. Берәү дигәнем, бер урам чирәмендә аунап үскән малай, Зәйнулла кордаш. Закон Зәйни дип йөртәләр. Артыграк та күп белә законны, төчкерүеңә кадәр, әлхәмделилла, законча булсын. Шуннан тагылган кушамат. Безнең чәкәләш тә шул нигездә чыкты. Болай сабыр гына малай үзе, шариклары да әйбәт кенә эшли. Шактый еллар районда җитәкче булып йөрде. Булды шәп кенә күтәрелгән чаклары, булды түбәнгәрәк очкан еллары. Тормыш дигәнең гел тигез юлдан әлдертәмени? Бар аның чалулары, борылышлары, кашлаклары. Булды бит әле шундый еллар... Районнарны төрлечә бүлгәләп, оешмаларны кырыкка үзгәртеп бетереп, бер дә галәмәт новаторлар булып киттек. Менә шул чорда моны эштән-эшкә, урыннан-урынга күчереп йөртә торгач, хуҗалар белән конфликтка кереп беткән дә, бөтенләй эшсез утырып калган бу. Бервакыт, очрашсак, үкереп җыламый гына бичара. «Мотоциклны сатам да, китәм Мәскәүгә. Иң югары җиргә кадәр барып җитәрмен, хаклыкны тапмый туктамам!— дигән була үзе.— Кешедән бу кадәр көлмәсеннәр, юк

ул бездә андый закон, күрсәтәм әле мин аларга!»— дип, мондагы житәкчеләргә йодрык та төйнәп ала. Шулай гайрәт орса да, күрәм, хәле шәптән түгел моның. Хатыны авыру, баласы икәү. Урыннан-урынга күчә-күчә йорт жиһазларын да таркатып бетергәннәр, бар булган кошкорт, мал-туар ишедән дә берни калмаган. Син, кордаш, мин әйтәм, алай йөргәнче, давай, тот та авылга кайт. Колхозда эш житәрлек, үзеңнең хаклыгыңны хәләл хезмәтең белән раслаудан да олырак дәлил бармы соң! Кулын гына селтәде ул вакытта.

Әмма бер ай үтте микән, үзебезгә кайтып егылды тагын. Чыннан да барган Мәскәүгә, кайларга кергән дә ниләр әйткәннәр — алары турында ләм-мим. «Кайттым илемә, язганын күтәрәм иңемә. Хет көтүче ит, хет тирес түгәргә куй, чит илләрдә хан булганчы, үз илемдә чабан булам»,— дип жибәрә. Бик хуп, мин әйтәм, нәкъ менә көтүчеләр кирәк тә безгә. Прәме кризис! Шулай дигәч, авызын кыйшайтып елмайгандай итте бу, дерелдәгән бармакларын көчкә тыеп папирос кабызып жибәргәч кенә «б-б-була ул», дип әйтә алды. Ну, минем моны болай гына әйтеп каравым, чынында, правлениедә киңәшеп, завферма итәргә чамалап куйган идек без аны. Район күләмендә житәкчелек тәҗрибәсе булган кеше, бер ферманы гына ничек тартмасын? Шушыны әйткәч кенә чырайларына төс керде.

Ярар, эшли башлады бу. Әллә ни шаккатырмаса да, эшен ничава гына алып бара кебек. Әмма ләкин, парин... Эшеннән бигрәк, акыл сатып, закон өйрәтеп кинәндерә бу безне. Теге карарны тиешенчә үтәмибез, бу карарның фәлән пунктын онытабыз. Болай итсәк законный булмый, теге эш законга сыймый... Колак итләрен кимерепме-кимерә, парин. Үзебездә генә сөйләнеп калса тагын бер хәл, эш арасында башка да килмәгән гаепләр табып, районга житкереп тора бит! Килеп тә тикшерәләр моның кләүзәләрен, үземне чакыртып та. Районнарның, теге, галәмәт тә эреләндерелгән чагы, үзәккә бер барып кайтырга төгәл өч йөз чакрым юл әйләнәсең.

Алай икән, мин әйтәм, шушы рәвешчә авторитет казанып, яңадан районга сикерергәдер инде моның исәбе, безнең жилкәләрне трамплин итүедер... Алай дисәң, авылга кайтуга, бик зурдан кубып яңа өй торгызып йөри башлады үзе, чынлап торып биредә төпләнергә дә ниятли шикелле. Күрәсең, ничәмә еллар районда эшләп, шулай акыл сату, закон өйрәтү бөтен күзәнәкләренә кадәр сеңгән моның, шунсыз яши дә алмый бу хәзер.

Ярар инде, мин әйтәм, аның закон белүе кайчак ярап та куя бит әле. Төрле хуҗалык оешмалары белән эш йөрткәндә, низаглары чыкмый тормый. Шундый чакта бу, законын таба, акыллы гына киңәшләр дә биргәли. Шулай да, парин...

Бервакыт, сабанга чыккан гына көннәр, райком секретаре... юк, парткомнар чоры бу, партком секретаре үзе чакырып алды. Яңарак кына эшли башлаган чагы секретарьның, холкын-фигылен, эш стилен әле чамалап бетергән юк. Шуңадыр, болай да пошаман күңел белән килеп керсәм, опять моның кләүзәсе! Таба белә бит гаепне... Булды бит бер заман, «паразит культура» дип, солыны бер дә яман хурлап ташладык. Ә мин, сельхозуправлениегә әйтмичә генә, аулаграк басуда күпмедер гектар солы чәчтергән идем. Шуны тишкән бит бу! Янәсе, мин консерватор, яңалыкка каршы килеп, кукуруз урынына солы чәчәм, жирне әрәм-шәрәм итәм. Ярар, секретарь да, Хәниф Садыйкович, минем кебек, сабый чактан ук ат жене кагылган малай икән, бу мәсьәләдә ничек тә аңлаштык. Юкса, борынгылар ук әйтеп калдырган сүзне жиргә салып таптап, атны солы белән түгел, чыбыркы белән куарга калыйкмы! Болай да, бигрәк почет бетеп бара бит жанашларыма. Монысына шулай бер жөннәрем котырса, тегенең тагын икенче бер кләүзәсе... Юк, кләүзе генә түгел монысы. Кләүзе әле ул яңакка кундыру беләнрәк тиң. Ә менә

яңакка гына түгел, жаныңа кизәнсәләр... Монысы инде, парин, үзәк бәгырьләреңне актарып ташлый. Монысына түзүләр, ай-һай... Кая, булмаса, берне көйрәтик әле, — дип ул тагын сигарет сорап алды.

— Кичә соңгысы дигән идегез, Газим Галиевич.

— Эчкә алмый гына суырам мин аны... Кеше күңеле бит ул, парин, төпсез диңгез. Ул төпсез тирәнлектә ниләр барын кеше үзе дә кайдан белеп бетерсен? Бигрәк тә күңел бакчасы — мәхәббәт мәсьәләләрендә. Адәм белән Һава заманыннан бирле кем аның серләренә төшенеп беткәне бар? Кыскасы, әнә шул күңел законнары кушуы буенча, бер авыру кызга... ну, ялгыз хатынга яңа йорт салып керергә булышкан идем. Между прочим, иң авыр елларда салкын фермаларда җанын аямый эшләп какшатты ул сәламәтлеген, бер өй салып бирү генә аз әле аңа. Аның каршындагы бурычыбызны түләп кенә бетерешле түгел. Ә теге, Закон Зәйни, үләт себергере дими ни дисен, моннан бик ямьсез мәгънә чыгарып, ниндидер закон бозулар табып язган бит районга җан көеге.

Менә шунда сабыр савытларым тәмам-тәмам тулып ашты минем. Монда инде мин түгел, әлеге күңел тирәнлегенең серле көчләре хәрәкәт итә башлады. Парткомнан ничек чыгып киткәнне дә, ни арада кайтып житкәнне дә хәтерләмим. Машина ничек чыдаган да, ничек авариягә эләкмәгәнмен — правление алдына килеп туктаганда, радиатордан паровоз уфылдавы күк пар бөркелә иде. Шунда, очрап торуын күр, каршыма ук килеп чыкмасынмы теге. Аулаккарак чакырдым да, менә шулай пинжәк итәгеннән урап тотып, мәче баласы күк бер кул белән күтәреп алдым моны, ә икенче кулны оборонада тотам. Җанга да закон эзли башладыңмы, мин әйтәм, моннан соң да тыгарсыңмы сасы борыныңны кеше җанына? Ант ит хәзер! Юк бит, кире беткән нәрсә, инде буылып бара, һаман үзенекен бытырдый. Авыр үзе, каһәр, гәүдәгә чандыр гына булса да, әллә бер центнер тарта. Кулбашларым суырылып чыгарга житсә житте, әмма моны тәмам антка китергәнче, әллә бер сәгать бүе, тәки күтәреп тордым шул. Бар иде таза чаклар, парин.

— Күз алдыма китерәм.

— Дорфалык, әлбәттә. Ләкин, әйтәм бит, җанына таш атсалар, монда инде син түгел, әлеге күңел көчләре хәрәкәт итә башлый, нихәл итәсең. Бу турыда моңарчы берәүгә дә сөйләгәнем юк иде, хәерлегә булсын.

— Хәерсезгә юрамыйк. Ничек соң, антын тотамы?

— Тота... тоттырсаң, — диде Газим Галиевич кырыс кына. — Между прочим, бу чәкәләш турында аннан да сүз чыкканы ишетелмәде. Җанга законны тәки таба алмаган, ахры.— Һәм ул бик куанычлы елмаеп җибәрде.— Күр, парин, сыерчык килгән бит! Бик дәртләнеп сайрый бу, тәңгә дә көр күренә. Әйбәткә бу, парин, игелеккә. Халык күптән сынаган.

Минем кайтып китәр көн алданрак житте.

Таныш сукмаклар буйлап соңгы мәртәбә әйләнгәндә, Газим шактый ара сүзсез генә атлагач, уйчан гына әйтте:

— Да, парин... Мең юлдаштан бер юлдашың юлдаш дигәндәй, кая гына барма — менә бу санаторий ишеләрдә дә — бер җан юлдаш кирәк икән адәм баласына.

— Бик кирәк. Ә менә җан тартмаган юлдашлар белән нишләргә соң? Синең кебек, якасыннан урап, антка китерсәң генә инде, — дидем мин, сүзне гадәттәге шук-шаян якка борырга ниятләп.

Газим Галиевич күкрәк кесәсеннән «бик хаҗәт чакка» дип саклап йөрткән сыңар сигаретын чыгарды. Сигарет кәкерәеп-бөкерәеп беткән

иде, хасиятләп шуны сыйпаштырды-төзәтте, аннары бик тәмләп бер иснәде дә, яңадан тыгып куйды,

— Андыйлары да, парин, өлешеңә тигән көмешең инде. Язмышың. Чыннан әгәр... Бу тормышта һәр юлдашың — яхшымы ул, яманмы — синең язмышыңа теге-бу яктан тәэсир итми калмый икән. Шулай икән ул...



## СӘЕРЛЕК

Һич көтмәгәндә Кама буе районына командировкага барырга кирәк булгач, күз алдыма шунда ук Газим килеп басты да, бу юлга мин бик теләп... юк, алай гына да түгел, куанып-ашкынып кузгалдым.

Мине бикләми генә зур йозак элеп куелган ишек каршы алды. Бакча яктан бик ачулы кырт-кыртлап, бер оя сары чебиләрен ияртеп чуар тавык килеп чыкты, әллә кайдан гына ала песи сикереп төште дә, ишек төбендә койрыгын үрә катырып алып, күзләремә карап мияулый башлады.

Дөресен генә әйткәндә, күңелем сизгән иде аны... Юк, болай бикле ишек күз алдыма килмәде, әмма Газимның өйдә булмаячагын чамалаган идем. Балыклыда райком секретаре әйткән иде: «Урак өстенә карaганда да кызурак чак хәзер, — диде. — Терлек азыгын күбрәк хәзерләп калырга кирәк. Печән котырып та уңган шушындый елда да форсатны кулдан ычкындырсак, тавыклар көләр бездән. Бөтен халыкны күтәрдек. Интеллигенциясе, хезмәткәрләр, пенсионерлар, укучылар — бар да сенажда, яфракта».

Әлбәттә, бу эштән Газим ничек читтә калсын? Өйдә тагын кемнәр бар дигән иде әле? Карчыгы, төпчек кызы... Күрәсең, алар да кузгалган.

Ә чуар тавык, ачулыдан-ачулы кырт-кыртлап, миннән чебиләренә җим сорый, ала песи ишек ачуымны үтенә. Ничек ярдәм итим соң сезгә? Кибеттә бирәр нәрсә булса гына инде.

Кибетле олы урамны чамалап акырын гына атлыйм.

Әйе, Газим, чыннан да матур икән туган авылың, туган якларың. Ындыр артындагы үрдән күксел урманы үзенә дәшеп тора, бакча артлары буйлап, каз-үрдәкле инеше бормаланып уза. Ул берсеннән-берсе иркен-матур өйләр. Анысы, йорт-җир һәркайда бик төзек хәзер, ә биредә шунысына игътибар итми мөмкин түгел: ул тәрәзә наличниклары, ул кәрнизләр, ул өй буе рәшәткәләре аеруча бизәкләп, нечкә-нәфис челтәрләп эшләнгәннәр монда, өстәвенә верандалар, капка-коймалар — һәммәсе ак-зәңгәр, сары-яшел төсләрне бик матур аралаштырып, зәвык белән буялганнар. Өй буйлары челтәрле-бизәкле булса да, ишегалды турыларында тоташ биек койма башлана. Янәсе, ишегалдында ни барын, нишләүләрен күрми узсаң да ярар, лутчы, әнә, тәрәзә буендагы чәчәкләргә сокланып уз.

Сокланып узам. Өй буйлары, тәрәзә төпләре тулы гөлләр, рәшәткә-коймаларда, кәрниз-наличникларда кеше кулы белән җан өретелгән чәчәк-бизәкләр. Һәм, әнә, бер капка башында сыерчык оясы никадәр бай хыял белән экиняттәгедәй челтәрләп-бизәкләп эшләнгән. Кара син аны. «Канатлы дускайлар, әйдә, безнең күк иркен-матур ояларда яшәгез әле»,— диюең ич бу, авыл!

Һәм кинәт... хисләремнән исердемме, нәрсәгәдер абындыммы, чак кына мәтәлеп китмәдем.

Мәтәлерсең дә! Бая Газимнар тыкрыгында һич сизелмәгән иде, һәр зуррак авылдагыча, биредә дә шул ук хәл икән: аз гына да яшел

чирәм әсәре калмаган, чокырлы-чакырлы, кантарлы-ерганаклы икән олы урам. Әйтә кебек урам юлы: «Әй, кешеләр! Матур бай өйләрегездән елтыр резин итекләр, затлы плащлар гына киеп чыгасыз да, атлар юлыгызны, аяк астыгызны бөтенләй дә күрми узасыз ахрысы сез хәзер? Бу балчык-тузан, ырым-ерым астында бихисап бәбкә үләннәре тамыры, хуш исле алма үләне орлыклары шыта алмый зар елап ята бит. Ник ишетмисез шуны?!»

Зур тәрәзәле таш кибет тә мине йодрык кадәре йозагы белән каршылады. Ишек янагындагы кибетнең эш сәгатьләрен күрсәткән яшел калайны укып торганда, якында гына дәштеләр:

— Килеп житәр инде Бибикамал. Обед сәгате чыкты.

Янәшәдәге шомырт күләгәле капка төбендә утырган апаны, янындагы олы көнбагыштай эшләпәле кызыйны шунда гына күреп алдым. Апа, башын ия төшеп, кара ырмаулы күзлеге астыннан миңа карый, ә бармаклары күз иярмәслек тизлек белән нидер бәйли иде. Кызыйның да кулында бәйләү икән, анысы, дөньяларын онытып, эшенә текәлгән.

— Нигәдер соңлады әле бүген Бибикамал, бик аккуратный ача иде, — диде апа, сәламнәр алышкач. — Сез кунак, ахры? Кая, кызым, бирерәк кил, абый да утырсын.

— Әәә, Газим кичсез кайтмас инде ул, — диде апа минем кемгә килүемне сорашкач. — Гомер-гомергә өй эчләрен ут яктысында гына күреп яшәде, бахыр.

— Печәндер инде?

— Кем белә аныкын... Юк, печән дип бик исе китмәс аның, басудадыр ул. Һәр гектарын димәсәң үзе карап эшләтмәсә, күзләренә йокы керәмени аның!

— Инде пенсиядә булса дамы?

— Һи! Зәйнулла юллап биргән пенсиягә риза булып ятса, Газим буламыни ул аннары. Бер курортка барып кайтканчы гына житте түземе. Райкомга, әллә обкомга кадәрме житеп даулап йөри торгач, мели... мелиа... фу, тел күнегеп бетми һаман да... Мелиорация агрономы итеп куйдылар үзен.

— Менә ничек. Ә Зәйнулла дигәнегез... Закон Зәйни мәллә?

— Артында шулай дип йөрткән булалар да бит. Берәр четерекле эш чыкса, киңәшкә һәммәсе аңа йөгереп килә. Законын да белә Зәйнулла, ничек-ничек эш йөртәсен дә.

Ана кызыйның бәйләмен тоткалап-тоткалап күздән кичерде.

— Уу, кызым, син миннән дә уздырасың болай булгачыннан. Ничек тигез бара... Әүвәл-әүвәлдән шәлчеләр безнең авыл. Менә Әнүзәнең дә кулы ябышып тора...— Ул, хәйләкәр-мут елмаюын яшерергә тырышып кына сорап куйды: — Ничек соң, яшь килен ошадымы?

Мин моны Әнүзәне урынсыз шаяртуга санап, аптырабрак калдым.

— Нинди килен?

— Бәй, сез туйга килмәдегезмени? Газимнең уртанчы улы өйләнде бит. Шуннан бер атна гына элек төпчек кызлары кияүгә чыккан иде. Ике туйны бергә үткәрергә йөриләр хәзер. Фәйрүзә шул мәшәкатьләр белән Казанга китте. Өйдә килен ялгызы гынадыр, кунакны ничек каршылады диюем иде. Яшьләр белеп бетерәмени!

Мин өйнең бикле икәнен әйткәч, апа энәсен йомгакка кадап куйды.

— Иии, шулай мени әле?.. Юлдан килеп, чәй дә эчмәгәнсез инде сез, алайса. Әйдәгез, бездә эчеп чыгыйк.

— Рәхмәт, апа, рәхмәт. Балыклыда бик ныклап ашап-эчеп чыккан идек.

— Булмый ул юлдан килгәч чәй эчмичә. Бу эсседә тамак бик тиз кибә. Сез бер дә тартынмагыз, аяк очы күршеләр без Газимнәр белән. Алар кунагы — минем дә кунагым. Әйдәгез.

— Алайса... кибет ачылсын инде. Газимнәрнең чебиләре бик интегеп йөри анда, шуларга сибәргә биредә ярма-фәлән булмасмы дип килгән идем.

— Чебиләрен үзем кереп карап чыгармын. Булмаса, кызым, син кайтып самовар куя тор. Аркаларың язылып, күзләрең ял итәр. Эшне шулай аралаштырып эшләсәң ардырмый ул. Бар.

— Нигә чәйнектә генә кайнатмыйбыз чәйне, әни? Тиз була ич.

— Кунакка чәйнек чәе эчермиләр, кызым. Самовар куй, иренмә. Бетсә, лапастан каты күмер апкер. — Апа кул сәгатенә күз төшереп алды, сәгатьнең әллә алтын, әллә алтынланган беләзеге күзне чагылдырып җемелдәп китте. — Шул туйга аяк киенүем иде инде минем дә. Бүләкләр дә аласы бар, шешә-мазарын да алдан алып куймасаң, мондый чакта уңайсыз хәлдә калуың бар. Яшь килен белән кияүне бөтен авыл чәйгә дәшә бездә. Ә минем чират алдан. Үзләре күршеләр, өстәвенә, килен белән мәктәптә бергә эшлибез. Яшь кенә булса да бик әйбәт укытучы килен. Балалар үлеп тә ярата үзен. Теге... тумыштан педагог.

— Гафу итегез... Ә сез нинди фәннән укытасыз?

Апа кулындагы бәйләме белән авызын каплады, ә аз гына яшькелтрәк, уңганрак соры күзләре хәйләкәр-шук көлемсери иде.

— Техничка мин мәктәптә. Егерме елдан артык шунда эшләп, тәмам икенче туган йортыма әверелде ул мәктәп.

Шыгырдап капка ачылды да, аннан таягына таянып авыр гына атлый-атлый бер әби чыкты.

— Мөкәррәмә, гафил булма, кибетне көтсәң, сәгать бишсез килмәс әле ул Бибикамал, — диде ул, исәнләшкәч. — Печәнчеләр янында сәүдә итә ул бу вакытта. Кичә утырышта шулай хәл иткәннәр.

Һәм теге якка таба юнәлде. Сырлап-бизәкләп эшләнгән таягын, иелә төшеп, алга ук тери дә, аяк очыннан аяк очына гына өч-дүрт адым атлый, туктап таягын алга селти... өс-башы бик пөхтә, затлы әбинең. Җиңел-нәфис шәлъяулыгы читеннән күренеп торган чигә бөдрәләре исле сабын күбегедәй ап-ак булса да, иелгәндә җиргә кадәр диярлек салынып төшә барган купшы-калын толымында чал бөртекләр бөтенләй күренми. Менә ул, бераз баргач, бире таба борылып карады. Бер генә күз салды, югыйсә, әмма шушы карашның минем хәтердә мәңгегә сеңеп калуы булды бугай бу. Каш асты, керфек тирәләре дә каралыбрак торган бу зур кара күзләрдә күл чоңгылыдай әчке ургулы тирән моң гына чайпала, тагын да бераз карап торсаң бу тын чоңгыл кайнап ташый да башлар, шуңа ул карашын озаграк текәүдән сагаядыр кебек иде... Юк, әби дип әйтерлек түгел әле аңа. Һич юк! Мине аның таягы гына алдаган. Моңы-сагышы белән бергә, тыенкы кайнар дәрт тә бөркелеп тора иде бу караштa.

— Зампред Фәрәхшат белми әйтмәс, кайтыйк, болай булгачыннан. Әнүзәнең самовары да кайнагандыр, — дип, Мөкәррәмә урыныннан кузгалды.

— Авырып тора, ахры, зампредыгыз?

— Авырый шул ахири. Күптәннән инде. Ә зампред дигәне кушамат кына ул... Кайда, үземнең дә иреннәр үтереп тә чәй сорый башлады монда, кайтыйк.

Күптән эчкәнем юк иде инде минем мондый чәйне. Суын ерак чишмәдән махсус алып кайткан самовар чәе, өстәлдә хуш исле яңа балы, эре-эре җир җиләге, балан кагы — чәй эчүнең бөтен шарты килгән.

— Сез Зәйнулланы беләсезме? — дип, Мөкәррәмә чәй эчү, чәй пешерү турындагы әңгәмәне шулай кинәт кенә борып җибәрде.

— Алай күргән-белгән кешем түгел. Бер сөйләшеп йөргәндә, Газим телгә алган иде аны, кушаматы кызык булгач, истә калган.

— Алай бик матур сөйләмәгәндер әле аны Газим. Гомер-гомергә бик килешеп бетә алганнары юк.

— Нигә икән?

— Кем белә инде кешенекен. Характерлары бигрәк ут белән су күк шул. Газим бик турыдан яручан, тынгысыз, ярпач халык, ә Зәйнулла сабыр гына, көенә-җаена китереп эш йөртергә ярата. Шуннан да чыга бугай чәкәләшләре.

Мөкаррәмә, урынынннан торып, «ачсаң, өйгә чебен тула, ачмасаң бөркү» дип, үз алдына сөйләнә-сөйләнә, тәрәзәне япты, тагын ачты, тагын шапылдатып ябып куйды.

— Анысы, уйлый китсәң, бар инде сәбәпләре. Инде олыгаеп беткәч, әйтергә дә ярыйдыр, яшьлек елларыннан ук килә аларның килешмәүләре.

— Шулай олыгайгач кына төшенә башлагандай буласың бит ул яшьлек сәерлекләрен.

— Боларныкын олыгайгач та аңламассың. Чисти бер табышмак.

Мөкаррәмәнең бу турыда нидер сөйләргә дә теле кычыта, ят кеше алдында бик җәелеп тә бетәсе килми иде бугай.

Шулай да, бераз тын гына утыргач, моңсу гына елмаеп куйды да, сөйләп китте ул.

— Баягынак Фәрәхшат ахирине үзегез дә күрдегез, хәзер дә күзгә чәчәктәй әле ул, ә яшь чагында... Ничек кенә дип әйтим? Ут чәчәк иде ул, янар чәчәк! Ләкин, әбиләр әйтмешли, ходайның рәхмәте, балачактан ук язмыш бик иркәләмәде аны. Үзе дә үсмер генә абыйсы белән печән ташыганда, Каенсар үреннән төшешли атлары дулап китә дә, олау башындагы Фәрәхшат яр астына тәгәри. Бик озак район больницасында ятып, шуннан сизелер-сизелмәс аксый торган булып кайтты. Аннан килеп, сул яңагында ярты ай-урак күк җөе калды, бәлки үзегез дә абайлагансыздыр? (Юк, һич тә күземә чалынмады). Менә шуңа бик тә кимсенә иде, ахры. Хәер, алай кимсенүен мин аның шактый соңрак сиздем әле. Болай булды. Сугыш елларында почта йөрттем мин. Көндезләрен басу-әвендә эшләсәм, иртә-кичләрен почта таратып авыл әйләнәм. Үзегез беләсез инде, җаның гына түгел, иңнәр дә күтәрә алмастай авыр кара кайгылы хатлар да ташырга туры килде, бии-биетә торганнарын да. Ул фронттагы егетләреннән хат килгән кызларны һич биетми калдыру юк. Шулай, кызларны биетәм, канатландырам, ә үзем... Үзем кругльй мәхрүм андый шатлык-куанычтан. Фәрәхшат та мәхрүм. Кая, сугыш башланганда җидене яңарак кына бетергән көйгә, егетләр сөяргә өлгерә алмый калдык шул без. Еллар үтте, яшьлек сугыш дип тормый, үзенекен итә, сөя-сөеләсе дә бик килә башлады. Һич югында, өлкәнрәк кызлар кебек, фронттагы егетләрдән хат алсаң икән, дибез. Язгы-җәйге кичләрдә авыл читенә, болынга ук чыгып китәбез дә, башларыбызны башка куеп төрле сөю-сагыну җырлары сузып йөрибез, эчләребез тулы мәхәббәт, сагыш-зарыгуларыбызны шулай юатабыз. Бер кичне әйтә куйдым мин: «Әйдә, дим, без дә сугыштагы егетләргә хат язабыз». «Кит, тиле! Кызлар егетләргә башлап хат язамыни, булмаганны!» — дип, төртеп үк җибәрде үземне Фәрәхшат. Соң, мин әйтәм, сөю-мәхәббәт хаты димимлә мин. Хәл-әхвәлләр, авыл хәбәрләрен генә язарбыз. Туган яктан хат алулары ут эчендәге егетләргә әллә күңелсез булырмы? Почта йөрткәч, белеп йөрим бит, фронтка киткән бар егетләр дә кызларга хат язып тормый, әти-әниләренә хатлары килә, туганнарына, ә кызларга юк. Бар андыйлар да. Шулай дигәч, Фәрәхшатым да күнде. Ләкин кайсыбыз кемгә яза? Беребез дә атап кына әйтә алмый. Озак уйлап тормастан, җирәбә салырга булдык.

Әйтерсең, әллә нинди серле-шомлы эшләр кылып йөрибез. Бакча

артларыннан гына безнең ак мунчага кайтып бикләндек, тәрәзәне томаладык. Чыра яндырып, газета кырыеннан кисеп алган кәгазьләргә дүртме-бишме егетнең исемен язып чыктык. Беренче булып жирәбә тартырга Фәрәхшат үземне күндерде. Миңа Зәйнулла исеме чыкты. Инде Фәрәхшатка чират. Әлегәчә хәтеремдә, күзләрен чытырдатып йомды ахири, бик авыр сулап, нидер пышылдады, аннары гына жирәбә бүрегенә үрелде. Жирәбәсен ачып укуы булды... Башта мин аның кулына чырадан утлы күмер төштеме дип торам, шулкадәр дә җан ачысы белән кычкырып җибәрде ахири. Ул да булмады, ләүкә читенә капланып, сулык-сулык үкси дә башлады. Нәрсә булды, ни булды дип янында бөтерелеп йөрим, сүзен дә әйтә алмый. Аннары гына учына йомарлаган жирәбә кәгазен күрсәтте, укып өлгерүемә, куйнына яшерде. Газим исеме чыккан икән моңа. «Юк, юк, язмыйм мин аңа... Мин аксактан, мин чалыш авыздан хат алуның ни кызыгы бар аңа, язмыйм, көләр генә ул миннән»,— дип өзгәләнә бичаракаем. Юатып-үгетләп карыйм, аның саен үзен кимсетә, җанашым. Соң, мин әйтәм, әйдә алмашып язабыз, алайса, Газим күршегә үзем язармын, ә син Зәйнуллага яз. Әйтә торгач, монысына ничектер риза булды... Әй, яшь чаклар — җүләр чаклар диген.

Мөкәррәмә тагын моңсу елмаюлы көрсенеп куйды.

— Әнә шулай язышып киттек, — диде ул җитди-коры гына. — Язышып киттек дим дә бит... Газим минем ике генә хатыма кыска-кыска җаваплар язды да, шуннан соң ник кенә бер хатыма каршы хат килсен! Нишлисең, сугышларның бик кызган чагыдыр, хат язарга вакыты юктыр, дип күңелне юатасың, солдат кешегә үпкәләп булмый. Аның каравы, Фәрәхшат бик тә уңды ул яктан. Ахиринең бер хатына Зәйнулладан ике-өч хат килеп өлгерер иде. И матурлар да итеп язар иде соң хатларын Зәйнулла! Ахири белән арада серләр юк, һәр килгән хатны бергәләп укыйбыз. Исәнлек-саулыктан, сугыш хәлләреннән берәр генә авыз сүз язуга:

> Күзләремне ала алмыйм
> Сезнең яктан таң ата;
> Хатка язып сүзләр бетми,
> Жыр күбрәк аңлата,

— дип берсеннән-берсе матуррак җырлар тезеп китәр иде. Булса да булыр икән кешедә шулкадәр дә җыр-моң байлыгы! Кайбер хатларында дөнья сүзләре бөтенләй дә булмый, гел җырдан гына торыр иде хаты.

Ахиринең дә җыр капчыгы сайдан түгел, ул да җырга җыр белән генә җавап бирә торган булды. Егет исән-сау кайтса, алу-баруга җитәрдер, ахры, боларның эшләре дип ахири бәхетеннән көнләшеп тә куйгалый идем. Яшерен көнләшү генә түгел, моны үзенә дә әйткәнем булды. Мәк чәчәге күк кызарып чыгар иде дә ахири алай дигәченнән, «китче, тиле!» — дип, янымнан ук йөгереп качар иде.

Сугышлар бетте, Зәйнулла да, Газим да исән-сау әйләнеп кайттылар. Берәр ай Зәйнулла белән ахири матур гына йөрделәр. Шуннан соң... Менә шуннан соң башланды инде бөтен сәерлекләр. Кинәт әллә генә ни булды боларның араларында. Җүнләп сөйләшми дә Фәрәхшат Зәйнулла белән, чакырган җиргә дә чыкмый. Ни кылануың соң инде, ахири, ник алай тилмертәсең егетне, дим. Көлә генә. Ачуланыштыгыз мәллә, дим. Дәшми алай дигәченнән, сүзне икенчегә бора да җибәрә.

Бервакыт, кыш көне, эти белән әни каядыр киттеләр. Ул елларда кышын бер иңле бәс кунган салкын клубта нинди ямь булсын, яшьләр аулак өйләргә җыелып күңел ача идек. Мин дә аулак өй үткәрергә булдым. Күңел ачу гына түгел, ниятем Зәйнулла белән Фәрәхшатны очраштыру. Аңлашып-килешеп китмәсләрме дим. Ярар, җыелыштык

шулай. Башка аулак өйләрдә бик күренми иде, күрше Газим дә кергән. Бик хәтеремдә, Зәйнулла да, Газим да гимнастеркадан әле ул вакытта, орден-медальләре дә күкрәкләрендә... Иа, күңелле дә үтә иде ул аулак өйләр! Уен да көлке, җыр да бию. Күңелләрең тәмам-тәмам бушанганчы шаярасың-уйныйсың, үрттәшәсең-көләсең. Ни генә әйтмә, хәзерге иркен клубларда безнең заман аулак өйләрендәгечә ихлас та күңел хөрлеге юктыр кебек хәзер. Аннары, башка якларда ничектер, безнең аулак өйләрдә уеннардан соң берәр пар куна кала. Куна кала дигәч тә, бернинди гөнаһ-ямьсезлекнең катнашы юк монда. Бер-береңнең сафлыгын, җан-тән якынлыгын шул формы сынашу бу. Мондый сынашу булачак гаилә өчен дә зарури бер нәрсә түгел микән?

Ярар, анысы бүтән әңгәмә. Шулай, уеннар беткәч, яшьләрне чат башына кадәр озатып җибәрдем дә, кайтып, абзарда озаклап сыерга башак болгаттым, баскыч алларын себердем, тегесен-монысын караштырып йөрим. Үземчә, өйдә Фәрәхшат белән Зәйнулла иркенләп сөйләшсеннәр, комачау итмим дим. Әмма күңел гел кыбырсына, тегеләрнең ничек аңлашканын тизрәк беләсе килә. Бераздан кердем. Керсәм... күзләремә күренәме дип торам. Фәрәхшатым Зәйнулла белән түгел, Газим белән калган. Сәке кырыенда икесе ике яклап бер мендәргә таянганнар да, күгәрченнәр күк гөрләшәләр, мин кергәнне сизмәделәр дә хәтта. Юкәдә икән чикләвек, дим эчемнән, ахири дип йөр син аны!.. Шулай уйлап бетермәдем, кинәт ян тәрәзә чылтыррр коелып төште дә, эт башыдай таш Газимның баш очыннан гына стенага шак килеп бәрелде, шундук егет аннан-моннан киенеп тышка атылды.

— Менә син!

— Соңыннан, Зәйнулла белән Газим канга батып сугышканнар икән, дип яшьләр арасында сүз китте, әмма бу турыда Зәйнулладан сорашсам, кулын гына селти, Газим шаркылдап көлә генә иде.

— Кызык.

— Анысы, шуннан ара Фәрәхшат белән Газим матур гына йөреп киттеләр, моның бер гаҗәбе дә булмас иде. Кемнәр өчен кем көймәс тә, кем ярларын кем сөймәс, диләр бит. Яшьлектә була инде ул андый хәлләр. Әмма боларныкын... Ни дияргә дә белешле түгел.

— Ничегрәк?

— Газимны, кайтуына, бригадир итеп куйдылар аны. Еллары нинди иде бит, үзегез беләсез инде. Җигәргә җегәрле аты, батырып эшләргә батыры юк, дигәндәй, таң белән торып йөгерә башлар иде Газим, кара төн җиткәнчегә кадәр аяк өстендә. Җитмәсә, кичке мәктәпкә укырга да керде, җидене генә бетереп киткән иде. Фәрәхшат белән таңнар сызыла башлаганчы урамда сөйләшеп йөргәннәр хәтердә. Юк сүзләрен бар итеп сөйли дә сөйли ахири, мине яныннан җибәрми. Белеп торам, Газимны көтеп йөрүе моның, ә тегесе я укуда, я җыелышта. Ничегрәк соң араларыгыз, дип сүз ачсам, авызын турсайта да куя Фәрәхшатым. Шулай ничәмә еллар үтте. Газим унны бетереп, Казанга, авыл хуҗалыгы институтына заочно укуга барып керде. Шул елларда председатель итеп тә куйдылар үзен.

Зәйнулланы районга эшкә алганнар иде, ул шунда өйләнеп, оя да корып җибәрде. Ә болар, инде утызга җитеп киләләр, һаман да егет белән кыз. Алай димен дә... Бөтен гаҗәбе-табышмагы да шунда аның. Әллә дөм сукыр булган Газим Фәрәхшатның мәхәббәтенә, әллә башта ук күңеле бүтәндә булган аның. Эшенә, укуына да баштанаяк чумган иде инде егеткәй — анысы да күңел күзен томалый калмагандыр дим. Үзегез беләсез, тиз генә аякка басып киттемени әле ул колхоз. Кырчылыкта авыр, терлекчелектә икеләтә кыен иде. Сыер саварга, дуңгыз карарга көн аралаш авыл бетереп кеше эзлиләр иде. Шунда Фәрәхшат үзе теләп фермага эшкә керде. Аңынчы медпунктта сестра иде ул, шунда тыныч кына ятасыла канә... Болай итүен газетада бик мактап язды-

лар язуын, ә мин белеп торам, барыннан да бигрәк, Газимгә якынрак буласы, әшенә дә азмы-күпме җиңеллек китерәсе килми аның.

Шулай итеп, бетте безнең таңнар аттырганчы бергә сөйләшеп йөрүләр. Көн-төн фермада Фәрәхшатым.

Хәтеремдә, бервакыт кичен моның янына фермага киттем. Кышның иң зәһәр суыклары башланган чак, йөгерәм генә. Дер калтырап барып керсәм, ахири олы киез итекләр киеп, биленә иске шәлләр урап алган да, саламны әй хәсиятләп тә ваклый-ваклый сыерларга башак болгатып йөри. Әйдә, җәтрәк җылынып чыгыйк, качмас сыерларың, дим. Көлә генә. «Миңа суык түгел, әйдә, салам ваклаш, җылынырсың», ди. Әшне бетереп дежуркага керсәк, монда да таракан катырырлык суык. Мичкә ягып җибәрергә дип аралыктагы утынга үрелүемә, кулыма чат ябышты Фәрәхшат. «Якмый торыйк, юкса иртәгә сыерларга су җылытырга утын калмый», ди. Газимнең укуы буенча Казанга киткән чагы, фермага утын кайтартуны уйлап багучы булмаган. Кит, тиле, иртәгә кадәр катып үләсең бит бу килештән, дип, моның ай-ваена карамыйча, какшап беткән утыргычларын ватып, мичкә ягып җибәрдем. Өйгә бераз җылы төшкәч, Фәрәхшат бозланып каткан киез итекләрен салды да, аякчуларын җылытып бәйләргә мич каршына килеп утырды. Аякларына күзем төшүгә әллә нишләпләр дә киттем. Болай да чирләшкә аягы бүрәнә күк шешеп чыккан җанашымның, тубык сөякләре дә беленми. Һай, бетерәсең ич үзеңне, ник дәваланмыйсың, дим. Һаман көлә генә. «Мин үзем доктор бит, эшләр бераз җайлануга, бик тиз шифасын табам мин аның», ди. Үзе көлә, үзенең күзләрендә яшь мескенкәемнең. «Утыз ике сыерга бер үзем калдым, күбесе буаз. Газимны үле бозаулар белән каршылаunion сак, күзләренә ничекләр күренерсең»,— ди.

Әнә шулайлар итеп көтеп ала иде ахири Газимны. Көтте-көтте дә, ниһаять, көтеп җиткерде... Укуын бетереп, диплом алырга китүеннән, Газим өйләнеп кайтмасынмы!..

— Менә син!

— Фәрәхшат шул көнне үк авылдан юкка чыкты. Бөтен халык бик шөбһәгә төште. Авыл бетереп эзләделәр, Газим үзе халыкны күтәрде, милиция дә аякка басты. Ике көннән соң Фәрәхшат Балыклыдан Авыл советына үзе шалтыраткан аннары. Әмма шул китүеннән авылга әйләнеп кайтмады, Казанда мехкомбинатка эшкә урнашты, икеме-өчме ел үткәч кенә кайтып, яңадан үзебезнең медпунктта элекке эшенә керде.

Нәкъ шул чорларда Зәйнулла да авылга кайтты. Язмыш бик аямады ул бичараны да. Йөрәк чиреннән хатыны вафат булып, ике баласы белән тол калды. Эшендә дә күңелсезлекләр чыккан диделәр.

Авылга кайтуга, Зәйнулла бик тырышып яңа өй торгызып йөри башлады. «Фәрәхшатны ала икән Зәйнулла, яңа йорт өлгерүгә, туйлары булачак икән» дигән сүз китте. Ихтимал, нигезсез-төпсез генә юрау булмады бугай бу. Ахиринең дә тел төбеннән шулайрак сизелә. Зәйнулланың иске өйләре медпункт каршында гына булганлыктан, эш арасында Фәрәхшат ятимнәр янына кергәләп йөри, «бигрәк акыллылар, зирәкләр» дип сабыйларны бик яратып сөйли иде. Әмма дә... Язмаган икән тыныч кына бәхет ахири җанашыма. Болай да сер бирмәскә тырышып кына эчтән сызлануын шактыйдан сизә идем, менә бер заман аяклары бөтенләй тыңламас булып, урын өстенә үк ауды Фәрәхшатым. Бер дә бүтән түгел, теге вакытта атналар буе салкын фермада ятуларының гына кәсафәте инде бу, болай да авыру аякларына шул чакта өсталгән чирләре чыга.

Менә шунда Газимгә әллә ни булды. Вөҗданы кузгалып, кинәт күзләре ачылдымы моның, әллә инде һаман да шул Зәйнулланы күрәлмавыннан җеннәре котыра башладымы... Бервакыт шулай Фәрәхшатның өйләренә барып кергән. Зәйнулла да шунда икән, әллә врач чакырып, әллә ниндидер дарулар сорапмы сәламәтлек министрына хат язып уты-

руы икән. «Кәгазь белән дәваламыйлар адәм баласын», дип, Газим иң әүвәл әнә шул хатны ертып ата, аннары, машинасын чакырта да Фәрәхшатны туп-туры Казанга алып китә, шунда иң әйбәт больницага салып кайта моны.

Шуннан соң да көн аралаш диярлек янына барып йөри торган булды. «Аның чиренә фәлән ризык килешә, шундый-шундый дару үләннәр кирәк икән», дип берәр сүз ишеттеме, җир тишекләреннән табып булса да илтер иде. Иренең болайлар итеп йөрүенә хатыны бик кул куеп тормагандыр инде Газимның, дисездер. Бөтен хикмәте дә шунда аның. Аныcы, кем белә, бәлки өйдә өермә-давыллар да купкандыр, әмма халык күзендәгесе шул: сирәк табышлы даруын, шифалы үләннәрен бергәләп эзләп йөриләр иде. Ул гынамы әле... Фәрәхшат карт әнисе белән генә яшәп ята, өйләре бик тузган иде. Бер заман, Фәрәхшат больницада чакта, Газим шул иске өйгә терәп үк шәмдәй нарат бүрәнәләрдән яңа өй салдырып йөри башлады. Инде дә кызулатып эшләтте, атна-ун көн дигәндә өйнең түбәсен ябып та куйдылар. Зәйнулла, үз кулында булмагач, яңа өенә матча да күтәрмәгән иде әле, Фәрәхшат өч айдан соң үз аягы белән Газим салдырган яңа өйгә кайтып төште. Зәйнулла, моңа задурлыгыннан, өен тагын бер почмакка үстереп, инде дә сырлап-бизәкләп бетерде. Өй өлгерде, тик күтелгән туй җырлары гына яңгырамады анда. Фәрәхшат үз аягы белән кайтса да, һаман тазалыкка туймады. Чир ул потлап керә, мыскаллап кына чыга шул...

Аннары килеп, тагын шунысы әле... Председатель чакта Газим колхозны бик алга җибәрде, халыкка яхшылыклары күп тиде. Әмма характеры бик крута булгач, председательгә берәр эшең-йомышың төшсә, моңа ни фурым әйтергә белми йөди идек. Кабинетында да утырмый, аннары, кәефсезрәк чагы булса, лутчы авызыңны ачма. Шуңа күрә, белмим кемнән ничек башлангандыр, халык председательгә үзенең үтенеч-гозерләрен Фәрәхшат аркылы йөртә торган булып китте. Ә Фәрәхшат «ярар, сөйләшеп карармын», дидеме, бетте, йомышыңны үтәлгәнгә сана. Ахиринең бер генә, бер генә сүзен дә җиргә салганы юк Газимның. «Зампред» дигән кушаматы әнә шуннан ябышты инде Фәрәхшатка.

— Менә ничек.

— Әйтәм бит, чисти бер табышмак. Исләрең дә китәр.

Мөкәррәмә тынып калды. Өстәлдәге кәрәзгә, бик кырыс безелдәп, бал корты килеп кунды, кинәт очып китте, тагын кунды.

— Менә шундый-шундый хәлләр...— Мөкәррәмә бал кортыннан күзен ала алмыйча уйчан гына әйтте. — Ә Зәйнулла тагын ялгыз. Фәрәхшаттан өметен өзгәч, бүтәнгә өйләнеп тә бакты, нигәдер торып китә алмадылар. — Ул кулындагы алтын сәгатен назлап кына сыйпап куйды.

Ашыгып кына Әнүзә керде, комод өстендәге бәйләмен эләктереп, ишеккә йөгерде.

— Әни, Сәрия бер кул иңе артыграк бәйләгән инде,— диде чыгып барышлый.

— Ярыша-ярыша бәйлиләр. Бу шәл акчасын чат үзеңә кием-салым алырга гына тотарбыз, дигән идем. Кыз баланы бигрәк затлыдан-затлыга гына киендерәләр бит хәзер. Кешедән калышасы киләмени! — Мөкәррәмә тагын тыенкы гына көрсенеп куйды. — Һай җиңел түгел ялгыз башка тормыш алып барулар...

«Әтисе кайда соң Әнүзәнең»,— дип тел очына ук килсә дә, соравымны кычкырып әйтергә базмадым.

Ул арада өй буенда нидер шакылдап ауды, шунда ук аһылдап кычкырып җибәрделәр. «Әллә егылды инде бу бала» — дип, Мөкәррәмә ишеккә атылды. Мин дә иярдем.

Бирегә кергәндә үк игътибар иткән идем. Баскычны сүтеп ташлаганнар да, иркен генә веранда эшли башлаганнар, хәзергә өйгә кереп-чы-

гып йөрергә такталар гына сөялгән иде. Әнүзә шуннан егылып төшеп кулын авырттырган икән.

— Берни булмады, әни, авыртты да бетте инде, — диде Әнүзә, бәйләмен тоткан кулына өрә-өрә, икенче кулы белән күзләрен сөртә-сөртә капкага таба йөгереп китте.

— Фәрәхшат апаңа күрсәтеп кайт, кызым, сөяге таймасын тагын,— дип Мөкәррәмә аңа кычкырып калды.

Аннары ул, үз алдына сукранулы сөйләнә-сөйләнә, шундагы аунап-таралып яткан такталарны, борысларны тәртипләбрәк өяргә тотынды.

— Һай, бу Зәйнулланы! Әхтәри гомерләренә сузды шушыны эшләп бетерүне... Ни берәрсен кушмый, ни үзе көн яктысындарак килеп эшләми. Кеше сүзеннән котлары чыгар... — Ул сәгатен кулыннан бик ачулы йолкып алды да кофта кесәсенә салды. — Шул гадәтләре бар! Ай яктысына гына кыймылдап, ничек алга барсын ди ул эш... Шул гадәтләре!

## ТЫКРЫК

— Ну, парин, ничек киләләр белдең! Бик тә шәп булды бит әле бу, — диде Газим, инде менә ничәнчедер кабат. — Теге... бар бит әле, китап хәзер телепатия дип атаса, халыкта «күңел сизенү» дип борынборыннан килә. Шуның шикелле, синең белән санаторий сукмаклары буйлап гәпләшеп йөрүләр гел искә төшә башлаган иде. Шуны сизенеп килүеңдер бу, рәхмәт яугыры.

Без өйдә икәү генә калдык. Яшь килен җитез генә йөренә-йөгерә өстәл хәзерләде, кече якта кияве белән тыелып кына көлешә-көлешә пышылдашып алдылар һәм бу як ишек төбенә килеп бастылар да: «Эти, без бер әйләнеп кермәкче идек» дип чыгып та киттеләр.

— Болай итик әле без... Фәйрүзәнең балы да әчеп өлгергәндер анда, икәү генә кече туй итәбез. Олы туйда барыбер утырып булмый... Шәп булыр бу.

— Нигә алай... утырып булмый?

— Бар инде сәбәбе, парин,... — Газим гадәтенчә кискен генә кулын селтәп куйды да, күңелле бер шуклык эшләргә җыенган сабыйдай, сак кына эре-эре атлап кече якка чыгып китте.

— Минем бу эшкә керешеп китүем дә нәкъ әнә шул син әйткән юллардан башланды инде, — диде ул, туй балыннан авыз итеп, мыекларны сыпыргалап куйгач. Очрашуга, Газим Галиевич: «Ничек соң, ошадымы безнең авыл?» — дип сорагач, мин соклану сүзләремнән соң, урам юлларының, бәбкә үләннәренең аяныч хәле турында да әйтми булдыра алмадым. Газимның әнә шул сүзне ялгап алып китүе иде бу.

— Санаторийдан кайткач, шулай бер ара, инде дә йорт җанлыга әверелеп киттем, парин. Гадәттәгечә, таңнан торам, гадәттәгечә, берәр стакан сөт чөмерәм дә ишегалдына чыгып китәм. Монда күптәннән эч пошып та кул җитмәгән эшләр атлаган саен. Ишекне ачып чыгуга, баскыч такталары ач чучкадай чинап җибәрде, капкасы урам каравылыдай шак-шок килеп утыра, ул рәшәткә-коймалар кайсы мәгърибкә, кайсы мәшрикъка сәлам бирә. Атна-ун көн кулдан балта-пычкы төшмәде. Ул арада бакча эшләре килеп җитте, атна буе анда казындым. Шулай итеп, бөтен ишегалдын, бакчасын, абзар-лапасын тәртипкә керттем. Соңгы эш итеп, капка төбенә эскәмия ясап куйдым да кәефләнеп кенә утырам. Тын безнең тыкрык, юл өсте түгел, бала-чага, тавык-чебешкә иркенлек. Иркенлек-тынлык та бит... Ә нигә чирәм үсми соң әле монда? Ул юлы тагын... чокыр да чакыр. Нигә болай әле бу?

Шунда, миңа җавап биргәндәй, чаттан җир селкетеп өченче тизлек белән бер ДТ борылды. Күрше малае кечкенә энесен детсадтан алып кайткан. Үз «Волга»сында фарсить итәмени! Юл бозып, трактор туздырып йөрүе өчен тетмәсен тетеп ташладым моның. Шунда ук чат башына олы казык кагып, «Трактор белән керү катгый тыела!» дигән такта кадакладым. Аннары килеп, көрәк белән юлны төзәткәләргә тотындым. Ишегалдын гына түгел мин әйтәм, тыкрыкны образцовый тәртипкә кертәм хәзер. Ну, бу эшкә картлар да кушылды. Бергәләп, юлларны тигезләдек, ерганакларга кәсләр җәйдек, аннары, үзең дә күргәнсеңдер, тыкрыкның буеннан-буена ике яклап яшь тупыллар утыртып чыктык. Әйбәт киттеләр, ник дигәндә, һәр агач аерым рәшәткәле, кәҗә халкы керерлек түгел.

Ярар, тыкрык та тәртиптә. Трактор кертү түгел, сыңар чүп тә төшермибез тыкрыгыбызга, ак өй кук җыештырып кына тотабыз. Бер кичне шулай көтү каршыларга капка төбенә чыгып утырдым. Көндезен бик әйбәт яңгыр явып үткән иде. Җәйге кәсләребез яшәреп киткән, тупылларыбыз бер карыш күтәрелгән кебек. Шуларга карап кәефләнеп утырам. Иртәдән бирле шул бил сыкрап җәфалый иде, алар ук онытылды. Фәйрүзә кибеткә киткән иде, ул кайтып җитте. Бутыйлары куныч авызы тиңентен былчыракка баткан моның. Кибетне мыкырый астына күчереп куйганнар мәллә, сазлыклар кичеп кайткансың, мин әйтәм. Сәер генә көлеп куйды да яныма җайлап килеп утырды. «Әй, карты-ым,— ди,— дөньяны су басса, үрдәккә ни кайгы, дия идең син. Әллә хәзер үзең шундый үрдәккә калып барасың инде?» Нәрсә, әллә туфан киләме илгә? Бер дә сизгәнем юк бит, дигән булам. «Килсә соң, синең утрау-тыкрыгың нык хәзер, ә анда... — ди карчык, олы урам ягына ымлый, — килеп җиткән инде ул туфаның. Председатель чакта күрмәгәнне, хәзер гомер күрәсең дә юк». Күрмәсә соң, мин әйтәм, пенсионер картка шушы утрау да бик җиткән. Эчтә мәчеләр тырнаша башласа да, үтә чыккан гамьсез кыланган булам.

Дөресен әйткәндә, шушы минутта гына уянуы иде инде ул мәчеләрнең. Безнең тыкрык үрнәгендә, башка урамнар халкын да күтәрәсе иде бит, дип теге чакта ук, янына картлар көрәк күтәреп чыгуга ук башка килгән иде. Әмма дә ләкин... Әлеге дә баягы, персональ пенсия дигән булып... Кая, булмаса, моны күтәреп куйыйк әле. Кымырҗуы тәмам җиткән моның, хәтерен калдырмыйк балның.

— Хәтер калу дигәннән, Газим Галиевич, минем теге вакытта да күңелгә килгән иде, инде менә бу бал әйттерәме. Минемчә, бу урында юккарак чыгымлагансың шикелле син. Сәламәтлек турында да уйларга кирәк ләбаса! Үзең уйлый белмисең икән, әнә, кешеләр кайгырткан. Бу бит нәкъ безнеңчә, советча.

— Син дә Закон Зәйни сүзен сөйләп утырма инде, парин.

— Нигә Зәйнулла сүзе генә булсын? Хәтерем ялгышмаса, райком секретареннан алып, кичә генә рульгә утырган тракторчы малайга кадәр ял-дәвалану турында әйтә башладылар, дигән идең шикелле.

— Әйтерләр шул... Зәйни котыртып йөргәч.

— Кызык син, Газим Галиевич. Мондый мәсьәләдә кемнеңдер котыртуы, кемнеңдер фикере түгел, соңгы сүзне врач әйтә бит. Бер генә врач та түгел, бөтен бер комиссия сиңа ял-дәвалану кирәк дип тапкан.

— Врач... комиссия... Сынган сөяк ялгана, күңел сының сынмасын, ди әнә халык әйтә. Менә эш нәрсәдә! Бәхәсләшеп утырганчы, балыңны чөмерә-чөмерә генә, дальше тыңла син.

— Бетте, Газим Галиевич, тыңлыйм, ә бал торыбрак торсын әле. Иә тагын бәхәсләшә башлармын.

— Шулай итеп, эчтә пыскыган утка җилне әйбәт кенә өрде бит карчык. Үз утрау-тыкрыгың имеш. Үрдәк тормышы... Таба белә бит сүзләрен дә! Шунда ук урынымнан сикереп тордым. Булмаса, мин дә бер

йөзеп кайтыйм әле, үрдәк бит мин, дим. Кызык бит ул хатыннар, үзе күңелне кузгатты, үзе шунда ук чат килеп ябышты тагын. «Утыр тыныч кына, бүген дә төне буе сызланып чыктың, анда аягыңны чылатып кайтып, бөтенләй егылыргамы исәбең». Юк инде, бер кузгалса, Газимны туктатып буламы! Исәбем — авыл Советына барып, безнең тыкрык үрнәгендә, бөтен авылны кузгату турында чын-чынлап зур сүз ачарга.

Олы урамга чыктым. Йа хода! Язын-көзен үзәккә үткәннәре хәтердә бу урамның, әмма бүгенге көк аз гына яңгырдан да болай сазлыкка әверелүенә моңарчы игътибар дә ителмәгән. Чыннан әгәр! Нәрсә, аякта итек, башта мең төрле уй була эш белән чапканда, кайдан атлаганыңны да сизмисең яки машинага утырып кына элдертәсең. Карчык әйтсә дә, үсүзләнеп, аякны да алмашмаган идем. Ботинкалар лачкылтлычкылт шыңшый, чалбар балаклары ләм капчыгына әверелде. Юк, ботинкалар гына шыңшымый, йөрәк сыкрый башлады бу хәлгә, парин. Ник дигәндә... Кая, син үзең кара, мин тагын бераз чөмерим әле.

Эһмм... Ни бит... Теге вакытта сөйләгән идем шикелле... Авыру хатын турында. Фәрәхшат исемле ул. Өе нәкъ шул олы урамда аның, ә медпункт теге очта ук. Ни авыр йөрсә дә, эшен ташлаганы юк. Их, мин әйтәм, әҗәл газапларыдыр бит аңа мондый көннәрдә бу сазлыкны үтүләре. Күңел күзе күрмәсә, маңгай күзе шул кадәр дә сукрайса сукраер икән, валлаһи. Шулай лычкылдаган аяклар, сулкылдаган күңел белән авыл Советына килеп кердем. Председатель, Гайрәт Гайшә, кайтып китмәгән икән, ялгызы гына утыра. Сүзне аяктагы ләм капчыкларыннан башлап җибәрдем, аннары, үзебезнең тыкрык үрнәге, олы урамдагы сазлык. Булмый бит болай, мин әйтәм, заман хурлыгы бу! Тагын да кичектерергә һич ярамый бу эшне. Күрәм, ничектер астыртын гына хәйләкәр көлемсерәп тыңлый мине Гайшә. Мин сүзне бетерүгә шаркылдап ук көлеп җибәрде.

— Хәтереңдәме икән, Газим абый, — ди, — моннан өч еллап элек тә безнең арада нәкъ шушындый сөйләшү булган иде? — ди. — Тик ул чакта рольләребез генә бүтәнчәрәк иде. Мин сорыйм-үтенәм, син исә бу эшне һаман да сузу да кичектерү ягында. Инде менә син дә минем яклы булгач, варисың Хәйруллинны җиңми калмабыз, бик зур рәхмәт, Газим абый,— ди.

Авызымны ачкан килеш, шап итеп урындыкка килеп утырганны сизми дә калдым. Урындыкка түгел, форменным образом төп башына утыртып куйды бит үземне Гайрәт. Әлбәттә, хәтергә төште, булган иде андый сөйләшү. Мәсьәләне бик зурдан кубарган иде Гайрәт. Иң беренче, ул олы урамны чын тәртипкә китерү өчен анда асфальт җәюне куйды. Ә тракторларга авыл читеннән аерым юл салуны кузгатты, болар өчен бер унлап йортны күчереп салырга кирәк булып чыкты. Бу кадәр эшкә авыл Советының үз бюджеты тамчы гына, колхоздан сорамый хәлләре юк. Ну, исәпләп карадык та, безнең дә кесә чамалырак булып чыкты ул елны. Терлекчелек комплексын төзеп бетерәсе бар, бик зурдан тотынып, Культура сарае сала башлаган идек, ничә ел ул сузылып килә. Шуларны әйткәч, Гайшә дә, нихәл итсен, минем белән килешкән иде кебек. Аннары килеп, Зәйнулла да... Син, бәлки, тагын әйтерсең, артыграк авыз чайкыйсың бугай ул кеше белән, бер яратмагач, гел яман ягын гына күрәсең, диярсең. Алай түгел, парин. Ул чакта йөз процент килештем мин Зәйнулла белән, рәхмәт кенә әйттем үзенә. Мондыйрак киңәш бирде ул. Фәлән карарда әйтелгәнчә, ди, гадәтенчә, законын полный табып сөйләшә, юлларны төзекләндерү буенча район юл бүлегендә махсус фонд бар, аннары әле трикотаж фабрикасы безнең өстән шефлык итә бит, алар да ярдәм итәргә тиеш, ди. Бик дөрес, мин әйтәм, андый эшне юллауның мастеры син үзең, авыл Советы депутаты буларак, әйдә, действуй, дидем дә мәсьәләне почти хәл кылынганга санап,

бу турыда оныттым да. Лэкин бит, парин, тиеш-тиеш дип кенә, итәгеннән тигәнәк тә төшми бу дөньяда.

Шулай итеп, күздән йокылар качты ул төнне. «Әйттем мин сиңа» дип, карчык грелкалар, дарулар күтәреп, янымда бөтерелеп йөри башлаган иде, гырылдап йокыга киткәнгә сабышып, аны тынычландырдым. Аяк чылатып йөрүнең файдасы тигән, биле дә сызлый, биленнән бигрәк, күңел сыкрануларына чыдар әмәлләр юк, парин. Фәрәхшатның ничек интегә-интегә ул урам сазлары буйлап үтүләре күз алдыма килә дә, «әйдәгез, заман хуры итеп тотмыйк урамнарны, кузгалыйк хәзер үк»,— дип бөтен авылга сөрән сала-сала чыгып йөгерер дәрәҗәләргә җитәм.

Соң, туктале, нигә сөрән салып йөгерергә? Иртәгә үк правлениегә бар да, чын җитди-төпле итеп сөйләш. Теге вакытта Зәйнулла җилкәсенә аударган эшеңне үзеңнең ныклы кулыңа ал. Пенсиядә булсаң да, правление члены бит әле син хәзергесе көндә, дип күңелне тынычландырмакчы итәм... Юк, парин, кая ул! Ник дигәндә... Бу инде, ни генә әйтмә, Зәйнулла алдына баш иеп килү булачак. Зампред ул хәзер безнең, какраз Хәйрулинның каядыр киткән чагы. «Әә, килдеңме каршыма?! Теге вакытта мин сиңа баш иеп килгәндә, ничек каршылаганыңны хәтерлисеңме? Шулай ул дөнья...» — дип, әй тантана итәр иде бугай теге. Ярар, анысы чурт с ним, анысыннан да бигрәк... Гырылдап йокыга киткәнгә сабышып, карчыкны тынычландырдым, дидем бит. Һе, алдарсың хатыннарны! Бер заман: «Син Фәрәхшатыңны күреп кайттыңмы соң? Әллә төшеңдә күреп уяндыңмы? — ди бу, терсәге янтыкны каезлый. — Бар, янына гына барып кайт булмаса, күңелең дә утырыр, бил сызлавың да басылыр»,— ди. Әнә бит, нинди акыллы башлары белән нинди җүләр сүзләр мыгырдап ята.

Да-а... Акыллы ир атын мактар, тиле үзен мактар, шыр тиле хатынын мактар, дигәндәй, ходай акыл-зиһенне бик, мулдан тамызган юкса минем карчыкка. Ул ягын никак не отнимешь. Дөресен генә әйткәндә, мин институтны аңа аркаланып кына бетерә алдым. Бергә укыдык без аның белән, факультетлар гына аерым: ул экономика, мин кырчылык буенча. Шул профессорныкы кебек акыл-зиһеннәре белән күңелләремне яулап алды да инде ул. Ә бит... Институтта укый башлаганчы Фәрәхшат белән безнең чәчләр бергә бәйләнеп бетә язган иде инде. Аннары әле килеп... Кызык бит ул дөнья! Бервакыт шулай, күрше Мөкәррәмә әйтә... әнә син чәй эчеп чыккан хатын. Болай ди: «Без Фәрәхшат ахири белән җирәбәләрне алышып кына харап булдык»,— дип җибәрә. Вакыйгасын да сөйләп алды...

— Әйтсәм әйтим инде... Мөкәррәмә ханым миңа да сөйләде ул вакыйганы. Күрәсең, сер түгелдер хәзер.

— Һе! Хәзер инде сер булды ни дә, сер булмаса ни. Ә соң, элегрәк, без сугыштан кайткач ук сөйләсә ни була! Ул чакта ни Фәрәхшаттан, ни Мөкәррәмәдән сүз чыкмады бу турыда.

Даа... Чыннан да, хәтерлим, фронтта Мөкәррәмәдән хат алдым. Лэкин, нәрсә? Күрше хакы итеп кенә язган хат дип санадым мин аны. Ә менә, җирәбә чыкканча, Фәрәхшаттан хат килсә, юк, бүтәнчәрәк карар идем. Әйе, чыннан да башка күзлектән карар идемдер. Булмады түгел, фронтта чакта, блиндаж мичендә утын өсти-өсти, уйга чумып утырганда, кинәт кенә Фәрәхшатның өздереп ала торган карашлары күз алдыма килгәннәре хәтердә... Алай, киткәнче, чынлап йөргән-сөешкән дә булмады, югыйсә. Кая, малайлар гына идек бит әле без киткәндә. Ә хат килсә... Ярар, син анда «бу карт тиле багу-юраулар белән саташуга кадәр җиткән икән инде» дип, эчеңнән генә көлеп утырасыңдыр, бәлки. Юк, парин, ашыкма авыз ерырга. Бер язучы әйтмешли, ниндидер язмыш шуклыгы бар монда. Әнә бит Зәйнулла белән Мөкәррәмә дә... Җирәбә

чыкканча булмагач, йөриләр хәзер... Ни ир белән хатын түгел, ни егет белән кыз түгел.

— Әллә Әнүзәнең әтисе Зәйнулламы? — дип, әрсез кызыксынуымның телемнән ычкынганын мин үзем дә сизми калдым.

— Анысын, парин, үзләре беләләрдер инде. Читкә-чатка чалуламыйк әле без... Кая, бирерәк тарт стаканыңны, эчәсеңме-эчмисеңме, алда туļы торсын.

Шулай итеп, нинди акыллы башлары белән әнә нинди җүләр сүзләр мыгырдап ята бит карчык. Ә бит «утрау-тыкрыгың» дип, «председатель чакта күрмәгәнне...» дип, үзе эчкә ут салды башта. Инде менә ишетмәсәң ишет: Фәрәхшатың янына бар!.. Түзмәдем, урынымнан сикереп тордым. Әйе шул, барып кайтыйм әле янына, дип, ашыга-ашыга киенә дә башладым.

Фәйрүзә дә торып утырды. Үзе хәзер бер сүз дә дәшми. Шулай бер сүз дәшмичә күзләре белән генә озатып калды. Бәлки, кая таба киткәнемне тәрәзәдән күзәтеп тә торгандыр — моны мин җилкәм белән тоеп атладым, ләкин тыкрыкны узуга, олы урамга түгел, туп-туры Каенсар басуына таба юл алдым. Җиде төн уртасында нишләмәк булам да, ни эшем төшкәндер минем анда, үзем дә белмим, барам да барам.

Хәер, ул чакта аякларымны ни өчен ул Каенсар басуы тартканын аңлап бетермәсәм дә, инде менә хәзер төшенәм шикелле. Эш менә нәрсәдә... Ихтимал, һәркемнең дә шулайдыр инде ул, бу тормышта бары үзең генә белгән, бары синеке генә булган, ну, максатың дип әйтикме, яки анда хыялыңмы була бит. Әйтик, мотор ничек эшли? Ягулыгы булсын, һавасы өреп торсын, шәме очкын бирсен — шунсыз эшли алмый мотор. Кеше дә шуның сымаграк. Аш-суы, сулар һавасы белән генә яшәми адәм баласы, җанында гел очкыны кабынып торсын аның — әнә иң мөһиме нәрсәдә! Әлеге хыял-максат дигәнем нәкъ шушы очкын инде ул. Ул очкын, яшь узган саен, төрлечәрәк тә кабына торгандыр, тик сүнмәсен генә, гел чатнап-яшьнәп торсын! Шунысы иң кирәге. Ну минем очкынга килгәндә... Яшь чактагыларын сөйләп тормыйм, соңгы елларым очкыны болай кабынды. Председатель булып яңарак кына эшли башлаган чаклар, уңыш гектардан уртача җиде-сигез центнердан артмый. Менә шунда бер елны Каенсар басуындагы уналты гектарлы участоктан утыз җидешәр центнер бодай уңышы җыеп алдык бит, парин. Картлар да шаккатты, газетлар да шаулап алды. Ә минем күңелләрне тәмам айкап салды бит бу хәл. Димәк, мин әйтәм, безнең басулар да әнә нинди юмарт, димәк, каядыр Кубань, Украин якларында гына түгел, безнең басуларда да уңышны уртача утыз центнердан ким алырга хакыбыз юк безнең, ким алабыз икән, димәк, бирәм дигәнне ала белмибез. Каенсар басуының безгә шушы турыда искәртүе бу. Әйе, әйе, гүя басукай безгә шулай үзе аваз сала, өйрәтә! Шулай кабынды яңа очкын. Шушы бер сан — һәр гектардан кимендә утыз центнер! — бөтен җанымны, хыялымны биләп алды, тормышымның төп максатына әверелде, парин. Уңышның елдан-ел арта баруы очкынны дөрләткәннән-дөрләтә килде. Дөрләгәннән-дөрләде очкын, ләкин олы ялкынга әверелә алмый калды. Җитә алмадым мин ул утыз центнерга. Дөрес, Каенсар басуы тагын берәр ел утыз центнердан арттырды, ә бөтен мәйданда алып булмады. Ә бит, хыялыма ирешсәм, кем белә, күкрәгемә Алтын Йолдыз тагарлар иде, бәлки. Тактылар, такмыйни... Пенсионер исеме тагып куйдылар.

Сабый чакта нәни гарьлек-рәнҗүләреңне ана куенына сыенып бушатасың. Сугыш кырында өстеңә туп-ядрә гарасаты ябырылганда, җир куенына сеңгәннән-сеңәсең. Бар котылу-өмет шунда, җиркәйдә. Инде менә, сакаллы сабый, гарьлек-әрнүләремә дә юанычны басуларымнан

эзләп баруым булгандыр ул минем Каенсар ягына. Шулайдыр... Хыялочкынымны да шушы ук басу кабызды бит.

Ләкин барып җитә алмадым. Ул басуга җиткәндә үр менәсе бар безнең. Үр итәгендә, инеш буенда, пар аккаен үсеп утыра. Менә шул турыда тукталып калдым. Күпме басып торганмындыр, кинәт кенә мондый бер җыр хәтеремә килеп төште:

Ике каен, бер карама
Урал тау башларында.
Ике кайгы бергә килеп,
Уралдич башларыма.

Ике каен... ике кайгы. Ике каен... ике кайгы, дип эчтән генә кабатлап, каеннарның әле берсенә, әле икенчесенә карый-карый тик басып торам. Менә шунда кинәт... әйтерсең каеннар телгә килеп, миңа җавап сүзе пышылдый башладылар! Юк, парин, моны болай гына аңлатып булмый. Лутче болай итик без. Һава иснәп керү дә булыр, тотыйк та, шул пар каен тирәләрен бер әйләнеп кайтыйк, ә?

— Гаҗәп тә әйбәт булыр бу, Газим Галиевич.

Без кузгалдык.

Сөйләшми генә инеш яры буйлап атлыйбыз. Яр бик текә, тирән. Борылышларда козырек сыман булып, өстәге чирәм катламы гына калган да, ак, кызыл балчыклы яр эчкә үк уелып-уелып кергән. Күрәсең, язларын бик усал сулы бу инеш. Хәзер ул аста гына, үги ана яфраклы, бака үләнле, сырганаклы киң төбенең уртасыннан гына, чуер ташлар өстеннән челтерәп агып ята.

— Заманында өч ташлы тегермән әйләндергән инеш бу, — дип сүз башлады Газим. — Әнә тегендәрәк ат-арба белән чыгып йөрешле буасы бар иде. Между прочим, пар каен миңа бу инешнең дә зарын сөйләп алды. Киләсе яздан чынлап тотынабыз без моңа. Буасын да буарга исәп, ярларын да, агачлар утыртып, кай төшләрен бетонлап торып ныгытабыз.

Аннары ул олы урамны асфальтлау өчен инде күпме вак таш, күпме битум әзерләнүе, шеф фабриканың фәләнчә ярдәме турында саннар, сумнарны бер-бер артлы тезә-тезә сөйләп китте.

Янә бер борылышны үтүгә, Газим минем беләгемнән тотып алып, алга таба күрсәтте.

— Әнә алар, каеннар. Кешеләргә нәрсәдер әйтергә, нидер искәртергә махсус чыгып баскан кебек алар. Шулай түгелме? Әллә мин генә нечкәрәмме?

Инешнең теге ягында, кыя сыман алгарак чыгып торган текә яр буена ук килеп баскан, ак кәүсәләре инде кара-көрән җыерчыклы карт каеннарга карап, беразга сүзсез калдык. Тәннәре җөйле-җыерчыклы каеннарның, ә астагы кызыл, сары балчыклы ярда, кутырлы җәрәхәт сыман кучкыл-кызгылт тамырлар челтәре...

— Шулай инде алар, каеннар, Газим Галиевич. Синең генә түгел, күпләрнең күңел кылларын тибрәтеп җибәрә торган әллә нинди тирән моң бар аларда.

— Менә-менә! Аларның әнә шул хасиятләре минем әллә кайчан онытылып беткән җыруны күңелдә уятты да инде. Мин җырлыйм, ә каеннар миңа җыр белән үк җавап бирәләр кебек. Чыннан әгәр! Бер әсәрләнсә, тап-таза аек баштан да тәмам тилесымак исәргә әйләнә икән кеше. Әй, Газим, Газим! — диләр кебек каеннар, үз көйләрендә. — Шул бер сан — утыз центнерың белән шашып, күп нәрсәләргә сукырчукрак була башладың бит син,— диләр.— Ул саз урамнарны, ишелеп беткән инеш ярларын, чәчәкләре сирәгәйгәннән-сирәгәя барган болыннарны күрмәү түгел, хыялың-гыйшкың булган туган басуларыңның да зарына колак салмыйсың бит! Балачакта язгы бычракларда ялан-

аяк йөреп тәпиләрең кутыр-чатыр чебиләп чыккач, чемчек-чемчек канлы җәрәхәтләргә өрә-өрә ничек әрнеп җылаганыңны хәтерлисеңме? Язгы ташулар шаулап үтүгә, басулар да шулай канлы-кутырлы җәрәхәтләреннән әрнеп сыкрый. Син аларны ишетмисең, әллә ишетмәмешкә салышасың? Туфракны ястыктай кабарткандай булып, ярма кардай төче минераль ашламалар белән сыйлаштырып, җирнең күңелен күрмәкче дә, уңышны күбрәк алмакчы буласың. Ә язгы яралар... Алар әрни бирә, аза бирә. Әй, Газим, Газим!

Әнә шулай диләр кебек, парин, каеннар. Ул гынамы әле! Берзаман, каршымда каеннар түгел, ә Фәрәхшат белән Фәйрүзә басып торалар сыман тоела башлады.

— Вакытында дәваламасаң, соңыннан никадәр генә иркәләмә-назлама, җир ярасы, нәкъ күңел ярасы кебек үк, барыбер тәмам төзәлеп җитә алмый инде ул, тын гына, эчтән генә сыкрый, әрни...

— Яра өстенә яра өстәүдән саклан, Газим! Монысын басулар да, кеше күңеле дә мәңге гафу итмәс!

Әнә шулай үзләре дә, Фәйрүзә белән Фәрәхшат булып та, шелтәләпме-шелтәлиләр, тетепме-тетәләр генә каеннар абзагызны, парин. Кыскасы... Кайда, килгәч-килгәч, яннарына ук чыгыйк инде без аларның.

Без олы ташлар өстенә аннан-моннан гына салган дерелдәк такта басма аша теге якка чыктык, бормаланып менгән тар сукмактан күтәрелеп, каеннар кыясына килеп туктадык.

Газим Галиевич ике кулын ике каен кәүсәсенә куеп, урталыкка килеп басты, гүя каеннарны үзенә тартып китереп, икесен берьюлы кочагына кысып алмакчы; ул калын-киң җилкәсе, ул зур куллары белән Газим Галиевич менә-менә нәкъ шулай итәр дә кебек иде.

— Кыскасы, менә шушы каеннар мелиоратор итте инде мине. Хәер, вазифама мондый исем соңрак бирелде әле. Анысын да сөйли китсәм... Син әйтмешли, үзе тагын бер хикәят. Кунакны сүз белән артыграк сыйлыйм бугай. Лутче менә болай итик әле без. Кече туй икән, кече туй булсын.

Газим тиз-тиз бүлтәйгән кесәләрен бушатырга тотынды. Зур гына шешә, җыелмалы пластмасс кружкалар, түтәрәм каклаган каз, тегесебусы чыкты.

— Әйтәм бит, безгә рәнҗеп калмасын туй балы,— диде ул кулларын угалап.

Ни өчен кала да ул бал, нигә утыра алмый Газим олы туйда? Бу соравымны бирәлмичә мин тагын эчтән тындым.

## ЮРТАК

Җылымса җил дулкын-дулкын уҗым исе белән мунча төтене исе бөркеп үтте, наянланып, каен толымнарын шыбырдатып узды... Юк, узмады, назланып кына шул толымнар арасына кереп сыенды бугай — кинәт тып-тын булып калды.

Миңа инде Газимның күп гадәтләре таныш. Алай тып-тын, кымшанусыз-тыныч озак ята алмас ул... Һәм елмаймый түзә алмадым: Газим каен төбендә кырын яткан җиреннән сикереп торып та утырды.

— Слуши, синең нярсез атка атланып чапканың бармы? Хет малай чакта?

— Безнең буын авыл малайларыннан кайсы гына чапмаган икән ул нярсез атта? Нигә алай дисең әле?

— Шуннан әйтүем аны... Әлеге дә баягы, минем мелиоратор булып китүемә менә бу каеннарның гына түгел, атларның да катнашы бар бит, җанашларымның.

— Кызык. Алайса, яңа хикәятне башлыйбыз, Газим Галиевич? Рәхәтләнеп тә тыңлар идем.

— Тыңлаучы барында, сөйләргә иренүчеләр без түгел. Ләкин яңа хикәят димәсәк тә ярар, бая сөйләгәннәрнең дәвамы гына монысы.

Да... Шулай итеп, парин... Ул төнне каеннар яныннан кайтып ятуга, изрәп йокыга да киттем. Нәрсә, күңел үз урынына утырды диярлек хәзер. Иртәгә ук правлениегә керергә дә, горур башны алай бик имичә генә, мәсьәләне уртага салып сөйләргә. Болайрак итеп: әйтик, кешеләрне дәвалаучы доктор бар, мал докторы бар. Ә мине колхозның бөтен табигатенә баш доктор итеп куйсыннар. Тыкрык-утраудан олы юлга чыгуның бердәнбер чарасы бары шулай гына. Председатель чакта өлгермәгән-күрмәгән эшләрне түгәрәкләргә бары шулай гына мөмкин.

Ләкин, парин, кичке акыл еш кына иртәнгә яраксызга чыгучан бит ул. Иртәгесен әй йөрим авыл урамнарын, инеш буйларын айкап, әй йөрим... Ә менә правлениегә таба тартмый гына аяк! Тартмый и все! Нишләтәсең аны? Шулай йөри торгач, бер заман конюшнига, атларым-аргамакларым янына килеп чыктым. Әйткәч әйтим инде... Соңгы елларда бөтен тирә-юнь бәйгеләрдә баш бирмәстәй бер аргамак үстерү белән шашып йөрмешем минем. Нәсел-нәсебен үзем тикшереп сайлап алган бер таебыз үсә. Әтисе Дон скакуны булса, әнисе башкорт тулпары. Исемен дә үзем куштым — «Очкын». Әлеге өмет-хыялым очкынына ишарә. Егетләр, быелгы сабан туенда ук сынап карыйк, дип аягыма гына егылмыйлар тик. Юк, бирмәдем. Быелга иртә. Ә киләсе елга, сабан туйлары җитүгә, газеталарны караштырып бар, безнең «Очкын» турында укымый калмассың.

Их, ул «Очкынкаем!» Канатлары бар диярсең җанашымның, тезгенләбрәк бармасаң, теге, әкияттәге юрга кебек, һавага ук күтәрелеп очып китәр иде, валлаһи. Бу юлы да җай гына атлатып барам, ә юлны үзе белә малкай — әлеге дә баягы, Каенсар басуы ягына алып китте.

Күпмедер баргач, күрәм, алдарак тагын бер җайдак бара. Ерактан ук чамалап алдым, тегенди-мондый гына атта баруы түгел моның, чабыш юргасына менеп алган. Тезгенне аз гына бушатуым булды, «Очкын» эһ дигәнче куып та җитте моны. Башта әле җайдакның үзенә күтәрелеп карау юк, аргамагын күздән кичерәм. Шәп малкайга ошый, шайтан алгыры.

— Сәлам, жокей! — дигәнгә, күтәрелеп карасам... Теге вакытта да әйткән идем шикелле, райком секретаре Хәниф Садыйкович та минем күк сабый чактан ук ат чебене малай безнең, атны солы белән куу турында шул сөйләшеп килешкәннән бирле, бу турыда серләр бик килә. Бу юлы да әңгәмәбез беренче сүздән үк атлар турында башланып китте. Бездән әллә ни ерак та түгел «Уңыш» колхозы юртагын, ял көне итеп, аяк яздырырга алып чыгуы икән секретарьның. Колын чакта ук күзе төшкән дә моңа, картлар белән киңәшеп, чабыш аты итеп үстерергә булганнар. Безнең «Очкын» кебек үк, киләсе ел сабан туе бәйгесендә генә катнашачак икән. Менә бит, парин, пенсиядә ятуның файдасы! Председатель чак булса, мондый көндәшем барлыгын ишетми калыр идем мени мин.

— Алайса, киләсе сабан туенда икенче урын «Уңыш»ка эләгүе бар икән, — дим, горур башны һичияр исәп юк.

Хәниф Садыйкович рәхәтләнеп бер көлде.

— Ни өчен икенче урын? Ә беренче призны кемгә юрамакчы буласың? — ди.

— Юрыйсы юк, — мин әйтәм, — беренчелекне безнең «Очкын» бирәүгә дә бирмәячәк.

Бәхәсләшеп үк киттем. Хәниф Садыйкович «Уңыш»ның байталын мактый, мин үзебезнең «Очкын»ны.

— Алайса, болай итик без. Әнә теге карамасы күрәсеңме? — ди Хәниф Садыйкович, ярты чакрым чамасы алдарак юл буендагы ялгыз агачка күрсәтә. — Әйдә, шунда чаклы чабышып үтәбез, үзенә күрә, нәни бәйге булыр бу. Бер, ике, өч, һоп!

Башта шактый ара янәшә бардык. Аннары байтал калыша башлады, ул арада тагын куып җитте. Шулай да финиш-карамага минем «Очкын» ике-өч адым булса да алданрак җитте.

— Мин начар җайдак шул, байталның гаебе юк монда, — диган була секретарь, һич тә сер бирәсе килми.

Сүзебез тагын атлар хакында дәвам итте. Колхозларда чабыш атларына карата сүнеп килә торган дәрт тагын кабынып килә, монысы бик әйбәт. Ә менә эш атларына карата гасырлар буе килгән крестьян дәрте, ай-һай, сүлпәнләнде. Әйтергә оят, авылда яшьләрдән җүнләп ат җигә белмәүчеләр күп бит хәзер. Машиналарга артыграк салынабыз. Бер ат арбасы йөк өчен дә, тузан туздырып, машина куабыз. Урманда бүрәнә чыгарганда, яфрак хәзерләгәндә күпме яшь агачларны харап итеп, трактор тырылдатабыз. Печән өсләрендә машина керә алмастай урыннардан чүмәлә тарттырырга тагын ат кирәк. Һи, парин, авыл хуҗалыгында, бары тик ат җанашым гына булдыра ала торган эшләрнең гомер бетәсе юк аның.

Аннары менә, йортка яшь киленне дә, шәһәрчәләп, кызыл, зәңгәр куыклар таккан «Победа», «Москвич» белән генә төшерәбез бит хәзер. Элеккечә, кыңгыраулы-шөлдерле, чуклы-чиккән яулыклы пар атларда килеп төшсә туй, яшьләргә гомерлек бер якты хатирә булып калыр иде бит бу.

Ярый, аты ат, шуларга өстәп, арба-чанасын, трантас-кошовкасын табу олы проблема хәзер. Тугымчы, трантасчы карт осталар китеп бетә бара, ә алар һөнәрен өйрәнеп калырга теләүче яшьләр юк. — Их, парин, — мин әйтәм, — атларга игътибар — хәзер без гел шаулый торган табигатьне саклауның аерылгысыз бер өлеше бит ул. Шушыларга ялгап, үземнең төне буе ничек тилереп йөрүем, кыя башындагы пар каенның миңа ниләр әйтүен-җырлавын да сөйләп киттем. Боларын инде үземнән көлебрәк, мәзәк сымаграк итеп сөйләгән идем, юкса. Әмма Хәниф Садыйкович бик җитди тыңлады үземне, тик авыл табигатебезнең баш докторы булырга теләвемне әйткәч кенә елмаеп җибәрде.

— Табигатьнең доктор Айболиты кебегрәк инде, алайса, — ди. Бик тә шәп бит бу, нәкъ заман таләп иткән должность. Тик аның исемен хәзергә бераз үзгәртергә туры килер, мелиорация агрономы дип атарбыз. Штатка кертергә шулай иплерәк, ә штатта торгач, халык та, без дә аяк терәп таләп итәбез, үзеңнең дә, кашыңны җыерма бер дә, вөҗданың да тагы да уяурак булачак. Ә теге утыз центнер дигәнең... Басуларны никадәр остарак дәваласаң, шулкадәр тизрәк киләчәк ул. Артыгы белән киләчәк.

Иртәгесен үк бик ашыктырып район больницасына чакырып алдылар. «Ял-дәва ничегрәк килеште икән, тикшереп карыйк әле» дип, врачтан врачка йөртә башладылар. «Әһә, йомшак җәеп катыга салуы икән бу Хәниф Садыйковичның, ул оештырган моны» дип, башта бик кәеф кырылса да, үземне нык тотарга тырыштым. Юкса, йомшап китсәң, юк авыруларың да әллә кайдан калкып чыгучан бит ул. Шулай күңелне нык тотуның файдасы тими калмагандыр, бар врачлардан да, солдатка каралгандай, «годен» булып үттем бит! Ярар, монысын үттем, ә менә кайткач... Син тагын әйтсәң әйтерсең, Закон Зәйни белән кабат чәкәләшеп алмый булмады. Ни ди... «Андый эшләр белән, әнә, районара мелиорация станциясе шөгыльләнә, шунда эшлә, хөкүмәт шулай кулайрак тапкан икән, мөгез чыгарырга йөрмә монда» дип җибәрә бит. Шундый да аяк терәп сөйләшә, председатель Хәйруллин, яшь нәрсә, ул да икеләнә калды. Әчтә давыл-өермәләр кубып өлгерсә дә, тыштан үземне

аяз күктәй тыныч тотарга көч таба алдым. Басуларны, инеш ярларын, урамнарны, болыннарны дәвалау буенча председатель чакта өлгерә алмаган, күрмәгән эшләремне түгәрәкләү өчен басам мин бу постка, аңлагыз шуны! — мин әйтәм. Мәсьәләне идарә утырышына куймый булмады. Монда инде, нихәл итәсең, ут чәчеп бәхәсләшергә дә туры килде. Менә шулай, парин. Әле эшнең башы гына. Ай-яй күп әле алда башкарасы эшләр, ай күп.

Һәм Газим Галиевич, башкарасы эшләрнең авырлыгын чын-чынлап җилкәсендә тойгандай, каен төбенә авыр гына чалкан сузылып ятты.

— Эшләр күп, ләкин беразга барысын бер читкәрәк куеп тормый да булмый... — Ул каен толымнарына текәлгән килеш уйчан гына әйтеп куйды.

— Әлеге... туй мәшәкатьләре беләндер инде?

— Мәшәкате мәшәкать, ә туйның үзендә, әйтәм бит, утыра алмыйм мин.

— Сәбәбе серме?

— Хәзергә сер диярга була.

Газим, бераз тын гына яткач, башта ишетелер-ишетелмәс, аннары тавышын көчәйткәннән-көчәйтә барып, сүзсез генә моңлы бер көй сузып җибәрде.

— Да, парин, хәзергә сер, — ул көйләвен бик кисәк өзеп, җитез генә торып утырды. — Ну, сиңа гына әйтсәм әйтим... Болай ул, парин. Теге вакытта син киткәч, Әзербәйҗаннан килгән бер иптәш белән таныштым. Шул сөйләде. Гаҗәп бер санаторий бар икән аларда. Нафталан дигән нәрсә белән дәвалап, аяк-куллары бөтенләй йөрмәс авыруларны да аякка бастыралар икән. Колаклар үрә торды минем бу хәбәргә. Озын-озак уйлап тормастан, Фәрәхшат турында шул санаторийның баш врачына хат яздым. Чын кеше икән врачлары, бик тиз җавабы да килеп җитте. «Килегез, путевка ала алмасагыз, курсовка белән дәваланырга була» дип язган. Ну, мин таптым бит путевка! Таптым дип... Яшерен-батырын түгел, Хәниф Садыйкович ярдәм итте, рәхмәт яугыры. Срогы нәкъ туй вакытларына туры килә килүен, ләкин анысы гына инде... Ни генә булмасын, Фәрәхшатны андый ерак юлга ялгызын гына чыгарып җибәрә алмыйм мин. Вөҗданым кушмый.

— Шулайдыр да... Фәйрүзә ханым ничегрәк карый соң бу мәсьәләгә?

Газим күңелле генә көлеп җибәрде.

— Син нәрсә! Хатыннар белгәч, сер була ди мени ул аннары? — Ул шунда ук җитдиләнде. — Хәзергә карчыкка әйткән юк әле бу турыда. Әмма ышанычым нык, килешми калмабыз дип уйлыйм. Кайчак, һәр хатын-кыз кебек инде, бераз тәртәләргә типкәләп алса да, ахыр чиктә килешми-аңлашмый калганыбызны хәтерләмим. Килешми яшәсәк, бу туйлар да булыр иде мени? Булса да, бүтәнчәрәк...

Газим Галиевич салмак кына атлап, тагын ике каен арасына килеп басты, ике кулын кытыршы-ак кәүсәләргә куеп, нәкъ баягыча каеннарның икесен берьюлы кочагына кысарга теләгәндәй итте.

## Фатих Хөсни

# КЕМ ГАЕПЛЕ?

хикәя

*Карт укытучы авызыннан*

## I



Үз вакытында эшләмәдем түгел, эшләдем, юкка гына ялга «Персональ пенсионер» итеп җибәрмәгәннәрдер. Чаптык та, укучыларның ата-аналары белән, күзгә-күз карашып, тел яшермичә сөйләшкән чаклар да булды, классны тулысынча бишкә куып, еллык йомгаклау җыелышларында президиум түрендә түш киереп утыргалаучы кем иде дип сорасагыз, ул да шушы Әфлутунов фәкыйрегез иде. Яшерен-батырын түгел, узган эшкә салават, еллык йомгакны түгәрәк итеп күрсәтер өчен итәк кисеп җиң ялгаган чаклар да булмады түгел. Мәгәренки, үтә дә гыйбрәтле хәлләр дә баштан кичкәләде. Шуларның берсен су кушмыйча гына сөйләп карарга исәп. Сөйләп булса әгәр. Ягъни, ничек булган — шулай чыгарып булса дигән сүзем.

Мин гади бер укытучы гына түгел, класс җитәкчесе дә идем. «Класс җитәкчесе» дигән сүз ул, егетләр, уен-муен түгел, дөресрәге, муенга өстәмә камыт дигән сүз дә. Син инде, а.ай-эне, бөтенесе өчен җавап бир, укучыларыңның ничек укулары турында гына түгел, аларның дәрескә ни дәрәҗәдә төгәл йөрүләре турында һәм дәрестән тыш, урамда — халык арасында үзләрен тотышлары турында да. Өйдә, каралты-кура арасында эти-энилөренә хуҗалыкта ничек булышалар? Кыскасы, бурыч та бурыч, тамактан ризык ничек үтә дигән.

...Шулай бер чакны минем бер укучым, аты коргыры, исемен атаганда да телеңне сындырырлык, Азоль дигән бер күсәк, рәттән өч көн дәрескә килмәде. Элек тә алай чәчрәп торучылардан түгел иде, шомлана калдым мин бу эштән. Әти-әниләре турында да җүнле хәбәр йөрми иде, этисе турында яманлап әйтүем түгел, сугыш инвалиды, илләә энисе турында, ташка үлчим, колакка килеп җиткәли: үз инвалиды гына җитми, «уҗым»га да чыккалый, эчеп тә кайткалый, имеш. Кыскасы, өйләренә барып чыгарга булдым мин бу семьяның. Әлләә ни төпчену нияте белән түгел, бурыч конкрит: малай нилектән өч көн рәттән мәктәпкә килмәде?

Барып кердем өйләренә һ күрдем тамашаны. Квартирлары болай әйбәт, сугыш инвалиды итеп, яңа салынган биш катлы пулаттан ике

бүлмәле квартир биргәннәр. Биш катлысын биш катлы да бит аның, малай, тота белмәсәң, бер катын, бер бүлмәсен дә эт оясына әйләндерергә мөмкин. Моның өчен әллә ни зур осталык соралмый. Боларның шул... әй, квартир тикшерүме минем бурыч! Минем бурыч арык алаша кабыргасы кебек үтәли күренмәле: Азоль нишләп өч көн мәктәптә күренмәде?

Җыелмаган урын-җир, карават буена өстәл тартып китергәннәр, өстәлдә киселгән, сындырылган ипи сыныклары, әрчелер-әрчелмәс ташланган суган кисәкләре, яртының яртысы эчелгән ак аракы һәм күз алдыгызга китерегез: исерек малай белән исерек ата. Дөрес, малай оятын югалтып ук өлгермәгән иде булса кирәк, мине күрүгә җәлт сикереп торды, читкә тайпылмакчы булды, ләкин өлгерә алмады, атасы өстәл сугып, җан ачуы белән кычкырды:

— Не смей урыныңнан кузгалырга. Җавабын син түгел, мин бирермен.

Яңагын-йөзен тоташ сакал-төк баскан ир урталары бу кеше дөм сукыр иде. Ләкин, һәр сукырга хас рәвешчә, әчке инстинкт белән минем кем һәм нишләп йөрүче икәнлегемне шундук чамалап алды булса кирәк. Мин сүз башлаганчы үзе тотынды:

— Беләм, минем малай чутыннан йөрүең булса кирәк. Күрәсең, школдан вәкил итеп җибәргәннәрдер. Соң алай булгач, сора да инде, ник дип мин аны, мәктәп баласын, көчекне, сабакка җибәрмичә аракы эчертеп утыртам, үземнең каршыма утыртып, панимаеш?

Артыкка логикасы җитмәде моның, үзеннән-үзе кабынып, ялгап алып китте:

— Утыртам, ник дисәгез, минем бу дөньяда шул малайдан гайре кешем калмады. Хатыным кайда әлексә — шунда чит ирләр белән себерелеп йөри, күршеләрдән кереп хәлемне белүче этле адәм юк, мин — сукыр, сугыш инвалиты. Гитлерга каршы сугышып йөргәндә ике күземнән яздым. Көне-төне ялгыз, көне-төне шушы котсыз өйне саклап ялгыз аунарга тиешмен. Әллә минем кеше белән кара-каршы утырып сөйләшәсем килмиме? Әле ничек кенә килә! Үкереп җыларлык булам вахыты-вахыты белән. Җылап кемне шаккатырасың? Бөтенегез эштә. Бөтенегез план куасыз. Кемгә кирәге бар сукыр инвалитның?

Ул кинәт исенә килгәндәй бүленде, капшанып, буш стакан тапты, аракы шешәсен, буш стаканны үзенә табарак алды һәм, гаҗәпкә каршы, тамчысын да читкә коймыйча, «голт-голт» аракы койды. Һәм шуны минем алга шудырды.

— Эчеп җибәр әле минем сыйны, әгәр җирәнмәсәң, — ул кискен, каршы килергә урын калдырмас дәрәҗәдә кискен иде, — мулла күршесе булып кыланмыйча гына. Мин синең белән шуннан соң сөйләшермен.

Мәсьәләнең аптыраткыч ягы шунда: мин, өлкән яшьләрдәге укытучы, класс җитәкчесе, хәлне ачыкларга, малайны дөрес юлга күндерергә дип килгән кеше, ул ярсыган инвалидның сукыр күзләре белән өстемә кадалып утыруын күтәрә алмадым, миңа, аның тәкъдимен кабул итеп, куйган аракысын күтәрү җиңелрәк иде.

Моны абайлап алгач, хуҗага да ничектер җиңелрәк булып калды кебек, ул кешеләрчә ачыграк, ихластанрак сөйләшә башлады:

— Сук мине, эттән алып этка сал, мәктәп баласын аздырып утыручы кешегә — мин сукин-сынга шул төс. Шуның өчен дип сугыштыкмени Гитлер сволочь белән? Бер оятлы булдым, бүтән кабатланмас. Кадаклап куегыз малайны сабагына. Укурат шулай сөйләштек булсын...

Ләкин аның бу «укураты» бер мизгел генә булды, эчендә кайнаган әрнүләре янә бәреп чыкты:

— Әйтәм әйтүен телдән, ә эчем кайный: укып кем булыр дип ышаныйк без аңа? Әнисенең себерелүен күреп үскән ул көчектән кем чыгар

дип көтәргә кирәк? Минем бу имансыз сүзләрдән күңелендә нинди нөктәләр калмас? И, абзыкай, күреп торабыз: сукыр күзләребез белән булса да күреп торабыз: укыган кешеләребездән кемнәр чыга? Җыен пумала баш та, эти тапкан малга ристаран бусагасын таптаучы.

Бу очракта үгетләү сүзләренең стенага сибелгән борчак кына булачагын аңлап, мин бу визитыма шуның белән нокта куярга булдым. Шулай да Азольгә дәрес калдырырга аслан ярамаганлыкны малайның үзенә дә, әлбәттә, әтисенә дә төшендерерлек итеп әйттем. Телдән шапырынмыйча гына күңелемә беркеткәнем тагын шул булды: юк, бу семьяны коры юату белән генә калдыру ярамас, килгәләргә, кызыксынырга кирәк болар белән.



## II

— Я ходам! Хатын-кызның әйтсә таш күңелне дә йомшарта торган тасма теле, булыр-булмас сәбәптән дә яки бер сәбәпсез дә түгелеп китәргә әзер торган яшьле күзләре булмаса икән! Без ирләрнең кайсыбызның гына өстә күбекләнеп яткан шул мәкердән алданмый калганыбыз бар икән! Чакырттым мин бу юлы Азольнең әнисен. Дирекция бланкасына яздырып, үземчә бик законный итәргә тырышып, берничә тапкыр чакырттым. Килмәде. Ахырда малаена кат-кат тукып, бернинди кәгазьсез чакырттым. Килде. Чапаланмады, балаларын һәм үзләрен ничек тә акларга тырышкан кайбер ата-аналар кебек, күп сүз белән күмеп калдырырга азапланмады. Җаваплары кыска, ышандырырлык иде. Чакыртуга килә алмаган, чөнки грипп белән авырып, температуралап яткан көннәре булган. Малае Азольне дә яклап тыпырчынмады. «Дөресе шулай. Сүз тыңламый. Дәресен карамый. Урамга, уенга акайган», дип барды. Әңгәмә икебез тарафыннан да тигез, кызмага бирелмичә дәвам итте. Шулай килә-килә, ниһаять, мин, өйгә һәм мәктәпкә буй бирмәс Азоль белән генә чикләнеп калмыйча, хатынны «Сыйрат күперенә» якынрак китереп җиткердем. Дуамал түгел, булдыра алганча дипломатия саклап. Янәсе, баланың тискәрелегендә өйдәгеләрнең, ата белән ана мөнәсәбәтләрендәге чарпалашларның да йогынтысы бар, педагогия фәне моны, янәсе, ачыктан-ачык шулай куя. Һәм башка, һәм башка төрле дипломатияләр... Әлбәттә, үзем булдыра алганча! Хәер, сүз бу якка килеп терәлгәч, хатын да ялындырмады. Йөзенә бер мәл алсукызыллык йөгерде, күзләре яшьләнде, ләкин берьюлы яшен түгеп җибәрде дип әйтмәс идем. Кыскасы, ул үзен тота белә иде. Чатыр-чотыр ташланып, ирен каһәрләргә дә ашыкмады.

— Мин аңа, ирем Миркасыймны әйтүем, яратып чыктым. Дөресен әйтә китсәм, яратып кына да түгелдер әле, җәллап тә бугай. Сугышка хәтле бер мәктәптә, бер партада утырып укыган чая, җор телле, без кызлар арасында теләсә ничек кулларын озайтып йөргән малай, сугыштан кайтканда шиңгән, аз сүзлегә әйләнгән. Әйтсә дә ничектер төртterеп, бәгыреңә кадалып әйтә иде. Миңа шуннан ук чамаларга кирәк булгандыр, югыйсә. Ә мин шул беркатлы, элекке дуслыкны онытып бетергән юк, җитмәсә кызганып та куйдым үзен. Әле дә хәтердә, дивана түгел диген Хәтирәне, уйлар-уйламас сүз каттым моңа:

— И, кайда онытып калдырдың син, Миркасыйм, теге еллардагы сайрап торган телеңне? Фашистны дөмектереп кайткан гвардин, ә авызыңнан сүз алып булмый.

— Нинди сүз аласың килә соң минем авыздан? — диде бу мәгънәле көлемсерәп.

Хәер, миңа да алла куәт бирде ул минутта, чатылдатып әйттем:

— Нинди сүз аласы килмәс, сагынып, ут йотып торган бичара кыз баланың, — мин әйтәм — Мәктәптә бергә укыган чактагы этлекләрең искә төшеп тәкатьсез калдыра торган иде.

— Әй, куйсана, Хәтирә, юхаланма. Биш ел фронтта йөреп каешланган солдат кайда дөреслек, кайда юхалык яшеренгәнне әллә белмиме? Юк инде, килешми безгә алай төчеләнү. Сиңа килешсә дә, миңа килешми. Сукыраеп бара торган күзләрем белән элекке сабакташ Хәтирә икәнлегеңне аера алганга рәхмәт әйт.

Юк, ул чагында сукыраймаган иде әле ул. Ишетеп торасыз, әйтәм дисә сүзен дә таба иде. Берничә кабат тагы очраштык, күңел кергәннән керә барды минем бу инвалитка. И, аллага тапшырып, тәвәккәлләдем. Шулай ирле-хатынлы булып яши башладык. Күпме кирәк шуннан соң бала булдырырга, элек берне таптым, анысы гомерле булмады, янә килеп, менәтерәк Азоль ташбашны өлгерттек. Кем белгән аның шулай җан кыршагыч малай буласын?

Сүз болай шук оборот ала башлагач, әйе, күреп торам, малаеның укытучысы алдында җавап тотарга дип килгән хатын сизелерлек җанланып китте, йөзе нурланды, сөйкемле кара күзләреннән хәтәр бер чаткы сирпелеп узды. Мин инде пенсия яшенә таба үрли башлаган өлкән яшьләрдәге кеше, укытучы, класс җитәкчесе бахыр, җаваплы. әңгәмә алып барам, яшерен-батырын түгел, хәтта мин булып мин, ул ханымның шулай уйнаП торган күзләреннән шүрли калдым: күңелгә нәрсә килмәс, мондый хәтәр утка туп-туры карый башласаң.

Дөресен әйтим, аның бу хәтәрлеге мине тугара алмады, киресенчә, нәкъ шуннан соң батыраеп киттем, моңарчы кымырҗап та кузгата алмаган мәсьәләне кабыргасы белән куйдым.

— Азоль егетне беразга калдырып торыйк, иптәш кем, — дип башладым мин, бераз тыныш ясап алганнан соң. — Җыйнаулашып тотынсак, без ул кыргый тәкәне, шәт, үз урынына утыртырбыз, малай хәзергә чит ярга тәгәрәмәгән, без дә үз эшебезне белә торган адәм балалары.

Һәм, тәвәккәлле-хода, башладым әйтә алмый азапланган сүзне:

— Мине янә бер мәсьәлә кызыксындыра. Дөресрәге, миннән дә бигрәк сезнең иргез Миркасыйм иптәшне кызыксындыра икән ул мәсьәлә. Менә шулай... ничек дип башларга да белгән юк, үтә дә четерекле мәсьәлә, дөресен әйткәндә. Мин, әлбәттә, чит кеше, сезнең шәхси эшегезгә тыгылырга тиеш тә түгелмендер, бәлки. Хәер, бала үстергәндә, яшь буынны тәрбияләгәндә чит эш юк, ата-ана да, мәктәп тә, укытучылар да, класс җитәкчесе тем более, без барыбыз да бердәй җаваплы. Кыскасы, Хәтирә туганкай, болай тора эш. Миркасыйм иптәшнең миңа бик тә аһ орып... бик тә читенлек белән җиткерүенә караганда... белмим инде ничек башларга да...

— Җылый-җылый җиткерүенә караганда дип башлагыз, нигә аны сылап-сыйпап торырга... Әллә бүген генә белгәнме Миркасыймны. Кем очраса, шуңа сөйли. Теләнә ни килсә — шуны ыргыта. Янәсе, бөтен бозыклыкның башы Хәтирәдән. Малаеның сабак калдыруы да, күрше фатирларда магнитофон акыртулары да, үзенең сукыр калуы да... Тыңлаучы булсамы? Ярый әле, соңгы вакытларда бераз колак тынды, сукырның килде-китте сүзләрен тыңларга ашкынып торучы юк, күршеләр кермиләр, чыгып йөрергә үзенең күзе юк.

— Аның каравы аракы бар... Мин барып кергәндә, мәсәлән, каршына Азольне утыртып, аталы-уллы аракы эчеп утыралар иде. Үз күзләремә үзем ышанмый тордым. Мәктәп баласы белән, әкәмәт.

— И, абзый җаным, аның белән генә калса иде әле, — хатын бу юлы үзен тыеп кала алмады, үксеп елап җибәрде. — Минем эшем шулай, әле җыелышы, әле дежурствосы, әле кайтышлый, йомышың төшеп, белгән хатыннарга сугыласың, без хатын-кызның сүзе тавык чүпләп бетермәслек, сөйләшә китсәң дөньяң онытыла, гел үзеңнең холыксыз ireңне генә уйлап тормыйсың. Җитмәсә тагы узган көз эти картны җирләдек, әни ялгыз калды, анысы да гел җылап тора. Килмисең, карт көнемдә ялгызлыкка дучар булган әниеңне ташладың, дип үпкәли. Бара

калсаң, чат ябыша, кундырмыйча җибәрми. Иртәгесен кайтып керешкә өйдә кубыпмы куба Сафура бураннары. Бусында инде никахлы ирең-нән колак ишетмәгән сүзләрне ишетәсең. Җаныңа таш булып кадала торган бөһтан сүзләр. Ул гына җитмәсә, кәкре башлы таягы да янында гына, ала да ора. И, абый җаным, минем хәлне агачка-ташка гына сөйләсәң иде, адәмгә сөйләп, адәм ышанырлык түгел.

Миңа озын-озак сөйләп торырга урын да калмады болай булгач. Иренекен тыңлаганда — иренең сүзе дөрес кебек күренгән иде, хатынның яшькә манчылып чыккан сүзләрен ишеткәндә — анык дөрес кебек.

— Бер җае чыкмый калмас, — дигән булдым мин, сүземнең мәгънәсезлеген үзем үк белеп торган хәлдә — түзегез инде, ханым, ничек тә...

Ә ничек түзәргә? Хәер, түзмичә кая барсыннар? Кем кай яктан аларны бу чытырманлыктан аралап алыр икән?

### III

Өйләренә барып, үзләрен чакыргалап, малайны класста алып калып, күзгә-күз сөйләшүләр бөтенләй үк файдасыз булмады тагы, Азолем дәрес калдырмый башлады, фәннәрдән дә өлгереше арта төште. Хәер, «малай» дип җиңеләйтеп әйткәч тә, ниткән малай, үсмер егет бит инде ул, иптәшләре, өлкән яшьтәге укытучысы алдында гел болай сүзгә урын калдыруы өчен хурланмый торгандыр дисезме? Шулай да йомыклыгы кимеми, кызыксына башласаң, «шулайдыр», «мин белмим», «юк» кебек турап ташланган кыска-кыска җаваплардан узмый иде. Бигрәк тә өйдәгеләре, әтисе белән әнисе арасындагы мөнәсәбәтләр турында ни дә булса әйтүдән кача, кызыксына калганда да, «мин каян белим аларны-кын» белән бетерә. Хәер, ул турыда, бигрәк тә шәкертемнән артык төпченеп сорашу миңа да килешми иде. Шулай итеп, сукыр ир белән аның әлегә укасы-бизәге өстендә елкылдап торган хатыны арасындагы хәл-әхвәлләр томанлы килеш кала килде.

Дөресрәге, билгеле бер вакытка хәтле кала килде. Азольнең мәктәпкә йөрешендәге үзгәрешләргә, өс-башының чистара төшүенә караганда, аларның өй тормышлары да яхшы якка таба борыла башламадымы икән, дип юрарга да мөмкин иде.

Ләкин рәхмәт фәрештәләре йоклаганда шайтан ни кылмыйдыр диген. Көннәрдән бер көнне Азоль дәрескә күз төпләре кара янган, битяңакларына «зәңгәр фонарьлар» утыртылган хәлдә килде. Әлбәттә, шундук сорашып торырга уңайсыз һәм сорашып, аңардан ни дә булса алырга мөмкин дә булмас иде. Шуннан соң атна-ун көн узгач, класста ялгызын гына туры китереп, болай гына кызыксынган атлы күренергә тырышып, сүз каткач та:

— Әй, үзем тяп-ляпь инде, утын ярганда полен ычкынып китте, — белән бетерергә ашыкты.

Хәлбуки, утын ярганда «полен» ычкынып китүдән генә булмаган, вакыйга җитдирәк килеп чыккан икән.

Хәер, безнең мәктәп практикасында нәрсәне булса да яшереп калырга мөмкинме соң! Азольнең «полен ычкынып китте»се дә иптәшләрен, әлбәттә, ышандырмаган, тотынганнар төпченергә. Кытыклый-кытыклый Азоль тешләкнең дә авызын ачтырганнар. Соңыннан, телдән-телгә күчеп, безгә килеп җиткәне болай: Ата белән бала арасында тагы бер кара-каршы утырып сыйлану булган булырга тиеш, бу юлы инвалидыбыз инде үзе җебегән, елый-елый хатынынннан, икенче төрле әйтсәк, малайның әнисеннән зарланырга тотынган. Янәсе, күрми дигәч тә, әллә Миркасыйм белеп-сизеп тормыймы: кайбер төннәрне әниең бөтенләй кайтмый да кала, кайда йөреп төн уздыра торгандыр ул? Йөрепме, әллә ятыпмы?

Артык тыңлый алмый малай, ул әнисенең нинди сукмаклардан атлап

йөргәнлеген электән үк чамалаган булгандыр, күрәсең. Эчтә аракы да котырта, әтисе сөйләгәннәре дә ярсыта егетне, шундук ул, нәрсәгәдер ирешмәкче булып, җенләнеп чыгып китә. Йөри, тыкрык икән — тыкрык дип тормый, шәһәр чите икән — шәһәр чите, очрап дәшкән кешеләргә игътибарсыз, үзе берәүгә бер сүз дәшми. Шулай атылып-сугылып йөри торгач, килеп җитә Подлужный урамындагы урамга арты белән торган астагы бер фатирга. Килеп керсә, күрә: мәш бу аскы кат фатирда. Өстәлдәге табын айкалган, ә табын янындагылар бөтенесе кәефле. Шаугөр килеп утырган җирдән малай килеп кергәч, кинәт басылалар болар. Тик арадан берәве генә аптырау катнаш янау белән, кемнән сораганлыгын үзе дә белмичә, яңгыратып сорау бирә:

— Ишек бикләнмәгән булганмыни соң? Җәннәткә чыккан икәнбез гүпчим дә.

— Җәннәткә чыкмыйлар, җәннәткә керәләр, тупица. Только синең белән мин түгел, — дип шаярткан була икенчесе.

Азольнең аларда эше юк, шул мәхшәрдә кысылып утырган әнисен генә күреп ала ул. Күреп ала һәм, кызмача баштан, шактый ук кычкырып, команда бирә:

— Синең урының монда түгел, стерва, синең урының эти янында. Момент кузгалган бул!

Менә бу, ичмасам, тынчыган күлне болгату дисәң дә болгату. Кайберләре шундук сикерешеп торалар, кайсылары, исләре китмәгән атлы күренергә тырышып, утырган җирләрендә кала. Янәсе, кайдан очып төште әле бу яшь әтәч? Кемгә кычкыра ул?

Кемгә икәнлеген әллә кайдан сизенгән Хәтирә дәррәү айнып китә, җәлт кузгалып, ишеккә таба атлый. Ләкин аларга ансат кына чыгып китәргә бирмиләр.

— Тукта, җырны бозган ул яшь әтәчне мин болай гына җибәрмим, мин ул пацанны Олы урамга хәтле озатып куям, — дип, зәһәр сүгенә-сүгенә иярә китә берсе. Ул арада исерек компаниядән тагы берсе килеп өстәлә, кайда монда Олы урам, малайны шунда, берәү дә күзгә чалынмый торган кыр ягында, әнисенең күз алдында дөмбәсли башлыйлар. Әнисе нишләсен, чапалана, чырылдап кычкырып карый, тик чырылдау белән генә туктатып буламы котырганнарны.

Кыскасы, Азольнең яңакларында, битләрендә куныл калган күксел «бизәкләр», күз төпләрендәге «фонарьлар» өчен утын пүләненең бөтенләй гаебе юк, монда гаеп тирәндәрәк булган, имеш. Ә мин, укытучы кеше, җитмәсә тагын класс җитәкчесе, башта шул сүзгә ышана яздым. Беркатлы шул без.

## АВТОРДАН

Хикәянең башында бик тә хәтәр итеп «Кем гаепле?» дигән сорауны куйдык та, асылда өзеп җавап бирмичә шуып уздык шикелле. Хәлбуки, җавап бирмичә ярамый, бу урында карт укытучыга, гәрчә ул класс җитәкчесе булса да, сөйләгән белән генә чикләнеп калу килешмәс, ялган тәкъвәлек булыр иде.

Әлбәттә, беренче чиратта сугыш гаепле. Сугыштан имгәнеп калды кайбер кешеләр — тәннәре белән генә түгел, җаннары белән дә. Миркасыйм инвалидны мин шундыйларның берседер дип карыйм.

Ләкин бөтенесен сугышка — Гитлерга гына сылтап, үзебезне судан ак, сөттән пакь итеп калдыру дөрес булмастыр. Шул ук Миркасыйм үзенең бәхетсезлеге өчен ул хәтле тузгымыйча, үзен бераз кешечәрәк тотса, тотарга тырышса, булмас идеме? Тузгып гына аның язмышы төзәлсә икән!

Ә күршеләре, туган-тумачалары бәхетсезлеккә дучар булган ул гарип бәндәне бөтенләй онытулары белән гаепле түгелләрме?

Ә хатыны Хәтирә? Әлбәттә, ул яшьрәк тә, бизәк-укалары коелып та бетмәгән булсын, ди. Ләкин никахлы ир хатыны буларак, гаилә алдындагы бурычларын бөтенләй онытып, койрыкны сыртка салып тәрханга чабуы олуг гөнаһ түгелме?

Сүз болайга киткәч, мин үзебезне — язучыларны да — бер якта калдырмас идем. Тормышның гел шәп якларын, аларны да үтә бизәп күрсәтергә яратучы купшы кияүләргә әйләнеп барабыз түгелме без? Ә бит тормыш катлаулы, аны шул катлаулыгында күрә һәм күрсәтә алсак, без укучыларыбызга якынрак булыр идек кебек.

Кыскасы, гаеплеләр юк түгел, тик алар, бармак белән төртеп күрсәткәнне көтмичә, үз гаепләрен үзләре вакытында күрә һәм бетерә алсыннар иде — теләк менә шул.

**Марсель Галиев**

# СИҢА МИН КИРӘК

хикәя

I



„Тагын мин дигәнчә булмады...»

Шундый үкенечле уй белән бергә йокысын аралап кергән сүрән яктылыкның торган саен көчәя баруыннан ул сискәнеп уянды. Җыерылып калган пәрдә читеннән бүлмәне урталай кисеп кергән кояш нуры аша сәгатькә күз төшерде һәм чәчрәп урыныннан торды. Көмгәдер рәнҗегән шикелле чыраен сытып, чалбарын кия-кия тәрәзә катына килүгә, соңга калуына ул инде тәмам ышанды. Өч-дүрт көн буена сибәләгән томан катыш вак яңгырның бетәренә, дөньяның ачыласына иманы калмаган иде аның. Менә бит, бүгенге таң — иртә ничек туган! Күк йөзе юып алгандай чиста, эчпошыргыч дымлы көннәр авырлыгыннан сыгылышып утырган агачлар да калкынып киткәннәр, җиңел сулыш алып, яфрак телендә сак кына лепердәшәләр.

Ачылып туган яңа көн аның йокы белән генә онытылып торган борчуларын уятып җибәрде. Ул кызыннан килгән телеграмма кәгазен өстәлдән алды да...

*«Миңа унҗиде яшь тулды. Сезне күрәсем килә.*
*Мөмкин булса каршылагыз... Сөембикә»*

... Рейс номерын тагы бер тапкыр карап, кесәсенә тыкты. Юыну бүлмәсендә озакламады, чәче, сакалы буйлап тарагы шуып кына үтте. Башка вакытта ул моны ашыкмыйча, тәм белән, бик пөхтәләп башкара иде.

Шкафтан күлмәген алып, инде сәдәфләрен эләктереп бетердем дигәндә генә, изүе турында сызылып калган үтүк эзе искәреп, теш арасыннан сүгенү сүзе сытып чыгарды. Ачуы килгәндә шулай бер телдә дә булмаган, әмма күп телләрнең яңгырашын үзенә сеңдергән берәр ясалма сүз әйтеп, бушана торган гадәте бар иде аның.

Ниһаять, ак җирлеккә вак кына кара борчаклар төшкән күлмәген киде. Сәдәфләрен эләктергәндә куллары калтырый башлады. Ашыгу, ашыгу гына да түгел — каушау, каушау гына түгел, алда торган очрашуны күзаллый алмаудан туган дулкынлану халәте иде бугай бу. Бер кирәкмәгәндә шулай дулкынланып китүенә, йомшаклыгына ачуы килә иде аның. Кирәк бит, симфония тыңлаганда, балет яисә спектакль ка-

раганда һич көтмәгәндә күзеннән яшь бәрә дә чыга. Сагышлы, тетрәндергеч фаҗигале урында булса бер хәл иде, бөтенләй кеше уйламаган, искәрми дә үткәргән бер моментта: матурлыкның, төгәллекнең билгеле бер ноктага ирешүен тойган күңеле тулышып китә дә, тын алуы авырлаша башлый һәм күзеннән яшь бәреп чыга. Бу шундый да рәхәт һәм бөек бер мизгел була ки, аннан соң инде күз яшен янәшәдә утыручыларга сиздермичә генә кул аркасы белән сөртеп алу һәм үз-үзеңне битәрләү башлана. Битәрләүнең сәбәбе: әнә шул бөек мизгелне туктатып тора алмаудан һәм, үтеп китүгә, беркатлы йомшаклыгыңны янәшәдәгеләргә күрсәтәсе килмәүдәндер, мөгаен.

Ул зур төенле галстугын буып, костюмын киеп, телефонга үрелим дигәндә генә... ишектә звонок чылтырады. Аэропортны белешү, такси чакырту иде аның теләге. Инде киенеп тә беткән иде бит... Звонок тавышын ап-ачык ишетсә дә, ул нигәдер ашыкмыйча гына телефон трубкасын алды. Йөрәк турыннан кузгалган хәвефле, рәхәт бушлык бөтен тәненә таралып оета башлады. Хәзер инде ашыгуның кирәге калмаган иде.

Самолетлар оча башлаганмы-юкмы икәнен белешеп, такси чакыртырга дип килгән иде бит әле ул телефон янына — хәзер инде шалтыратып торуның мәгънәсе юк иде.

Ишектә кем булуын һич икеләнүсез белә иде ул. Башка кеше булу ихтималы зиһененә килмәде.

«Өч тәүлек буе көттем, югыйсә. Кешечә итеп каршылый алмадым. Ике тәүлек аэропортта кундым. Хәтта, дежур милиционер да миннән шикләнеп, янымнан сынап-төбәлеп үтәдер шикелле тоела башлады. Справочныйда да тәүлекләр буе гел бер кыз эшлидер кебек иде (мин аның йөзенә игътибар белән карамыйм да), һаман-һаман килеп сорашкач, ул миннән тәмам туйган рәвештә, тупас җавап бирә иде кебек. Аптырагач, мин аңа телефон-автоматтан шалтырата идем... Томанлы яңгыр яуды да яуды. Мин гаеплемени соң? Бүген төнге сәгать өчтә генә кайтып яткан идем. Менә бит, иртәнгә һава ачылып та киткән. Син килеп төшкәнсең, кызым. Матур итеп каршылармын дигән идем — булмады. Тагын мин дигәнчә булмады...»

Кабат звонок тавышы яңгырауга, ул, сагышын җыйган кара шкатулканың капкачын япкан шикелле, телефон трубкасын куеп, урыныннан кузгалды.

Ишек төбендә басып торган озын буйлы кызны күргәч, ул нәрсәнедер әле генә оныткан һәм нәрсәнедер әле генә исенә төшергән шикелле (ә бу вакытта куллары таянырга дип ишек яңагын эзләде, кызның саф, чиста карашыннанмы күз төпләрендәге җыерчыклары тартышып, сызлап куйды) өн белән төш арасында буталгандай бер мәлгә чарасыз калды. Әйтерсең моңа кадәр ул бөтенләй яшәмәгән дә, борчу-сагыш һәм шатлыклар белән аралашып үткән еллар бөтенләй булмаган да... ә бары тоелган гына. Һәм шуның чынлыгына хөкемдар сыман бусагада ул басып тора. Читтә яшәп, кызының тәмам үсеп җитүен, өлгерүен күрә алмаган ата гомеренә үкенеч булып яшьлек кыяфәтендә үзе килгән. Әнә шул үкенеченә бер юаныч табу өмете белән ул бусагадагы кызыннан үз чалымнарын эзләде. Сүзсез карашып торган бик чамалы вакыт эчендә алар бер-берен икеләнүсез таныдылар, ә шулай да...

— Марат Битаманов сез буласызмы?

— Сөембикә... исәнмесез... әйдә үтегез...

(Күңел түреннән күтәрелеп килгән «кызым» сүзен бүлеп — «Сөембикә»).

Кыз җилкә аша төшкән киң каешлы сумкасын алып куйды һәм икеләнеп кенә күрешергә дип кулын сузды.

— Гафу ит, каршы алалмадым, менә әле генә... Өч тәүлек буена тоташ койды бит...

— Мин кереп тормам диган идем дә...

Акланугa каршы шелтә кебегрәк әйтелгән бу сүздән Марат тотлыгып калды. Сумка бавын рәтләп торган кыз маңгай астыннан әнисенең күзләре белән шундый итеп карап алды — Маратның йөзенә юеш чүпрәк ятпылармыни. Күп яшьләргә хас мондый кырыс, аяусыз караштан соң ул «Кызым» дип дәшә алмаячагына тәгаен төшенде.

— Юлда бик аргансыңдыр инде, кая, сумкаңны үзем тотыйм, әйдә. Өч көн буе койды бит, өч көн буе...

«Аэропортта каршылавы бүтәнчәрәк булыр иде. Күрешү нинди салкын килеп чыкты. Стеналар кыса... Бәлки шулай булуы табигыйдыр да. Бер-беребезнең бар икәнен белеп яшәсәк тә, без бит бөтенләй чит кешеләр. Хәер, алай дию килешер микән?..»

Сөембикә юынган арада, ә үзе ашыга-кабалана чәй әзерләп йөргәндә дә баягы караш аның күз алдыннан китмәде. Томаннар, яңгырлар артыннан киләсе кызын ул әлегә кадәр билгесез бер дулкынлану белән ышанып-ышанмас кына көткән иде. Нигә дип килергә уйлаган соң әле ул? «Миңа унҗиде яшь», дип балигъ булуын искәртүе дә юкка түгелдер. Димәк, хәзер ачыктан-ачык, зурдан кубып сөйләшә ала.

Чәйгә утыргач та ул кызының күзләренә туры карый алмады. Чәй пары кебек сизелеп күтәрелгән киеренкелек аны кырысрак булырга өнди иде. Ирләр кулы белән бик тәфсилләп җыештырылса да, хатын-кыз эргәсендә җитешсезлекләре калкып чыккан бүлмәдә, юл киемнәрен алыштырып, җиңел кимоно күлмәк кигән Сөембикә иске чүлмәккә утыртылган нәфис гөл шикелле балкып утыра. Шкафларны өрфия тузан каплаганны, диван башларындагы чүпрәкләрнең тәмам тузганлыгын Марат хәзер генә искәреп, гомумән мебельләрнең дә бик җайсыз куелганлыгын абайлады. Нишләп соң әле барысы да кинәт кенә торышларын үзгәрттеләр, дип уйлап, шушы ваемсыз-күнегелгән тормышына Сөембикәнең килеп керүенә эчтән ризасызланып та куйды.

— Менә, балы белән эч, Сөембикә.

— Рәхмәт.

— Юлда бик йончыгансыңдыр инде.

— Әллә ни түгел. Бу — элек без торган квартирамы? Әйберләре дә шул укмы?

— Әйе. Әниең монда калырга теләмәде бит. Без алай зур низагълар чыгарып аерылышмадык. Бүлешеп булмаслык әйбер дә юк иде. Завод-фабрикалар, янсә зур биләмәләребез булса, бәлки тавыш та чыгар иде, — дип Марат үзалдына көлеп куйды. Аның шаярта язып ук аклануын Сөембикә игътибарсыз гына үткәреп җибәрде.

— Миңа биш яшь ярым булган югыйсә — берни хәтерләмим. Ә стенадагы менә бу поши мөгезен кайда күрдем икән дип уйлый идем, монда икән!

— Син аны шүрәле кулы дип йөртә идең.

Сөембикә бүлмәне күзәткән арада Марат сиздермичә генә аңа күз төшереп алгалады. Кызның косметика тимәгән йөзе күбәләк тә кунарга өлгермәгән беренче яфрак кебек чиста, нәфис тиреле. Мәхәббәт кагылудан ачылып китәсе эчке моңы, ягымлылыгы җитди буласы килүдән туган кырыслык артында тыелып тора. Чак кына күтәренке борыны, ирен читләренең елмаерга кыҗрап өскә бөгелебрәк тәмамлануы йөзенә җәелгән кырыслыкның вакытлыча гына икәнлеген искәртә сыман иде.

— Син әниеңә охшагансың.

— Әни сиңа охшаган ди.

Бер карауда кабынып китеп тә, әкрен-әкрен сүрелә баручы бозлы матурлык түгел, ә күз карашлары, итагатьле хәрәкәтләре, мәгънәле кысылган иреннәренең үз вакытын, сүз тәмен белеп кенә ачылып китүләре белән тоташ бер бөтен булып, сизелеп-сизелеп кенә терелә барган тыйнак матурлык бу, дип уйлады Марат, кызына карап. Ләкин бу соклану

артында һаман да әле телеграммадагы «Миңа унҗиде яшь тулды» дигән сүзләр кинаяле искәртү ясагандай хәтерен ялмап тора иде. Сүзсез утырудан сабыры төкәнә башлаган Марат буш чынаякларны бер кырыйгарак этәреп куйды, баядан бирле калкавыч сыман бер батып, бер калкып торган икеләнүле уйларына чик куярга кирәк иде — тавышын күкрәк төбеннән үк суырып алды.

— Сез, яшьләр, безгә караганда күбрәк беләсез бит. Нигә энә өстендә утырырга — ачыктан-ачык сөйләшик! Ятим иткән өчен миңа рәхмәт әйтергә дип тә килмәгәнсеңдер. Я, башла!

Сөембикәнең керфеген дә селкетмичә шулкадәр сабыр утыруы Маратны аптырашта калдырды. Ул, капылт юашланып, клеенканың гел бер төшен кулы белән басып-басып ышкырга тотынды.

— Мин үземә Битаманов фамилиясен биргән кешене күрергә дип килдем — бары шул гына. Килеп борчыганмын икән, гафу ит, мин озакка түгел, иртәгесе самолетка билет алынган. — Маратның баягы тупас тавышыннан калган күләгәләрне Сөембикә әнә шулай сабыр җиңеллек белән җыйды да алды.

— Нигә алай бик тиз?

— Мин ятимлекне китапларда укыганча: дустына әтисе алып, янсә ясап биргән әйберне күргәч көнләшеп: «Ә минем юк, чөнки мин — ятим», дип рәнҗүдә түгел — минем бөтен әйберем дә җиту иде — ә рухи ятимлектә татыдым. Бабама рәхмәт, ул икегезне дә алыштыра алды.

Марат тирләгән маңгаен сөртеп куйды. Үзен кечерәйтеп, басып торган шик-икеләнүләрдән арына барган җанын газаплы сөенеч били иде.

— Сине дүрт яшькә кадәр бабаң үстерде. Без, укуны бетереп фатир алгач, сине дә үз яныбызга китерттек. Монда син бары ел ярым гына яшәп калдың. — Марат җәһәт кенә кузгалып шкафның аскы бүлекчәсен ачты. — Менә синең уенчыкларың, үзең куеп киткәндәгечә, кагылынмаган.

— Шул гомерме?!

Сөембикә паласка тезләнеп, уенчыкларның әле берсен, әле икенчесен кулына алды, иснәп-иснәп карагандай итте; әйтерсең уенчыклары аша үзенең балачак исен, балачак хатирәләрен исенә төшерергә тели иде ул. Күзләрендә кырыс җитдилек онытылып самими нур кабынды. Менә ул кыштырдавык капчыктан алып өр-яңа, тотылмаган да дип әйтерлек шүрәле-курчакны кулында әйләндергәләп торды да, кыюсыз гына:

— Бусын үзем белән алырга мөмкинме? — дип сорады.

Марат елмаеп баш какты.

— Боларның барысы да синеке, — дип үзе дә Сөембикә янына килеп тезләнде. Кайчандыр төннәрен дә «бабам», дип елап уяна торган кызчыгын үзенә якынайтасы килеп, сөендерер өчен алып кайткан уенчыкларны дистә елдан соң янә тотып-тотып карады.

— Син әлек искереп, тузып беткән уенчыкларыңны ныграк ярата идең. Бигрәк тә урамнан табып кергәннәрен...

Бер-берсе каршына тезләнгән хәлдә, шакмаклардан йортлар төзеп, төсле ташларны алмаша-алмаша мозаик сурәтләр тезеп хәтсез вакыт онытылып уйнадылар. Сүз арасында уен, уен арасында сүз тукталмады.

— Укырга кая керергә уйлыйсың?

— Медицинскийга.

— Бәләкәй чагында стюардесса булам, дия идең. Пассажирларга конфет өләшү ошый иде сиңа.

— Хәзер дару өләшермен.

— Бәйрәмнәрдә минем котлау открыткаларын ала идеңме?

— Ы-һы. Ә син?

— Рәхмәт инде, бөтенләй онытып бетермәгәч, — дип Марат Сөембикәгә сынаулы карап алды. — Нигә җавап язмый идең соң?

— Син дә язмый идең бит.
— Әниең монда килүгә каршы булмадымы?
— Юк.
— Ул һаман шунда эшлиме?
— Әйе. Кандидатлыкны яклады.
Бераздан Марат төргәк эченнән альбомнар тартып чыгарды. Анда— төсле карандашлар белән кайчандыр Сөембикә ясаган рәсемнәр иде. Борынгы кешеләрнең тау куышына сызыклардан гына ясаган сурәтләре шикелле — чәчәк, кеше, йорт сурәтләре. Сөембикә шакмаклардан төзелгән йортны ишеп төшерде дә, дулкынланып, үзенең балачак хыялларын кулына алды.

2

Ике рәтле машиналар агышын сыйдырган гөжелдәп торган урам аста калды. Маңгае гарип куаклар белән капланган гаҗәп текә яр өстенә менеп җиткәч, олы урам шавына күнеккән колаклар гадәттән тыш тынлыкка ияләшә алмыйча торды. Монда бөтенләй башка күренеш иде. Чирәмле сукмаклар, агач өйләр, капка төбендәге утыргычларга кадәр— барысы да авылдагыча. Кинәт кенә авыр киемнән котылган шикелле үзеңдә җиңеләю сизәсең, тагын да зәңгәрләнебрәк киткән төпсез күк йөзе ирексездән карашыңны били.
Текә баскычлардан шәһәрнең тыныч катына менгәч алар бераз онытылып киткәндәй булдылар.
— Әнә теге яшел түбәле йорт. Кырыйдан иң соңгы тәрәзә безнеке иде.
— Әйдә, кереп карыйбызмы?
— Ике генә ай тордык бит без анда. Надя түти хәтерләмидер дә инде.
Шулай да Сөембикәнең теләгән сүндерәсе килми иде аның. Ул бит үзенең балачагын сагынып килгән. Яшәргә дә өлгермәгән әле югыйсә, ә инде үткән эзләрен барлап йөри. Димәк, эзлекле үсешен югалтып, вакытсыз килеш нидер өзелгән. Шуны ялгарга кирәк аңа, киләчәктә үзе ялгышмас өчен.
— Ике генә айлык идең әле син ул чакта.
— Бабай көн дә хатлар язып торган.
— Бүлмә кысан иде шул. Сине карарга дип әби килгән иде. Әниеңнең дә, минем дә институтта имтиханнар вакыты.
Марат, җил капканы ачып, Сөембикәне алдан кертте.
— Кергәч тә бүлмәнең сул ягында борынгы караватбулыр, без аны иптәш малайның сараеннан әтисенә әйтми генә алып чыккан идек. Түр почмакта бер аяклы өстәл — студент чакта дуслар ярдәмле була бит ул — такталар юнәтеп ясап бирделәр. Менә шулай итеп Надя түтинең шып-шыр бүлмәсен без сине каршыларга әзерләп куйган идек.
Иске йортларга хас муртайган исле караңгы коридорны сак кына үтеп эчкәре керделәр. Ишекне челтәрле ак майка, трико кигән таза гәүдәле ир ачты.
— Надя түти өйдәме? — дип сорады Марат.
Хуҗа ир Сөембикәгә йотлыгып карап куйды да, майка челтәреннән шытып чыккан йонлы күкрәген ышкып алды.
— Аның үлгәненә биш былтыр инде. Монда — мин хуҗа.
Бер улым бар, төрмәдә, дип сөйли иде Надя түти, шул үзедер ахрысы, дип уйлады Марат.
— Фатир кирәкме? — дип хуҗа ир җавап та көтмичә, кайчандыр Маратлар торган кырый бүлмәнең ишеген ачты. — Кызга ошармы соң, уңайлыклар юк инде бездә...

Кыстатып та тормастан ниндидер ашкыну белән Сөембикә керә башлауга ук, хуҗа ир Маратның җиңеннән тотты, Сөембикә артыннан ишекне кысыбрак куйды да, авызыннан тынчу җылы ис бөркеп:

— Күрәм, син хатыныңнан «командировкага» киткәнсең, губа не дура, мин әйтәм. Кызның шәбен эләктергәнсең. Хакыннан тормасаң, бер атнага мөмкин, бүлмә буш — студентлар практикада...— диде. Мондый әчкерсез тупаслыктан чарасыз калган Марат түземен җыеп:

— Миңа фатир кирәкми, — диде, — бу минем үз кызым. Без кайчандыр монда яшәп алган идек.

— Шулаймыни! Гафу ит, туган, гафу итә күр.

Ул арада Сөембикә ишекне ачты.

— Нәкъ син дигәнчә бит монда, ничек шулай хәтереңдә калган барысы да?!

Акшарлары купкан стеналар, хуҗа ирнең кабалана-кабалана таушалган костюмын иңенә салуы, әле генә аның рәтсез сүзләрен тыңлаган Марат — бөтенесе дә бусагада елмаеп торган Сөембикә каршында картая, туза, таркала барган Вакытның бер чагылышы булып тоелдылар.

«Монда хатирәләргә урын юк. Түшәмнән салынган сәләмә пәрәвезләр, чебеннәр сипкелләп бетергән бәләкәй лампочкадан төшкән зәгыйфь ут, юылмаган идәнне түшәм белән тоташтыручы караңгы почмаклар — керләнгән дөнья!.. Монда хатирәләргә урын калмаган — барысы да күмелгән, сүнгән, тапталган. Бары тик таныш әйберләр генә исән, чит кул тигән әйберләр генә. Тизрәк моннан һавага чыгарга кирәк — яктыга! Тизрәк чыгарга... Сәләмә пәрәвезләр, зәгыйфь ут яктысы — керләнгән дөнья. Менә бу тар, караңгы коридорны үтәсе дә...»

Марат Сөембикәнең кулыннан тотып үз артыннан тартты.

— Сез гафу итегез инде...

Сөембикә бусагада калган иргә борылып елмайды:

— Нигә гафу үтенәсез? Сезгә рәхмәт. Киресенчә, безне гафу итегез.

Яр читенә килеп баскач кына Маратның агарынып чыккан йөзенә тынычлык җаелә башлады. Аста, еракта Иделнең кояш төшкән көзге кыйпылчыгы сыман бер чите күренә, яр тирәсенә елышкан кызыл түбәле йортлар, гүя шул көзгедән үзләренең борынгы йөзләрен карарга дип җыйналганнар. Бер кырыйдан шул иске манзараны кысрыклап, тоташ пыялалары, кырыс мәһабәтлеге белән ялтырап яңа биналар чирүе килә...

— Мин менә шушыннан шәһәр өстенә карап торырга ярата идем. Аста машиналар чабыша, тавышлары монда кадәр менеп җитәлми. Тыныч. Рәхәт. Ул чакта без өчебез дә әбигә бәйле идек. Син дә, мин дә, әниең дә әби карамагында. Финанс ягыннан да, башка яктан да. Әби, махсус, эшеннән сорап килде. Белмим, ул булмаса без нишләр идек... Әби менә шушы яр читенә колясканы куя иде дә, үзе бәйләм бәйләп утыра иде. Яз. Кояш. Алмагачлар чәчәк аткан чак. Син берни белми таралып йоклыйсың. Минем бар курыкканым шул иде: коляска яр читендә үк тора, җил иссә дә аска тәгәрәп төшеп китәр кебек. Үзем куркам, ә үзем әбигә әйтергә кыймыйм. Ул берәр йомыш табып өйгә кереп киткән арада тәгәрмәч астына агач кыстырам, яисә колясканы яңы белән борып куя идем. Ә ул көн дә шулай, колясканы яр читенә ук чыгарып куя да, үзе бәйләм бәйләп утыра. Институттан һәр көн бер-бер хәл булмагае дип шөбһәләнеп кайта идем, төннәрен дә ярдан төшеп киткәнеңне күреп саташып уяна торган идем. Ләкин бу турыда әбигә дә, әниеңә дә әйтә алмый идем. Чөнки минем ата буларак бер хокукым да юк иде. Ни акчам, ни фатирым... Ничә еллар үткән бит инде, һаман да, шушы яр читендә торган син төшләремә керәсең дә... куркып уянып китәм. Беләм, зур үскәнеңне дә беләм, югыйсә.

— Мин үзем дә курка башладым, — дип Сөембикә куырылып яр читеннән арткарак чигенде.

Кичке шәфәкъ көмешсу аллыгын шәһәр өстенә сирпегән. Офык сызыгында мөлдерәп тулган кояш чирканчык алыр да, менә-менә Иделгә чумар шикелле. Төсен үзгәртә барган киңлекләрдә көн белән төн алмашыр алдыннан була торган моңсулык.

Аста — машиналар ташкыны.

Миллионлаган язмышларны ышанычлы түбә белән ышыклаган шәһәрнең, бер нокта булып, Җир белән әйләнә-әйләнә чиксез мәңгелеккә йөзеп барышы.

Битамановның үз гаме.

Сөембикәнең үз хисләре. Аның тукталышы бу чиксезлек дәрьясында арырак булыр. Әмма ул бу турыда уена да китермидер әле — яшьлекнең вакытка битарафлыгы...

3

— Әйләнеп торган пластинкага кара син: уртасына язылган хәрефләре туры бит, югыйсә, әйләнгән вакытта ана ничек, түгәрәк булып күренә. Әйләнеп торган өслектә һәммә нәрсә дә каршылыкны җиңеп түгәрәк булырга омтыла. Җир шары да пластинкага охшап әйләнә бит. Җирдәге нәни генә орлыктан алып зур агачларга кадәр, гомумән, бөтен тереклек иясе, күпмедер дәрәҗәдә йомры-түгәрәк булып яратылган. Шакмаклы, турыпочмаклы түгел бит. Ничә мең ел элек төзелгән Колизейларны, ничәмә гасыр элек төзелгән чиркәү-мәчет гөмбәзләрен кара: шакмаклы итеп төзелгән булсалар, җимерелмичә, бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән булырлар идеме! Әйткәнемчә, зур тизлектә әйләнгән җирдә һәммә нәрсә дә түгәрәк булырга омтыла. Димәк, борынгы архитекторлар моны исәпкә алганнар. Һәм мин шушы фикеремне куәтләү өчен бер мисал да китергән идем. Пасха утравындагы таш сыннар турында беләсеңдер. Ул сыннар тупас кырлы, шакмаклы итеп эшләнгәннәр бит. Ни өчен? Бәлки аларны чынлап та башка планета иляре ясап калдыргандыр? Димәк, ул планета Җиргә караганда бик акрын әйләнә. Бәлки андагы үсемлек-агачлар да шакмак формасындадыр?.. — Марат сүзеннән бүленеп фужердагы шампанны эчеп куйды. — Студент чагында фәнни конференциядә мин рәсем сәнгате белән архитектураны бәйләп әнә шундый романтик мәкалә белән чыккан идем. Мин ул чакта әниең белән таныш идем инде. Нигә дип сиңа сөйлим соң әле? Хәер, болай гына...

Болай гына... Кафе-мәгарә түрендәге колонкалардан саркып килгән стереомузыка, стенадагы сурәтләрдә — тормышның кадерен, тәмен белеп яшәгән канәгать-сабыр йөзләр, вакытны чутлаудан туктаган җиз телле борынгы сәгатьләр, кара авызын ачып өнсез калган «җиз еланлы» граммофон — болар барысы да үз күңеленә тирәнрәк төшәргә вакыты да, табигать тынычлыгы да мул булган унтугызынчы гасырның сагышлы хәтере сыман. Маратның шул халәткә ярашкан күңеле Сөембикә күзләреннән үзенең яшьлек чалымнарын эзли, инде кире кайтмаска киткән елларының көлен аралап, ачылып бер сөйләшәсе, бушанасы килә иде.

— Кызык бу. Тик менә Пасха утравындагы сыннар гына...

— Ышандырмыймы? Синең яшеңдә минем ышанасы килә иде...

— Бүгенге монументаль сәнгатьне алсак, анда бит Сикейрос иҗатына хас тупас, эре йөзле кешеләр сынландырыла. Әйтик, мең елдан соң шуларны табып алып, егерменче гасырда да шакмак йөзле кешеләр яшәгән икән димәсләрме?

— Дөрес фикерлисең. Әлбәттә, Пасха утравындагы сыннар шул чор сәнгатенең бер этабы булырга мөмкин. Бу бит минем студент чакта фикеремне дәлилләү өчен логика җитмәүдән туган таяныч кына.

— Әйт әле, нигә син... Әниемнең дә, бабаемның да сиңа ышанычы зур иде. Минем хыялымда... Менә икенче көн инде, син әле миңа бер картинаңны да күрсәтмәдең.

— Менә бит ничек! Син гадәти кеше генә күрергә дип килмәгәнсең икән әле. Ә килеп күргәч... Мин электән үк шуңардан курка идем. Мәктәпкә укырга керерсең дә, укытучылар синнән әтиең кем дип сорарлар, син художник диярсең. Алар исемемне дә белмәсләр. Художник икән, ул бит билгеле булырга тиеш. Бигрәк тә синең әтиең, ул бит синең әтиең! Менә шул чагында син миңа ничек карар идең микән?..

— Син чынлап та шуларны уйладыңмы?

— Уйладым. Киләчәгеңне күз алдына китергәнгә шулай уйладым. Синең җырың-көең башка булачак иде. Минем каныма-аңыма сеңгән көйне ят иткән килеш син миңа, батып барган көймәне коткарырга маташкан бер мәхлук итеп көлеп карарсың, дип уйладым. Син — бүтән туфрак сайлаган бер гөл, үткәнеңә, тарихыңа битараф хәлдә, мине архаик бәндәгә санап... ә сине үземчә тәрбияләргә минем вакытым җитмәячәк иде... — Марат читкә борылып юталләргә тотынды, фужердан шампан кабып куйгач кына тынычланды. — Кыскасы, син үсә барган саен безнең аралар ерагаер, бер-беребезне аңламабыз дип уйладым. Әгәр син минем сәнгатемне кабул итмәсәң — бу минем өчен үлем белән бер булыр иде. Үз кызым да аңламагач, үз кызымны да сокландыра алмагач, минем сәнгатем нәрсәгә кирәк, һәм мин ни өчен яшәгәнмен!

— Алдан ук син ничек шулай төшенкелеккә бирелә алдың?

— Бу — кечкенәлек дип саныйсыңмы? Бәлки... Шулай да үз вакытында сәнгать белән араны өзүем дөрес булган. Күпләр... Хәер, кирәкми... Урта кул сәнгатькәрләргә хәзер дә кызыгып карыйм мин. Алар бер әйбер өстендә эшлим диләр икән, һич икеләнүсез, ышаныч белән ул картинаның үзәгендә ни булачагын да, сайланасы төсләрен дә алдан ук исәпләп, ап-ачык күрәләр. Ә син бер әйбер уйласаң, әйтергә кыймый йөрисең, ничек башкарып чыгармын дип баш ватасың, алдында — мең билгесезлек, мең борылыш, мең икеләнү. Эш барышында син уйламаган күпме төсләр үз артыннан ияртеп китәчәк. Ә алар бөтенләй башка — канәгать, тыныч, бәхетлеләр. Күп кирәкмени — куныең беренче каты да җитә. Шунысы гаҗәп: алар бер дә картаймыйлар... Үтә бер тәм белән, олыдан кубып, ашыкмый-кабаланмый гына әсәрен бетерәләр дә, икмәге өлгергән крестьян кебек, күпме башак, күпме бөртек чыгасын исәпләп йөри башлыйлар. Җәллим мин аларны һәм кызыгам. Кызыгам икән, димәк, мин дә кечкенә кеше. Юк, юк, болар барысы да соңыннан әле...

Кара бантик таккан ыспай егет өстәлгә йөземле мороженое китереп куйды һәм кырыйга иелеп, пластинканы алыштырып китте. Марат чәкәштереп шампанны эчеп җибәрде, Сөембикә фужерга иренен генә тидереп алды.

— Сәнгать әсәре тудыру үзе бер көрәш бит. Вакыт белән бермә-бер көрәш. Шул көрәштә арган җаныңны үз даирәңдәге вак көрәшләр талкый башласа... Күңелдәге изге уйларны ваклый торган тирә-юнемдә барган хөсетлекләрне сизеп (аны бары тик сизеп кенә була) рәнҗетелеп кайта идем дә, моның тамыры нәрсәдә икән, дип уйга кала идем. Бәлки безнең ерак бабаларыбыз Мөхәммәт пәйгамбәрне Христос шикелле итеп кадаклап, каһәрле ләззәт кебек олы тетрәнү кичерә алмагангадыр. Әнә шул фаҗигале легенда, тарих төбеннән килеп, кешене сакларга, кешене күтәрергә кирәк дигән искәртү булып буыннан буынга күчми дисеңме. Тамырында: ялгышмагыз, үкенерсез дигән фаҗига яткан легенда булмау геннан генга күчеп бездә хөсетле вак көрәш ләззәте тудырадыр. Дингә мөнәсәбәтле булмасак та, без шуннан тиз генә чистарына алмыйбыздыр? Тора-бара менә нәрсәгә төшендем мин: үн башка югары булсаң гына сине таныячаклар, бөтен барлыгың белән ка-

бул итәчәкләр. Ә инде бер башка гына югары булсаң, тирәлек сине матур гына тигезли, кыркып куя. Үз тирәмдәге ваклыклар белән көрәшергә көчем җитмәячәк иде минем. Булалмаган солтан булганчы, булалган олтан булуың яхшырак. Нигә тартышырга, гомер болай да кыска бит.

— Һәр сәнгать кешесе мөмкинлеген үз гомере белән генә чикләсә, без күп нәрсәләрдән мәхрүм булыр идек.

— Син максимумнарга таянма. Киләчәк, мәңгелек дигән төшенчәләргә төренү җиңел. Чөнки без аны күрмибез дә, татып та карый алмыйбыз.

Сөембикә үзенең фужерын Марат алдынарак этәрде дә, калак очы белән генә алып мороженое кабып куйды.

— Бусы читтәгеләре, ә менә яшәгән куышыңда ничек? Күз алдына китер: сиңа илһам килгән вакыт, хыялыңа чумып, ялгызлыкның кадерен белеп кенә утырасың, шул вакыт кухнядан гап-гади тавыш ишетелә (Интеллектуаль тормыш өчен бер бүлмә кысанрак шул). Кисәтүләме ул тавыш, үтенүләме — барыбер, сиңа бер кем кирәк булмаган чакны син — кемгәдер кирәк. Аннан соң инде сумкаңны тотып, тәмәке төпчекләре ташланган баскычлар буйлап түбәнге катка төшеп китәсең. Кайтып кергәч, үзенә азык ташудан башканы белмәгән кырмыскадан аермалы буласы килгәнгә, үзеңне мәҗбүр итеп уйларыңны барларга тотынасың. Ләкин бая гына әле хыялыңда туып килгән дөньяңның тупсасы инде биегәйгән, ул сине кабул итми.

— Гафу ит бүлдергәнем өчен, вакыты белән Толстой да Толстой башы белән крестьян эшләре эшләгән, хәтта итек тегәргә вакыт тапкан.

— Һы, бу бит алла тәхетен калдырып җиргә төшеп алу, бер мавыгу гына. Итеге булмаганнан текмәгән бит ул аны.

Сөембикә риза түгеллеген сиздереп башын түбән иде.

— Янсә икенче бер момент: син иңемә килеп кагыласың, эшемне бүлдергәнеңә ачуым чыгып сиңа борылам. Ә син, ягымлы тавыш белән үтенеп, миңа кайчы, кәгазь сузасың. Кайчы белән кәгазьдәге рәсемне кисеп бирү — синең өчен никадәр зур эш! Мин чарасыз калып, чиста, самими күзләреңә карыйм да... Я хода! Бу үзе бер сәнгать бит! Табигый сәнгать. Тагын нәрсә кирәк һәм миңа баягы хыялым каршында оят була башлый. Мин дә соң шушы сабый кебек дөнья-табигать каршында нәрсәдер эшләргә теләп ялварып торам түгелме? Юк, ялварып түгел, сабыйдан аермам шунда: мин үзем эшләргә омтылам... — Марат костюмын салып кресло аркасына элде, галстугының төенен бушатыбрак куйды. — Менә шулай итеп минем студент чактагы хыялларым әкеренләп тоныклана, мәгънәсен югалта башлады. Югыйсә бит әниеңне дә үз артымнан ияртkән идем. Ул фән юлыннан китте. Ачыктан-ачык әйтмәсә дә, ачыш ясау иде теләге. Ә гаилә булгач, вакытны икебезгә дә тигез бүләргә кирәк икән. Миндә — бер гаиләдә ике шәхес булаламы дигән икеләнү туа башлады. Аның берсе, үз-үзен корбан итеп, икенчесен үстерергә тиеш түгел микән? Ә кем? Минме? Улмы? Болай булмый имеш, гаиләне таркатып ирекле булабыз, аерым-аерым үз хыялыбызга ирешәбез. Ләкин дөньяның яртысы бүленгәч ирекле була алмыйсың икән шул. Хикмәт шунда: без кайчандыр омтылган хыялларыбызның инде артта калганлыгын, төзиячәк сараебызның хәрабәләре өстендә утыруыбызны аңладык. Бер-беребезнең кечкенәлегең күргән хәлдә, күзләргә туры карый ала идекме соң без?! Бер-беребездән качарга, онытылырга, югалырга кирәк иде. Аерылышканнан соң әниең белән очрашмауның сәбәбе бәлки шундадыр да. Поезд киткән, җитәкләшеп тә, аерым-аерым да без инде аны куып җитә алмаячак идек...

Сөембикәнең үзчел карашында бик әчкәре яшерелгән сагаю сизелә иде. Марат сүздән туктагач, ул, бераз тын утырды да, әйтә куйды:

— Максатыңа хыянәт итүеңә мин ышанмыйм. Бу бит үз-үзеңне үте-

рү, яшәүдән ваз кичү дигән сүз. Анализ белән артык шөгыльләнү, белмим, аңлый алмыйм, үз-үзеңне аклау өченме бу, әллә икеләнүме?..

Марат дәшмәде, артык нечкәреп китеп түгелүенә үкенгәндәй бер сүз дә әйтмичә кресло артына ята төшеп күзләрен йомды. Бераздан, музыка авазын аралап, Сөембикәнең тавышы әллә каян, бик ерактан ишетелгәндәй булды.

— Мин туңа башладым. Салкын бу базда...

## 4

Сөембикә кара сулы кечкенә күл ярында туктап иелде. Суда сизелер-сизелмәс кенә дулкыннар чыгарып аккошлар йөзә. Үткән гасырның аксөяк кызлары шикелле, муенын горур тотып, ак каурыйларын затлы күбекләндереп йөзә бирәләр. Бу көяз су кошлары эргәсендә тирә-юньдәге яшеллек тә гадәттәгедән яшелрәк тоела, утыргычта утырган әбиләр, бала-чагалар да гадәттәгедән мөлаемрәк күренә.

Күл яныннан ары киттеләр.

— Бәләкәй чагыңда сине бер дә монда алып килмәгәнмен икән. Сөйләшә торган капканы күрәсең киләме?

Сөембикә, эчке соклануына ирек биреп, үзалдына елмаеп бара. балалар чыр-чу килә, карусельләр әйләнә. Кечкенә машина руленә тотынган сабыйларны бәхет баскан. Хәрәкәтсез торудан арган таш боланнар, әгәр бу балалар паркы булмаса, кузгалырлар да, ыспай гына атлап урманын эзләп китеп барырлар иде сыман. Әнә теге авыр гәүдәле аю, шикәр ыргытсаң, таш киемен салыр да, гәүдәсен мәзәк селкетеп биеп тә күрсәтер шикелле. Сөембикә һәммәсен дә тамаша кылып бара, каршы килгән балаларга юл бирә, башларыннан сыйпап үтә. Гүя ул шушы паркка керәлмичә адашып калган балачагын эзли.

Тип-тигез кыркылган сыек яшел үләнле аланга килеп чыккач, Сөембикә Маратның кулын кысты.

— Әйдә, җитәкләшеп бер йөгерик әле!

Ни әйтергә белми торган Маратка икеләнергә юл калдырмыйча Сөембикә туфлиләрен сала башлады.

— Мин сине йөгерергә өйрәтәм.

«Мин сине йөгерергә өйрәтәм», дип кайчандыр үзе аңа әйткән Марат йөзендә кырыс җитдилекнең эзе дә калмаган, күзләрендә уйнак очкыннар биегән кызы каршында вакыт төшенчәсен югалткандай булды. Бик тирәндә, үз-үзен мәҗбүр итү аркасында гына йомылып калган фантазиясе уяндымы — күңелен кытыклап яңа, моңарчы күрелмәгән төс чагылып үтте. Кызыктырып торган әлеге төс тәэсиренә бирелеп онытылудан, кызының менә шушы халәттәге ваемсыз шатлыгын күләгәләүдән курыккандай, ул «коткар» дигән шикелле аның кулын кысыбрак тотты.

Йөгерә-йөгерә үзәк аллеяга килеп чыккач, Сөембикә үтешли генә фонтан касәсеннән учы белән Маратка су алып сипте, чыркылдап көлә-көлә инде еш-еш сулу ала башлаган Маратны һаман алга әйдәкләде.

— Мороженое саталар анда, Сө-ем-би-кә.

— Кирәкми.

— Коктейль... эчәсең килмиме?

— Калышма, иптәш Битаманов!

Карт юкәләр тезелешкән аллея кырт борылган төштә ниһаять тукталылар. Сөембикәнең битләре алланган, бөтен барлыгы белән көлә, галстугын чишеп кесәсенә салган Марат исә, күкрәген тотып, чабыштан килгән ат шикелле туктый алмый йөренә иде. Марат кинәт кенә тагын да якынаеп, үз булып киткән кызына сөеп карый, ә күзләрендә — йөзенә җәелгән елмаюга кушыла алмаган күзләрендә — тынкы сагыш, кыска гомерле шатлыкны сузарга теләгән уяулык.

— Ун елга яшәрттем үзеңне.
— Инфаркт була язды бит.
— Кырык яшьтәме?! — Сөембикә артистланыбрак көлеп куйды, — коктейль дигенме әле бая?
— Бая бит ул, хәзер соң инде, — дип шаяртты Марат.
Сөембикә кулъяулык чыгарып Маратның тирләгән йөзенә китерде. Бик күптән инде хәтергә сеңеп калган таныш ис — әнисе яраткан хушбуй исе маңгайны, иякләрне сыйпап узды. Күңел төбеннән тынын буып рәхәт һәм газаплы дулкын күтәрелә башлады. Ул йөзен борды, ерак та түгел уенчыклар тезелгән лотоклар каршында бала-чагалар кайнаша иде. «Әти, миңа үзем кадәр аю алып бир әле, әти, ал инде, мин аны кочаклап йоклар идем, әти...»
«Әти» дигән сүзне юкка чыгарган еллар артыннан шулкадәрле дә ягымлы, үтенүле сабый тавышы ничек соң әле сакланып килгән?
Марат кара күзле, кара борынлы түм-түгәрәк плюш аюны култыгына кыстырып килгәндә, Сөембикә арык суында юган аягын кулъяулыгы белән сөртеп, иелгән килеш кенә туфлиен киеп тора иде. Марат аюны артына яшерде дә, Сөембикә күтәрелүгә, ачулы мырылдаган булып, аңа таба килә башлады һәм кинәт кенә аюны чыгарып кызына сонды. Сөембикә кычкырып җибәрде, тышка бәреп чыккан гаҗәпләнүле сөененеченнән тыела алмыйча аюны кочаклап алды.
— Ай, нинди матур!
Аюның битен, колакларын сыпырды, хатын-кызга гына хас нәзәкать белән күкрәгенә кысты. Сөембикә үз шатлыгы белән әвәрә килгән арада Марат, иелеп, чирәмдә онытылып калган дымлы кулъяулыкны алып кесәсенә тыкты. Нигәдер кызының күзләренә туры карый алмый иде ул. «Никадәр соңарып бирелгән бүләк аю... Ә Сөембикә берни сизми, берни хәтерләми бугай. Хәтерләсен иде, күзләргә туп-туры карап әйтсен иде — Маратның аклану көткән үкенечле уйлары авыр төен булып калмас иде». Сөембикәнең эчкерсез рәхмәтен дә, ихлас куанычын да үзе генә белгән сагыш аша кабул итте Марат.
— Сөйләшә торган капка бар дигән идең?
— Әнә бит ул — каршында.
Сөембикә, куакларны аралап, Марат күрсәткән якка карады. Ян якларына челтәрле тимер коймаларны тоташтырган биек капка ак дуга сыман калкып тора, аңа менүче баскыч төбендә җилдән яңгырдан каралган таш арыслан йокымсырап ята иде. Сөембикә баскычтан менгәндә шуңа игътибар итте: арысланның кысылган авызы көләгәләнеп тора — ачуланган да, елмайган да кебек.
Баягы гөнаһсыз минутлар, яшәү мәгънәсенә торырлык кыска вакытлы рәхәтлек капканың бу ягында, сабыйлар утравында калачак. Һәм аны бүтән беркайчан да кабатлап булмас. Ләкин эчке бер көч Маратны әлеге капкага тарта, ыгы-зыгылы шәһәр урамына шушы борынгы капка аша гына чистарып чыгар сыман тоела иде аңа.
— Нигә соң моны «Сөйләшә торган капка» дип йөртәләр?
— Күрәсеңме, эчке ягы тоташ канау итеп чокырайтып эшләнгән. Бер-береңә карамыйча икең ике якка басасың да пышылдап кына эндәшәсең. Дуга буйлап килгән аваз янәшәдәге кебек яңгырап ишетелә.
— Кызык. Мин уң якка басыйм әле.
Мәшәкатьле шәһәр белән чыр-чулы ваемсыз балалар дөньясын аерып торган капка, бөтен тавышлардан арынып, алар пышылдавына күчте.
— Ишетеләме?
— Ишетелә.
— Бәләкәй чагымда алып килгән булсаң, бу капка минем хәтеремдә калган булыр иде, әйеме?!
— Соңлап булса да...

— Ул чакта без нәрсә турында сөйләшкән булыр идек икән? Син берәр әкият сөйләр идең, әйеме? Ә мин?

— Туктаусыз сораулар бирер идең.

— Синдә бер генә тапкыр булса да мине күрү теләге булдымы? Нигә дәшмисең? Ишетелмәдеме? Синдә...

— Ишетәм... Киткән чакта син миңа: «Әйбәт эти булгач килерсең», дигән идең. Күрәсең, мин һаман шул... әйбәтләнә алмадым.

— Шул сабый сүзенә үпкәләдеңме?

— Ул сабый — син идең бит.

— Әгәр мин үзем килмәгән булсам, димәк син... беркайчан да... нигә дәшмисең? Ишетмисеңме? Нигә... Син елыйсың бит, эти!

— Кызым... Юк, юк, гафу ит, кызым дияргә, беләм, хакым да юк. Бәләкәй чагыңда да әйтә алмадым. Кешеләрдән ояла идем. Икәү генә калгач кыенсына идем синнән, «кызым», дисәм кинәт шул сүзнең кадере бетәр кебек тоела иде.

Кызының баягы кульяулыгы белән битен сөртеп торган Марат иңенә килеп кагылудан сискәнеп артына борылды. Сөембикәнең күз төбендә яшь тамчысы калтырый, яшь тамчысы менә-менә зураер да күзен каплар кебек. Марат кызының иңеннән кочып алды.

— Син килеп төштең дә... Үземнең шулкадәр керләнеп, таушалып беткәнлегемне сине күргәч кенә аңладым. Матурлык каршында мин һәрвакыт шулай, яшәвемнән оялам.

— Син әнигә бер мәртәбә дә яратам димәгәнсең.

— Сүзнең көченә ышанмыйм мин. Аны бөтен гомереңбелән исбатларга кирәк.

— Мин сине гафу итә алмыйм, әнине дә... вакытында аңлашмаганыгыз өчен. Син нечкә күңелле кеше бит, югыйсә, шул нечкә күңеллегеннән оялып, шуны яшерү өчен тупас булып кыйланасың. Син кешеләргә үзеңне әкренләп, бөтен гомереңбуена аңлатырга тырышкансың, ә кешеләрнең моны аңларга вакыты тар, алар менә шушы минутта якты йөз, җылы сүзгә мохтаҗ...

— Мин күп нәрсәгә соңлап ирешәм шул. Китмәле бүген, кызым, сөйләшергә дә өлгермәдек ич.

— Телисеңме, монда укырга киләм?

— Чынлап әйтәсеңме?! — Марат гадәтенчә күкрәгенә кулын куйды. — Бер кешенең югалуыннан дөнья керфеген дә какмый икән. Менә беренче мәртәбә син язмышым белән кызыксындың — чын күңелдән. Рәхмәт сиңа. — Сөембикә әтисенең сизелер-сизелмәс кенә калтырап торган кулына игътибар итте. Тырнак төпләреннән бары тик рәссамнар гына чыгара ала торган төсләрдәге буяу эзләрен искәреп алды.

— Мин аңладым... Син... син бары икеләнәсең генә...— Сөембикә кыюланып әтисенең чем кара куе сакалына бармакларын тигезде.— Сиңа мин кирәк, эти.

---

Кадыйр Сибгатуллин

# ХАЛЫК ҖЫРЫ

Ишеттем мин кичә: бераү җырлый...
...Әллә нинди зарлы, моңлы көй.

*Г. Тукай.*

Бишегемнән килгән шушы моңга
ияләнеп булмый, гадәтләнеп.
Гомер буе тыңлыйм, гомер буе
үз халкыма үзем гаҗәпләнеп.
Көлә димә аны,
елый димә:
җырлый халык. Халык җырлаганда
куанычы һәм сагышы бергә.
көлә күрмә берүк,
елый күрмә!

Язган халык.
Тумышын да язган,
чыгышын да язган —
еллар чиккән.
Үзен-үзе таныр вакыт җиткәч
гасыр тузаннарын сөртә биттән.
Язган халык.
Туган елын, урынын,
шөгылен язган,
язган кәсепләрен.
Дошманнарны җиңүләрен язган,
үзен аның кемнәр рәнҗеткәнен.
Кабер ташы... Баш сөяге... Кылыч...
Курганнарда туктап халык уза.
Киләчәккә килеп җитәр-җитмәс
тузлар туза,
ташта язу туза.
Гадәтләре, халәтләре — бары
килә безгә килә алган кадәр.
Тарих тугры:
һәрбер таш кисәге
саклап торган безгә бәрәр хәбәр.
Кайда? Кайчан? Ничек?

Җавапларын
бүгенегә кадәр укыйм аның.
Бу аз миңа!
Бир син аның миңа,
ачып бир син аның газиз җанын!
Үзе туып басып торган төштә
ни уйлаган,
ничек уйлаган ул?
Данын җуйган чакларында ничек,
ничек итеп аңын җуймаган ул?
Кадере ни аның, җәбере ни?
Нинди аның зары, горурлыгы?
Каян килә,
каян килә аның
бу дөньяда төз, нык торырлыгы?
Мескен булыр иде иркә үссә,
моңлы батыр булган сызланудан.
Нишләп үзен кызгандырмый торган
халык була үзе кызганучан?
Бик җитәрлек атсыз-йортсыз чагы.
Булды микән аның моңсыз зары?
Йөрәгеңне кысса... Ул зар мыни?!
Моң гына бит ул зар,
тик моң бары.
Моң гына бит,
моңлы моң гына бит!
Бар гомере сыйган шушы моңга.
Йөрәгеңне кысса... син халыкны,
син халыкны әнә туктап тыңла!

Бик кадерләп төргән тузда түгел.
Ташларга да чокып уелмаган.
Иң кыйммәтле асыл гәүһәрләре
биктә түгел,
әмма җуелмаган.
Сак кына тот!
Чиста кулың белән.
Тапланмасын берүк, буялмасын.
Бер нөсхәдән,
бары бер нөсхәдән
халык күңелендә кулъязмасы.
Һәр бөртеген аның кеше рухы,
кеше җаны океанында тапкан.
Халыкныкы хәзер,
авторларын
эзләп табып булмый инде ВОАПтан.
Үзенеке аша халыкныкын
тоя белгән кемнәр,
күрә белгән?
Мәңгелеккә барып җитсен өчен
яза алган халык йөрәгенә.
Кемнәр алар?
Тарих телсез монда.
Җырларның да туза таныклыгы.
Инде халык җырны үзенә алган,
җыр язучы чөнки халыкныкы.
Кемнәр алар моңны моңга ялгап

рухын илгә ачып бирә алган?
Киләчәккә җырын озатканда
кайсы чатта кемнәр басып калган?
Кемнәр алар моңны моңга ялгап
тоташтыра алган чорны чорга?
Кемнәр алар? Халык кадәр халык
кулын куйган кемнәр язган җырга?

Тыңлап торам уй-хисләрем белән.
Халкым минем җырлы, моңлы илдән.
Башымны иям моңга җиргә кадәр,
имзасы бар:
халык җыры дигән!
Актарма син ертык тарих битен.
Көндәлеге үзенең бар бит аның.
Тыңлыйк әле,
тыңлыйк халык җырын,
халык җырын тыңлыйк —
халык җанын!

## Сыерчык бураны

Бик озак китмәде кышлары.
Еракта әле яз кошлары.
Өлкәннәр офыкка карый да,
бөтерә чал мыек очларын:

Бу язлар соңарды, соңарды,
белмәссең заманны, елларны...
Шулай да, җәмәгать, бул түзем,
әйтер ул, боерса, үз сүзен.

Әй, кинәт кузгалды ташулар,
гөрләште, җырлашты бар сулар.
Басулар битләрен ачтылар,
җиһанда уянды ярсулар.

Сизгәндәй халыкның уйларын,
томалап кырларын, юлларын,
бөтерелеп-бөтерелеп уйнады,
уйнады сыерчык бураны.

...Ә халык уңышка юрады.

Ашыгып китте кыш, ашыгып.
Ачынып китте кыш, ачынып.
Иң соңгы гөрләвек артыннан
өлкәннәр башларын кашыды:
ни ара килде соң, ни ара?

Майга да бер ай бар, майга да...
Калырмы туфракта дымнары?
Белмәссең заманны, елларны...
Шулай да, җәмәгать, бул түзем,
әйтер ул, боерса, үз сүзен.

Кырларның тузаны тузмады.
Яз тагын пошынмый узмады.
Томаны төште дә басуга,
офыкта болыты кузгалды.

Сизгәндәй халыкның уйларын,
томалап кырларын, юлларын,
бөтерелеп-бөтерелеп уйнады,
уйнады сыерчык бураны.

...Ә халык уңышка юрады.

Яз саен, яз саен урый ул.
Үзенең көнендә уйный ул.
Уйный ул сыерчык бураны,
хак була халыкның юравы.

## Күңел

Кемдер җиңде, кемдер узып китте, —
ачуы кабарды.
Әле генә алсу кебек иде,—
йөзе агарды.
Тиделәр күңеленә.

Бәхәсе дә булды, фикере дә, —
буталмады хак.
Кемдер аңа бер туры сүз әйтте,—
диде ул: нахак!
Тиделәр күңеленә.

Бер кауры белән кагылып үтте
яла вә әләк.
Олы афәт килгән кебек йөрде,
илгә үпкәләп.
Тиделәр күңеленә.

— Лаек! — диде халык, кулын чабып,
аңа бер мәлне.
Яшен сөртте бармак бите белән, —
күңеле нечкәрде.
Тиделәр күңеленә...

Хәниф Хөснуллин

# ЧАЛЛЫМ ЯКТЫСЫ

## Кырда

Куян куркып качты кинәт
Үләнлек арасына.
Бездән нинди зыян килсен
Табигать баласына.
Бу җырләрне иңләп, буйлап
Ул бит күпме йөргәндер.
Арышларның шаулый-шаулый
Үскән чагын күргәндер.
Хәзер монда — күпкә түгел —
Билчән һәм әрем түе.
Йөрибез шуларны ерып,
Йөрибез көне буе.
Акыллы күз — теодолиттан
Кирәк тарафны табып,
Без барабыз, билге өчен
Агач казыклар кагып.
Урам булыр,
Юл булыр, дип
Каккан казык азмы соң?!
Эшче һөнәрен ала кыр,
Ала эшче язмышын.
Без дә үстек авылларда,
Үстек атта чабышып.
Дөште булачак заводлар,
Дәште шәһәр тавышы.
Ил исеменнән чакырганда
Килмичә калалармы?
Заводлар — Индустриянең
Батыр ил балалары.
Без барабыз урын карап
Заводлар каласына...
Куян куркып качты кинәт
Үләнлек арасына.

## Бар да яңа

Яңа йортлар,
Яңа утлар,
Яңа урам,
Яңа төн.
Яңа сүзләр сөйли-сөйли
Кыз җитәкли егетен.
Яңа күктә —
Яңа нурлар,
Яңа йолдыз кабына.
Бар нәрсә дә яңа тоела
Шәһәр яңа чагында.
Яңа уйлар,
Яңа хыял,
Яңа язлар,
Яңа җыр.
Яңалыкны
Киләчәктән
Яшьлек шулай аладыр.

## Коллекторда

Җыр тарала бетон торба буйлап,
Кыз тавышын тыңлый җир асты.
Бер урында уйган тишек аша
Эзләп төшә нуры кояшның.
Тыңлап барам. Тарта җыр агымы

Каршы барам. Йөзәм моңнарда.
Бу шәһәрдә йортлар гына түгел,
Торбалар да тора җырлардан.
— Саумы, туташ?
— Болай исән әле.
Нинди җилләр белән, юлаучы...
— Җыр җылысын ныграк тойган саен
Якынгарак килә тыңлаучы...
Кыз елмая. Үзе әйтә шаян:
— Җырлыймын да икән, кара син.
Үзем бары сылыйм гына кебек
Торба белән торба арасын.

Хушлашабыз. Мине җыр озата.
Кыз тавышын тыңлый җир асты.
... Яңа буын яңа тормыш өчен
Кабул итәр безнең мирасны.
Шул чакта да кызның тыйнак тавышы
Яңгыратып торыр елларны:
— Без батырлык кылдык микәнни соң? —
КамАЗ гына салдык нибары.

## Тоя күңел

Тоя күңел, тавыш килә.
Йөзенче бабай дәшә:
— И, улым, фани тормышка
Мөкиббән булып яшә.

Тоя күңел. Тавыш килә.
Йөзенче онык дәшә:
— И, бабай, безнең буын да
Белерлек итеп яшә.

## Белгәндер

Киләләр, яшьләр киләләр,
Кулларында чемодан.
Аналарның җан җылысы
Аңа гына сыймаган.
Бәхетле юл теләп ана
Озаткан үз баласын.
Шуннан соң тормыш күзенә
Кемнәр куркып карасын?
Көн дә тынмый, төн дә тынмый:
Яшьләр килә — меңләгән.
Ил көнен зурлап, кемнәр соң
Дан атына менмәгән...
Нинди җирләр куанмаслар
Яшьләрнең дәртен күреп:
Биек йортлар, киң урамнар
Шул чемоданда кебек.
Сорамыйбыз: ил көнендә
Бу гадәт яңамы бу?
Утызынчы еллардагы
Килүләр дәвамы бу.

... Монда сине табасымны
Әниең дә белгәндер.
Шуңа күрә озатканда:
— Хәерле юл, — дигәндер

## Нәҗип Мадьяров

●

Күзгә кояш белән балкый басу,
Күзгә тынлык белән уралып.
Карап торам үрдә шул киңлекне
Күзгә өмет белән сугарып.

Сукаларның буй-буй сызган эзе
Офыкларга кереп югала.
Алар, беләм, кушылганнар инде
Хәзердән үк язгы дөньяга.

●

Алмагачка күз нурымны түгеп,
Карап торам алсу алмага.
Зурдан түгел, әмма гүзәл җәйнең
Олы яме балкый аңарда.

Коелыр көне ерак түгел, сизәм
Һәм күзаллыйм аның нишләрен...
Җиргә төшеп чәлпәрәмә китерер
Җәйнең дә ул бер ямь кисәген.

●

Ташка тамган тамчыга
Җиңел мени?!
Йөзләрчә кисәкчә булып
Чәчрәде ул.
Тамчы тамган чакта ташка
Җиңел мени?!
Уелудан йотты күк
Яшьләрен ул.

●

Төш күрәдер, ахры,
Күз тиярлек итеп
Елмайгалап кую
Ничек килешә аңа:
Тәрәзәдән төшкән
Кояш нурын кочып
Йоклый бала.

## Мөсәгыйт Хәбибуллин

# ЯҢА ӨЙ

хикәя

I



Көйләп куйган хуш исле чәй өстенә яңа салынган веранда тәрәзәсеннән кояш нурлары төшә. Чәй өстеннән чагылып киткән нурлар әле анда, әле монда сикерәләр дә бер урында дерелдәп, калтырап тора башлыйлар. Майкасын салып ташлаган ир-ат тирләп-пешеп чәй эчә. Аның каршында хатыны Хәнифә басып тора. Хатынның кулында тастымал, ләкин тастымал-сөлгене ул иренә дип китермәгән, үз-үзен тотышыннан, кыланыш-кыяфәтеннән үк күренә, тастымалны ул болай гына тотып тора, чынында исә хатынның иренә житди сүз әйтәсе бар, әмма әйтергә базмый, шуңамы, гасабилана, чәй өстеннән чагылган кояш нурлары кебек, йөрәге дерелди.

Өч ел элек аның беренче ире Ярулла кай тарафларгадыр чыгып киткән иде. Бүген шуңардан хат алды. Ире бүген-иртәгә өйдә булам дип язган. Ярулла югалып йөргән арада Хәнифәгә йортка кергән Нурислам хат турында белми, әмма ул да хатынының килешеннән нидер сизенеп, хәләл җефетенең күзенә күтәрелеп карарга базмый утыра.

Беренче ире Ярулланы Хәнифәнең бер дә җибәрәсе килмәгән иде. Тик әллә нигә китеп барды шул. Килешмәгән нәрсәләре дә юк иде кебек... Ир үзе гаепле булды. Һич тә йортка күңел салмады, шәһәр ягын карады. Ярата иде аны Хәнифә. Китә күрмәсен дип, Шаяхмәт бабасыннан калган йорт-каралтыны да авыл Советына барып ир исеменә күчертеп кайтты. Әмма Ярулла барыбер китте. Китүе дә сәер булды. Көннәрдән бер көнне Хәнифә иртән торса, янында Ярулласы юк. Карават башындагы өстәлдә хат кисәге. Анда да нибарысы ике-өч сүз: «Хәнифә, гафу ит, мин китәм. Дөнья гизеп кайтырга исәп».

Китте Ярулла һәм гүя суга төште, хәтта хатынын яз бәйрәме сигезенче март көне белән дә котламады. Бер ел көтте качкын ирне Хәнифә, ике ел көтте һәм Ярулла китү белән үк артыннан килеп сарып йөргән юаш һәм йомыкый Нурислам атлы егетне йортка кертте. Нурислам, Хәнифәдән дүрт-биш яшькә кечерәк булса да, тол хатынга бик теләп йортка керде. Хатын-кызны сөя-назлый белмәсә дә, эшкә гаять хирыс иде егет. Ел тулганда нигез бүрәнәләре череп беткән өйне сипләтеп, яңадан салды, абзар-кураны сүтеп, заманча итеп корды. Хәнифә аңа: «Нурислам, нигә саласың ул абзарны, мин бит укытучы, мал-туар асрарга

авыр булыр», — дисә дә, үзенекен итте. Җәй килсә печәнен хәстәрләде, ә көз җитүгә, күрше башкорт авылына барып, бер бозау, ике сарык, мамыклы кәҗә алып кайтты.

Нурислам колхозда төрле эшкә йөрде. Балта остасы да ул, кирәк чакта тракторчы да. Бөтен авыл халкын шаккаттырып, йортка кергәч, Нурислам турында авыз чайкаучылар да булмады түгел: «Нурислам түгел, Хәнифә өйләнде бу мүкләккә», — диештеләр.

Быел Нурислам җәй буена уракта булды. Бүген менә бодайны бетереп кайттык диде, ир-егет тирләп чыккан, рәхәтләнеп, тәм табып чәй эчә, үз дәрәҗәсен бик тә әйбәт белгәнлеген сиздереп хатынына карамый гына:

— Бодайда әйбәт эшләнде, хезмәт хакы мул булыр, — дип куйды.

Хәнифәнең бәгыре тәлгәләнә, түшенә яшергән кош теле хәтле генә хат йөрәген көйдерә. Хат турында әйтергә курыкты Хәнифә. Әйтмичә дә ярамый, моңа кадәр Нурисламнан яшергән сере юк иде.

— Нурислам, — диде хатын һәм каушаудан кулындагы тастымалны угаларга керешге.— Нурислам, Ярулла кайта. Хаты килде.

Нурислам аңа хәтта күтәрелеп тә карамый, чәй эчүен дәвам итә, чәй өстенә төшкән кояш нурлары ирнең җил-кояштан тутыкланып калган битендә чагыла. Ирнең дәшми торуына хатын гаҗизләнә башлый, сабырсызлана.

— Кайта? — диде ниһаять ир. — Нигә кайта? Өч елга якын җил куып йөргәчме?!

— Йорт-җир аңа язылган бит, аныкы, Нурислам.

— Мин ул өй-каралтыны өр-яңадан эшләдем түгелме? Ни сөйлисең син?!

— Закон буенча барыбер аныкы, йорттагы һәммә нәрсә аныкы.

— Рәхмәт, куандырдың... Өен авылда бер өй иткәч... Ярый, бик исең китмәсен, тигән өлешен бирербез дә, ничек кайтса, шулай китеп тә барыр.

— Риза булырмы соң?

— Булыр, — диде ир кузгала башлап. — Булмый кая барсын. — Ир текәлеп хатынга карап алды. — Туктале, нишләп әле син теге вакытта, тиктомалга дигәндәй, бабаң йортын аңа яздырдың?

Хәнифә башын түбән иде, үзе дә сизмәстән хатны тастымалга төрергә тотынды, тәмам каушап калды хатын.

— Мин аны шуңа алданып авылда калмасмы дип уйлаган идем, ә ул... — хатынның ияге, аскы ирене дерелди башлады.

— Ә ул китеп бардымы? — дип кинаялэп кенә сорап куйды Нурислам һәм сүзе бетүен аңлатып, торып басты. — Яхшы хатыннан ир китми. Үзең гаепле булгансыңдыр әле, узындыргансыңдыр, кирәгеннән артык яраткансыңдыр...

— Яраттым, — диде хатын, үткән өчен мыскал да үкенү тоймыйча яшьле күзләрен иренә күтәреп. — Яраттым. Тимә минем үткәнемә, Нурислам. Ишетәсеңме, тимә!

Ир түргә узып майкасын, күлмәген киде һәм сәдәфләрен эләктерәэләктерә янә ишеккә юнәлде.

— Ташла әле шул төчеләнүеңне. Яраттым, имеш. Яраткач, ияреп китәләр аны, декабрист хатыннары кебек. Менә алар ичмасам ирләрен яратканнар. Себер кадәр Себергә ияреп киткәннәр.

Хатын тастымал белән битен каплады.

— Кайгырма, — диде аннан ир. — Өлешен алыр да китәр. Өч ел буена ялгыз яшәмәгәндер әле. Менә күрерсең, үзе белән берәр юка сыйракны ияртеп кайтыр. Өй бәясен бирербез дә озатырбыз. Җитәр, юкка балавыз сыкма. Мин тимерчедә булам. Кояш баемыйча кайта алмам. Җитәр дим, — ир хатынның иңбашына авыр кулын салды. — Тиздән

укытуларың башлана, шул мунчаны сылап куйсаң икән. Балчыгын бастым инде мин аның, абзар түрендә түль каплап куйдым...

Ир чыгып киткәч, хатын бер ара исенә килә алмый торды, аннары түр якка керде дә диванга барып капланды.

— Ярулла,— диде хатын үртәлеп һәм ачыргаланып, гүя беренче ире күрше бүлмәдә генә утыра иде. — Ярулла, нишләвең бу синең? Нигә алай бер кайтып, бер китеп минем җанымны кыйныйсың!..

...Ярулла хыялый кеше иде. Барысы да исендә Хәнифәнең, барысы да хәтерендә. Мактанырга ярата иде. Педагогия училищесын тәмамлагач та өйләнештеләр. Хәнифәләрнең авылларына эшкә кайтырга рөхсәт алгач, табигатенә хас хыялга бирелеп киткән иде яшь ир. «Үги әтиең белән җан әниең Чаллыдалар, шунда тора бирсеннәр, бабаң тиздән дөнья куячак, без бабаң йортында төп хуҗалар булып калачакбыз. Пар күгәрченнәрдәй гомер итәрбез, Хәнифәкәй. Үбеп кенә уятырмын үзеңне, һәр көн эшеңнән каршы барып алырмын. Үрнәк гаилә булып яшәрбез».

Тик авылга кайтып бер ел да эшләмәде Ярулла, шәһәргә китү ягын каера башлады. Әле анысы, әле монысы ошамый аңа, әле анысы, әле монысы кыерсыта аны. Балалар белән дә рәтләп эшли алмады, җай табып, район үзәгенә инспектор булып күчте. Атна-ун көнгә бер кайтыр иде дә, Хәнифәгә киләчәк тормышлары турында сайрар иде.

«Бер дә кайгырма, Хәнифәкәй, РОНО мөдире квартира ышандыра. Бер елданмы, ике елданмы булыр, ди. Әлегә Ярулланң тулай торакта ята, кыен, әлбәттә», — дип юмалар иде Ярулла әллә ире кайтуына, әллә матур итеп сөйләп тә, матур итеп яши белмәгән иренә үпкәсе чыккан хатынын.

Җилкуар, мактанчык, күзгә кибәк сибәргә яратучы булса да, Хәнифә ирен һәрчак зарыгып көтеп алды. Ярулла үтереп төчеләнә белә иде. Нурислам исә Яруллага бөтенләй капма-каршы булып чыкты. Аз сөйләр, күп эшләр, назлау-сөю дигән нәрсәне белмәс, һичкайчан төчеләнмәс, комплиментлар әйтмәс. Ярулла исә Хәнифә үзенә көлмәк тектереп кисә дә, хатынына өч көн буена сокланыр иде.

«Күр әле берәүне, хан кызымы, көлмәгенең килешүләрен кара үзенә. Төсен кара, төсен, күз явын ала, чын-чын»...

Ярулла, Ярулла...

Бар нәрсәгә дә бик теләп тотынып, һичкайчан очына чыга алмаган Ярулла РОНОда да озак эшли алмады.

Истәлекле уйларга бирелеп, Хәнифә бик озак диванда ятты. Ята-ята тынычлана төште. Түр тәрәзәдән диван башына кояш нуры төшә, Хәнифәнең битен иркәли. Хәнифә әкрен генә күтәрелде дә ишегалдына чыкты. Көн кичкә авышып килә. Офык читендә үтә күренердәй сыек болытлар күренә, көн эссесе сүрелмәгәнгәме, бераз бөркүрәк. Абзар янында тавыклар чүпләнә, Нурислам бодай сибеп киткән, күрәсең, кайберсе, чүпләнеп туйган да, куначага менәргә әзләнә. Тавык көне — ярты көн, әтәч көне — бер тәүлек, ди Нурислам. Үзе дә ул таң белән уяна, кояш чыгар-чыкмас эшкә китә. Шулай өйрәнгән, шулай гадәтләнгән. Ярулла битенә кояш төшкәнче йоклый торган иде, җитмәсә уянгач та иренчәкләнеп, иркәләнеп ятыр иде. Ул гынамы, Хәнифәнең эшен калдырып, үз янына чакырып алыр иде дә: «Үбеп уят әле, Хәнифәкәй, мин юри күзләрем йомып, йоклаган булып ятам», — дип, әллә ниткән юк-барны уйлап табар иде. Хәнифә аңа ачуланыр иде дә, ачуланмас та иде, ачуланган хәлдә дә йөрәктән түгел, болай гына, юри генә. Чынында исә иренең шул сүзләреннән гелән җаннары эреп китәр иде.

Кояш баешка таба киткәч кенә Хәнифә мунча сыларга кереште. Ул ашыкты, Нурислам кайтып кергәнче эшләп бетерә алмам дип курыкты...

Эш беткәч, Хәнифә кул-аякларында арганлык тоеп, шәфәкъ нуры кабынып-кабынып киткән офык читенә карап торды, офыктагы болытлар болында утлап йөрүче ат көтүенә охшап калды. Бабасы гомер буена

атлар карады, Хәнифә белә-белгәннән колхозда конюх булып эшләде. Бер тапкыр бабасы болыннан, онығына күрсәтергә дип, яп-яшь кенә тай күтәреп алып кайтты. Әй куанган да иде соң тайны күргәч Хәнифә. Гүя тайны бабасы аңа бөтенләйгә алып кайткан иде.

«Бабакай, бабакай, миңамы, миңамы?»

«Анасы бирерме соң? Бирсә — сиңа», — диде бабасы. Шунда гына күрде Хәнифә бабасы артында томыраеп таена карап торган кола бияне. Атның күзләрендә кичке шәфәкъ нурлары биешә иде. Күрде дә Хәнифә кола бияне, шундук төшенде: беркемгә дә бирмәячәк бия колынын, ул аныкы, тик аныкы гына.

«Җаны булган җанның аңы бар, аңы булган җанның саны бар, балам. Бирик әнисенә, кинәнсеннәр икәүләп»,— диде бабасы.

Колынны җиргә бастырды бабасы. Хәнифә аның колакларыннан сыйпады, ак төшкән маңгаена кагылды, йомшак иреннәренә бармагын каптырып карады. Аннары колынның муеныннан кочаклады да тынып калды.

«Ул йомшак, матур, бабакай, бирмим әнисенә, калсын минем белән».

«Ярамый, балам, кара, әнисе ничек ачулы...»

Чынлап та кола бия күзләреннән утлар чәчә, тыенкы гына кешникешни таен чакыра иде.

«Җибәрик инде, кызым, карыны да ачкандыр, имсен бераз»,— диде бабасы.

Шулай диде дә бабасы, тайны җибәреп, онығын кулына күтәреп алды. Бабасы кочагыннан яшь колын исе килә иде. Ә тай әпен-төпен атлап әнкәсенә таба китте, һич ялгышмыйча имчәкләрне тапты, тәмләп имә башлады, колынның ирен читләреннән күбекләнеп сөт тамды.

Бабасы белән тайны күз алдына китерүгә, Хәнифә Нурисламны исенә төшерде. Икенче ире һәммә нәрсәне үзе эшләде, малны да үзе тапты, өй-каралтыны да үзе салды, шуңа мал кадерен белә, юк-барга акча туздырмый, мәгәр кешедән оялырдай итеп саранланмый да иде. Әлбәттә, Хәнифә икенче ирен Яруллланы яраткан кебек һичкайчан ярата алмады. Ул аңа гадәтләнеп, өйрәнеп кенә бара иде әле. Алай да соңгы вакытта Нурислам озаграк кайтмый торса, хатында ирне юксыну, борчылу, хафалану галәмәте була башлады. Ярулладан килгән хат исенә төшеп, хатирә-уйларга бирелеп утыра-утыра: «Тиле баш, ни кирәк инде тагын сиңа, нидер өмет итәсең. Нурисламың җитмәгәнме, кеше янында — кеше, ир янында — ир дигәндәй», — дип, үз-үзен тиргәп алды Хәнифә.

Шул вакыт Нурислам кайтты, хатынның мунча кырында дөньясын онытып утыруын күрде дә, бер сүз дәшмәстән өйгә кереп китте.

Хәнифә кергәндә ир бәрәңге әрчи иде инде.

Нурислам дәшмәде, бәрәңгене плитага куйды да, киемен алыштырып, телевизор карарга утырды.

Аш-су хәзерләгән арада, түр якка кергә-чыга йөргән Хәнифә иренә карап-карап алды. Кара чәчле ире, ап-ак күлмәк киеп утыргач, чибәрләнеп киткән иде. Хәнифәнең аны килеп кочасы, хатын-кыздан гомер ишетмәгән тәмле-татлы сүзләр әйтәсе, кара чәчләреннән үбәсе килеп китте. Әмма шундук шиккә калды, гомер бакыена андый сүзләрне ишетмәгән Нурислам моны аңлармы? Аңлар, нигә аңламасын ди. Хатын-кыз сөйгәндә ир-ат түгел, бала-чага да куана ул. Хәнифәнең тәмам күңеле нечкәрде. «Җүләр дә соң бу хатын-кыз, билләһи. Ни җитмәгән сиңа? Нурисламга ни булган! Кулыннан килмәгән эше юк. Хәнифәм дип кенә тора. Юк, соңгысын әйткәне юк. Хәнифәм дип нечкәртә белмәде, хәерле булсын. Нигә әле Нурислам турында кинәт кенә шулай начар уйлады? Ярулладан хат алгангамы? Алса соң?! Юк, юк, Нурислам әйбәт ир, Хәнифә аны беркемгә дә алыштырмаячак... Хәтта Яруллага да...»

Сөйләшми-нитми генә ашап-эчүләре булды, капка каршына машина

килеп туктады. Ир белән хатын күзгә-күз карашып алдылар. Хәнифәнең йөзе агарынып китте. Моны күргән Нурислам нәрсәдер әйтергә дип авызын ачты, әмма икенче мәлдә, нидер уйлапмы, әкрен генә күтәрелде һәм, җилкәсенә пинжәген салып, ишеккә юнәлде. Хәнифә бер мәлгә исенә килә алмый торды. Аннары кинәт урыныннан купты да, йөгереп ишегалдына чыкты, кайнарланып типкән йөрәген тыя алмаудан гаҗиз булып, капкага таба китте. Шунда аның колагына Ярулланың зәгыйфь тавышы ишетелде. Шул вакыт Нурислам, инвалидлар коляскасын тәгәрәтеп, ишегалдына алып кереп китте. Хәнифә аңа иярде. Коляскада ап-ак чырайлы (ут яктысында аның йөзе бигрәк ак күренде) Ярулла утыра иде. Уң кулын тасма белән муенына аскан, бер аягы юк, икенче аягы да бинтта, тик сул кулы гына җиңелчә, калтыранып, инвалид арбасының тәгәрмәч өстендә ята иде.

— Ярулла!..

— Хәнифә! Мин бу, Ярулла. Танымадыңмыни?!

Инвалидның тавышы калтырап китте. Хәнифә арбага таба атлады, әмма килеп җитәр-җитмәс туктап калды. Өй кыегына аскан электр утыннан көндезгедәй яктылык коела, Ярулла аскы иренен чәйни, ни сәбәпледер башын чайкый.

— Ярулла! Ни булды сиңа, Ярулла! Нишләттеләр үзеңне?!

— Сорашма, Хәнифә, бәлагә тардым миң. Соңыннан. — Инвалид иңбашына пинжәген салып, әле бер кәлимә дә сүз әйтмәгән Нурисламга ымлады.— Бу кем? Телсезме әллә, әпә-фәләнме?

— Ирем ул минем, Ярулла. Ирем...

— Ирең?! Син кияүгә чыктың, Хәнифә?!

— Әйе, Ярулла.

— Минем белән аерылышмыйчамы?

— Бер түбә астында яшәп тә, ике дөньяда яшәгән кешеләр бар, Ярулла.

— Белмәгән идем.— Ул Нурислам ягына таба башын борды.— Ә синең исемең ничек?

— Өйгә керик, — диде Нурислам, аның соравын колак яныннан уздырып.

Алар янына шофер килде.

— Ну, Ярулла туган, каласыңмы? — дип сорады машина йөртүче.

— Кала, — диде Ярулла өчен Нурислам һәм күптән хәл ителгәнгә санап, арбаны өйгә таба тәгәрәтте.

Ярулла дәшмәде, башын түбән иде, Хәнифә хиссез һәм чарасыз калып аларга иярде.

Нурислам Ярулланы түр якка күтәреп алып керде, сак кына йомшак креслога утыртты. Аннан борылды да, танымастай булып үзгәргән ир-атка таңнар калып карап торган хатынына:

— Хәнифә, ашың калган иде бугай, җылытып керт әле, аннары бергәләп чәй эчәрбез, — диде.

Хәнифә башта Нурислам әйткән сүзне төшенә алмый торды, төшенгәч, кинәт купты да кухня ягына чыгып китте. Күп тә үтмәде, хатын тарелка белән аш кертте, савыт белән ипи китерде һәм, кулын кушырып, Ярулланың ашаганын күзәтә башлады. Ул аңа дәшәргә курыкты, җепкә генә тагып куйган йөрәге өзелеп, идәнгә төшеп китәр, пыяла савыттай чәлпәрәмә килеп ватылыр сыман иде. Сөйләшмәделәр. Нурислам белән икәүләп чәй өстәле хәзерләделәр. Нурислам Ярулланың креслосын өстәл янынарак күчерде.

Шулай ук тын гына чәй эчтеләр, тарелка-чәшкәләрне җыештырганда Хәнифә үзендә Ярулланың карашын тойды, бу караш аның кулларын богаулады, чарасыз итте. Нурислам Ярулланың креслосын читкәрәк күчерде дә үзе диванга утырды, Хәнифәне дәшеп алды.

— Җитәр, авызыбызга су кабып утырмыйк. Ике уйлау — бер кисү,

сөйләшик. Ярулла баҗай, бәлки, синең әйтер сүзең бардыр? — диде Нурислам.

Ярулла Нурислам ягына күз төшереп алды. Хәнифәгә карады һәм бүлмәне күзәтеп чыкты.

— Тиздән миңа протез ясаячаклар. Мин сулагай кеше, сул кулым исән, анысы ярап куйды, — дип шаяртты Ярулла. — Уң кулым да мәнә төзәлеп килә...

Хәнифә башын иде, итәгендәге кулына тып-тып яшь бөртекләре тамды. Ирләрнең икесе дә, шул яшь бөртекләрен санаган шикелле, телсез калдылар. Хатын үзенчә уйланды: «Мескенкәем, исән җире калмаган, ә үзе һаман шаярта».

— Кая болай тападылар үзеңне, баҗай?

Хәнифә дә яшь тулы мөлдерәмә күзләрен күтәрде, Яруллага төбәлде, ул да нәкъ шул сорауны бирергә кыймый тора иде бугай.

— Әйе, — диде хатын, тавышы калтырап китте.

— Шахтада коткаручылар командасында эшләгән идем. Берәүләрне коткарырга төшкәч, үземне таш басты. Ничава, бер аяк ярыйсы, куллар да төзәләчәк, илдә чыпчык үлми.

— Син алай әтәчләнмә әле, баҗай. Хәлең күрәбез, сукыр түгелбез, — диде Нурислам. — Ары ничек яшәргә исәбең? Агай-энең, этиеңәниең бармы дигәндәй?..

— Беркемем дә юк минем. Әнә бер Хәнифәм бар иде, ул да...

Нурислам Яруллаң соңгы сүзләрен дә ишетмәгәнгә сабышты.

— Димәк, баҗай, адәм рәтенә кергәнче бездә торып торасың булып чыга. Өй зур, түр якта яшәрсең. Ашау-эчү ягына кайгырма, Хәнифә барысын да җайлар, — диде Нурислам, эш кешесенә хас җитдилек белән.

Ярулла белән Хәнифә икесе дә сөйләшкәндәй күзгә-күз карашып алдылар. Хатын да, инвалид ир дә тәмам аптыраушта калганнар иде.

— Син, баҗай, үз өеңдә, — дип дәвам итте Нурислам. — Без синдә фатир торабыз. Телисең икән китә алабыз. Авыл шәһәр түгел, торыр урын табылыр. Колхоз яңа өйләр бетереп ята. Ләкин мин сиңа сәламәтләнгәнче ашыкмаска кушар идем. Хәнифә барысын да җайлар...

Ярулла елмаерга тырышты, булдыра алмады, ияге калтырап китте, башын каккалап утырды. Хәнифә куллары белән битен каплап елап җибәрде. Яруллаңың йөрәге бүлк-бүлк итте, ни әйтергә, ни кылырга белми тәмам тынсыз калды. Тик торганда изгелек эшләүче кешеләрне күргәне бар иде Яруллаңың, аларга сәерсенгән, аптырап калган чаклары да аз булмады, ни дип изгелек эшли бу адәм баласы аңа? Ни ява аңа моңардан? Ярулла үзе кешегә изгелек эшләүнең ни икәнен белмәде, аңа калса һәркем үзе өчен үзе тырышырга тиеш иде. Артык изгелек эшләү кешене боза, бүтәннәргә салына башлый адәм баласы. Тапкан малның кадерен белми, тиз туздыра. Бу хәл исә кешене акыл тотрыклыгына, гамьсезлеккә, битарафлыкка китерә. Тиктомалга изгелек эшләгән кешеләргә Ярулла гомер буе ачулы булды. Больницада ятып чыккач, ул, гомумән, бөтен дөньяга ачулы иде. Монда әйләнеп кайтуы да, йорттан өлеш алу өчен түгел, Хәнифәнең мәхәббәт җылысын тоймаммы, мине аңлаганн, мине аңлардай бердәнбер кеше ул гына, дип уйлаудан иде. Ә монда, авыл картларыдай акыл сатып, киң җилкәле, типсә тимер өзәрдәй сау-сәламәт кеше утыра. Җитмәсә баҗай дип болай да ярсу вә әрнүле йөрәккә ут өстенә ут өсти. Кияүгә чыкмаган булса, Хәнифә аны шушы хәлендә дә кабул иткән булыр иде, бәлкем. Нурислам каткат: «Бирегә калырсың, Хәнифә барысын да җайлар», дигәч, күңел түреннән күпереп чыккан тиле ярсуын көч-хәл белән тыеп калды инвалид ир. Нишләсен соң, аягүрә басып изүенә барып ябыша алса икән. Юк бит, хәленнән килми. Ул хәзер яралылар арбасына әсир төшкән бер мескен. Кайтканчырак Хәнифәнең кияүдә икәнен белгән булса, бер хәл иде әле, бәлкем Себер ягында бөтенләй дә калган булыр иде. Белмәде

бит, белмәде. Хәзер инде соң, хәзер инде Нурислам бажасы ни әйтсә, шуның белән килешәсе кала.

Ярулланың, гомерендә беренче тапкыр дияргә була, әрнеп күңеле сызланды. Ул дәшмәде, башын түбән иеп утыра бирде.

— Хәнифә, диван-караватны менә монда, түр тәрәзә янынарак күчерермен, бажай шунда йоклар. Соңыннан күз күрер. Ни, Ярулла туган, син бажай дигәнгә ачулана күрмә тагын. Безнең Чаганлыда күрше ире белән күрше хатыны туктап сөйләшсәләр дә бажай диләр. Без синең белән кәк-никәк законный бажайлар.

Бу юлы да Ярулла дәшмәде, Хәнифә исә тәмам аптырашта калды. Нәрсә инде, инвалид кешедән шулай көлүеме, чын-чынлап изгелек эшләргә теләвеме бу Нурисламның? Ләкин ирнең күзләренә туры каравы булды, тәмам иманды: мыскыл итми иде Нурислам кунагын, чын күңеленнән әйтүе иде. Хәнифәнең акрын гына эчке дөньясы киңәя башлады, гүяки Рә тавы артыннан кояш чыгып килә дә һәр караңгы почмакны яктырта бара. Хатынның йөзе ачылып китүен күреп, Ярулла да Хәнифә ягына күз сирпеп алды. Һәм нигәдер сагая калды. Бажай сүзен ишетүгә, инвалид ирнең башта ук йөрәге кысылып куйган иде, сүзнең мәгънәсенә төшенергә теләде, җавапны Хәнифәдән көтте, әмма хатын йөзендә нурлар балкып килүен күргәч, аңа тагын да авырсу булып китте.

— Телевизор карарга да уңайрак булыр, — дип сөйләнде диван-караватны күчереп куя-куя Нурислам.

Хәнифә дә кузгалды, Яруллага урын хәстәрләргә керешге. Ярулла аның һәр хәрәкәтен дикъкать белән күзәтеп торды. Гәүдәгә тулышыбрак, юанаебрак киткән Хәнифә, күзләрендәге нурлар гына тәүгечә калган. Җете кара чәчен малайларча кыска итеп кистергән, килешеп тора тагын үзенә, колагында энҗеле алтын алкалар. Инвалид ир карашын хатынның гәүдәсе буйлап аскарак төшерде. Кайчандыр ул шушы хатынның кочагында яткан иде, хәзер исә гүя ят бер кешене күзәтә. Яшьлектәге гөнаһларны онытытыра торган шифа булса икән, Яруллага тәүге сәламәтлеге әйләнеп кайтса икән, ни әйтер, ни кылыр иде икән шунда бу изге хатын? Иргә чыккан булса да тыелып кала алмас иде, һәрчак шат, җор телле Яруллага ияреп китәр иде. Ә хәзер...•

Мәхәббәтне корал итеп сайлауга Ярулла җаны-тәне белән каршы иде. Әмма күңел дигәнең Хәнифәдән нидер өмет итә, һич югы, хатынның кызгануын тели шикелле. Инвалид ир бер мәлгә тәмам чарасыз калды. Ләкин өметен өзмәде. Ул хатынның күзләреннән ук күрде. Хәнифә аны онытмаган, кияүгә чыкмаган булса, ул аны хәтта шушы хәлендә дә кабул итәчәк иде. Мәхәббәт кисәкләргә бүлгәләнми, ул сине бөтен көйгә генә ярата, аның үз бизмәне, үз чамасы, үз сиземләве бар.

Хәтере таркау чагы иде, уйларының очын-очка бәйли алмады Ярулла, җитмәсә, машинада озак селкенүдәнме, төзәлеп бетмәгән кул-аягы сызлый башлады.

Ярулланың чырае үзгәрүен күреп, Нурислам Хәнифәгә су җылытырга кушты. Су кайнарлангач, ул ләгән алды да бернечә бөртек марганцовка салып болгатты һәм Ярулланың аягын юарга булды. Марляны ул гаҗәеп оста итеп сүтеп алды, әйбәтләп бөтереп куйды, шуннан соң гына яралы аякны сак кына юарга керешге. Моңа кадәр ни әитергә, ни уйларга да белмәгән Ярулла әллә җөйләнеп бетмәгән ярасы авыртудан, әллә йөрәге әрнүдән йөзен чытты, иреннәрен чәйнәде. Ярулланың болай да иреннәрендә теш эзләре ярылып ята иде, нык тешләүдән аскы иреленнән кан тибеп чыкты. Хәнифә инвалид ирне кызганудан йөзен читкә борды, күзләрен йомды.

Яраны әйбәтләп югач, марля белән аяк-кулны яңадан бәйләде дә Яруллага карады йортка кергән ир.

— Бераз җиңеләйдеме?

— Кая болай яра бәйләргә өйрәндең?

— Чик буенда хезмәт иткәм идем. Этләр духтыры булырга туры килде. Мескенкәйләр, чын духтырларны тешләштергәлиләр, ә миңа ырлап та карамыйлар иде, — диде Нурислам мактана төшеп.

Янә һични аңламады Ярулла. Әллә шаярта иде Нурислам, әллә чынчынлап әйтә иде. «Эт духтыры булып хезмәт иткән, имеш. Иткән булса бер хәл, хезмәт итмичә ялганласа? Мине эт белән тиңләвеме шулай? Бая бажай, әле эт», — дип ярсынып уйланды Ярулла.

Ни генә булмасын, соңгы мәлдә Яруллaның Нурислам турында начар уйлыйсы килмәде. Инвалид ир үз хәлен үзе бик әйбәт белә иде, аяксыз-кулсыз кеше кая барсын да, ни кылсын?.. Ир түгел ул хәзер, алладан да, бәндәдән дә каргалган бер мескен.

Ярулла иртән уянганда Нурислам эшкә киткән иде инде. Инвалид ир түшәмгә карап бик озак уйланып ятты. Больницада ятканда кай вакытны аңа, аеруча ниндидер укол салгач, кул-аяклары исәндер, торып, йөреп кенә китәсе бар кебек тоела иде. Бүген дә ул үзен шундыйрак бер хәлдә тойды. Йокы туйган, «чукмарбашлар» да (ул үзенең киселгән аяк-кулын шулай дип атый иде) сызламый. Алгы якта Хәнифә йөренә, Ярулла аның адымнарын мең кеше арасыннан танып алыр иде, Хәнифә аны йоклый дип уйлый булса кирәк, сак кына басып йөри. Ярулла түшәмгә игътибар итте. Хуҗа түшәм такталарын шул хәтле тыгыз һәм тигез итеп тезгән, сокланырлык иде оста эшенә. «Үзе эшләдеме икән?» — Ярулла балта тотып йөргән кеше түгел, гомумән, балта белән эшләү түгел, рәтләп утын да яра белмәде. Шахтага коткаручы булып керүе дә рәтле һөнәре булмаудан иде.

— Хәнифә! — дип дәште Ярулла, ләкин тавышы чыкмады, диван астына төшеп югалды.

Яман төш күреп уянып киткәндәй Яруллaның йөрәге кысылып куйды. Күңеле белән гел исән-сау кеше кебек фикер йөртә икән бит ул. Ә баксаң ул гарип-гораба, хәле мөшкел икән. Ярулла кинәт өшеп китте. Ул мескен кеше. Аны хәтта Хәнифә дә кабул итмәде. Күрде, сизде, тойды бит ул, хатын аны күрү белән кызганды, тик кызганды гына. Ә хатын-кыз кызганса, ул беркайчан да сине тәүгечә яратмаячак. Шушы кызганудан качып бирегә кайтты түгелме соң ул. Бар иде бит аның Себердә йөргән, вәгъдәләшкән кызы. Яруллaның хәле арулана башлагач, ул кыз (Нәҗия атлы иде) больницага килде. Палатага килеп керүе һәм кул-аяксыз килеш креслода утырган Яруллaны күрүе булды, тәмам төсе агарынып китте. Әмма үзенең куркуын җиңеп, Ярулла янына узды, елап утырды, ә кыланышы, үз-үзен тотышында элеккеге сафлык, самимилек юк иде инде. Ярулла моны күңеле белән сизде. Нәҗия аңа хәтта:

«Мин сине, Ярулла, шушы хәлеңдә дә...» — дип инвалид егет өчен иң кадерле сүзне дә әйтмәкче булган иде, әмма Ярулла аны тиз туктатты.

«Кирәкми, Нәҗия. Беләм бит мин сине, икейөзлеләнмә. Бәхетле бул. Үтенәм синнән, моннан ары минем янга килеп йөрмә. Мин өйләнгән кеше (моңа кадәр Нәҗиягә хатыным бар дип әйткәне юк иде), хатыным бар минем. Больницадан чыгуга, мин аның янына кайтып китәм...»

Хатирәләргә бирелеп, уйланып ятканда түр бүлмәгә Хәнифә килеп керде. Хатын биленә алъяпкыч бәйләгән, янбашлары тагын да калкуланыбрак киткән, мич каршында маташкангамы, бит очлары алсуланган. Йөзендә тыенкы елмаю, күзләрендә һаман шул инвалид ирне кызгану.

— Хәерле иртә! Йоклап булдымы?

— Иртә хәерле кебек, — диде, көттерә төшеп Ярулла. — Юынасы иде башта, Хәнифә.

Әйе шул, Хәнифә бөтенләй онытып җибәргән икән бит, инвалид ич ул, гарип кеше. Хатынның күзләрендәге кызгану әүвәл күз төпләренә, иреннәренә, аннары чыраена күчте.

«Кызгана, — дип ярсынды Ярулла. — Үзе ярата, үзе кызгана».

— Чемоданда теш пастам, щеткам, сөлгем бар иде.

— Чемодан! Нинди чемодан? Юк иде чемодан,— дип гаҗәпләнде Хәнифә. — Машинада китте микәнни?

— Киткән, димәк, — дип башын иде Ярулла. Чынында исә бернинди чемоданы да, әйбер-мазары да юк иде аның.

— Кайгырма, — диде хатын, нидер аңлап. — Безнең щетка бар, пастасы да табылыр.

«Безнең — дип үртәлде Ярулла.— Безнең. Шулай ук Нурисламны яратуы микәнни?»

Юындыргач, Хәнифә аңа коймак кертте, чәй ясап бирде. Коймак ашаганда янә Ярулланың йөрәге кысылып куйды. Түр якка керә-чыга йөргән Хәнифә аз сөйләште, инвалид ирнең күзләренә туры карамаска тырышты.

Чәй эчкәч, инвалид ир яңадан диванга ятты, сыңар кулын баш өстенә куеп, түшәмгә текәлде. Түшәм тактасында аңа бөтен бер дөнья күренде. Ботак эзләре, ел саен эз сала-сала үскән агач гүя аның гомере иде. Туры сызыклардан мәхрүм ителгән бормалы-сырмалы сурәтләр. Әйе, Ярулланың гомер юлы тигез булмады. Нигәдер тотрыклы гына эшләп китә алмады. Эзләнде, бер эштән икенче эшкә күчте, шәһәрдән шәһәргә чапты. Чәчкәдән чәчкәгә кунып йөргән күбәләк инде менә. Хәнифә, аннары Нәҗия. Инде хәзер берсе дә юк. Нәҗия, Нәҗия инде, аның белән ул егет булып кына йөрде, ә менә нинди Хәнифәне югалтты бит! Нинди хатынны! Үзе дә тыймады инде бераз Ярулланы. Дөрес икән, ирне адәм иткән дә, әрәм иткән дә хатын.

Ул арада бүлмәгә Хәнифә килеп керде. Хатынның өстендә зәңгәрсу күлмәк, иреннәрендә куе помада, кашларына сөрмә тарткан, юан да, чандыр да булмаган балтырларын тән төсендәге капрон оек кысып алган. Укыганда гына түгел, педучилищены тәмамлап бергәләп авылга кайткач та, чит-ят хатыннарга күзе төшкәндә дә Ярулла аларны Хәнифә белән чагыштырыр иде. Табигать бу хатынга гәүдә нәфислеген дөньядагы бөтен хатын-кыздан берәмтекләп, аз-азлап кына җыеп биргән, күрәмсең. Озын да, кыска да булмаган муен, нечкә бил, күпереп торган нрләр кызыктырырлык янбашлар, оста юнып ясагандай аяклар, төз, нәфис гәүдә. Тик менә йөзне генә чамадан уздырган: җәлпәк яңаклар, җәенке борын, кирәгеннән зуррак авыз, калын иреннәр.

— Ярулла, мин мәктәпкә барып кайтам, чыгасың килсә, горшок менә монда, аяк очында.

Шулай диюгә, колакларына хәтле кызарды Хәнифә.

— Рәхмәт. Җаен табармын, — диде Ярулла һәм ишеккә таба китә башлаган хатынга ымсынып карады. — Хәнифә?

— Әй, онытканмын икән бит, кырынасың килсә, машинка менә монда, аяк очындагы тумбочкада, — Хәнифә борылды да ир янына килде, йомшак кына итеп ирнең яңагына кагылды. Хатынның кулыннан кыйммәтле француз хушбуе исе бөркелде.

— Рәхмәт инде, Хәнифә, — ир-ат хатынның кулыннан тотты.

— Бик сусасаң, графинга чәй ясап куйдым. Тиз кайта алмам. Быел минем классымда кырык ике бала укый. Искитмәле хәл. Хәтереңдәме, син укыта башлаган елны синең класста нибарысы унҗиде бала иде.

— Мин аларның берсен дә хәтерләмим. Укытучы түгел идем мин, Хәнифә.

— Укытучы да идең син, Ярулла, коткаручы да идең. Эшкә теләгең булмады синең. Үз-үзеңне эзләдеңме, эзләндеңме, белмим. Кулыңнан эш килмәде. Теләгән эшне тапмадыңмы. Әйт әле, хак әйттемме?

— Хак әйтәсең, Хәнифә. Мин бик күп нәрсәне күрми-белми йөргәнмен икән. Бер тапкыр миңа дөнья күргән бер хатын: яраткан хатыннан

яратасыңмы дип сорамыйлар, дигән иде. Сорарга ярамаса да, Хәнифә, сорыйм әле: яратасыңмы син аны?...

Ярулла үз соравыннан үзе курка калды. Кайтуына икенче көн дигәндә шул сорауны бирү ахмаклык булып тоелды аңа. Ләкин соң иде инде, сорау бирелгән иде.

— Ярулла,— диде хатын, әллә рәнжеп, әллә үртәлеп.— Ярулла, кирәкмәс иде алай...

Шулай диде дә, хатын эшенә китте.

Ярулла уйга калды. Гаҗәп хәл. Беренче курста укыганда бар студент та бер төсле була, әйтерсең бер тавык астыннан чыккан чебиләр. Һәрхәлдә, Яруллага шулай тоелган иде. Әмма беренче семестр үткәч алар бер-берсеннән аерыла башлыйлар. Кемдер бик җиңел укый, җиңел генә имтиханнарны бирә, икенчесе исә шаян, һәрвакыт шат, өчле алса да исе китми. Кайберәве икеле алса җаны кыйналып кайгыра, гүя ул билге аның өчен шәхси трагедия. Бер ишләре бер нәрсәгә дә шаккатмый, гүя бу дөньяга мәңгелеккә килгән.

Ярулла группада барысыннан да аерылыбрак торды. Җитез, хәрәкәтчән, мәзәкләр сөйләргә ярата, җитмәсә, рәссам ук димәсәң дә стена газетасына рәсемнәр төшерүче булып китте. Берәүгә дә сер түгел, тыйнаграк, оялчанрак, яңа гына авылдан шәһәргә аяк баскан кызлар нәкъ менә шундый егетләргә елышырга тырыша. Алар, әлбәттә, нинди дә булса олы мәхәббәт дәгъваламыйлар, шулай да шәһәрчәрәк киенергә, шәһәрчәрәк чәчләрен кистерә, шәһәр кызлары кебек йөрергә дә өйрәнә башлыйлар. Иң гаҗәбе шул, бу өлкәдә алар кайчак шәһәрдә туып-үскән кызлардан да арттырыбрак җибәрәләр. Кеше үзенә җитмәгән активлыкны һәрчак башка берәүдән эзли. Хәнифә дә бер мәлне Ярулла янына килеп:

«Ярул, син миңа ошыйсың, әйдә йөрибез», — диде. Нәкъ менә шулай әйтте: «Йөрибез», — диде. Бу хәл тәнәфес вакытында, коридорда булды. Башта Ярулла гаҗәпләнгәндәй итте, детдомда үскән егеткә бу сүз ул хәтле ят күренмәде, әмма бераз торгач, Ярулла шаркылдап көлеп җибәрде. Көлеп җибәрде, әмма кызның күзләрендә ут чаткылары күреп, сагайды. Әүвәл, яңа гына күргәндәй, кызны баштанаяк күздән кичерде. Авылдан алып килгән озын һәм калын чәч толымнарын кистергән, иреннәренә дә куе итеп помада сөрткән, күз төпләрен шәмәхәләндергән кыз аңа кулын суза иде. Нәкъ шулай аңлады аны Ярулла. Ул башта кызны шаярта дип уйлады һәм уенны бик тиз кабул итте.

«Кайчан башлыйбыз соң?» — диде.

Ярулла да Хәнифәгә кул сузганда, бу хәл йөреп китү һәм өйләнешүгә кадәр барып җитәр дип уйламаган иде. Ярулла моңа әле дә ышанып җитми. Әллә ничек булды да куйды шунда. Өйләнештеләр, аннары Хәнифәләр авылына эшкә кайттылар.

Ул вакытта Хәнифәнең Шәяхмәт бабасы да исән иде әле. Картка Ярулла беренче көннән үк ошамады. Сиксәнне җыеп бетереп, туксанынчыны ваклый башлаган карт, Ярулланың кем икәнен шундук аңлаган иде күрәсең. Һәм ул һич тартынмыйча бу турыда Ярулланың үзенә дә әйтте, Хәнифә алдында әйтте.

«Зимагурлыктан башың чыкмас синең, кияү балакай. Май чүлмәге тышыннан билгеле. Бер дә эшкә кулың ятмый», — диде. Нәкъ менә шулай: «Эшкә кулың ятмый»,— диде.

Хәнифә бабасында тәрбияләнде. Әнисе Шәяхмәт бабасының өеннән чыгып киткәндә Хәнифәгә биш яшь чамасы иде. Шуннан бирле Хәнифәнең әнисен күргәне юк, нигәдер күрәсе дә килми. Хәнифәнең әтисе, юаш бер авыл кешесе, Чаганлыдагы бер тол хатынга йортка керде, моңа кадәр тол яшәгән хатын, үч иткәндәй, аңа һәр елны бер бала табып торды. Хәнифәгә унҗиде яшь тулганда аның җиде сеңелесе, ике ир туганы бар иде инде. Әти кеше, Хәнифәләргә килә йөрсә дә, беренче

кызына ярдәм итә алмады. Тулысы белән Шәяхмәт бабасы кулында калган Хәнифә үзе дә мохтаҗлык тоймады. Шәяхмәт бабасы, әгәр дә мәгәр кайдадыр әҗәл даруы бар дисәләр, шул даруны да оныгына барып алырга әзер иде. Тик Хәнифә генә авылдан китмәсен, тик туксан яшькә кадәр кулыннан сәнәк-чалгы төшмәгән бабасын гына ташламасын. Ә Хәнифә исә китәргә дә уйламады, авылны ярата иде ул. Педучилищены тәмамлап авылга укытырга кайтуы да шуннан иде. Ярулланы авылда калдырырга тырышуы да авылны яратудан иде. Әмма нишләмәк кирәк, Ярулла моны аңламады. Әйе, хикмәтле кеше иде, мәрхүм. Ир-ат булса да сыер асрады, бик яшьли Хәнифәне сыер саварга өйрәтте. Бабасы кебек Хәнифәнең дә кулыннан килмәгән эше юк иде. Ә менә Ярулла Хәнифәгә бөтенләй капма-каршы кеше булып чыкты.

«Китәр ул синнән. Тиң түгел ул сиңа, балакай»,— дигән иде бабасы Ярулла турында. Әмма дөрес тә тойган икән картның күңеле...

*

* *

Ни сәбәпледер, Хәнифә эшкә чыгып китүкәч, Ярулла да Шәяхмәт картны исенә төшереп ятты. Хикмәтле карт иде соң үзе. Бер тапкыр шулай Яруллага багана чокыры казырга кушты бу. Үзе бер читкә барып утырды да кияүнең эшен күзәтә башлады. Ике көрәк тирәнлек итеп казыды да Ярулла чокырга баганәны утыртмакчы булды. Түзмәде карт, килде дә кияү кулыннан көрәкне тартып алды, ыңгырашыбрак булса да метрдан тирәнрәк чокыр казып ташлады. Ә үзе бертуктаусыз сөйләнде.

«Баганәны тирән утырт, кармакны тирәнгә сал, хатының яшьли кочып кал, ди торган иде мәрхүм әтәй. Карыйм-багам да, кияү балакай, кулыңа бер дә эш йокмый синең».

Ярулла елмаеп утыра бирде. Ни белә бу авыл карты. Дөньяда бит әле акыл эше дигән нәрсә бар.

«Һәй, бабай, анысын гына беләбез лә...»

«Хәнифәгә кайгы-хәсрәттән башка нәрсә китермәссең, ахрысы, син, кияү балакай. Җилдән килгән кешедәй сөйләшеп утырасың».

«Табигать кешене бер эш өчен генә яратмаган бит, бабай. Ни өчен элек: белеме бар — меңне егар, белеме юк — берне егар» дигәннәр? Хикмәтле әйткәннәр бит. Тиздән базларны да машина гына казыр. Баганасы да башка булыр. Тиздән барысын да роботлар эшләячәк».

«Робот дигәнең кем инде ул, нindirәк кеше?»

«Кеше үзе үк иҗат иткән автомат-эшче. Телисең — багана чокырын казый, телисең — күңелне ача, телисең — җырлый, бии, телисең — балаңны карый».

«Хикмәт. Кешеләр нишләр микән соң ул чакта?»

«Ял итәчәкләр, күңел ачачаклар».

«Кайчан булыр икән соң ул, кияү балакай?»

«Тиздән, тиздән, бабакай».

«Күке белән күбәләккә генә килешә эшләмичә күңел ачып яшәү, кияү. Адәм баласы үзен тапса хезмәттә таба, тапмаса аңа яшәү хокукы юк бу дөньяда. Китер баганәны, утыртыйк башта. Юкса кайчан килә әле синең ул роботың безнең авылга».

Шуннан соң ике-өч ай да үтмәде, Шәяхмәт карт дөнья куйды. Үлем түшәгенә яткач, карт үз янына Хәнифәне чакырып алды һәм булыр-булмас тавышы белән тотлыга-тотлыга нидер әйтте. Хәнифә аңа җавап бирмәде, башын гына чайкады. Картка, күрәсең, шул җавап та бик җиткән иде, кинәт иреннәре калтырап куйды һәм дәшмәс булды.

Шәяхмәт картның җидесен уздыргач, Ярулла шул хәлне искә төше-

реп, Хәнифәдән: «Нәрсә әйтте шул вакытта бабаң?» — дип сорады. Хәнифә аңа беравык карап торды да: «Берни дә әйтмәде», — диде.

Дәресләре беткәч, Хәнифә өйгә кайтты. Ярулла китап укып ята иде. Ярулла янына килде. Хатынның күзе-йөзе елмая, борын яфраклары агарынган, сөенче әйтергә җыенгандай шат иде. Әмма хатын инвалид иргә бер сүз дә әйтмәде. Килде дә йомшак кына Ярулланың күпереп торган чәченә кагылды, хискә бирелеп, башыннан сыйпады. Ярулла аның кулыннан тотып алды, хатынның кулына иреннәре белән кагылды, аннары әсир төшкән кулны яңагына кысты.

— Хәнифә, — диде ир, каушый калып. — Хәнифә, син мине онытмадың, онытмадың бит, әйеме?

— Белмим, Ярулла.

— Кызгануың гынамы әллә?..

— Кызганмаслыкмыни, Ярулла. Телмәсәнә бәгырьләремне!.. Ярата идем бит мин сине, үлепләр ярата идем?!

— Ә хәзер, хәзер, Хәнифә?

Хатынның күзләре зурайды, бер мәлгә ачкан авызын ябалмый торды.

— Кирәкми, Ярулла. Кискән ипи ябышмый. Кирәкми ул турыда, ярыймы? Ярыймы, Ярулла?

Хәнифә инвалид ирнең чәчләреннән үбеп алды.

— Миңа бер-ике айдан протез аяк китерәчәкләр.

— Ярый, Ярулла. Аш пешерим. Тиздән Нурислам кайтыр.

Кичке якта өйгә өч врач килеп керде. Ярулла протез ясау өчен аяк размерларын алдылар. Киткән чакта берсе, өлкәнрәге, Хәнифәнең терсәгеннән алды да алгы якка алып чыкты.

— Аның йөреп китүе бер сездән генә тора, зинһар мәрхәмәтле була күрегез, — диде.

— Миңа агач аяк кирәкми, — дип ярсынды Ярулла, врачлар чыгып киткәч.

— Ярулла,— дип ялварды Хәнифә.— Кеше кебек йөреп китәсең килсә — ризалаш. Йөрергә өйрәнергә кирәк сиңа. Сәламәтләнсәң, мәктәп китапханәсенә эшкә керергә мөмкинлек бар.

Ярулла дәшмәде, болай да чәйнәлгән, ярылып беткән иреннәрен тешләде дә тынып калды.

— Тиздән Нурислам кайтыр, аш салыйм, — дип, Хәнифә алгы якка чыгып китте. — Мунча ягып җибәргән идем, рәхәтләнеп мунча керерсез.

«Мине гел бала-чага итеп күрә башлады бу», — дип үртәлде Ярулла.

Ниһаять, эштән Нурислам кайтты. Мунча узганын белгәч, туп-туры түр якка үтте.

— Нәрсә, баҗай, бәлкем, башта мунча кереп кайтырбыз, каткан сөякләрне йомшартып, ә? — диде дә Ярулланы күтәреп тә алды. — Сыңар кулың белән булса да муеннан кочакла. Шулай.

Мунчага килгәч, Нурислам Ярулланы чишендерде, ләүкәгә менгезеп утыртты, ташка пар салды, инвалид ирнең кулына каен себеркесе тоттырды.

— Җилпенә тор. Арыгач үзем чабармын.

Гаҗәп хәл, Ярулла хуҗаның һәр сүзенә буйсынды, авыз ачып бер сүз әйтмәде. Аякларны каен себеркесе белән чабуы рәхәт иде. Себеркесе кагылган саен тән тәмле итеп кытыкланып китә, кытыкланган саен катырак итеп чабасы килә. Соңга таба Ярулла кызып ук китте, рәхәттән ни кылырга белми уларга тотынды.

— Тизрәк сихәтләним дисәң, ныграк селтән, баҗай. Мунча яратасың икән үзең. Хәнифә ике көнгә бер ягып кертәчәк безне хәзер. Протез кайтып, үзең йөри башлагач, мунча кадерен тагын да белә төшәр-

сеҥ әле,— дип сөйләнде Нурислам. Ярулланың кулыннан себеркене алып, ир-егетнең аркасын, янбашларын чапты. Аннары салкынчарак су көйләп коендырды да алгы якка күтәреп алып чыкты.

— Син бераз хәл ала тор, мин хәзер.

Ярулла Нурисламга бераз өркебрәк карый иде. Ул аны аңламады. Хәер, аңлаганы да бик җиткән иде: йортка кергән ир Хәнифәне аннан ким яратмый, бәлкем, әле ныграк та яратадыр.

Нурислам аны мунчадан тунга төреп алып кайтты. Диванга китереп салгач, күлмәк-ыштан кидерде, аркасына мендәр куйды һәм өстәлне диван кырынарак тартып китерде.

— Чәй эчәбез хәзер, ирләр, — дип килеп керде Хәнифә.

— Хәнифә, син безгә теге шайтан суын да бир әле. Тәннәр йомшармасмы бераз...

Хәнифә өстәлгә чәй хәстәрләде, ике рюмка, бер шешә китереп куйды.

— Ә үзеңә? — диде Ярулла?

— Ул эчми, — диде хатын өчен Нурислам.

— Ярулла, сиңа да ярамас иде, — диде Хәнифә.

— Миңа! — дип гаҗәпләнде Ярулла. — Миңа сары май булып ятачак ул.

— Борчылма, Хәнифә, без берәрне генә. Шулаймы, баҗай?

— Бир әле берне, аннары күз күрер,— дип, кинәт кыюланып китте Ярулла.

Ярулла рюмканы эчте дә тозлы кыяр капты, озак итеп кыяр чәйнәде. Ләкин тагын берне салып бир әле дип Нурисламнан сорарга кыймады.

— Син, баҗай, без юкта күңелсезләнмә. Әнә телевизор бар. Китаплар да ярыйсы гына. Мин үзем кичләрен китап укырга яратам. Әле теге нине... инглиз язучысы Джек Лондонны укып чыктым. Шәп яза. Ә эчү мәсьәләсенә килгәндә, бу рюмкага, баҗай, бик күп Чаганлы кешеләре батып үлде инде. Теге югароч Кадермәт нинди тракторчы иде. Алтын куллы. Тракторы-ние белән күпер астына... Эчкән булган. Димәк, ул да рюмкага төшкән.

— Кеше таракан түгел, рюмкага батып үлми, — диде Ярулла, акыл сатып утырган баҗасына ачуы чыга башлап.

— Ничек кенә баталар әле, баҗай, ничек кенәләр баталар. Хәнифәнең әнә тотып та караганы юк, ә мин менә салып куйгалыйм, нәфесне тыя алмыйм, шайтан алгыры.

Ярулла дәшмәде, мунчадан соң сусаган иде, берсе артыннан икенчесен көйләтеп чәй эчте.

Ятар алдыннан ул, тәрәзәнең пәрдәсен сыдырып, тышка карады. Күктә бихисап йолдызлар арасында мөлдерәп тулган ай йөзә. Җанны эретерлек тынлык. Ярулла бөтен булган сагышын, хәсрәтен шушы төн өчен саклап килгән кеше шикелле сыкрап куйды. Унҗиде яшьне кире кайтарып, яңадан яшәп булса икән. Бирегә кайткач, Нурисламны, Хәнифәне күргәч, аңа якты дөнья бөтенләй башка ягы белән ачылып китте. Әлегә кадәр яшәүнең мәгънәсе нидән гыйбарәт икәнлеген уйлап та караганы булмаган иде бит аның. Хәзер исә Нурисламның Хәнифә белән ал да гөл тормыш итүләрен күргәч, Ярулла ни кылырга да белмәде. Җитмәсә җанны эретерлек тынлык. Ачудан йөрәк кайный, башны бүрәнә стенага төя-төя елыйсы килә. Ярулла, дивана кеше сыман, керфек какмыйча тулы айга карап торды.

Яткач та ул бик озак йокыга китә алмый интекте. Санап карады, алҗыды, тәмам йөдәде, әмма йокы килмәде дә килмәде.

Иртә белән беренче булып Нурислам уянды, ул аяк очларына гына басып мич каршына узды, чәй куйды, аннары ишек алдына чыгып китте. Бераздан кире әйләнеп керде. Ашарга утырды, аннары торып киенде дә сак кына чыгып китте. Ишек ябылуга Ярулланың йөрәге ярсын-

ды, Хәнифәне үз янына чакырып аласы килде, үзе бу уеннан коты алыныр хәлгә җитеп курыкты.

Бераздан Хәнифә дә уянды, тышка чыгып юынып керде, мич каршында мыштыр-мыштыр нидер пешерәнә башлады. Ярулланың борынына май исе, төче коймак исе килеп керде. Инвалид ирнең тамак төбен кытыклап, карнын котыртып җибәрде.

Коймак-чәй әзер булгач, Хәнифә түр якка керде. Ярулла аның һәр адымын сизеп, тоеп торды. Ул юри йоклаганга салышып ятты. Хәнифә диванга килеп җитәр-җитмәс тамак кырды, акрын гына дәште.

— Ярулла, йокың туйдымы инде, ашап алыр идең...

Инвалид ир кирелгән-сузылган булды, күзләрен ачты.

— Хәерле иртә, Ярулла.

— Ә-ә, иртә хәерле кебек. Рәхмәт. Саташып уяндым, шуннан арына алмый ятам.

Хәнифә аңа комган белән су китерде, битен юындырды. Аннары тарелкага өеп коймак китерде, чәй көйләде.

Ярулла акрын гына ашады, ашыйсы килмәсә дә ашады, чәй эчте. Савыт-сабаны җыештыргач, Хәнифә аның янына килде, янәшәсендә утырды.

— Бәлкем, һавага чыгып, бераз йөреп керерсең, көн шундый матур бүген.

— Арбаны чыгарып куйдыңмы соң?

— Коляскаң әллә кайчан ишегалдында инде, Нурислам чыгарып киткән.

Шунда аларның күзләре очрашты. Хәнифәнең чәч көдрәләре маңгаена төшеп тора. Ярулла бер мизгелгә педучилище студенткасы Хәнифәне күз алдына китерде. Ул вакытта яланбаш иде сыман, калын толымнары билдән түбән төшеп тора. Шомырт кара күзләрендә әллә ниткән уйчанлык, балалык кызыксынуы китмәгән беркатлылык. Шул чакта Ярулла аның беренче булып кулын кыскан иде. Әле дә кулы Хәнифәгә тартылды, йомшак нәфис бармакларга кагылуга ул әллә нишләп китте. Тәүге дулкынлануы күз алдына килде. Яшь чактагы кебек дулкынланмады ул, әсир төшкән кош баласыдай чәбәләнмәде, киресенчә, нидер көтеп, тынып калды.

— Их, Ярулла, Ярулла, — диде ниһаять хатын, уч төбендәге кул да һични сиздермәде.

— Син мине кызганасың гына бит, Хәнифә. Чынын гына әйт әле, кызганасың гына бит?

Хатынның күзләре яшь белән тулды, тамагына килеп тыгылган төерне йотып җибәрә алмый торды.

— Балагыз да юк икән... Гаеп кемдә соң?

— Тимә аңа, Ярулла. Ул минем өчен изге кеше. Андый кешегә хыянәт итү мөмкин түгел. Ишетәсеңме, Ярулла, тимә аңа...

Хатын кинәт инвалид ирнең башын кочаклады да тынып калды.

— Син кайтканнан бирле безнең бергә ятканыбыз да юк. Тимә аңа, Ярулла, зинһар. Беләсең килсә, ул үзе...

— Син аны яратасың?

— Ярулла дим, тоз сипмәсәнә болай да яралы йөрәгемә!

Инвалид ирдә Хәнифәгә карата булган рәнҗү хисе торган саен нечкәрә, зәгыйфьләнә барды, ахыр чиктә ул ни сәбәпледер бәгыре каткан хатыннан җылы сүз ишетүдән тәмам өметен җуеп:

— Гафу ит, син аны шул хәлгә җитеп яратасың дип уйламаган идем.

Хәнифә почмакка карап, бер тын дәшми торды.

— Үзең гафу ит, Ярулла. Ә, әйдә, кочакла сыңар кулың белән булса да.

— Мин авырмы хәзер. Бер кулсыз, бер аяксыз кеше, — диган булды Ярулла, ике арадагы киеренкелекне эретергә теләп.

— Күпердән ары китмәсәң генә чыгарам, — диде хатын шаяртырга маташып, ләкин шул сүзне әйтүе һәм инвалид ирне күтәреп алуы булды, әллә кайчангы таныш ир-ат исен тоеп, күңеле айкалып китте. — Ярулла, аръякка чыга күрмә, текә анда, менә алмыйча кире тәгәрәп төшеп китүең бар.

— Мин теге яр буендагы карамадан да ары китмәм, Хәнифә, борчылма. Хәтереңдәме, беренче тапкыр кайткач, кич якта шул карама төбендә хыялланып утырган идек. Ул вакытта...

— Ыграк тотын, күп телеңә салышсаң кире керттем утырттым, — диде хатын һәм болдырдан төшеп, инвалид арбасына таба ашыкты. Ярулла истәлекле урыннар турында сөйли башлауга хатынның йөрәге кузгалып, көен саташтырып тибә башлады. Күңел кыллары зыңлап китте.

— Әйт әле, Хәнифә! Әйтче, онытмадыңмы Яруллаңы?!

— Ярулла,— дип китереп арбасына утыртты ирне хатын.— Кирәкмәс, телмәсәнә бәгырьне...

— Мин гел исерек кеше кебек, элек ничек булса, хәзер дә шулай ук гашыйк сиңа, Хәнифә, — дип, китә башлаган хатынның кулыннан эләктереп алды Ярулла.— Мин әле дә...

— Житте, Ярулла, зинһарлап әйтәм, кер хәлемә. Нинди мәхәббәт булсын ди инде безнең арада. Кеше эчеп-исереп йөри икән, аның язмышы да исерек була, мәхәббәте дә...

Инвалид ир хатынның кулын, берәм-берәм бармак битләрен үбә башлады һәм Хәнифәнең кулын яңагына кысты да тынып калды.

— Хәнифә...

— Китим инде, Ярулла. Эшкә соңга калам...

Хәнифә шулай диюгә, инвалид ир аның кулын җибәрде һәм арбасын урамга тәгәрәтеп чыгып китте. «Ул мине кызгана, бары тик кызгана гына», — дип үртәлде ул арбасын күпергә таба тәгәрәтә-куалый.

Хатынның соңгы сүзләре аның йөрәгенә утлы ук булып кадалды. «Исерек кешенең язмышы да исерек була» дидеме? Андый кешенең хәттә мәхәббәте дә исерек, имеш. Бу ни тагын! Каян килгән бу акыл сату аңа!» — дип ярсынды Ярулла.

Ярсулы уйлар белән дуамалланып ул күпергә якынлашты. Күрче, яр буендагы карама агачы нинди күркәмләнеп үсеп киткән, ябалдашлары коры елгага су эчәргә үрелгәннәр. Тик коры елгага үрелүдә ни файда?! Хәнифәгә булган минем өметем дә шул коры елгага үрелгән ябалдашлар инде. Эчәсем килә, ә елгада су юк.

Ярулла инвалид коляскасын кырт борып, карама агачына таба тәгәрәтеп алып китте. Агач янына житәрәк ул туктады, кулында талу тоеп, күтәрелеп күккә карады. Күк гөмбәзе себереп куйгандай аяз, ә күпернең аръягындагы чаукалык өстендә кара болыт укмашып маташа. Шул якта кыр-басулар. Басу яклап, тоныкк кына комбайн гөрелтесе ишетелә. Кызу урак өсте, һәммәсе дә басуда, авыл тып-тын. Ярулла шактый вакыт күпер тирәсендә чупләнеп йөргән чуар тавыкка карап торды. «Юк, болай яшәү мөмкин түгел. Яшәү өчен генә яшәргәме?»

Шул вакыт ул күпергә таба килүче кыз белән егетне күрде һәм авылга беренче тапкыр кайткач, урак өстендә Хәнифә белән култыклашып йөрүе күз алдына килде. Әлегедәй хәтерендә, ул вакытта болар кебек үк Хәнифә белән Ярулла да джинси чалбардан иделәр.

Инде инвалидлар арбасында бөкшәеп утырган Яруллаңы күреп, узып баручы егет:

— Әллә аръякка чыгаргамы исәбегез, абый? — диде.

Ярулла, кирәкми дип, башын чайкады. Кызы егетнең колагына үреләп нидер әйтте, шул хәрәкәтне күреп Яруллаңың йөрәге әллә нишләп китте. «Барысы да мин бахырны кызганалар, барысы да!..» Кыз белән егет күперне чыктылар да туп-туры Балтапты чаукалыгына таба киттеләр. Ярулла аларны карашы белән озатып калды.

Ниндидер уй башына килеп, Ярулла ашыга-кабалана арбасын күпергә таба тәгәрәтеп алып китте. Күпергә килеп кергәндә аның маңгаена бөрчек-бөрчек тир бәреп чыкты, куллары талды, арбасын туктатты да таза кулы белән күпер терәгенә ябышты һәм бар көченә тирәккә тартылды. Шунда, һич көтмәгәндә, арба артка тәгәрәп китте һәм инвалид ир сыңар кулда терәккә эленеп калды. Кул бик тиз талды һәм акрын гына терәк агачы кулдан ычкына башлады. Ярулланы чын мәгънәсендә курку алды. Ләкин ул кычкырмады. Икенче мәлдә инвалид ир арты белән лып итеп күпер читенә килеп төште. Ярулла аягына терәк тапты һәм сыңар кулы белән күпер читенә ябышты. Шул хәлдә ул тынып калды... Бераздан тәүге куркуы узды, Ярулла тирә-юньгә күз салды. Чаукалыкны томалап кара болыт килә, кинәт чатлатып, якын-тирәдәге һәммә җан иясен куркытып күк күкрәде, җил чыкты, тузан өермәсе кузгалды. Күп тә үтми, яңгыр тама башлады. Агачлыкка кереп барган яшьләр кире борылып, күпергә таба йөгерә башладылар. Яңгыр стена булып явып килә, урман ягында чабышкан ат көтүе кебек ниндидер гүләү ишетелә. Ярулла кымшанмады да. Яңгыр ява башлауга, күпер өстеннән су агачак, Ярулла утырып торган җир юешләнәчәк, анда инде котылу юк, сыңар кул белән күпер читенә озак тотынып торам димә. Ярулла көч-хәл белән генә үрелеп, терәккә ябышты, ләкин терәк агачы яңгырдан чыланган иде инде. Аның кулы тайды һәм арт аягы күпер читенәрәк шуышты. Шул чак яман итеп, каты дөбердәп күк күкрәде. Ярулланы кинәт курку алды һәм ул җан ачысы белән:

— Коткарыгыз! — дип кычкырып җибәрде.

Яңгырдан качыпмы, инвалид ирнең күпер читендә утыруын күрепме, йөгереп күпер башына килеп кергән яшьләр аның янына ашыктылар.

Аларның аяк тавышы якынлашкан саен Ярулланың йөрәге җилкенде. Хәзер, хәзер килеп җитәрләр, килеп җитәрләр дә... Ул яшәргә тиеш, аның яшисе килә. Яшисе!

Соңгы мәлдә аның кулы терәктән ычкынып, ап-ачык итеп күпер астына очуын күзалдына китерде. Ул кызның: «Ах!» дип чырайлап кычкырып җибәрүен ишетте... Әйтерсең бу тавыш Ярулла ишеткән соңгы аваз иде...

**Азат Ганиев**

# ИМАН

хикәя




втовокзал. Юка пальто кигән бер егет автобусларның килү-китү вакыты язылган расписание каршына туктады. Кечерәк юл чемоданын җиргә куеп, расписаниегә караган килеш күшеккән кулларын угалады, бармакларына җылы тынын өрде. Үтеп баручы чибәр кызны күреп, егет аны карый-карый өч йөз алтмыш градуска борылып чыкты, шул уңайдан яңадан расписаниегә текәлде. Аннары автовокзалга керә торырга уйлапмы, иелеп чемоданын кулына алды. Шунда чемоданының биге ачылып китеп эчендәге бөтен байлыгы: өч-дүрт китап, сабын савыты, «Поморин» тюбигы, щетка, электробритва һәм берничә кәгазь төргәк җиргә коелды. Егет аларны кире чемоданына салып, биген карарга кереште. Шул чак янына яшь булса да

чигәләренә ак төшкән, тулы гәүдәле, түгәрәк йөзле бер адәм килеп тукталды. Өстендә каракуль якалы пальто, йон шарфы астыннан галстугы күренә.

— Мансур!? — диде ул үтә гаҗәпләнеп. — Карыйм, карыйм... Ул бит бу, мин әйтәм!

Күптәннән күрешми торганнар, күрәсең, Мансур дигәне, бераз аптырабрак торганнан соң гына урыныннан торып, тегене кочаклап алды. Аннары үзеннән читкәрәк этеп:

— Әкрам! Ну, ма-лай! Үзгәргәнсең! — диде. — Укыганда чандыр гына, сөйкемле генә бер малай идең бит.

Әкрам Мансурга текәлеп карап торды-торды да, үз чиратында:

— Соң сине үлгән дип чыгарганнар иде бит! — дип кычкырып җибәрде. — Егерменче каттан егылып төшкән дип сөйләгәннәр иде.

Күңелсез хәлне искә төшерүдәнме, Мансурның күзләре кысылып алды.

— Егерме-үк түгел дә, бераз булды шул, — диде ул сүрән генә елмаеп.

— Һәй, малай! Кайгырганны белсәң! Утырып еладым дажы. Салган идем. Кая әле, кая?!

Әкрам Мансур тирәли әйләнеп чыкты. Җиңнәрен тарткалап, куллары хәрәкәтләндереп карады. Шуннан соң үрелеп җилкәсенә сукты.

— Бөтен җирең исән-сау икән ләбаса. Соң болай булгач, әйдә буфетка кереп чыгабыз.

Алар яныннан исерек ир үтеп бара иде. Әкрамның: «Әйдә, буфетка кереп чыгабыз», дигәнен ишетеп борылып карады, елмайды, таныш кешеләр булмагач, өмете өзелеп, башын селки-селки ары китте.

— Билет алдыңмы әле? Авылга кайтасыңдыр?

— Юк, Чаллыга барам. Хәниф абый янына. Минем больнистан чыгу гына бит.

Репродуктор бераз аңлаешсыз гү-гү итеп торды, соңыннан гына: «...тобусы биш минуттан кузгала», — дигән тавыш ишетелде. Әлеге кызлар, егетләр, дәррәү кузгалышып, рюкзак, чемоданнарын күтәренеп китеп бардылар.

— Абыең нәрсә, эшкә урнаштырам диме әллә?

— Хирург бер ел тирәсе ял итәргә диде. Кашыктан авыр нәрсә күтәрмәскә кушты.

— Кашыктан авыр?! Трактор сабанына җигәргә була сине.

Кечкенә генә бер әби болар янына килеп сөйләшкәннәренә колак салыбрак торды да, тел елмайгангамы, бик ачык күренгәнгәме, Әкрамнан:

— Улым, Бөгелмә ахтабузы китмәдеме икән? — дип сорады.

Карчыкның кипшенгән бармаклары арасында соңгы яфрак кебек билет кәгазе җилферди иде. Әкрам салкын бер битарафлык белән билетны алып карады да:

— Бер сәгатьтән китә,— диде.

Болай дип кенә аңлатканны төшенерлек түгел иде шул әби.

— Нәрсә дисең, улым? — диде әби, кулын колагына куеп, — Ә?

— Китмәгән дим, китмәгән! Бер сәгатьтән китә. Утырып тор әнә, әйтерләр.

Әби үзалдына сөйләнә-сөйләнә китеп барды. Үзе кебек түгәрәк портфель тоткан берәү үтеп барышлый:

— Сигез тулмыймы әле? — дип сорады.

Әкрам кабаланып сәгатенә карады.

— Ун минуттан тула, — диде. — Әйдә, Мансур, читкәрәк, бигрәк юл өстендә торабыз. Университетта укый идең бит. Бетерә алдыңмы соң аны?

— Бетерүен бетердем дә, диплом якланмаган әлегә.

— Больнистан чыккансың. Хәзер нишләргә исәп?

— Язарга исәп.

— Нинди факультет иде әле синең?
— Физика-математика.
Әкрам:
— Шулаймыни?! — дип баскан урынында кисәк сикереп куйгандай итте. — Кара син! Ә мин физика укытучысы таба алмый йөрим. Әйдә миңа. Хезмәт дәресләрен дә бирермен. Кулларың алтын бит синең. Укыган чагында, хәтерлисеңме, әллә ниләр ясый идең. Самолет, пароход модельләре, әллә ниткән җайланмалар. Карале, Мансур, монда якында гына ресторан бар. Кереп утырыйк булмаса. Син миңа кирәкле кеше булып чыктың бит әле.
— Акча юк минем.
— Ниткән сүз?! Үзем сыйлыйм. Әйдә, әйдә.
Әкрам иелеп Мансурның чемоданын алды. Ләкин теге хәерсезнең капкачы тагын ачылып китеп, эчендәге бөтен нәрсәсе җиргә коелды. Мансур чүгәләп аларны берәм-берәм үз урыннарына алып куя башлады. Аның әз генә дә кәефе кырылганы сизелми иде. Мансурга булышырга дип иелгән Әкрәм ачуы килеп:
— Синең бу чемодан нәрсә? Гел шулаймы? Бер дә эчең пошмыймыни соң моңа?! — диде.
— Ә моның нәрсәсенә ачу килергә? — диде Мансур. — Бу бит, — ул чемоданына «дык» итеп сугып куйды, — материя. Тере булмаган материя. Ул синең ачуың килгәнне барыбер аңламый. Ачу килү ул, малай, уйлый белмәү галәмәте. Минем беркайчан, бернәсәгә дә ачуым килгәне юк. Ачу килердәй нәрсә булса мин башта аның сәбәбен ачыклыйм, аннары тиешле чарасын күрәм. Менә син игътибар иттеңме икән: Күтәреп йөргәндә чемоданның биге ачылмый. — Мансур капкачын тарткалап күрсәтте. — Ни өчендер ул җиргә куеп алганнан соң гына ачылып китә.
Мансур чемоданын кабат җиргә куйды да яңадан күтәреп ала башлады. Капкач ачылып китте, Мансур, аны тагын берничә мәртәбә шулай кабатлады. Үзе иелеп, җиргә үк ятып дигәндәй бикнең ничек ачылганын күзәтте.
— Пружинасы бушаган, — диде ул, ниһаять, — җиргә куйгач, капкач күтәрелә дә, келә телен эчкә этеп кертә. Күтәреп алганда, әлбәттә, ул ачылып китәчәк. Сәбәбен ачыкладык, хәзер чарасын күрәбез.— Мансур кесәсеннән пәке алып бераз вакыт чемоданның биге белән кайнашты. Аннан бикләде, кисәк-кисәк селеккәләп карады. Эшеннән канәгать булып: — Күрдеңме! — диде.
— Гел үзгәрмәгәнсең син, Мансур. Урта мәктәпне бетергәндә нинди булган булсаң, шулай. Аягыңа сыер басмаган шул, нужа күрмәгән. Ярар, бу чемоданың материя дә булсын ди, ә кеше? Берәр кеше ачуыңны китерсә?
— Ничек?
— Соң менә синең бу чемоданыңны мин әнә анда, чүплеккә атып бәрсәм?
Мансур чемоданын бастырып өстенә атланып утырды да дивана кеше шикелле елмаеп җибәрде.
— Хе-хе-хе... Ю-ю-юк! Атып бәрмисең. Син бит минем авылдаш, классташ, күрше, бергә уйнап үскән дус. Ә инде алай-болай атып бәрсәң, акылына зыян килгән икән моның дип, мин сине бик кызганыр идем.
Әкрам көлә-көлә:
— Ә бүтән кеше атып бәрсә? — дип сорады.
Мансур кисәк җитдиләнеп:
— Бәрми, нишләп бәрсен,— диде.— Сәбәпсез сәдәп тә төшми.— Мансур урыныннан торып кулларын як-якка җәеп җибәрде. — Бу дөнья без уйлаганга караганда мең, миллион мәртәбәләр гүзәлрәк, мәгънәлерәк

бит ул. Анда бөтен нәрсә бер-берсенә бәйләнешле, бернинди очраклы хәлнең булуы мөмкин түгел. Менә син без очраклы рәвештә генә килеп очраштык дип уйлый торгансыңдыр?

Әкрам шулай булмый ни, дигәнне аңлаткан хәрәкәт ясады.

— Түгел шул менә. Безнең очрашуыбыз мәңгелектән килүче үсеш-үзгәреш процессларының эшлекле дәвамы ул.

— Бигрәк хәтәр икән! Ә мин бүген районга килмәгән булсам... Килсәм дә бүтән җирдә тоткарлансам...

— Бу мизгелдә алай итсәм болай булыр иде, болай итсәм алай булыр иде, дип уйлау язмышка вариантлар сайлау түгел. Бу инде алга таба яшәү була. Вакытның агышы даими бит, ул гел бер юнәлештә бара. Тырма белән печән җыйгандагы кебек аны алга-артка күчереп йөртә алмыйсың.

Билетын тотып баягы әби тагын болар янына килде.

— Аймыл булып калам бугай инде. Актабузлар гел китеп тора, Бөгелмәнеке дә киткәндер инде, ходаем.

— Аңлат әле шуңа, — диде Әкрам йөзен чытып.

— Әйдә, әби. Мин сине Бөгелмәгә баручылар янына илтим, — диде Мансур урыныннан торып. — Шулардан бер адым читкә китмәссең, яме. Әйдә, әби, әйдә.

— И-и-и-и, рәхмәт төшкере. Шулай шул. Син үзең, балам, кайсы якныкы? Бөгелмәгә кайтмыйсыңмы?

Әкрам үзе генә калгач, әрле-бирле йөренеп килде. Мансурның чемоданы каршына туктап: — Кулы алтын, тотып эшкә җигәргә моны, — дип уйлады.— Күндерә-алсам, бер атуда ике куян. Бердән, физика укытучысы Сабир абыйны мәктәптән шудырам, икенчедән, Мансурга хезмәт дәресләрен бирәм дә мастерскойны ремонтлаттырам. Ремонтлау өчен бүленгән мең сум акча янга калачак. Оста кушсам, акчаны ул каерып алачак. Миңа бармый. Миңа мастерской да ремонтлансын, акча да янга калсын. Сабир абый — карт бүре шул, башта договор төзик, шунсыз бармак та селкетмим, ди. Ә Мансур акча эшләрендә профан...

— Болай итәбез, яшьти, — диде ул Мансур килү белән. — Хәзер РОНОга кереп Гомәр Садриевичтан гаризаңа кул куйдырабыз да туптуры Турайга. Ишеткәнең бармы шундый авылны? Юктыр. Олы юлдан читтә, бәләкәй генә, аулак кына бер авыл. Берәр карчыкка урнаштырырмын. Ну, авылы! Урам саен чишмә. Елгасы ни тора! Бурсык, төлке ауларга йөрербез...

Мансур сүзсез генә тыңлап торды да, классташының хәтерен калдырмас өчен кыюсыз гына:

— Ай-һай! Бу бит егерменче гасыр, кем хәзер бурсык аулап кинәнә икән? — диде.

— Менә әкәмәт! Ышанмый. Әйтәм бит бар дип.

— Булса да, берәү-икәү — соңгы могикандыр. Тукта әле, нигә болай бик үтереп кыстыйсың әле син мине?

— Вәг тиле! Синең өчен тырышам түгелме? Абыең җилкәсендә утырмассың бит инде, ял итәм дип. Ике көн яшәрсең, өч көн, ә дүртенче көнне үзеңне кызган табадагы кебек тоя башларсың. Бераз гына беләм бит инде мин сине. Ә Турайда син үзеңә үзең хуҗа. Минем канат астында җил-яңгыр тимәс. Чыннан да ял итәрсең.

— Укыту эшен ял дисеңме? Хәзерге көндә укытудан да авыр хезмәт бармы икән? Икеле куярга ярамый, күчерми калдыра алмыйсың. Күрсәткеч процентлары югары булсын дип син укытучыларны кысасың. Чөнки сине РОНО мөдире кыса, РОНО мөдирен югарыдан кысалар, аларны тагы да югарырактан. Кемгә кирәктер шундый күз буяу?! Синең бу чәчләр тикмәгә агармагандыр.

Әкрам эсселәгәндәй пальто якасын ача төште.

— Чәч ансы минем кинәт агарды,— диде ул, табигыйрәк, басын-

кырак тавыш белән. — Мин дә үлемнән калдым бит, малай. Су кергәндә күзәм җыерды да бата башладым. Өскә калкам, яр тулы халык, көлешәләр. Тагын төпкә китәм. Ә анда... Бер үзең... Шул ничәдер минут эчендә баштан әллә ниләр үтте, малай. Дөнья дигәнең кызык икән ул. Кеше гомере санаулы еллар гына. Кеше гомере нәрсә?! Дөнья үзе дә, менә бу зәңгәр күк, әнә ул кырлар, басулар, урманнар да мәңгелек түгел. Хәтерлисеңме, без класста иң яхшы укучылар идек. Без бит укыган, без егерменче гасыр кешеләре. Мин элек тә материянең өзлексез бер төрдән икенче төргә әверелеп торуын, бер нәрсәнең дә мәңгелек булмавын белә идем. Ләкин батып үлә язганга кадәр ул төшенчә миңа кагылмый торган абстракт бер нәрсә булып тоела иде. Баксаң, алай түгел икән. Мин дә шул тотрыксыз материянең бер кыйпылчыгы икәнмен.

Әкрам сер сөйләргә җыенгандай Мансурга елыша төште.

— Беләсеңме шуннан соң нинди нәтиҗәгә килдем? Бәй, мин әйтәм, дөнья дигәнең шундый бер нәрсә генә икән, минем ничек теләсәм шулай яшәргә хакым бар. Кемнән оялырга?! Нәрсәдән куркып торырга?! Ни теләсәм шуны эшлим, ничек теләсәм шулай яшим! Элекке Әкрам үлде, шунда су төбендә калды ул. Мескен бигрәк кыюсыз, бигрәк мәхлүк адәм иде. Әсмага сүз катарга да куркып йөри иде. Ә мин шуннан соң бер ай эчендә Әсмага өйләнеп куйдым. Укытучы кыз ул. Директор кызы. Бабайның пенсиягә китәргә җыенып йөргән чагы иде. Гомер-гомергә директор булып эшләгән, һәркайда сүзе үтә. Мине дә укытырга урнаштырды. Дипломсыз тоже ерак китә алмыйсың, бу мине педагогия институтына да төртеп кертте. Хәзер менә — Әкрам Әкрам гена түгел, Әкрам Хафизович, мәктәп директоры.

— Үлем белән очрашу кешенең эчке дөньясын айкап сала, тетрәндерә. Мин дә үлемнән калдым, ләкин болай үзгәрмәдем шикелле. Дөрес, элегә минем бернәрсәгә ирешә алганым юк. Әллә ничек кенә үтте минем гомер. Бала чак — бала чак инде. Яшел чирәм, кояшлы яңгыр булып хәтердә калган. Үсмер чак — үземдәге үзгәрешләрне гаҗәпләнеп күзәтү чоры. Егет чак... Ансы минә булмады да кебек. Миемә күгәргән кадак сыман кереп утырган яшәү мәгънәсе турындагы уйлар йотты минем егет чакны. «Ярар, — дип уйлый торган идем,— аерым шәхес буларак минем гомер чикләнгән дә булсын, син әйтмешли, кеше гомере санаулы еллар гына да булсын. Ә Тереклек мәңге дәвам итәрме? Шушы сорау миңа тынгылык бирмәде. Үземә профессия, шөгыль сайлаганда да шушы сорауга килеп төртелә идем. Менә, мәсәлән, мин рәссам ди. Кеше тәненең гүзәллеген, камиллеген сурәтләргә телим ди. Ә шунда берәрсе килеп: «Карале, туган, синең бу эшең фәлән-фәлән елда, яки гасырда бөтен кешелек дөньясы белән берьюлы барыбер юкка чыга бит»,— дип әйтсә? Яки мин композитор ди. Кеше күңеленең иң тирән кичерешләрен музыкага салырга телим. Яки кешеләр өчен йортлар салам, кешеләрнең хезмәтен җиңеләйтә торган җайланма турында уйлап баш ватам, ди. Һәм шунда миңа: «Бу шәһәрләр, завод-фабрикалар, хәтта уйлаган уйларыбыз, кичерешләребез дә бер заман эссез югалачак»,— дип әйтсә, мин башлаган эшемне нинди күңел белән дәвам итәрмен икән дә, каян, нинди илһам алырмын икән? Ул чагында мин рәссам да, композитор да, төзүче дә, конструктор да түгел, ә вакытлыча гына яшәп маташучы кешеләрнең күңелен табарга, кәефләрен күтәрергә тырышучы кәмитче генә булып калам түгелме?

Тереклек мәңге дәвам итсә генә яшәүнең мәгънәсе бар.

Тереклек мәңге дәвам итәме, юкмы?

Яши башлаганчы иң элек мин шушы сорауга җавап табарга булдым. Әгәр тереклек мәңге дәвам итсә, мин үземнең иманымны табам, миндә кешелек сыйфатлары тантана итәчәк. Ә инде мең, миллион, яки анда миллиардлаган еллардан соң тереклек юкка чыгарга тиеш булса, мин менә синең кебек имансызлар рәтенә басам. Чөнки кешелекнең ки-

ләчәге булмагач, аның алдында мин җаваплы түгел. Ничек теләсәң шулай яшәргә була.

Мәктәп елларында шушы уйлар белән изаланып беттем мин. Аннары армиягә алындым. Кайту белән университетның физика-математика факультетына укырга кердем.

— Кара әле, Мансур, чыннан да, нигә кирәк булды сиңа ул физика-математика факультеты. Син гуманитар фәннәр белән кызыксына идең бит.

— Динне идеология буларак нәкъ менә физика, астрономия, биология кебек фәннәр ботарлап ташлаган бит. Тереклек мәңге дәвам итәме, юкмы дигән сорауга да шул фәннәр җавап бирер дип уйлаган идем.

— Соң?

— Тары орлыгын он итәргә була, ә шул оннан фән нигезендә җиргә төртсәң шытып чыга торган тере орлык ясый алмыйсың. Җир шарын да көл итәргә була, ләкин фән ярдәмендә яшәргә яраклы икенче бер планета ясарга теләсәң, анысын булдыра алмаячаксың. Яшәү серенә төшенү мөмкинме? Егерменче гасыр! Фән-техника революциясе! — дип шапырынабыз. Табигатьне буйсындырырга маташабыз.

Әкрам сәгатенә карап алды.

— Ярты сәгатьтән Турайга бара торган автобус кузгала. Утырыша башларга вакыт. Я, ничек, киттекме Турайга?

— Ә-ә, син һаман шунда кыстыйсың. Кыставын кыстыйсың да, нигә кыставыңның чын сәбәбен генә әйтмисең.

Әкрам җилкәсен җыерып куйды.

— Үзем әйтимме? — диде Мансур.

— Әйтеп кара.

— Син үзеңдә педагог сәләте юклыгын, әлбәттә, беләсең. Әйләнәндәгеләрнең кырын карауларын, өнәмәүләрен дә сизәсең һәм болар әзсез генә узмаган. Йөрәгеңә карышып яшәү иртә картайткан сине, Әкрам. Мөгаен, син мине анда үзеңә арка таянычы итмәкче буласыңдыр.

— Соң, Мансур, без дуслар идек бит. Элек тә бер-беребезне ярты сүздән аңлый идек. Яшерен-батырын түгел, чыннан да шулай.

— Элек шулай иде, ярты сүздән аңлый идек. Хәзер алай түгел. Хәзер без икебез ике телдә сөйләшәбез. Ярар, хәерле булсын, алып бар мине Турайга.

— Әйдә, ал чемоданыңны, автобуска соңга калабыз.

Мансур белән Әкрам автовокзалдан чыгып киттеләр. Расписание каршына төп кебек таза ир уртасы кеше килеп басты. Кесәсеннән кульяулык чыгарып күзлек пыялаларын сөртте. Аның яныннан кыз белән егет узып баралар. Көннәр буе басып торсаң да бу хәрәкәт кабатланмас, гел башка булыр. Һәм бу учактагы ялкын телләренең биешүе, агымсуларның челтерәве, яңгыр шыбырдавы, агачлар шаулавы кебек үк туйдырмый, ялыктырмый. Ә моның сере нәрсәдә? Мисал өчен су чылтыравын тикшереп карыйк. Су таштан ташка сикерә дә «чулк» итеп куя. Аның артыннан килгән су да нәкъ шулай «чулк» итәр иде, таш инде урыныннан күчкән була һәм ул «чулк» түгел, ә «чылк» итә. Аннан соңгысы бүлгәләнеп «чалк-чалк» итеп ала, чөнки ташлар арасына ком бөртекләре, вак-төяк чүп-чар килеп тыгылган. Су ага, ком бөртекләре, тамыр, бөҗәк калдыклары берәм-берәм дә, ише-ише дә ычкына, ары агып китә һәм агымсуның чылтыравы да үзгәреп, гел үзгәреп тора...

## Зиннур Мансуров

### Уйлый белгән йөрәк

Кешелегем!..
Шөкер әле,
үз-үзеңә ия син.

Була кайчак шундый халәт —
хисләр анархиясе!..

Шул вакытта күңелеңдә
билгесезлек сизәсең,—
«Кай ярларга илтеп бәрер
Хиссият зилзиләсе?..»

Кинәт кенә айныйсың да,
бер уй суга: «Кайда син?..»

Һәм аз гына черем иткән
акылыңа кайтасың.

Шулай аз-маз татыдым мин
хисси мираж алдавын.
Беләм, салкын акылның да
җанны эретә алмавын...

Хис сагында торыр өчен,
дөрес, ул да кирәктер.
Кешелекнең чын иясе —
уйлый белгән йөрәктер!

### Бурыч

*Тукай үлгән шифаханәдә дөньяга килгән А. га.*

«Күп тә үтмәстән, утым ялт-йолт итә һәм селкенә,
«Гөлт!» итеп актык нурын бер күрсәтә, аннан сүнә...» [1]

Түбәнәчә янган шәмдәл...
Сорыйсың күк: «Бу — кайдан?»

Тукайдан ул, Тукайдан...

Беләсеңме: теләсә кем
кабызалмый бу шәмне.
Ә син ут ал,
нур көлтәсе
чәеп чыксын түшәмне!

«И мөкаддәс моңлы сазым! уйнадың син ник бик аз?
Син сынасың, мин сүнәмен, айрылабыз ахрысы!»

---

[1] Өземтәләр Г. Тукай шигырьләреннән алынды. Автор.

«...бетте көч, сынды кылыч...»

Мөкатдәс саз...
Бәгыреңә
бәйлә өзек кыл очын.

Сынган, димә — кулыңа ал
Фидаи җан кылычын!

«Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы...»

...Төш аралаш, кулың сузып,
сорыйсың күк: «Бу — кайдан?»
Хөрлек сөйгән күңел кошы! —
Тукайдан ул,— Тукайдан!..

Үз җаныңа кабул итеп
алырсыңмы бу кошны?

Тукай үлемсезлеген син
озайтырга бурычлы!

## Тау елгасы балыгына

Тау елгасы буйлап, салда төшү
көч, кыюлык сорый кешедән!..
Сине генә кызыксындырмыйдыр
мондый җиңү, моныңише дан.

Бар, утырып кара, шашкан аттай
башын бирмәс дулкын өстенә!..

Ә сиңа ни...
Агым уңаена
агып төшү уен эш кенә...

Без бу юлы аска ыргылабыз!
Синең, әнә, сыгып бар көчең,
дулап аккан шарлавыклар буйлап,
югарыга менеп барышың!..

Хак анысы: биеклеккә таба
тик җансызлар гына юл алмый.
Ә бит мең газаплы менүгә тиң
бөек төшүләр дә булгалый...

## Иске арбага карап, вакыт турында янә бер уйлану

Юлда җуелган
күпме ат башы...
Ә ул узган бит
чорлар арасын!...

Чыккан, әйтерсең,
тәмуг аша да.

...Агач күчәрен
еллар ашаган...

Үткән юлларын
ничек үлчәргә?..
Дөнья кадәр йөк
төшкән күчәргә!

Түзми бастырык,
камыт баулары...
Ә ул күтәргән
нужа тауларын!

Алга күчергән
Җирнең бар ямен!..

Вакыт барыбер
изгән арбаны...

## Хат

Шундый кайнар булып янды
җан өшеткеч шул хат та!..

...Баксаң, мине ярам гына
җылыткан бит ул чакта.

Янган гитара күк, нидер
чыңлап куйды учакта.

...Җаныбызны бәйләүче кыл
өзелгән нәкъ шул чакта...

## Мәгъсүм Хуҗин

# КАРА КҮЛ

хикәят



Жәйнең эссе көннәре күзгә калган икән. Язның соңлап килү галәмәте булды инде бу. Май аенда уҗымнар мескенләнеп, җылы көтеп, күтәрелми утырдылар, сабан чәчүе озакка сузылды. Табигать дигәнең игенче күңеленә баштан ук әнә шулай борчу оеткысы салды, сабан туйларына чаклы явар-яумас яңгырлары белән хәвефләндереп торды. Аннары табигатьнең миһербаны килде тагын, иреннәр күкрәп уңды, урырга-җыярга көннәре аяз булды. Дөрес, иген соңлап өлгерде дә, кыр-ындыр эшләре бергәрәк өелде өелүен. Әмма Габделхәй белән этисе Мортаза кырда тәүлекләп ятарга да риза инде — уңышы гына булсын.

— Быел ашлык белән лар тула да тула инде. Кышлай ипи пешерербез,— дип сөенеп йөрде Габделхәй.

Алар авыл читендә чәчелгән игеннәрен вакытында җыйдылар — арыштан ике, ә бодай көлтәсеннән бер кибән куйдылар. Габделхәйнең этисе шәп оста шул, эшкә кулы ятышлы, аларның кибәннәре бөтен басуда менә дигәннәрдән булды — көлеп торалар. Габделхәй дә бик тырышты, кырдан кайтмады да диярлек. Ул бөтен-бөтен көченә булышмаса, ашлыклары алай күп булмас та иде, мөгаен. Урагын да урды Габделхәй, кибән төбенә көлтәсен дә тезеште. Яз башыннан ук көннәрен басуда уздырды ул. Үги әнисе Гатифә:

— Ишетсен колагың, каз-үрдәктән, мал-туардан таптатсаң, сыңар сынык ипи күрмәссең! — дип әмерне каты биргән иде.

Габделхәй басу саклаган җиреннән көндез ашарга да таякка атланып кына чабып кайта иде. Ә басу сакларга куанып-шатланып риза инде ул. Габделхәйләрнең үз җирләре бит. Беләсегез килсә, Габделхәйнең үз өлеше дә бар бу җирдә. Әле былтыр гына, үз әнисе исән чакта, авылда җирне яңабаштан бүлгәннәр иде.

— Җирнең яртысы синең өлешеңә тиде, улым. Бәхетең белән тудың, балакаем. Безгә — өч бөртек кешегә — бик җиткән, бик күп инде бу җир, — дигән иде әнисе.

Тик җирләренең игелеген күрә алмады шул, кышка кергәндә бик каты салкын тидерде, атнадан артык түшәк өстендә ятты. Аягына басып кына килә иде, этисе Мортаза, каладан Даут бай килеп сыйлагач, әнисен кыйнап ташлады. Шуннан соң әнисе урын өстеннән күтәрелмәде. Ире

Мортазаның бәхиллек соравына эндәшмичә күзләрен йомды. Габделхәйнең башына куйган кулы малайның күкрәгеннән туктала-туктала шуып төште...

Йортка үги ана килде. Аның килүе сәер генә булды, малай моны абайламыйча калды. Язгы су төшкән чаклар иде. Габделхәй көндезен мал-туар карарга этисенә булышып йөрде, алар икәүләп өй нигезен кардан ачтылар. Басуга чыкканчы рәтле булсын, дип, бер төрәнле суканы көйләп майладылар, тырманың какшаган тешләрен чөйләделәр. Алакай боларны үзе тартасын сизенеп, әмма моңа ваемсыз гына койма буенда кояшта кызынып-йокымсырап торды. Көндезге чәйдән соң әнисенең төсе булып калган әйберләрне карадылар: чулпылар, кашлы йөзек һәм беләзекләр, алкалар һәм таңкәләр. Йөзек-беләзекләрне Мостафа үзе коеп бирде. Әйе, андый һөнәре дә бар аның, әмма бу эш белән табыш итү өчен шөгыльләнми, туган-тумача, дус-иш сораганда гына сөрмә-көмеш кайната.

Истәлек әйберләрен шәлъяулыкка аерып-аерып пөхтәләп төреп, сандык төбенә салып куйдылар. Аннары Габделхәй, күтәртмәле чабатасын киеп, гөрләвекләр агызып уйнарга чыкты, караңгы төшкәч кенә әйләнеп кайтты. Өйдә лампаның ялкау яктысында этисе янында таныш булмаган хатын утыра иде. Ирләр сыман таза беләкле, олы сынлы бу апа Габделхәй белән кулга-кул күреште, саран гына исәнлек-саулык сорашты. Һәм ул көнне малайга башка сүз әйтмәде, Габделхәйләрдә кунып калды. Иртәгесен этисе кече як сәкедә олы түшәккә мендәрсез-нисез чумып яткан Габделхәйне иртәрәк уятты һәм түр якка алып чыкты. Кичәге апа киенер-киенмәс килеш чәч тарап утыра иде.

— Улым, менә бу апаң, Гатифә апаң, сиңа яңа әни була инде,— диде.

— Әйе, — дип бер сүз белән генә әйтеп куйды Гатифә дә.

Габделхәй эндәшмәде, хәер, моңа этисе дә, яңа әнисе дә илтифат итмәделәр.

Үги ана килүе Габделхәйләрнең уены кебек булды — түгәрәк сызасың да, һәркемгә үз өлешен бирәсең, аннары басып алышлы уйный башлыйсың. Гатифә дә Габделхәйләрнең йортына басып килеп кергәндәй тоелды.

Эшне кызу тота торган хатын булып чыкты үги ана. Бакча-басу, мал-туар тирәсендә артык күренеп йөрмәде ул, барысы да этисе белән Габделхәй өстендә калды. Аның каравы башкасында алдыра иде Гатифә. Сабан чәчүе вакытында калага барып, тарантаска сөлек кебек юртак җигеп кайтты. Келәт сатып алып, шуны абзар итеп өйдерде, анысы юртакка булды. Юртакны Габделхәйләрнең үз Алакайлары белән бер абзарга япмадылар, аны сукага-тырмага да җикмәделәр, тик калага яки рус базарына барганда гына Гатифә үзе дилбегә тота торган булды. Уракка төшкәнче, ишегалдының каршы ягына ике катлы йорт та күтәреп куйдылар, монысын Малмыж баеннан Гатифә үзе сатып алып кайтартты, калган барысын осталар яллап эшләтте.

— Мортазага җайлы хатын туры килде, — дип сөйләнделәр авылда.

— Байлыгы бар, эш майтара да белә, эредән йөртә эшне.

— Мортаза юашны тәмам учына кысып алыр әле, — дигән сүзләр дә йөрде.

— Кысса да урынында, ничәмә еллар каралты-кура кузгата алмый йөрибез, Гатифә бер җәйдә йорт җиткерде. Йортның да ниндие әле! Малмыж баеның кунак өен күчертеп салды,— дип кызыгучылар да булды...

Хак иде, Гатифә бөтен каралты-кураны күз ачып йомганчы дигәндәй үзгәртте, алай гына да түгел, йортка яңа тәртип кертте. Җәһәтлеге, ялланган кешеләрне эшләтә белүе белән бөтен авылны таң калдырды. Хәзер инде авылда Габделхәйнең этисе Гатифә Мортазасы булып китте.

— Кереп капты тәмам Мортаза, — дип нәтиҗә ясадылар авылдашлары. — Алтын шәп эләктерә шул, кысып-боргычлап ала ул.

Гатифә исә мондый сүзләргә колак салмады, чөнки бу авылда кем дә булса үзенә каршы төшәр дип шикләнмәде. Хәер, алтын-көмеш белән эш итүен ул үзе дә яшереп тормады.

Калада Даут байга асрау кыз булып кергәндә, аңа әле нибары ундүрт яшь кенә иде. Абыстайның барлык көйсезлекләренә түзеп, баштарак басынкы йөрсә дә, соңыннан нәләште, мондагы тәртипкә өйрәнеп житте. Көмешчеләрнең эш бүлмәсен җыештырганда, җай туры китереп, калдык алтын-көмеш тамчыларын күлмәк изүенә яшерә иде. Аларны, вакыты-вакыты урынын алыштырып, яшереп йөртте. Тора-бара байлык белән зур гына тартма тулды. Ә беркөнне Даут бай үзе миһербанлык күрсәтте аңа.

— Абыстасы, — диде ул хатынына, — Гатифә уңган булып чыкты бит. Кыз бала, кеше арасында бизәнеп тә йөрисе киләдер, берәр нәрсә бүләк итәр идең үзенә.

Ире сүзенә карышмады абыстай, Гатифәнең атсыз бармагына кашлы йөзекне үз кулы белән киертте. Әмма ул йөзек өчен бурычны инде үсеп буйга житкән Гатифә, абыстай утырмага киткәч, Даут байга яшьлек сафлыгы белән түләде. Нишлисең, акчада — көч. Шул вакыт Гатифә бу дөньяда замана тоту өчен кемнедер рәнҗетмичә, хәйләләмичә мөмкин түгеллеген төшенеп калды. Моңа каланың алтын-көмеш белән эш итүдә даны таралган кешесе Даут бай үрнәк иде. Чамасын белеп кенә байның осталарына да елмаерга өйрәнде Гатифә. Кыз куены яратсаң, байның алтын-көмешен «чиртү»нең әмәлен табасың инде, бу дөньяда бер эш тә әҗерсез булмый! Кимү-югалтуны бай сизсә, көмешче үзе түли, я ай буена бушка эшли. Көмешчеләрне Даут бай үзе карап кына эшләтә, ә тегеләре барыбер җаен таба: алка койганда берәр тамчысын идәнгә тамдырасың да, тиз генә табаның белән каплыйсың — һәм Гатифә кичен синең куенда!

Асрау кыздан шәбрәген дә табарлар иде көмешчеләр, Даут бай осталарны калага чыгарып йөртми шул, аларның бөтен гомере аның йортында уза. Китәм, дисәң — кит! Тик тамчы көмеш урлармын димә! Даут бай барын да бик нык уйлап куйган — өстеңдәге киемнәреңне калдырып, абыстай биргәннәрне киясең... Алтын-көмештән ике көн читтә торгач кына Даут бай ихатасыннан чыгарга рөхсәт аласың.

Ә Гатифәгә тамчылап та ярый, җыела ул! Бер явызы, алтын, дип бакыр ялтыратып биргән иде дә, тиз таныды Гатифә, бакырны тегенең йөзенә бәрде.

Тора-бара Гатифә үзе дә көмешчеләр тотарлык хәлгә житте, әмма башта ниятне сиздермичә генә Даут байдан котылырга кирәк иде. Яхшылык белән ычкынасы иде дә рәтләп-иплә кенә башлыйсы иде! Аннары ул Даут байны уздырып та җибәрәчәк, әле теге кашлы йөзек өчен үчен алмый калмас.

Даут бай унлап көмешче тота, күбрәк Балык Бистәсе ягы осталарыннан әзер мал сатып алып, шул бизәнү әйберләрен дала якларына илтеп биш бәягә сата. Гатифә дә башта шулай эшләр — байга килеп йөргән кешеләрне белә, ничек сүз алышырга кирәклеген дә чамалый, аннары бу тирәдә йомылып ятмас иде әле. Мәскәве белән дә, чит илләре белән дә элемтә бәйләп җибәрер иде. Себер алтын оясы бит — күңелдә анысы да бар. Ничек башларга менә? Хәер, әлегә ашыгу файдасыз, әлегә байны да, көмешчеләрне дә «иму» ярап тора. Ә алтын җыела торсын, череми ич ул.

Гатифә беркөнне, табын әзерләп йөргәндә, бай белән абыстайның күрше бүлмәдәге канәфигә утырып, ашыкмыйча гына сөйләшүләрен тыңлап торды.

— Атасы, — диде абыстай, — хәтерлисеңме икән, Мортаза исемле

берәү килгәли иде безгә. Аз-маз алтын-көмеш алгалый иде. Анысы да елына бер дигәндәй. Бүген ашка барганда очраттым шуны.

— Беләм Мортазаны, Сөлекле остасын белмәскә соң? Алтынны аз алуы да хак, әмма үз кулы алтын аның. Сөрмәне беләзеккә-йөзеккә шәп сала да соң, аның үз бизәге бар. Чакырган идем мин аны эшкә, күп акча вәгъдә иттем. Аның кулыннан чыкканны чит илгә озатырлык — бернинди тап булмас. Микулай галиҗәнабларының кулын бизәр идем мин ул ясаган йөзек-балдаклар белән! Патшаң сокланып рәхмәт кенә укыр иде! Ризалашмады бит Мортаза миңа эшләргә. Мин крестьян кеше, җиргә береккән, ачуланмагыз, авылымда яшим, урта тормыш миңа бик җиткән, диде. Мәскәү купецы Александровка илткән чылбыр-беләзекләрне аңардан койдырган идем. Биргән алтынның калганын бөртегенә хәтле кайтарды. Саф кеше ул, алтын тирәсендә бик йөрмәс.

— Хатыны дөнья куйган икән шул Мортазаның.

— Алай, бер малае да бар иде бугай мескеннең. Хатынның саулыгы чамалы, дип әйткән иде шул. Хәзер ялланмас микән соң? Тирә-юньнең көмешчеләре белән янчык йөртешкән-алышкан Тенеки остасында малайлыкта булган ул. Һөнәренә шунда өйрәнгән. Мортаза бер үзе генә дә читкә чыгарырлык күпме нәрсә эшләр иде бит миңа, ә!

Бу әңгәмәне йотлыгып тыңлаган Гатифә байларга чәй эчерткән арада уй-фикерләреннән түгәрәк йомгак чорнады.

— Баем-абыстаем,— диде ул итагатьле генә итеп,— сезгә әйтергә бик тә уңайсыз да инде, беркөнне Сөлекле Мортазасы минем катка килгән иде әле. — Гатифә чәй касәләрен поднос өстенә алып куйды һәм, кызган тимергә нәкъ шушында сугып калырга кирәклеген сизеп (сузарга ярамый — Даут бай күз ата Мортазага), сүзен әйтеп бетерде. — Бик юаш кеше күренә үзе, бай белән абыстайдан оялам, шуңа күрә аларга кермәдем, ди, син үзең... ничек соң, ди... Мине... хатынлыкка сорый... Миңа да оят инде моны сезгә әйтергә, шулай да әйтергә булдым, этиәнием кебек бит сез...

— Алай... Соң, үзең ни дидең?

— Баемнан, абыстаемнан узмыйм, алар ни әйтер, дигән идем.

— Шулай булмыйни! Җибәрмәбез, атасы, аның кияүгә чыгасы бар дип, асрау алыштырырга ди...

— Туктале, тыныч тор! — Даут бай җыйнак мыегын каты басып сыпырды — Мортазаны әйтәм, кыз сорап керергә дә оялган бит, ә. Бәхетең бар икән, Гатифә, бездә балда-майда яшәдең...

— Шулай шул, гел майда-балда, асрау дип кимсетмәдек.

— Бездә кыз булып җиттең...

— Әйе, булып җиттем...

Даут бай сискәнеп китте, әмма моны карчыгына сиздермәде. Гатифәнең урынлы-урынсыз кыстырган бу сүзләре мәсьәләне тиз хәл кылырга этәрде.

— Алай... Үз кызыбыз юк инде туй ясап бирергә...

— Ниткән туй ди?! Асравыңа туй ясар идеңме әллә?! Байлык бетереп! Аннары икенче хатынлыкка бара бит әле ул...

Бүген Габделхәй белән этисе арыш басуын сукалап бетерергә исәпләгәннәр иде. Иртәдән бирле әле сука башы тотып, әле ат куалап йөрү малайны ардырды, инде әллә кайчан ашыйсы килә башлаган иде. Әмма өйлә җиткәч, әбәткә кайтабыз, дип кенә торганда, этисе, атны тугарып, муенына дилбегә бәйләп, Габделхәйгә тоттырды да:

— Инеш буена төшер, чемченсен бераз, су да эчерерсең, үзеңә ризык алып килермен, — дип, егетләрчә эшләп йөргән малайның тел очларын пешерә-пешерә кабыклы бәрәңге ашау өметен кырт кисте.

Бөкрәеп чирәмгә утырды Габделхәй. Аннары инешнең текә ярына карап дөньясын онытты,— әлеге хәсрәтләре кинәт кенә юкка чыкты ке-

бек. Әнә, теге ярда озын булып наратлар үсә, шундый төз үзләре, ярның текәлегенә исләре дә китми, тауны үтеп күккә ашалар. Алгы тамырлары кояшка чыккан шома кәүсәле шул юан наратка хәтле менгәне бар Габделхәйнең. Шуның бөкре тамырына атланып, түбәндәге инешкә карап утырды ул. Әмма башы әйләнеп китте дә, аз гына мәтәлмичә калды. Аннары елга төбенә дә «дүрт аяклап» арты белән генә чигенеп төште. Күтәрелеп караган иде — тамырларын ачкан нарат өстенә авар кебек тоелды. Шуннан бирле ул тауга менгәне дә юк. Беркөнне көрәк-себерке сапларына яшь каеннар чабарга чыккач та, әтисе чакырса да, тау итәгендә генә калды, әтисенең башы әйләнмичә сикерә-йөгерә йөрүенә сокланып карады...

Алакай башта малай тирәсендә кимеренеп йөрде, аннары читкәрәк китте. Габделхәй дилбегәне тарткач, тагын аңарга якынлашты. Малай бер уч чирәм йолкып, атка бирде. Алакай аның нәни учын ялады.

«Син соң, балакай, нигә үзең ашамыйсың, минем качарлык чамам калмады, бар кайт, әле көн озын, сука артыннан йөреп хәлең бетәр»,— Алакайның Габделхәйгә караган кызгылт күзләре шулай диләр иде кебек.

— Ә син, Алакай, үги әнинең кара юртагыннан барыбер ун-унбиш тапкыр яхшырак. — Малай үрелеп атның яңагын сөйде. Алакайның инде качып китмәсенә ышанып, җиргә таянды. Күзләренә салмак кына, туктатып булмаслык итеп йокы төшә иде.

Үзәкләр өзелә — тамак тәмам ачты. Үги ана килгәч, ашау ягы такы-токыга әйләнде. Малайга табындагы калдык-постык кына эләгә хәзер. Ризык юклыктан түгел. Габделхәйләрнең келәтләрендә лар тулы бодай, арыш. Үги әни кысты дөньяны. Әтисе дә игътибарсызланды, малайның ашавын-ашамавын белеп-белешеп торсын иде ул. Юк шул. Беркөнне әтисе рус базарына йомышлаган иде. Аның күчтәнәч алып кайтуын озак көтте Габделхәй, ашыйсы килсә дә, үги әнисеннән ипи сорарга кермәде, капка төбендә көтте. Әтисе арба төбендәге юл кәрзиненә күчтәнәчкә дип прәннек, әтәч конфет, тагын... кыяклы суган тутырган булса! Аларны Габделхәйгә алып бирүен урамда ук күрсеннәр әле күрше малайлары!

Әмма әтисенә ияреп өйгә кергәч тә кәрзин тулы күчтәнәчтән аңа өлеш чыкмады.

Габделхәй, кече як сәкедә бүлмә тактасына сөялгән түшәкне аударып, йөзтүбән капланып ятты. Үксеп елады, ә елап ни файда соң...

Алакайның йомшак кешнәвенә уянды Габделхәй — әтисе килгән икән.

— Менә, — диде әтисе, куеныннан бер телем ипи чыгарып.

Әтисе үзе каерып кискән телем, үги әнисе Габделхәйгә ипине карындык калынлыгы гына җибәргән булыр иде. Их, шикәр дә булса... Габделхәйнең өйдә сабан туенда ук күрше әби биргән бер шакмак шикәре бар барын. Аның кайда икәнлеген әтисе белми шул, бишмәт кесәсенә яшерелгән ул, суырырга җәлләп йөри аны Габделхәй, почмагын киткән килеш тора. Әй, шикәрсез дә бик тәмле икән икмәк, бал тәмнәре килә, ә шикәр хәтле шикәрне тиз бетерергә ярыймы соң...

— Тизрәк бул,— дип уйларыннан бүлде малайны әтисе һәм күрсәнеп үз алдына әйтеп куйды: — их, заманалар...

Әтисе нәрсәгедер үкенә, кемгәдер ачулана кебек тоелды. Малай төшлектә өйдә зур тавыш кубуын, икмәкне әтисе урлап кына диярлек алып килүен белмәде.

Габделхәйгә алып барырга дип ризыклар төрергә кушкач, Гатифә кабынып-тузынып китте, Мортазаның уелган күңелен ботарларга тотынды.

— Бетмәс синең эрәм тамагың. Хайванга ашатсаң, симерер, ичмасам. Мин сине башта ук кисәттем, бел: я — мин, я — малай, дидем

— Бала бит ул, сарык бәрәне түгел — чалып ташларга. Кешеләр гарип-горабаны да авырыксынмый үстерәләр. Акылыңа кил. Аның үз өлешенә — ир бала өлешенә тигән җире бар. Җәй буена кырда бит ул бала, үзе үстерә.

— Соң, Мортазакаем, мин сине яратып хатынлыкка чыктым, — дип юхаланды Гатифә. — Мин китсәм, өченче хатынга өйләнермен, дисеңме? Булмас! Кем генә табылыр икән?! Шушы йорт-җирләрне юньләтү өчен күпме көч түктем, күпме байлык тоттым — минекеләр бит. Гомер итеп адәм яшәрлек өй дә житкерә алмагансың. Китмим, әнә, теләсәгез — үзегезгә ишек ачык! Бала кирәкми, чит-ят бала үстереп интегер хәлләрем юк. Тап җаен. Андый эшләр борын-борыннан була килгән. Икебез генә яшәсәк соң. Гөрләшеп... Я — мин, я — малаең...

— Булмый... Гөнаһның гөнаһына этәрәсең...

— Һәй, җебегән! Булмый да булмый! Булдыра белмәсәң, булмый инде! Мин сиңа нинди байлык белән килдем?! Күрәсең, нинди йорт житкердек?! Күз ачып йомганчы эшләттек, мин эшләттем. Юртагы тирәюньгә бер, артыннан бер ат җитә алмый — юл йөрүе хәвефсез. Көмешче Даут байны чакырып, калага көнен барып кайттым юртак белән. Килермен, диде. Мортазадан эшләтәсе әйберләрем дә бар иде, диде. Килсен! Элекке асраулары ни җимерткәнен күрсен бер! Син менә йөзек-беләзекләреңне күбрәк кой. Иген игүне бөтенләй ташларбыз. Алтында — бәрәкәт. Оста бит син көмеш эшенә. Менә бу иске йорт үзеңә эш урыны булыр. Кирәк, дисәң, быел ук эшең өчен кирпечтән йорт салдыртам. Һәм салдыртам! Алтын житәрлек әле миндә. Яңа өйдә икәүләп кенә яшәрбез, исемле-атлы кешеләр белән кунак-кунак уйнарбыз. Минем байлыктан болар. Ә синең байлыгың — әнә шул бала. Аның алтын-көмеш эшенә өйрәнергә нияте юк, кулы да ятмый. Һөнәр иясе булмагач, кирәге юк аның миңа! Әрәм тамак ул, көмеш эшен белмәгәч. Хезмәтче булырга да ярамый бит ул, ичмасам. Уйла, минем яшьлегемне дә уйла.

Мортаза озак кына дәшмәде. Аннары, нәтиҗә чыгаргандай, әйтеп куйды:

— Шулай, кешеләр менә ничек берсен-берсе ашыйлар икән...

Гатифә, аның сүзләренә игътибар итмәстән, үзенекен тезде:

— Син миңа йөзек-беләзекләр, алкалар кой! Бизәкләп. Даут бай кебек мин аларны казакъ арасына барып сатып йөрмәм, җаен белермен, патша хатынына бүләкләр илтермен, Истамбулына, Мисырына житәрмен. Я — мин, я — малаең...

Кичен әтисе исереп кайтты. Теге чакта Габделхәйнең үз әнисен ничек изеп ташлаган иде, ә бу юлы үги әнисенә кул да күтәрә алмады, әле Гатифә үзе Мортазаның билен сырлы бәләк белән сырды.

— Каткырысы, эчертермен мин сиңе! — дип, үги әнисе этеп җибәргәч, әтисе сәке йөзлегенә маңгае белән барып бәрелде. Их, әтисе үзе дә бер-ике тамызса соң, аның йодрыклары эләксә, Гатифәң яртылаш сеңәр иде — Габделхәйне кыерсыткан-каккан өчен үч кайтару булыр иде. Әтисе бөтенләй мәлҗерәгән иде шул.

Гатифә кунарга яңа өйгә менеп китте.

Габделхәй идәндә аунап яткан әтисен сәкегә салмакчы булган иде дә, көче житмәде, баш астына мендәр генә кыстырды, өстенә юрган япты. Үзе, әнисе авырып яткан кызыл шакмаклы түшәккә чумып, төнне йокысыз үткәрде. Күңеле тынычлана алмады, йөрәк менә-менә дөньяларны иңләп ярсып китәр кебек, әмма талпынып кына кала, нәфрәт көчле булса да, тышка бәреп чыгарлык фикер тумый.

Малай иртәнге чәйдә самавар артына посып утырды, алдына куелган ризыкның бар булганын ашап, ишегалдына чыкты.

Әтисе Алакайны җигеп өлгергән иде инде. Айнып та җитмәгән — күз кабаклары кысык, әледән-әле башын селки, уфылдый. Арба төбенә җәелгән кабык ярыгына балта кыстырды.

— Әйдә, Габделхәй улым, кузгалыйк әле...

Үги әнисе, Даут бай килүенә дип, яңа өйдә пешеренеп-төшеренеп калды.

Урманга менәбездер инде, дип уйлады малай. Соңга калган җәйнең тузанлы юлына ул талчыбык белән суккалап бара. Чыбыкның яфраклары берәмләп коелды. Инде чыбык чыжлый гына, лепелдәми, кызыгы бетте...

Әтисе сул аягын арбага сузып, уң аягын салмак кына селтәп бара. Кинәт, нәрсәгәдер ачуы килеп, тәгәрмәчкә тибә. Аннары тынычлана кебек. Ул чалбар кесәсеннән пәке алып Габделхәйгә бирде.

— Мә, улым, сиңа булыр.

— Ә үзеңә?

— Миңа кирәкми.

— Рәхмәт, әти.

— Дәү үс...

Габделхәй күптән кызыгып йөри иде шушы пәкегә. Әтисе аңа икенчене ясамакчы булган иде дә, әллә ничек вакыт җайлый алмады шунда. Моның белән малайларга мактансаң да ярый! Пәке ич ул, тиле! Әтисе ясаган пәке! Авылда беркем дә болай ясый алмый. Әтисе, әнә, гүпчигә үзеңә булыр, диде. Рәхмәт инде әтисенә, ничек шәп итте бит пәкесен биреп! Сынык чалгыдан ясаган иде аны әтисе, озын итеп. Сабын кырып эшләде, пыяла белән шомартты, сабы әнә ничек кәкрәеп килгән — тотарга җайлы.

Малай пәкесе белән чыбыкның кабыгын куптарды. Нинди матур булды! Пәке шәп шул!

Чыбыкны малайларга күрсәтеп мактанырга дип арба төбенә салганда, чәнчи бармагы ялгыш балта йөзенә тиде дә, урак кискән ярасы каный башлады. Шунда кинәт әнисе исенә төште.

— Учмаңны чамалап кис, чәнти бармагыңны уракка эләктерә күрмә, улым, — дип гел кисәтә иде ул.

Ә быел тәки кистерде бит. Авыртты да соң, җитмәсә, үги әнисе бәйләргә чүпрәк тә бирмәде. Малай өйгә йөгереп кайткач:

— Чәнчелмәссең әле, карап маташалар аны, бәбәй, бар, әйдә уруыңны бел! — диде.

Габделхәй бармагын әрекмән яфрагы белән төреп куйды...

Казлар каңгылдашкан тавыш ишетелде — Кара күлгә җитәләр икән. Казлар дигәннән, былтыр Габделхәй суга чалкан яткан бер казны коткарган иде шушы күлдә. Иптәш малайлары белән су коенырга килгәч булды бу. Шушы хәлне ул әнисенә сөйләгән иде.

— Рәхмәт, улым, исән калган бит менә, син ярдәм итмәсәң, үлгән булыр иде шунда, — дип сөендерде аны әнисе.

Күр инде, башка нинди уйлар керә. Кара күлгә якынаеп казлар тавышын ишеткәч, мескен зәгыйфь каз бәбкәсе исенә төшеп тора бит малайның...

— Их, заманасы... хәлләре, — дип куйды әтисе, күгәргән күз төбен сыпырды.

Арбаның ике ягына утырышып, эндәшмичә-сөйләшмичә килгәндә, әтисенең бу сүзләре Габделхәйне сискәндереп җибәрде. Аның офтанунда малай ниндидер ачу һәм явызлыкка җиткән ярсу сизенде.

Кара күл. Ярының иң биек төшеннән күз салсаң, ул кап-кара булып күренә, дегет карасы. Калкулыкта тирән чокыр булып торгангамы, җил искәндә дә күл дулкынланып иркәләнә белми — аның өсте шомартылган кебек. Тик көн төшкә авышкан чакта гына күлнең өсте беразга шадраланып ала. Бу вакытта монда берәү дә коенмый, йөзгәндә тал яфрагыдай озынча шадраларның үткен пәке булып муенга уйнаклыйуйнаклый бәрелүе шикләндерә, күрәсең, кешеләрне...

— Улым, әйдә, су коеныйк, — диде Мортаза, Алакайны тугарып җибәргәч.
Габделхәй, нәрсә әйтергә дә белмичә, аптырап торды.
— Су салкындыр, әти...
— Җәй көне кебек бүген, бер дә сентябрь димәссең, кояшы шәп кыздыра. Хәл кереп китәр, бүтән әллә коенып була, әллә юк быел...
Чирканчык алгач, суның салкынлыгы артык тоелмады. Алар шактый озак йөзделәр, уртагарак та керделәр. Коенып чыккач, Мортаза киенмичә генә чирәмгә утырды да Габделхәйне үз янына чакырды. Малай бер сүз дә дәшмичә әтисенең алдына керде, иркәләнәсе килеп, әтисенең тезенә башын салды. Кинәт аны гамьсезлек, нинди дер онытылу биләп алды, чәчләрен сыйпап әтисенең иркәләве шулай иттте, ахрысы. Дөнья хәзер, нигәдер тигез иде, анда кайгы-хәсрәт чигеп яшисе дә юк кебек иде. Әнә, төпсез күктә сыек болытлар йөзә... Алакай кешни... Әмма, никтер әтисенең күзләреннән яшьләр ага...
«Улым, улым, Габделхәем, кичер мине... Мин гөнаһка баттым, мин сине.... Гатифә кушкач... Кичер... Авыл катындагы урманлы тауга алып менеп, текә җиреннән тәгәрәтергә уйладым, күрми калганмын, дип аклануым әзер иде — син тауга менмәдең... Урманда өстеңә агач аударырга исәпләдем. Анысына да җавабым бар иде, ә син сизгер идең... Бүген менә... суга батырмакчы идем... Гатифә шулай кушты. Булдыра алмыйм мин моны. Үзем тормыш бирдем мин сиңа, аны кире алырга вөҗданым кушмый, хакым да юк... Кичер гөнаһымны, кая телисең — шунда кит! Мин язмышымны үзем хәл кылырмын...», — дип уйлый-уйлый Мортаза Габделхәйне кочаклап үкседе, ләкин күзләренә туры карый алмады.
— Улым, бәхет юк сиңа монда... Кит син, кит, Алакайны калдырма...
Күзләреннән ачы яшьләр ага әтисенең, алар Габделхәйнең битенә тама, алар битне чеметә...
Мортаза малаен иләп кенә җиргә куйды да, Кара күлне тетрәндереп:
— Улым-м-м!.. — дип кычкырды һәм ботарланып суга сикерде...
Кире чыкмады Габделхәйнең әтисе...

Малай өйгә җәяүләп кайтып керде. Нигә кайтты, нинди нияте бар иде?
Яңа өйнең өске катында кысып куелган ут яна. Габделхәй ишеккә килде — бикле. Тәрәзәдән керде. Бүлмә тактасы буендагы чыбылдык корган киң караваттан ак күлмәк-ыштан кигән бер ир төште, аннары Гатифә күренде. Икесенең дә күңелләре күтәренке.
— Ә син икән, йолкыш. Каян кердең? Нишләп йөрисең, черек баш...
— Мин... әти... ни...
— Бетмәдеңмени әле син, килмешәк? Хәзер үзем, синең җебегән атаңнан эш чыгамы соң...
Гатифә чәчләрен тузгытып малай өстенә килә башлады.
Килсен, әйдә, якынрак килсен...
Хатын кинәт гөрс итеп идәнгә ауды, ачык күкрәгенә сабына тикле пәке кадалган иде.
Ишек катында телсез калып, Даут бай калтырана. Нәрсә булганын ул да, Габделхәй үзе дә төшенеп җитми иде әле.
Идәнгә кан җәелде. Малай аны күрмәде, күзләре тонып-туңып баралар иде. Ул салкын битарафлык белән, ишекнең келәсен ычкындырып, ашыкмыйча гына чыгып китте. Үз өйләренә керде. Сандык төбеннән төргәк алды, аны сүтте һәм әтисе әнисенә коеп биргән кашлы йө-

зекне, беләзекләрне, чулпы-тәңкәләрне, тамчы алкаларны әйләндерә-әйләндерә карап торды.

...Төн, мәгънәсез караңгы төн. Кара күл. Яр читендә әнисенең истәлекләрен куенына кысып, Габделхәй басып тора.

Кинәт Кара күл чокырын күкрәтеп, аны яшендәй телгәләп, Габделхәй тавышы яңгырады:

— Әти-и-и!..

Үзәкләрне өзеп, Алакай кешнәде.

Шушы Кара күлгә килсәң, аның дегет карасыдай уртасы, алланып торган кырыйлары, яшел ярлары сиңа борынгы кайтавазны ишеттерә кебек:

— Улым-м-м!..

— Әти-и-и!..

Төнге ярда Алакай кешни...

## Альберт Хәсәнов

# ФӘНДӘМ ФОНДЫ

хикәя



Ерак Себердән Мәскәүгә юллаучы һава корабы кинәттән генә түбәнәя башлады. Ярым йокымсырап, газета-журналлар караштырып утырган пассажирлар сәерсенеп сәгатьләренә карадылар, чөнки иртәрәк иде әле. Главкада ясыйсы отчетын тагын бер кат күздән кичереп утырган Мәүлет Мурзин да, алдында яткан күн папкасына кәгазьләрен җыештырып, түш кесәсеннән чылбырлы сәгатен чыгарды. Колагына куеп тыңлап караганнан соң, кемгә дә булса, мөрәҗәгать итүдән бигрәк, үз-үзенә сөйләнеп:

— Алай... Безнең кораб иртәрәк якорь ташларга җыена бугай. Ярар, хәерлегә булсын,— дип куйды.

Самолет куе болытларны ертып түбәнәя барды. Ул да булмады, лайнер дөк иттереп бетон полосага утырды һәм кар бураннары туздырып йөгереп тә китте. Шул рәвешчә өч-дүрт минутлар чапканнан соң, түбәсендә локаторлар әйләнеп торган ике катлы бина алдына килеп туктады.

— Менә сиңа кирәк булса!—дип куйды берәү. Мурзин белән әле Новосибирскида ук танышып өлгергән, әле теге, әле бу күршесенә сүз катып, башыннан узганның барын сөйләп, нужа суын күп эчсә дә, терекөмеш бөртеге кебек бөтерелеп торган татар карты иде бу.— Ышанып утыр син, боларның канатсыз кошларына. Борынгылар: «Мәккәгә дип сәфәр чыксаң, Мәдинәгә барып чыгарсың, дип белми әйтмәгәннәр шул».

Ул арада кемнәрдер тәрәзә аша:
— Ка-зан аэ-ро-пор-ты!— дип укыды. Аларны менә кая китереп утыртканнар!
Салонда:— Моторы сафтан чыккан булгандыр, әйтмәгәннәрдер генә. Ярый әле, монда исән-сау килеп төштек, шуңа сөеник,— дип пышылдашкан шик-шөбһәле хатын-кыз тавышлары ишетелде. Әмма имеш-мимешләрне артык куертырга урын калмады. Салонга матур елмаеп, кашкүзенә куе итеп сөрмә тарткан, чәчләрен килештереп тараган стюардесса килеп чыкты. Бары да аңа төбәлделәр.
— Әйе, иптәшләр, без Казан аэропортына төштек,— диде ул.— Кичә Европага Төньяк боз океаныннан бәреп кергән көчле циклон, бу сәгатьләрдә Мәскәү өстеннән уза. Башкаланың бар аэропортлары да ябык. Үзәктән безгә өч шәһәрне: Казан, Куйбышев, Горькийны тәкъдим иттеләр. Без менә Казанны сайладык.
— Их, чибәрдиссә кызым, чибәрдиссә кызым! Самарга гына утырырга акылыгыз җитмәгән икән,— дип теге карт тагын сүзгә кушылды.
Ә кыз:
— Бер генә минутка гафу!— диде дә, кулындагы кечкенә генә белешмә китабына күз салгалап:
— Казан — Татарстан АССРның башкаласы. Халкы миллионнан артып китте. Бик матур шәһәр, зур культура үзәге,— дип пассажирларга Казан турында мәгълүматлар бирә башлады һәм бераз сөйләгәч:
— Кыскасы, иптәшләр, сезгә иркенләп шәһәр карап йөрергә тәкъдим итәбез. Чөнки сезне бирегә кичке дүртләргә генә көтәбез,— дип сүзен тәмамлады.
Мурзин янә дә сәгатенә карап алды. Вакыт әле иртәнге уннар тирәсе. Кичкә хәтле күпме буш вакыт бар. Әлегә башында төгәл бер планы булмаса да, вакыт күплектән канәгать калып, чак кына елмаеп куйды ул.
— Экскурсиясе аның ярый торган нәрсә дә бит,— дип сузды Мурзин артындагы креслода моңа кадәр тавыш-тынын чыгармыйча гына йокымсырап барган такыр башлы, юантык гәүдәле бер агай.— Миңа бүген министрга керергә иде бит! Өч ай көтеп йөрдем. Понимаете, өч ай! Эх, чәнчелеп кенә китсен, тагын булмады,— дип ул кулын селтәде.
— Һай, таптың кайгырыр нәрсә!— дип бүлдерде аны алтын тешле, кара мыекле кавказлы агай.— Министрың Мәскәүдән чыгып качмый торгандыр ич! Бүген өлгермәсәң, иртәгә керерсең. Кабинетында туры китермәсәң, дачасына эзләп бар. Ә мин менә чыннан да беттем. Бүген икедә минем Ашот, дуңгыз, язылыша. Кырык эшемне кырык яры ташлап, самолетка менә шуның аркасында утырдым. Улым, муеныңа камыт кияргә ашыкма, аңа кайчан да өлгерерсең, дип ни әйтә тордым. Икенче курста гына укый бит әле, башсыз нәрсә. Минем сыртны үзе каезлау гына җитмәгән, хәзер икәү менеп атланырга, икәү каезларга җыеналар, күрәсең. Миңа җомга көн сәгать икегә килеп җит, без Соня белән язылышабыз дип, срочный телеграмма суккан. Нинди Соня, кем кызы, анысын шайтан белсен. Моннан бер ай элек, җәйге каникулга Нина белән кайтырга җыенабыз, дип язган иде. Вах-вах, нишләргә хәзер миңа? Кем белә, моннан Мәскәүгә еракмы? Такси яллаcам, сәгать икеләргә Мәскәүгә илтеп җиткерәме?
— Иптәшләр, мин барын да аңлыйм. Ләкин ни эшлик соң? Мин дә бик ашыгам. Аэропортта мине нәни кызым белән ирем каршыларга тиешләр иде,— диде әлеге «чибәрдиссә», пассажирларының хәленә кереп.— Безгә бары тик түзәргә, һава ачылганчы көтәргә генә кала.
Шулай да һич көтмәгән, уйламаган җирдән Казанга килеп әләгүчеләр арасында көенүчеләр генә түгел, сөенүчеләр дә бар иде. Анысы — Мәүлет Мурзин. «Казан» дигән сүзне ишетү белән йөрәге аның тартылып куйды. Йөзенә әсәрләнү билгесе чыкты. Шулай булмыйни! Соңгы

елларны «без — сибирякларl» дип күкрәк сугарга күнегеп китсә дә, асылда Татарстан егете бит ул. Яшьлегенең иң матур чорында Казанда яшәде, укыды. Дөрес, монда аның инде байтак еллардан бирле булганы юк. Дөресрәге, була алганы юк. Университетның геология факультетын тәмамлагач, эшкә Якутиягә билгеләделәр. Мурзин татар егетләренә хас тырышлык, күндәмлек һәм беркадәр үҗәтлек белән Европаны сыйдырышлы Якут киңлекләрен аркылыга-буйга иңләргә кереште. Бүгенге көннәрдә дөньяны шаулаткан якут газын табуда да аның хезмәте зур булды.

Егет гади геологтан башлаган иде. Аннары өлкән интерпретатор итеп күтәрделәр, партия на́чальнигы итеп билгеләделәр. Составында ике йөз, өч йөз кеше булган экспедицияләр белән дә җитәкчелек итте. Ике ел Әфганстанда, дүрт ел Иранда эшләп кайтты. Илгә кайткач, җылы урын эзләмәде, яңадан Якут якларына кайтаруны сорады. Хәзер ул бирedәге газ чыгару идарәләренең берсендә баш геолог, фәннәр кандидаты. Сәфәр чыгуы яңа ачылган газ ятмаларын промышленность максатларында файдалана башлау мәсьәләләрен тагын бер кат ачыклау иде. Әмма көтмәгән җирдән Казанга килеп эләгүенә ул чиксез шат. Күңелендә дулкын-дулкын булып матур тойгылар уянды. Үзе якын, үзе сагынылган, инде байтак еллардан бирле күрелмәгән матур каланың урамнарыннан ашыкмый гына үтәсе, бакчаларына кереп уйланып утырасы килеп китте.

Мурзин беренче эше итеп университетка кереп чыгарга булды. Дөрес, бу яклар белән ул күптәннән бәйләнеш тотмый. Аңа күбрәк Фәннәр Академиясенең Себер филиалы белән эш йөртергә туры килә. Диссертациясен дә Новосибирскида яклады. Әмма шулай да, факультетта я кафедрада ул белгән кем дә булса бардыр әле. Мурзин партия начальнигы булып эшләгән елларны җәйге практикага Казаннан студентлар килә иде. Университетта аны күбесе хәтерли, әле теге, әле бу профессор аңа сәлам әйтеп җибәрә. Әлеге студентлар аша Мурзин аларга үзе дә күп сәламнәр юллап торды. Ләкин болар барысы да моннан күп еллар элек булды шул инде. Белмим, кафедрада хәзер аны хәтерләүче, барып керсә, танып кул бирүче булырмы икән? Хәер, эш анда гына мени! Хәтерләү, хәтерләмәү монда һич тә шарт түгел. Очар кошлар да бит туган җирләренә үзләрен хәтерләтү, таныту өчен кайтмыйлар. Аңа да үзе укыган заллардан узса, иптәшләре, сабакташлары белән «терәтеп торган» стеналарга кулы белән кагылса, шул җиткән...

Стюардесса исә бик уңганнардан булып чыкты. Ни арада кемнәр беләндер бәйләнешкә кереп, сөйләшеп, автобус юнәткән. Пассажирларын үзе белән шәһәргә экскурсиягә төшәргә чакыра.

Мурзин экскурсиягә катнашырга җыенмый иде. Башкалардан аерылып, ул көтү залына чыкты.

Хәзер кая барырга? Университетка төшсә дә аптыраш. Анда хәзер занятиеләр чоры. Кемне генә күрер дә, кем белән генә сөйләшер. Әллә туп-турыдан студентларның тулай торагына китәргәме? Анда комендант булып, яшь чагында Кара диңгез хәрби флотының мичманы, аннары Ватан сугышы инвалиды, кыскасы, сөйләшеп, гәп корып утыру өчен дөнья бәясе кеше, дядя Жора тора иде. Әгәр исән булса, аны табу берни тормаячак. Менә шулай икеле-микеле уйларга чумып, Казан буенча сәяхәтен кайдан башларга да белми утырганда, Мурзинның исенә кылт итеп, аның пани Данусяда яшәгән чаклары килеп төште. Әйе, беренче эше итеп аңа менә кая барырга, менә кемне күреп чыгарга кирәк. Чынлап та, пани Данусяны хәлләрдә икән. Булды, хәл ителде, ул хәзер үк пани Данусяларга төшеп китә. Анда буш кул белән барып керү килешмәс. Студент чаклары түгел ләбаса. Мурзин урыныннан торып, буфетка юнәлде. Күчтәнәчкә тәмле-тәмле әйберләр алды. Шунда пани Данусяның зефир яратуы исенә төште. Аңарда торган егетләр

практикалардан кайткан чакта, аңа күчтәнәч итеп һәрчак зефир алып кайталар иде.

Мурзинның матур яшьлеге узган шәһәрнең тукталышларында туктап, урамнарына троллейбус тәрәзәсе аша ашыкмый гына карап, уйланып төшәсе килде. Ул шулай итте дә. Буш урыннарның берсен сайлап, тәрәзә янына килеп утырды.

Алай... Вакытның узуын гына күр инде. Егерме ел гомер аккан су булып узган да киткән. Ә бит ул шушы калага әле кайчан гына мыек та чыкмаган унҗиде яшьлек егет булып килгән иде. Геолог булырга теләде. Документларын университетның геология факультетына тапшырды. Имтиханнар вакытында математика белән сердәш булуын Мәүлет тагын бер кат танытты. Аудиториягә кергәч, парта артына утырып, мәсьәләсен кәгазьдә чишеп маташмады. Билетка күз йөртеп алу белән такта янына чыгарга рөхсәт сорады. Кулына акбур алды да, пространствода күзаллап чишүгә корылган башваткычның өч төрле ысул белән чишелешен бер-бер артлы язды да чыкты. Мәүлет, маңгаена төшкән коңгырт чәчләрен артка сыпырып, мәсьәләнең дүртенче юл белән чишелешен язарга әзерләнде. Кырыйлары ука белән чигелгән кәләпүшле, калын пыяла күзлекле карт профессор аны:

— Мин канәгать, дустым. Тулысы белән канәгать,— дип туктатты. Профессор кайбер хәрефләрне йотыбрак, ничектер бараз сакаурак сөйли иде.

— Бе-ер сү-зем юк. Чын Эве-рест Га-луа! Лобачевский!— дип аркасыннан какты.— Тик шунысын гына аңламыйм. Нигә геологияне сайладыгыз? Ни өчен мехмат түгел? Хәер, анысы сезнең үз ихтыярыгыз. Яхшы геолог булу өчен дә,— карт профессор бармагы белән идәнгә, үзе басып торган җиргә күрсәтте,— табигатьнең анда яшеренгән серләрен ачу өчен, минемчә, шулай ук яңа Галуалар, Лобачевскийлар, Колмогоровлар кирәктер. Уңышлар телим, дустым, зур уңышлар. Сезнең белән танышуыма шатмын, бик шатмын.

Мәүлетне ишеккә хәтле озата килде профессор, саубуллашып кулын бирде. Зачеткасына Мурзин коридорга чыккач кына күз салды. Профессор аңа «отл», «отл», «отл», дип рәттән өч отлично тезгән. Менә шул отличнолар ачтылар да инде аңа университет ишекләрен. Башка фәннәрдән имтиханнарны ничек тапшыруын, алардан нинди билгеләр алуын ул хәтерләми дә.

Әйе, укырга әнә шулай җиңел генә керде, ә менә фатирга урнаша алмый байтак интекте. «Абсолют ирекле гражданнарның абсолют сыйныфсыз җәмгыятенә» әгъза булып кергәнче, ягъни авылдашы Виктор Курагин аны урамда очратып пани Дануся фатирына алып кайтканчы, аңа байтак нужа күрергә туры килде.

Бер көнне шулай квартир эзләп йөргәндә, тимер-юл вокзалына сугылды. Машинист малае бит, күңеле тарткандыр. Керсә, әллә ничә зал. Бер башында халык күп булса, икенче башы бушрак. Яшь балалы аналар залында гомумән тынлык. Мәүлет кунарга, ягъни төн уздырырга шушында төшә торган булып китте. Әлеге залда зур мич артында тын гына урын бар. Мәүлет мыштым гына керә дә шунда поса. Йокы ястык сорамый ди. Аның шулай икәненә Мәүлет тә ышанды. Пассажирлар арасында көйсез балалар булмаганда, төн сизелми дә уза. Ә кайбер төннәрне һич тә ястык таләп итмәгән йокыны монда да бүлгәлиләр. Вокзал тирәсе бит, кем булмас та, кем йөрмәс. Таң алларыннан, йокының иң татлы вакытында тимер-юл милициясе залларга тентү ясый. Шиклерәк күренгәннәрнең документларын тикшерә. Мич артында мәлҗерәп йоклап яткан Мәүлетне дә җилтерәтеп уяталар. Бүлеккә алып керен киталәр. Куенындагы дүрт калын дәфтәреннән, кесәсендәге документларыннан аның кем булуын тиз ачыкласалар да, башыннан сыйпамыйлар, бармак янап орышалар. Нигә монда кунып йөрисең, икенче

eләгә калсаң, укыган жиреңә хәбәр итәбез, дип куркыталар. Мондый янауларга гына бик исе китә инде Мәүлетнең. Ул да хәзер эт каешына әйләнеп бара. Авыл җирендә, буразнада аунап, тормышның ачысын-төчесен яшьли татып үскәнлектән, Мәүлет зарланмый, үзенең хәлен чыдарлык, түзәрлек дип саный иде.

Мурзин утырган троллейбус елга портына хәтле төшә икән. Аңа Киров урамына хәтле дә ярый. Әмма ул Кольцода төшәргә, калган юлын җәяү генә дәвам итәргә булды. Сагынылган, ничек кенә сагынылган икән Казан, яшьлеге үткән кала! Тәрәзә аша урамнарга карап барганда, һәр тукталышта үзенә бер әсәрләнә Мәүлет. Аларның һәркайсы аның күңелендә үзенә бер вакыйга, үзенә бер татлы истәлек булып уелып калган икән. Менә Горький паркы тукталышы. Бу паркка да күп йөрде ул. Университетның ул елларда үз стадионы юк иде. Физкультура дәресләре, төрле ярышлар гел шушында уздырыла. Беренче кар төшкәнне, чаңгыга басар чакларны Мәүлет елның-елында түземсезләнеп көтеп ала торган иде.

Троллейбус «Академия театры» тукталышына килеп җитте. Бу тукталыш та аңа туган йорты, үскән нигезе кебек якын иде. Ул елны театр сезоны «Башмагым» комедиясе белән ачылды. Алар бөтен группалары белән культпоходка хәзерләнеп, билетны алдан ук алып куйганнар иде. Бер үк группада укыган Казан кызы Асия спектакльгә әнисен дә алып килгән. Инде нишләргә? Билет каян табарга? Мәүлет күп уйлап тормады, ничек тә «артык билет» табарына ышанып, Асиягә үз билетын бирде. Әмма ул кичне «артык билетлылар» күренмәде. Беренче звонок та, икенчесе дә, өченчесе дә шалтырады. Халык кереп утырып бетте. Мәүлет ишек катында бер үзе басып калды. Инде кайтып китәргәме дип кенә торганда, уттай атылып, ике кыз килеп керделәр. Менә бәхет! Бер «артык билетлары» да бар. Әйе, кеше дигәнең бәхетен менә шулай һич көтмәгәндә дә табып куя икән. Кызлар билетны ертып та тормадылар.

— Урыннар рәттән, кергәч разберемся, — дип, аны үзләре белән алып кереп тә киттеләр. Мондый кичләр, мондый спектакльләр, мондый уңышлар егет тормышында бер генә була торгандыр ул. Сезон ачылу хөрмәтенә артистлар да аеруча тырышып уйнадылар шикелле. Ә Мәүлетнең күзе кызларда гына. Кара кашлы, кара күзле, озын толымлы, нечкә биллесендә. Аңа әледән-әле серле караш ташлап утыручысында. Анысы инде бик табигый, шунда ук танышып та киттеләр. Сәрия исемле булып чыкты ул кыз. Андый чакта Мәүлет бәясен төшерүчеләрдән түгел. Соңыннан ярты ай буена ачлы-туклы яшисе дип тормады, барлы-юклы акчасына такси алып, кызларны Каравай ягына хәтле озатып куйды. Ә соңыннан шушы Сәрия аның гомерлек хатыны булды.

Күңеленең иң түреннән кузгалып, бөтен халәтен биләгән шундый татлы хисләр Мурзинны тәмам биләп алды. Мәүлетнең троллейбустагы һәр кешенең килеп кулын кысасы, кочасы-үбәсе килә башлады. Гаҗәп минутлар кичерә иде ул. Бер уйласаң, күп җирләрдә булып, күпме илләрне гизгән, ил-дәүләт колачлары белән исәп-хисап, фикер йөртергә күнеккән ир уртасы лабаса. Болай мәлҗерәп төшү аңа бер дә килешми югыйсә. Ә йөрәк дигәнең әнә ничек дөпелдәп тибә. Чаңгы ярышыннан кайткан диярсең.

Мурзин Кольцодан атлый. Күр генә син биредәге үзгәрешләрне. Менә бу ундүрт катлы кунакханә юк иде бит аның заманында. Ә менә бу универмаг! Кай арада салып куйганнар. Әмма Мурзинны гаҗәпләндергәне кешеләр, урамнан агылган халык иде. Кара, күр генә син аларны, ничек горур басып атлыйлар. Ә Мурзин заманында ничектер башкачарак иде шикелле.

Атлый торгач, ул Болак буена да килеп чыкты. Яңа мунчага, «Дуслык» кунакханәсенә сокланып узды. Теге чакта, кичен соңлап кына вок-

залга, тагын бер төнне уздырырга төшеп барганда, Виктор аны шушы урамда тотып алды бит инде. Тотты да, үзе белән алып китте. Виктор аны шушында алып кайтты. Йортны күргә, Мәүлет үзе дә сизмәстән: — Уф, юкка ут йотканмын, урынында икән бит! — дип җиңел сулап җибәрде. Нигә? Сүтеп ташлаулары, аның урынына яңаны корып куюлары да бик мөмкин ич. Әнә теге баштан ничек үзгәртеп корып киләләр. Тимер капка да исән. Мурзинның эченә бөтенләй җылы керде. Капканың сыңар ишеге, аның заманында ук шулай кыек, «Рәхим итегез!» дигән төсле бер якка янтаеп тора иде. Күргәч тә уңда, кемдер тарафыннан бик хасиятләп, баф күңел җылысын, кул осталыгын салып ясаган эт оясы бар. Анда — бер көтү көчекләре белән Актырнак яши иде. Бөтен ишегалды бала-чагасы шушы Актырнак оясы янында була торган иде. Аның үзләре йонлач, үзләре туп кебек түгәрәк, курчак кебек матур көчекләрен, алар ни эшләтеп кенә бетермиләр. Куеннарына да тыгып йөриләр, бишеккә салып та тирбәтәләр. Чанада тартып та китәләр, велосипедка утыртып та әйләндерәләр. Шушы галәмәттән тәмам гарык булгач, Актырнак түземлеген җуя, малайларның берәрсенә я алгы тәпи белән чәпи, бик туйдырганын, моннан башкача котылу мөмкин түгел дип, юри генә тешләп тә куя. Ишек алдында куба гауга, куба дау. Теге малайның әнкәсе Актырнакны котырганга санап, аны һич кичекмичә юк итүне таләп итә. Калганнар Актырнакны яклап чыгалар. Мондый җәнҗалларны Актырнак үз гомерендә күп күрде. Ул кайгырмый, офтанмый, борчылмый. Җәнҗалның ни белән бетәсен белә ул. Оясының яссы төбәсенә менеп, алгы тәпиләренә башын салып, тын гына тыңлап ятуын белә.

Берзаман Актырнак япа-ялгыз кала. Күрше ишек алды малайлары аның тагын да үсә төшкән, тагын да матурайган көчекләрен үзара бүлешеп тә бетергән булалар. Әмма күп тә үтми, Актырнак тагын бер өер шундый ук матур көчекләр китерә.

Шушы маэмайның зирәклегенә бөтен ишегалды халкы хәйран кала иде. Йөздән артык квартиралы ишегалдында күпме халык яшәгәндер. Актырнак шуларның барысын да белеп, танып тора иде. Җиде төн уртасында кайтып керсәң дә каршыңа өреп чыкмый. Ул сине аяк атлавыңнан ук таный. Әгәр инде ишегалдына берәр ят кеше килеп керсә, шиклерәк тә күренсә, аны утлы табага бастырып куып чыгара.

Күңелен тәмам биләгән матур истәлекләрдән арына алмыйча, Мәүлет әкрен генә эчкә атлады. Шунда ук аның каршына дүрт көчек иярткән зур гына бер маэмай өреп килеп чыкты. Бу Актырнак түгел иде, әлбәттә. Әмма усаллыкка аннан һич тә калышмас. Мурзинның чабуыннан чак кына эләктереп алмады. Шушы хәл аның күңелендә нииндидер матур өмет, ничәмә еллардан соң да монда килүенең табигый булуына ишарәле татлы уйлар кузгатты. Маэмай да, аның күңелен сизенгәндәй, бер-ике генә һау-һаулап, балаларын ияртеп, ишегалдының аргы башына китеп барды.

Мурзинның хәзерге халәтен сөйләп бирерлек тә түгел. Шушы ишегалдына ничәмә еллардан соң эзләп, сагынып килеп аяк басуы бит. Атлаган адымы саен нинди дә булса яңалык, көтелмәгән хәбәр көтеп. өч катлы кирпеч йортның өченче подъездына керде. Җырлап торган баскычтан икенче катка күтәрелде. Зур тоткалы ишекне үзенә тартуга, борынына кыздырган бәрәңге, теш пастасы, итек кремы исе килеп бәрелде. Болар барысы да тереклек булганда, гөр килеп тормыш корып ятканда гына туа торган исләр. Моңа сөенми мөмкин түгел.

Ярым караңгылыкка күзе күнеккәнче Мурзин ишек катында торды. Бераздан ул коридор стеналарына эленгән велосипед, озынча ләгән, тагарак кебек әйберләрне шәйли башлады. Озын коридор буйлап

ике-өч квартирага бер газ плитәсе. Алар янында төрле вак-төяк өчен кечерәк кенә шкафлар. Бары да нәкъ ул яшәгән заманнардагы кебек. Теге көзге кичтә авылдашы Виктор Курагин аны шушы коридорга алып кайтты. Коридор буйлап өч ишекне узсаң, дүртенчесе пани Дануся квартирасы. Дулкынланып, Мурзин ишек каршына килде. Күтәрелеп карады да, сискәнеп китте. Ишекне танымады. Заманында бикне белмәгән, ябылып торуны күрмәгән җилбәзәк ишек урынында затлы кара дермантин белән тышланган, эшләпәле җиз кадаклар белән бизәкләнгән түрә ишекне күрде ул. Тотка өстендә биш тиенлек акча хәтле генә английский йозак тишеге. Күзлегенне киеп карамасаң, ачкыч тыга торган җирен дә таба алырлык түгел. Министр кабинетына да һич каушамый кереп йөргән Мурзин, шушы ишек каршында коелды да төште. Бу ишек артында хәзер кемнәр яши икән, пани Данусямы? Исәндер, исәндер, нигә исән булмасын? Әмма Мурзин шалтыравыкка басарга ашыкмады. Авыр портфелен идәнгә куеп, стена кырыенда торган сандык өстенә утырды. Коридордан берәрсе узмасмы, күрше ишекләрнең берәрсе ачылмасмы, дип көтә башлады. Әнә теге башта кер кайнатырга куйганнар. Икенчесенең плитә өстендә келтер-келтер чәйнек кайный. Әмма коридорга ник берәү чыксын. Ул яңадан каршындагы ишеккә төбәлде. Күз алдына дулкын-дулкын чәчен килештереп бер якка тараган, киң яңаклы, кысыграк күзле Виктор килеп басты. Мурзин аның артыннан ияреп теге кичтәгечә эчкә узды. Кергәч тә чаршау белән генә аерып куйган, тар гына чишенү урыны. Егетләр өс-башларын чөйгә элгәч, залга керделәр. Анысы — ике тәрәзәле озынча бүлмә. Тәрәзәнең, каршы йорт шәүләсе төшмәгәне, яктырагы каршында аяклы тегү машинасы. Аркасына шакмаклы калын шәл салган мөлаем йөзле бер апа башын да күтәрми нидер тегә. Түрдә зур комод. Аның өстендә будильник, ике башында ике зур курчак. Бүлмәгә керүчеләрне сәламләгәндәй, борыннарын югары күтәреп, комодның бер башыннан икенчесенә хәтле унбер фил тезелешкән. Барысы да сары мәрмәрдән. Уртада матур шкатулка. Монысы, Мәүлет соңыннан белгәнчә, «Фәндәм фондының» саклык кассасы.

Стена буенда әүвәлге заманча иркен итеп чикләвек агачыннан ясалган, үзе ярты бүлмәне биләп торган кием шкафы тора. Әмма хәзер ул бөтенләй башка максатларга хезмәт итә. Аның башына, кирәккәндә шалт итеп кенә кабызырга ут көйләп, колагына киеп тыңларга радио үткәреп, Александр Суворов — да не тот, менеп урнашкан. Биш ел буена шуннан төшмәде ул. Шунда математикасын өйрәнде, инглиз телен ятлады, кызларга хатлар язды, шуннан торып кына җавапларын укыды. Бөек полководецтан үзгә буларак, җылыны бик ярата иде. Егетләр кайбер кичләрне аска, диванга төшеп ятарга чакыра башласалар:

— Һи! Минем урын болай да уңайлы, бөтен бүлмә күз алдымда. Монысы бер. Икенчедән, миңа, булачак. авиаторга, биеклекләрне үзләштерүгә бүгеннән үк күнегә башларга кирәк, — дип кенә җибәрә.

Шкафның урта шүрлеген үз холкына хас пөхтәлек, тыйнаклык белән булачак ревизор Яшка биләгән. Аста тагын бер шүрлек бар. Анысы — резерв. Виктор әйтмешли, вакансия. Буш шүрлек Мәүлет кебек табылдыклар өчен икән. Шкаф янында тар гына кушетка тора. Бөренче күрүендә болар әллә игезәкләрме икән дип әфсенерлек, берберсенә ике тамчы су төсле охшаш, хыялый йөзле ике егет шул кушетка өстенә чүгеп нидер күчерәләр. Алларында кайсы ачык, кайсы ябык калын-калын китаплар. Мәүлет шикелле табылдыкларны Виктор еш ияртеп кайта, күрәсең. Тәрәзә каршында нидер тегеп утырган хуҗа апа да, шифоньер башында китап укып яткан күзлекле егет тә, идәнгә тезләнеп нидер күчергән әлеге ике хыялый да аларга күтәрелеп карамадылар. Сдельно эшлиләр мени, һәркайсы үзе эше белән мәшгуль.

Викторны әллә өнәмиләрме дисәң, ул монда үзен бик иркен тота. Беренче эше итеп мич алдында торган зур кәстрүлнең өстен ачып карады. Борынына килеп бәрелгән истән канәгать калып, «М-м-м!» — дип куйды.

— Я, ничек, безнең торак ошыймы? — ул ярыйсы ук кыршылган, күн тышлы диванга күрсәтте. — Монысы минем ложа. Учти, старик, ул беренче карашка гына шулай миниатюрный. Кирәк чакта резинадай сузыла, ничәү ятсаң, шул хәтле кешене сыйдыра. Соңгы тапкыр без монда сигез егет йокладык. Шәмәрдәннәр килгән иде, дус егет Вагыйзьне армиягә озаттык.

Виктор диванга килеп утырды. Мәүләтне дә үз янына чакырды.

— Синә үтереп мактаган мировой пани Данусябыз менә шушы инде, — дип, бүлмә эчендәгеләр белән таныштырырга кереште.

Хуҗа апа:

— Комплиментлар сибеп безне юмалармын, димә. Идән юасы көнең. Бүген дә онытсаң, арт ягыңа каеш белән төшерәчәкмен,— диде.

Виктор бу сүзләрне ишетмәмешкә салышуны кулай тапты. Шифоньер башында битараф кына калып яткан егеткә ымлап:

— Монысы Александр Суворов, да не тот, була. Но башы эшли, колаклары мишәйт итмәсә, далеко пойдет! — дип куйды. Ә сәер күренгән егеткә житкәч:

— Болары Әкәм белән Төкәмебез! Болай ничава гына егетләр дә, әмма нарасыйлар. Чын мәгънәсендә нарасыйлар! — диде. Аннары үзләренә күрсәтмичә генә кулы белән чигәсенә төртеп күрсәтте. Шөрепләре житешми янәсе. Сәерсенеп калган Мәүләткә:

— Һәй, шагыйрьләр бит болар! Шакмакка такмак төзүчеләр. Боларга ике дөньяң бер, уртасы камыр, — диде. Ә тегеләр аңа күтәрелеп тә карамадылар. Пышын-пышын килеп бәхәсләшәләр иде. Мәүләт егетләргә зур кызыксыну белән карап торды.

Барысы да бүгенгедәй хәтерендә Мурзинның. Шушы кысынкы гына бүлмә уртасында түгәрәк өстәл дә бар иде. Малайлар анда дәрес хәзерлиләр. Саша Суворов оперетталардан отып алган күңелле көйләр сызгыра-сызгыра, сызымнар сыза. Ә пани Дануся кызларга туй күлмәкләре кисә. Виктор өстәлгә күрсәтеп:

— Бушрак кичләрне без монда преферанс уйныйбыз. Ә бәйрәмнәрдә пани Дануся тантаналы чәй уздыра.

Башын да күтәрми тегеп утырган пани Дануся бу юлы түзмәде:

— Тәртибегез «бишле» булганда. Әмма андый чакларыгыз, особенно синең, Виктор, соңгы көннәрдә бик сирәгәйде әле,— дип куйды.

Ишек артында кемнеңдер йөткергәне ишетелде, тавыш Мурзинны бүгенге көненә кайтарды. Ул ни булса, шул дигәндәй, кисәк кенә урыныннан торды. Дерматин тышлы ишек янагындагы звонокка басты. Эчтән:

— Иду, иду-у-у — дигән тавыш ишетелде. Кемнеңдер лыштыр-лыштыр башмагын өстерәп ишеккә килүе ишетелде. Кем булыр икән бу? Ул арада ишек ачылып китте. Аннан тузгак чәчле, күзлекле, майка кигән яртылаш гәүдә күренде. Хуҗаның кулында гәҗит. Йөзе болытлы көн кебек сытык, бер сүз әйтергә тотлыгып калырсың.

— В чем дело, дорогой?

— Вы меня простите великодушно, — диде Мурзин, бөтен кыюлыгын җыеп. — Здесь жила пани Дануся.

— Не знаю, дорогой, никакой пани! — диде хуҗа һәм шапылдатып ишекне япты. Аның эчке яктан татарчалап: — Тәмам туйдырдылар инде шул панилары белән,— дип зарланганы ишетелде. Әмма Мурзин өчен өметле хәбәр иде бу. Әһә, пани Данусяны бер ул гына сорап килми, димәк. Киләләр, шакыйлар икән әле бу ишекне. Димәк, «Фәндәм фонды» яши!

Хәзер ни эшләргә соң? Тагын шалтыравыкка басу килешмәс. Хуҗа бик холыксызлардан күренә. Кая барырга, кемнән сорарга? Мурзин төгәл бер карарга килә алмыйча, тагын әлеге сандык өстенә барып утырды.

Аргы баштагы ишекләрнең берсе ачылып китте дә, аннан яшь кенә бер кыз килеп чыкты. Башта ул Мурзинны күрмәде дә бугай. Күргәч, шикләнә калды. Ярым караңгы коридорда кем утырмас та, нинди ният белән утырмас. Әлеге кыз плитә өстеннән чәйнекне алып кереп китүгә, шул ук ишектән тагын башын тыгып карады. Мурзинның үзенә дә уңайсыз булып китте. Кайчаннан бирле утыра бит инде. Ни дип утыра соң ул монда? Кемне көтә? Пани Данусяның чыгып алганынмы? Аңа бик аңлаешлы итеп: — Не знаю никакой пани! — дип әйттеләр бит инде. Ә кайда ул? Аңа ни булган, кая киткән? Һич югында шуны ачыклап китәргә кирәк. Ул чакларда аңа иллеләр булса, хәзер житмешләр тирәседер. Менә бит ул яшьлек нинди ваемсыз. Ике ел торып пани Данусяның ничә яшьтә икәнен дә белми. Монда хәтле килгәч, ни дә булса ачыкларга кирәк иде. Мәүлет уңайсызланып кына тагын шалтыравыкка басты. Әмма бу юлы ишек тиз ачылды, анда өстенә чәчәкле матур халат кигән, чәчләренә бигудилар бәйләгән яшь кенә ханым күренде.

— Бу әле һаман сезмени? — диде ул ягымлы тавыш белән.

— Сез мине зинһар гафу итә күрегез инде. Мин ерактан, бик ерактан килгән сәфәрче. Узып кына барышым. Вакытым да бик чикле. — Мурзин сүзен куәтләү өчен бармагы белән сәгатенә күрсәтеп алды.

— Аңлыйм. Мин сезне аңлыйм,— диде әлеге чибәр хатын.— Без монда өченче елыбызны гына торабыз. Безгә хәтле дә берничә гаилә торып чыккан. Ә пани Данусяны еш сорап киләләр. Ләкин без аның турында берни әйтә алмыйбыз. — Ачык йөзле чибәр ханым ишекне ябарга җыенды. Аннары кинәттән генә башын тыгып: — Картлык галәмәтедер инде, хәзер генә исемә төште, — дип куйды. — Ялгышмасам, аңа танкодромнан квартира биргәннәр бугай. Ул инде моннан күп еллар элек киткән. Исәндерме, юктырмы, анысын сез белешмә өстәле аркылы гына ачыклый аласыз.

— Танкодромнан дидегезме?

— Әйе. Колагыма ничектер шулай чалынган иде. Нинди магнитлы пани булгандыр инде ул. Пароход белән үтеп барышым, поездан махсус төшеп калдым дип, төн уртасында, хәтта таң алларыннан да килеп шакыйлар, күчтәнәчләр калдырып китәләр.

— Берүк кичерә күрегез, борчып, тынгысызлап йөрүем өчен. — Мурзин кулына авыр портфелен алды. Коридор ишеген сак кына ябып, шыгыр-шыгыр баскычтан аска төште. Ярады, хет монысын ачыклады. Пани Дануся танкодромга күченгән икән. Казанның яңа микрорайонын шулай йөртәләр икән. Анысы яхшы булган. Бу квартираның уңайлыклары чикле иде. Такси яллап әллә шунда китәргәме? Моның өчен башта белешмә өстәленә барып аның адресын ачыкларга кирәк. Тукта, аның фамилиясе ничек иде соң әле? Үтереп сал, хәтерләми. Хәтерләми түгел, белми. Хәер, моны Виктор да әйтә алмас иде. Пани Дануся бу хыялый егетләрен, ә егетләр эчкерсез хуҗа хатынны болай да яраталар иде ич. Яшьлекнең үз кануннары бар. Кешене ярату, чын күңелдән хөрмәт итү өчен аның туган елын, фамилиясен белү һич тә шарт түгел. Их, нинди матур, нинди саф, күңелгә мыскал да юшкын утырмаган чаклар булган икән ул!

Мурзин ишек алдына чыкты. Элек утынлыклар, ә хәзер гаражлар корып куйган җирдә түгәрәк өстәл күрде. Алар заманында да бар иде бу өстәл. Күз алдына Җагур бабай килеп басты. Зәңгәр сатин итәкле мич кебек юан карчыгы бабка Катя аны шушы өстәл артына иртәнге сәгать биштән үк чыгарып утырта. Җагур бабай гомере буе Иделдә

бурлак булган, пароходларга, баржаларга йөк төягән, йөк бушаткан. Күзләре инде байтак еллардан дөм сукыр булса да, колаклары бик сизгер иде аның. Бер дә туксанга җитеп килә димәссең. Янынннан узучыга сүз катмыйча, бераз утырып кит димичә калмый. Әлеге Җагур бабай бөтен ишек алдына бер хәзинә иде. Сукыр булса да, кемнең кая киткәнен, кай сәгатьтә кайтасын, кайчан өйдә буласын барысын белеп тора. Кибеткә-мазарга чыкканда күбесе ачкычларын да аңарга гына калдыралар. Ә Җагур бабай үз чиратында:

— Ачкычларыгызны күбрәк ышаныл йөрсәгез, үзегезне бер кызык итеп куярмын әле, — ди. — Җагур бабаегызны белмисез әле сез. Үзегез югында фатирыгызга керермен дә, оек балтырына тутырып куйган акчаларыгызны чәлдерермен. Күрми дә калырсыз. Катя әбиегезне култык астыма кыстырып, гел кенәриләр сайрап торган Канар атауларына китеп барырмын. Менә шул, — дип шаярткан була. Кайбер кичләрне Виктор белән Мәүлет тә, аның янына чыгып, озаклап сөйләшеп утыралар иде.

... Тәмле кәбестә ашыннан соң Виктор Мәүлетне бүлмәнең эчке кагыйдәләре белән таныштырып чыкты.

— Учти, старик, биредә абсолютно сыйныфсыз җәмгыять, болары сиңа аңлашыла торгандыр, — дип сөйләп китте. Ә пани Дануся аны шунда ук:

— Сыйныфсыз җәмгыять булса да, нянькалар кастасы, түбәнге иерархия бетерелмәде, синең артыңнан тәлинкәләрне һаман да мин җыям, — дип бүлдерде. Виктор пани Данусяның «кирәкмәгән чакта сүзгә кысылуын» ишетмәмешкә салынды. Диванга җайлабрак утырып, сүзен дәвам итте:

— Берсен-берсе ихтирам һәм хөрмәт итүче ирекле әгъзалар яши монда. Җәмгыятьнең иң югары органы булып ике айга бер уздырыла торган корылтай санала. Тактика, стратегия мәсьәләләрен шунда ачыклыйбыз, шунда тикшерәбез. Корылтай бертавыштан кабул иткән карарлар җәмгыять әгъзалары тарафыннан катгый рәвештә үтәлергә тиеш.

Пани Дануся тагын түзмәде. Бу юлы инде теләмәсәң дә ишетелерлек итеп:

— Аларны башлап бозып йөрүче дә син. Ә сөйләвенә карап, мәхлук бер җан икән бу, диярсең, валлаһи, — диде һәм, энәсен изүенә кадап, санап та китте. — Съезд сиңа юк-бар сүз сөйләп кызларның башын катырмаска дип боердымы? Укуыңны тәмамламыйча аларга борылып та карамаска дип карар чыгардымы? Ә син шуннан соң гына да бүлмәгә күпме кыз ияртеп кайттың. Җитмәсә, ул бичараларны өйләнәм дип ышандырган да булгансың. Менә җае чыкты, ичмасам, авылдашың алдында йөзеңне тулысы белән ачып салыйм әле. Бәлкем, файдасы тияр. Соңгы вакытта бик узына башладың.

Виктор чын-чыннан рәнҗегән тавыш белән:

— Пани Дануся, шундый тантаналы минутлар, җәмгыятебезгә яңа член алабыз, ә миңа тәлинкәмнән һаман тараканнар чүпләргә туры килә, — дип авызын турсайтты. — Менә күрерсез, киләсе съездда үзем дә авызыма су кабып утырмам. Кайберәүләрнең аерым шәхесләрне ихтирам итмәве, аларның ирекләрен кысуы, сүз әйтергә дә хут бирмәүләре турында сөйләячәкмен.

Мурзинның бүлмәгә аяк басуына күп булса ярты сәгать. Аңа күп нәрсә аңлашылып та бетми. Әмма биредә яшәүчеләр арасында тату дуслык хөкем сөрүен, аларны күңел якынлыгы, уртак теләкләр, матур хыяллар берләштерүен сиземләми калмады ул. Ә Виктор, Мәүлетнең иңбашына дусларча кулын салып:

— Учти, старик, безнең җәмгыятькә член булып кергән кеше «мин», «минеке» дигән сүзләрне мәңгегә онытa. Безнең арада «без», «безнеке»

дигән төшенчәләр генә яши. Беренче эш итеп без, кешелекне гасырлар буе үзенең колы иткән, әледән-әле дөньякүләм сугышлар, кан коешлар чыгарып торган хосусый милекне бетердек. Учти, старик, бездә бары уртак булса, югы пополам. Акчаң бар икән, кесәңдә йөртмә, хосусый милеккә табыну шуннан башлана, әнә комод өстенә куй. Кирәккәндә, кирәк хәтлесен шуннан алырсың.

Моңа хәтле сүзгә дә катышмый, кәбестә ашы ашарга да төшми, йоклаганга салышып яткан Александр Суворов, да не тот, кинәттән генә аларга таба борылып:

— Булса мишәйт итми ул. Очраганда ташлап калдырыштан түгел, — диде.

Пани Дануся да яңадан сүзгә кушылды:

— Ирекле җәмгыятьнең акчасын иң күп туздыручы, иң күп җилгә очыручы икәнеңне дә әйт, авылдашыңнан анысын да яшермә, — дип өстәде. Ул Викторның үзе төсле, аның сүзләре белән сөйли иде.

Шушында Мәүлет ике ел яшәде. Өстенә кара белән «Фәндәм фонды» дип язылган матур тартмада акча бетеп торганын хәтерләми. Югыйсә, шактый авыр, зур кытлык булган заманнарда укыдылар алар. Җитмәгәндә юнәтү җаен табалар иде. Саша белән Яшкага ияреп Мәүлет тә һәр атнаны вокзалга күмер бушатырга, утын төяргә йөрде. Кайчакларны тешләре генә күренеп, кара күмергә, цемент тузанына батып кайталар. Ач түгелсез, салкын аш ашатканым юк, нигә шулай иза чигәсез дип, пани Дануся соңыннан нык кына орыша иде үзләрен. Әмма егетләр гир түгеп тапкан акчаларын тиене белән шушы тартмага кайтарып салалар. Үз кирәкләренә дә сорап кына алалар. Җәмгыятьнең акчасы булачак финансист Яшка кулында. Аннан күп таммый. Бәлкем шуңа күрә дә шкатулкада акча бетеп тормагандыр.

Әкәм белән Төкәм бу фондка әллә ни өлеш кертә алмаганнардыр. Берсен-берсе уздырырга тырышып төне буена сонетлар, шигырьләр язып чыгалар да, иртән лекциягә бара алмыйлар. Пани Дануся аларның колак төбендә самавыр конфоркасы, калай чүмеч кагып карый. Юк. Егетләрне урыннарыннан торгыза алмый. Әйе, аларның стипендия алган айларыннан алмаган айлары күбрәк була иде шул. Аның каравы егетләрнең әле берсенең, әле икенчесенең шигырен, я мәкаләсен пионерлар журналында, яшьләр газеталарында басып чыгаралар. Моңдый көн бәйрәмгә әверелә. Әлеге газетаны шагыйрьләр кочагы белән сатып алып кайталар. Үзләре кат-кат укыйлар, пани Данусяга укыталар. Пани Дануся миндә менә нинди талантлар яши, дип күршеләргә күтәреп кереп китә. Шигырьне баскач, аның әле акчасы да була икән. Егетләр колхоз базарына чабалар. Андый чакта юлбашчы, әлбәттә, Виктор башлап йөри. Бер бүрек әчтерхан чикләвеге, бер бүрек өрек җимеше алып кайталар. Бу кичкә бүлмәдә чыннан да бәйрәм була. Сыйныфсыз җәмгыятьнең ирекле әгъзалары түгәрәк өстәл артына утырып кич буе чикләвек яралар. Пани Дануся урам аркылыгына аптекада дару җибәреп торучы дусты Хәдичә Терегуловнаны дәшә. Кул эше тотып, ул да кереп җитә. Пани Дануся шунда башкаларга шаян күз кысып ала да, Викторга ымлап:

— Поэзия белән сиңа да шөгыльләнеп карарга кирәк. Глядишь, үзеңнән бәлки шагыйрь чыгып куяр иде.

Виктор аны чынга ала. Панның шаяртуын аңламый:

— Булмый ул миннән. Аннары темам да юк,— ди.

— Ничек темаң булмасын. Кызларның бер кичтә башларын әйләндерүең тема түгел мени!

Виктор да, шаян тонга күчеп: «Монда, пани Дануся, шигырь түгел, роман, целый роман кирәк»,— ди.

Пани Данусяның Хәдичә Терегуловнаны, ягъни Кайчә апаны кичләрен чикләвек ашарга дәшүенең дә үз сере, үз хәйләсе бар. Хәдичә

апада ике медик кыз тора. Аһ, чибәрләр! Әмма Дануся егетләренә борылып та карамыйлар. Хәтта аларны Виктор да үзенә карата алмый. Ә пани Дануся белән Кайчә апаның егетләрне шул кызлар белән таныштырып, дөбердәтеп туй ясыйсылары килә. Тел төпләреннән шул сизелә.

Гаҗәп фонд иде ул «Фәндәм фонды». Аңа взносның иң зурысын пани Дануся үзе кертә. Андый оста тегүче Казанда тагын булдымы икән әле. Чөнки заказларны аңа әллә кайлардан, Яңа бистәләрдән, Бишбалталардан китерәләр. Эзләп киләләр. Гозерләп, ялынып әллә нинди фасонлы, уймак хәтле генә билле, колач җитмәслек киң итәкле күлмәкләр тектерәләр. Үзе дә заказларны теләсә кемнән алмый. Заказчы күңеленә хуш килсә, китергән материясе ошаса, фасоны матур, яңа булса, аны дәртләндерсә генә алына. Мондый заказлар өчен акчасын да яхшы түлиләр. Әмма пани Дануся тегүдән килгән акчаның тиененә хәтле әлеге шкатулкага салып бара. Аның дөньядагы бар шатлыгы, бар куанычы да шушы егетләр иде бугай. Аларның барысын бер тигез итеп, үз уллары кебек якын күрә иде. Юк, шулай да Викторны үзе дә сизмәстән артыграк күрә, иркәли, узындыра иде.

Пани Дануся поляк революционеры кызы булган. Казанга сугыш вакытында эвакуация белән Ленинградтан күченеп килгән. Аның ире укчы полк командиры, сугышның беренче көннәрендә үк хәбәрсез югалган. Әтиләре артыннан аның ике улы, ике лачыны — икесе дә хәрби училище курсантлары — Мәскәү янында хәбәрсез югалганнар. «Хәбәрсез югалдылар» дип, пани Дануся гына сөйли. Ана кеше бит. Ана өметсез яши ала мыни. Өметен җуймас өчен генә шулай сөйли. Бер вакыт комодтан нидер эзләгәндә, похоронныйларын Виктор үзе табып укыган. Пани Дануся торган-яшәгән өчен дә егетләрдән бер тиен алмый иде. Бервакытны бу хакта сүз чыккач пани Данусяның бөтенләй йөзе үзгәрде, бит урталары янып чыкты.

Гомердә булмаган хәл:

— Сез беләсезме, мин кем, — дип кычкырып җибәрде ул һәм өстәлгә китереп сукты. — Мин сугышның беренче көннәрендә үк хәбәрсез югалган совет офицерының, полк командирының хатыны! Сугыш кырында минем ике улым, ике күз нурым хәбәрсез югалды. Сезнеңчә алар мин сезне талап, оек балтырына акча җыеп, череп, баеп ятсын дип башларын куйганнар булып чыга. Мине шулай рәнҗетергә ничек телегез барды! — Ул шәле белән битен каплап үз бүлмәсенә кереп китте. Бу турыда икенче сүз кузгатырлык итмәде.

Пани Дануся Викторны фронтта хәбәрсез югалган кече улы Сигизмундка охшата иде. Шуңа күрә дә иркәли, узындыра. Идән юарга кайтмаса да, каеш төшерәм дип йөри-йөри дә үзе юып куя. Ике ел хәрби мәктәптә укып чыккан Викторның, чалбарымны тигез үтүкли алмыйм диюе дә, белмәс бар, хәйлә генә. Моны пани да белә. Әмма хәйләкәрнең чалбарларын үзе үтүкли. Бераздан ул үз бүлмәсеннән егетләр янына чыга.

— Карагыз аны, минем тарафтан берниндн дә ташламалар булмаячак. Шалтай-балтай йөрсәгезме? Минем йөземә, ата-аналарыгызның йөзенә кызыллык китерерлек итеп укысагызмы? Карагыз аны, барыгызны да урамга куып чыгарырмын, — дип куркытып ала. Булачак финансист Яшка белән бик килә иде аларның гәпләре. Пани Дануся белән Яшканың шалт та шолт счет төймәсе тартып, бәхәсләшми-нитми бу айда кемнең өстенә, кемнең аягына юнәтергә, ашарга-эчәргә, башка кирәк-яракларга күпме акча калдырырга икәнен бик тату киңәшеп утырган чаклары Мурзинның күңеленә аеруча тирән уелып калган.

Һәр нәрсәгә зур кытлык булган ул елларны пани Дануся каян бар кирәк-яракны юнәткәндер, каян барын да табып өлгергәндер. Ул һәр

якшәмбе бәйрәм ашлары пешерә иде. Кичке чәйдә барысының да өйдә булуларын таләп итә. Мондый көнне иртәнге якта егетләр бүлмәләрен җыештыралар. Өс киемнәрен чистартып, урын-җирләрен чыгарып кагалар. Шкаф башларын, тәрәзә төпләрен юеш чүпрәк белән сөртеп, идәнне юып чыгаралар. Аннары Яшка барын да җыеп мунчага алып китә. «Бер кыз белән очрашырга сүз куешкан булса да», Яшкага каршы Виктор да бер сүз әйтми. Уфылдап, әледән-әле сәгатенә күз салып, егетләр артыннан ул да мунчага атлый. Барганда гына шулай кәҗәләнә. Барып өстен чишенгәч, ләүкәдән алып төшеп булмый үзен. Төшеп өстенә бер ләгән салкын су гына коя да тагын ләүкәгә менеп китә. Чабынып та күрсәтә торган иде.

Егетләрнең мунчадан кайтышына бүлмәне алма бәлеше, кәбестә пирогы, җимеш паштеты исләре баскан була.

Бүлмә уртасында торган түгәрәк өстәлгә пани Дануся ап-ак эскәтер чыгарып җәя. Үзе дә матур йон күлмәктән. Каршыдагы парикмахерскаяда бик килешле итеп чәчен ясатып чыккан. Егетләрне дә кунак каршылагандай ачык йөз белән каршылый. Өстәлдәге бар тәлинкәләр, ташаяк савытлар бары да чын фарфордан. Башка чакларны пани Дануся аларны еракка җыеп тота. Ә бүген бары да өстәлдә. Салкын чия компоты салынган стаканнар да, фужерлар да чын хрустальдән. Егетләр кыстаганны да көтеп тормый табын артына утыралар. Пани Дануся барысының да алларына ап-ак итеп крахмалланган тастымаллар салып чыга. Аларны күлмәк якасы астына ничек кыстырырга икәнен күрсәтә. Егетләрне танырлык та түгел. Саша Суворов ак күлмәктән, галстук таккан. Иңбашына ярыйсы ук кыршылган булса да, чын күннән икәне ачык күренеп торган саргылт тужуркасын салган. Яшканың пани Дануся белән колхоз базарыннан алган эре шакмаклы костюмы бар. Әллә ни яңа булмаса да, булачак финансист костюмны бөртек тап төшерми, тузан кундырмый, бик кадерләп кия.

Әкәм белән Төкәм ашауга исләре китмәгән кебек, кием-салым турында да бик кайгыртмыйлар. Әмма пани Дануся аларны аерым ярату белән ярата. Ул бик укымышлы, киң карашлы, бигрәк тә әдәбиятны яхшы белә. Шуңа шагыйрьләргә мөнәсәбәте дә аеруча йомшак. Тегеләрне укуларыннан чыгарып йөргән чакта, ректорга барып, деканнары белән сөйләшеп, яңадан алдырып кайтты. Андый чакта үзенең кем икәнен бик тиз таныта белә. Ватан сугышы кырларында ире һәм ике улы югалган ананың, полк командиры хатынының сүзе кая барса да үтә. Ә шагыйрь егетләр дигәндә, кирәксә, министрга да кергән булыр иде. Алар шигырь язганда, тегүеннән үк туктый, бүлмәдә дә аяк очында гына йөри. Әкәм белән Төкәм өстәл артына пани Данусяның улларыннан калган зәңгәр пар костюмнан килеп утыралар, ә Викторның үгезнеке кебек юан муенына нәрсә кисә дә, изүе житешми. Күлмәк киеп, галстук такса да, бик сәер килеп чыга, үгезгә камыт киерткән төсле була. Шуңа күрә анын яраткан киемнәре матрос тельняшкасы, изүе төймәләнми торган майкалар, тенискалар.

— Укыган чакта әле ярый,— ди ул аптырагач, — ә менә укып бетергәч, мәктәп директоры булгач галстуксыз килешмәс бит инде, ул чакта ни эшләрмен мин бу муен белән?

— Анысы өчен кайгырма, — дип тынычландыра аны пани Дануся. — Кызларны күп сайласаң шундыена килеп кабарсың әле, игәүли башласа, муенын бер айда нечкәрер дә калыр.

Викторның да күз карасы кебек кадерләп кигән киемнәре бар. Мәктәпләрен таркатыр алдыннан, бездән истәлек булсын дип, тик генералларга гына тегә торган югары разрядлы ательеда аларның һәркайсына яшел бостоннан китель, зәңгәр бостоннан киң балаклы чалбар тегеп биргәннәр. Виктор аларны пани Данусяның сандыгы төбендә саклый. Көя-мазар тишмәсен дип вакыт-вакыт алгалап, нафталинлап

кына тора. Хәрби урта мәктәптә укыган чакларын сагына ул. Шушы кителен кисә: — Виктор, ты вылитый мой Сигизмунд! — дип, пани Дануся анын яныннан китә алмый. Әмма мондый бәйрәм ашлары вакытында кызартулар да күбрәк аңа эләгә.

— Сигизмунд! Как ты держишь вилку! Тьфу, тагын саташам, Виктор, ваемсыз, сиңа әйтәм! Ашау белән булышма. Синең тәлинкәңә салынган ризыкны күршең ашамас. Күтәр башыңны тәлинкәдән. Чын интеллигентлар өстәл артына баш күтәрми ашау өчен түгел, күңелле итеп сөйләшеп утыру, кәеф-сафа кору, уртак мәсьәләләрне хәл итү өчен җыйналалар. Әй синең, кара, йөзең чытык. Күршеләреңә игътибар юк, үзең тутыру ягында, — дип тукып кына тора.

— Крахмалланган тастымаллар сезгә авыз сөртү өчен түгел. Вак кына кабып ашасагыз, тастымалның кирәге дә юк, читтән караган кешегә дә матур күренә. Тастымал, өстәлгә куелган чәчәкле ваза кебек, тантана өчен генә. Ул этикет җиһазы. — Пани Дануся аларга өстәл артына ничек килеп утырырга, алдан кемнәрне утыртырга, ничек торып китәргә икәнен, барысын үзе күрсәтеп чыга. Хуҗа өстәл артына иң соңыннан утыра, иң соңыннан күтәрелә. Ризыкларның иң тәмлеләрен, алмаларның иң кызарып пешкәннәрен, бәлешләрнең иң матур итеп киселгәннәрен кунакларга салырга кирәк. Чын кунакчыллык, аларга чын күңелдән ихтирам шул була. Әмма кулга кашыкны беренче булып үзең аласың, ризыклардан беренче булып үзең авыз итеп карыйсың. Кунакларны шуннан соң гына кыстарга кирәк. Табын янында тик күңелле, шаян сүзләр, барлык кунакларның да күңеленә хуш килә торган сүзләр генә сөйләнелә. Әгәр дә берәр кунагың ризыгын идәнгә койса, күрмәмешкә салыш, кирәкмәгәнрәк сүз башлап җибәрсә, оста гына итеп икенчегә бор, — дип пани Дануся шундый кечләрне үзенең егетләрен әдәпкә, югары культуралы кеше белергә тиешле гадәтләргә өйрәтә. Аларга матур, күркәм булу өчен, кино-театрда, мәҗлесләрдә, кеше арасында уңайсыз хәлгә калмас өчен үзләрен ничек тотарга кирәклеген аңлата. Эчендә бүреләр уласа да, аны Виктор да түземле генә тыңлый. Тастымалны да якасы астына нәкъ пани өйрәткәнчә кыстыра, чәнечкене дә ул күрсәткәнчә тота. Әмма шунда кинәттән генә сабырлыгын җуя. Тәлинкәсендә тәгәрәшеп яткан симез-симез пилмәннәрне берсе артыннан берсен йота башлый.

— Виктор! Мин боларны кем өчен сөйлим? Ашавыңны гына күр? — дип пани аны орыша, ә Виктор пилмәннәрне чүпли. Тәмам сабырлыгын җуйган пани түзми, кул уңаеннан аңа берне сыптырап та ала. Ярый әле үпкәчән түгел. Ә егетләр моны хуплап кул чабалар.

Дүрт-биш телем арыш ипие белән бер тәлинкә пилмәнне шулай талаша-талаша сугып куйгач, Виктор өстәлдән башын күтәреп, бик тәмләп кикереп җибәрә. Пани Дануся сүзен дәвам итә.

— Сез тиздән тормышның хуҗасы, төп терәге, җәмгыятьнең күренекле кешеләре буласы егетләр. Сезнең һәр адымыгыз, һәр сүзегез культуралы, матур, чын интеллигентларча булырга тиеш. Әйтик, Александр Суворов, пусть не тот, но зур заводта баш инженер, җитәкләүче конструктор булыр.

— Ә Яшка — финанс министры, Әкәм белән Төкәм күренекле шагыйрьләр булып танылырлар.

— Ә мин? Мин кем? — дип Виктор да киң күкрәгенә сугып алды.

— Арагызда иң зур бәхет Викторны көтә, — дип дәвам итте пани. — Ул бит балалар укытачак. Ул атказанган укытучы, мәктәп директоры, мәгариф эше алдынгысы булыр. Сездән дә күрмәгәч, кешеләр, яшьләр матур үрнәкләрне кемнән алырлар? Кемгә охшарга тырышырлар? — дип гыйбрәтле сүзләрне аларга тукый пани. Ул үгет-нәсихәт сүзләрен аларга күп кичләрне сөйләде.

Бәйрәм ашыннан соң танцы кичәсе була. Кичәнең бу өлешен аеруча пани Дануся ярата. Яшь чагымда танцыларга күп йөрдем, дип искә ала ул. Булачак ире белән дә беренче мәртәбә бию залында күрешкәннәр. Өстәлгә телен тик Саша гына белгән иске патефон менеп баса. Виктор берәр кыз алып кайтса, яисә Кайчә апа да килеп керсә, кичә тагын да күңелле чыга. Пани аларны танго, вальс, вальс-бастон биергә өйрәтә. Әлбәттә, ул үзенә кавалерлар ролен ала. Кызларны ничек чакырырга, зал уртасына ничек чыгарга, бию тәмамлангач ничек озатып куярга икәнен дә күрсәтә.

— Ох, Виктор, какой из тебя кавалер, за что только тебя так девчата любят? Ты ведь не танцуешь, а грязь месишь, — дип пани тагын аны орышып ала. — Ә минә шагыйрьләр ничек сизгер, бер күрсәтүдә отып алалар, — дип Әкәм белән Төкәмне мактый.

Шулай шатлыклары да бергә, кайгылары да уртак бер тату семья булып, гөр килеп яшәделәр. Дөрес, мондый шау-шулы кичәләрнең ахыры күңелсезрәк беткән чаклар да була иде. Пани Дануся үзе дә сизмәстән, ире командир булып хезмәт иткән полкның тынлы оркестрын, шунда танцыларга барган чакларын исенә төшерә.

— Андый оркестр тик безнең полкта гына бар иде! Йөз музыкант барысы берьюлы уйнап җибәрә, яшен яшьни, күк күкри, җир тетри. Әйе, андый оркестрлар бүтән юк инде алар, — пани күзләрен яулык белән каплый, күңеле тулып үз бүлмәсенә кереп китә. Мондый чакта аны юатса, Виктор гына юата.

Яшка Типләшев янына аның үзе кебек җирән чәчле, түгәрәк алсу йөзле Оля дигән бер студентка кыз килеп йөри иде. Күзгә күренеп култыклашып йөргәннәре дә булмады, икәүләп кенә киногә да йөрмиләр иде. Яшка аны егетләргә үзенең авылдаш кызы, группаның комсомол оешмасы секретаре дип кенә таныштырды. Әмма шул Оля килсә, усал һәм бәйләнчек, бүлмә егетләрен пани Дануся кебек өркетеп торган Яшка бөтенләй икенче егеткә әйләнә. Оляны ничек чишендерергә, кая утыртырга белми. Кулына себерке алып бүлмәне себереп чыга. Аннары бушрак почмакка күчеп алар чүкердәшеп утыралар.

— Оляның комсомол секретаре, Яшканың авылдашы булуы ни причем монда, — дип куйды беркөнне Виктор, пар күгәрченнәрдәй гөрләшеп утырган Яшка белән Оляга ымлап. — Мин әйтте диярсең, болар өйләнешәчәк һәм бик тиздән. Учти, туй булачак.

Чыннан да күп вакыт та узмагандыр, Яшка йомырка баскан ана каздай ябыгып дәүләт имтиханнары тапшырып, укуын тәмамлап йөргәндә, болар бер көнне бүлмәгә ир белән хатын булып кайтып керделәр. Виктор шунда Мәүлеткә: — Әйткән идем бит! — дип күз кысты.

Язылышу кәгазьләре дә кулларында. Пани Дануся исә нигә миннән яшереп йөрдегез, дөбердәтеп туй итәргә әллә хәлебездән килмәс идеме, дип үпкәләп, елап алырга да җыенган иде. Әмма, куып чыгарырсыз дип курыктык, хәзер куа алмассыз инде, дипломнарыбыз да кулыбызда, язылышу кәгазьләребез дә дип, аны бик тиз юаттылар.

Өстәлгә крахмалланган эскәтер чыгарып җәелде, фарфор чәшкәтәлинкәләр, хрусталь рюмкалар тезелә башлады. Әкәм белән Төкәмнең дә шигырьләре басылган чак иде. Үзләре әйткәнчә, «уч тутырып гонорар» алганнар.

Бу кичне пани Дануся егетләре гөрләтеп туй ясадылар.

Өйләнешүчеләрне үзләрен генә калдырып, егетләр ул төнне Кайчә апада кундылар. Иртәгесен исә ике яшь ревизорны поездга утыртып, үз якларына, Ижевскига озаттылар. Пани Дануся шундый кеше иде инде. Никахлы тормыш коручыларга үзенең күз карасы кебек саклый торган уникә кешелек затлы сервизының яртысын бүлде дә бирде. Ә бүлмә егетләре исеменнән икесенә дә бик матур җиләп алган.

— Хуҗа Насретдин кешене киеме белән каршы алырлар, дигән

Ә сезнең бер белмәгән кешеләр, яңа коллектив алдына килеп басасыгыз бар. Бу сезгә «Фәндәм фонды» бүләге, аның истәлеге,— дип бүләкләрен тегеләргә купега кереп утыргач кына тапшырды.

Мурзинның күңеленә һич онытылмас хатирә булып тагын шунысы уелып калган. Пани Данусяның туган көне июнь ахырларында иде. Бүлмә егетләренең кайсы җәйге практикага, кайсы каникулларга таралып беткән чак. Бер көнне шулай Виктор аңа тиктомалдан гына:

— Старик, киләсе җомгада пани Данусяның туган көне, нишлибез? — дип әйтеп куйды. Туйдан соң Фәндәм фондының саеккан чагы. Портта да эшләр юк. Яшелчә-җимеш, кавын-карбыз да өлгермәгән. Китерәсе цементны инде күптән китереп, бушатып бетергәннәр.

Бу фондны Фәндәм исемле ярлы бер студент оештырган булган. Пани Данися квартирасында төп яшәү законына әверелгән башлангыч коммунизм, социаль тигезлек, уртак акча тоту, уртак ашау, уртакка кием-салу алу, үзара ярдәмләшеп дөнья көтү тәртипләрен дә ул башлап, кертеп калдырган. Ләкин шунысы кызык: шушы Фәндәмнең кем булуын, кемлеккә укуын, хәзер кайда яшәвен берәү дә белми. Пани Дануся да аны әле агроном ди. Икенче тапкырында безнең Фәндәм ул юрист булып чыкты, ди. Өченчесендә исә, бүгенгедәй хәтерлим, ул балалар врачы булырга укыды, дип сөйли. Тик шунысы хак, Фәндәм төзеп калдырган фонд бүген дә яши. Һич көтмәгәндә шушы фонд адресына дөньяның әллә кай почмакларыннан зур гына суммалар, тәмле балык, апельсин-лимон, кипкән җимеш, грузин чәе килеп төшә. Ләкин бу араларда керемнәр дә күренми.

Озак баш ватып тормадылар.

— Киттек скульпторлар янына, — диде Виктор.

— Бер сәгатькә генә түзәрбез, ничек кушсалар, шулай торырбыз.

Башка егетләр портка төшеп, манма тиргә батып авыр эшләрдә йөргәндә, Виктор үткән кышны үзенә бик җиңел эш табып кайтты. Кремльдән астарак, ике катлы бер особнякта архитекторлар-скульпторлар берләшмәсе ачылган. Аларга Үзәк ял паркын сыннар белән бизәү бурычын йөкләгәннәр. Виктор моны кайдан ишетеп алган диген, көннәрдән бер көнне шунда барып натурщик булып ялланып кайтты. Билгеләнгән вакытка гына килә дә, бер бүлмәгә кереп чишенә, аннан зур зал уртасында торган түгәрәк өстәл өстенә чыгып баса. Скульпторларның соравы буенча Виктор я ишкәк ишүче, я гер күтәрүче, я футболист кыяфәтенә кереп баса. Аның таза гәүдәсе, нык куллары, үзе әйтмешли, сынчылар өчен чын хәзинә иде. Бер кыш чамасы йөрде ул алар янына. Бер көнне рәссамнарнең башлыгы аңа зал уртасына шәрә ялангач, анадан тума килеш чыгып басарга кушкан. Сын коючыларның яртысы кызлар.

— Тегеләр белән дипломатик мөнәсәбәтләрне өздем, — дип дулап кайтты ул кичне Виктор. Ә хәзер:

— Кушалар икән, анадан тума да торырбыз. Ике кешегә ояты да азрак, түләве дә күбрәк, — дип Виктор Мәүлетне шул сынчылар янына алып китте. Әмма бина ябык булып чыкты. Каравылчы карт җәй көне бу оешманың гомумән эшләмәвен, ә сынчыларның, рәссамнарның кайсы кая булуын әйтте. Инде нишләргә? Әмма башына бер-бер уй төштеме, аны тормышка ашырмый калучы түгел инде Виктор. Уйланып торды да:

— Старик, безнең тагын бер вариант бар. Монысы аның йөз процент ышанычлы, — дип куйды. Аннары ул: — Ашыгырга кирәк, юкса соңаруыбыз бар, — дип Мәүлетне бу юлы Суконный бистәсенә алып китте. Трамвайдан төшеп озак та бармадылар, фасадына зур итеп кызыл хач сурәте төшерелгән ике катлы бина каршына килеп чыктылар.

Егетләрне монда кадерле кунаклар төсле бик якты йөз белән кар-

шы алдылар. Кан тапшыру, ягъни донорлык пункты иде бу. Дөресен әйтергә кирәк, донорлык турында күп ишетсә дә, Мәүлет башта ярыйсы каушап калды.

— Мин монда беренче тапкыр гына түгел, бер дә курыкма, — дип Виктор аны тынычландырырга тырышты. Өсләренә ап-ак җәймәләр ябып икесен дә озын өстәлгә сузып салдылар. Каннарын алгач аларны аскы каттагы махсус буфетка алып төшеп китәләр. Донорлар пунктының баш врачы егетләрне үзе каршы алды. Аларның алдына меню куйды.

— Кадерле донорлар, зур рәхмәт сезгә. Биргән каныгызны бүген үк шәһәр больницаларына озатачакбыз,— дип егетләрне мактый-мактый, менюдан ни теләсәләр, шуны сайларга кушты. Алларына җимеш суы белән тулы графин китереп утыртты. Виктор Мәүлеткә күз кысып алды:

— Старик, минем белән кайда да югалмассың. Тартынып утырма тагын. Ашау бушлай, монда тәртибе шул аның, — дип җиңнәрен сызганып ашарга кереште.

Ап-ак халатлы мөлаем йөзле врач хатын ниндидер кәгазьгә кул куйдырды, егетләрнең кулларына илле сумга якын акча китереп тоттырды.

Аннан чыккач, егетләр кибеткә ашыктылар. Бәясеннән тормыйча үзләренә ошаган иң матур ефәкне сайлап, пани Данусяга күлмәклек кистерделәр. Материалны кәгазьгә төрдереп, өстеннән ал тасма белән бәйләткәч, күңелләре тагы да күтәрелеп китте.

— Әйттем ич, старик, минем белән булсаң, беркайчан да хур булмассың, — диде Виктор.

Матур истәлекләрне башыннан кичереп, Мурзин күгәрченнәр ашатып утырганда пани Дануся квартирасының тәрәзәсе ачылып ябылды. Анда әлеге чибәр ханымның башы күренде. Ә бераздан аның ягымлы тавышы Мурзинның артында ишетелде.

— Гафу итә күрегез инде, — диде ул, гаебе булган кеше сыман итеп. — Сезне чәйгә дә дәшә алмадык. Иремнең эшендә зур неприятность. Бер генә дә кәефе юк.

— Юкка борчыласыз. Кем килмәс тә, кем китмәс. Барын да чәйгә чакыра башласагыз...

— Алай түгел инде. Күрәм ич мин, кайчаннан бирле бирелә утырасыз. Ә сез, беләсезме, Хәдичә әби янына керегез. Безнең йортта ул бик күптәннән тора бугай.

— Хәдичә Терегуловнамы? Кайчә апамы? Ул исәнмени әле? Ул бит пани Данусяның дусты, сердәше иде. Кара, ничек ул минем башыма килмәгән!

Мәүлет шакырга җыенган бу ишек тә дермантин белән тышланган. Эмма звонокка ул курыкмыйча басты. Эчке яктан:

— Керегез, кер, ишек бикле түгел, — дигән тавыш килде. Мурзин тотканы үзенә тартты.

— Хәдичә Терегулова шушында торамы?

— Кайчә әбиегез мин булам. Керегез. Түрдән узыгыз. Сез кем буласыз соң?

Мурзин каршына инде җитмешләрдән узган җыйнак гәүдәле һәм көр тавышлы татар карчыгы килеп басты. Өстендә тире күкрәкчә, аягында җылы башмаклар.

— Кызлар әле укуда. Тиз генә кайтмаслар. Керегез, чишенегез, хәзер чәй куям.

— Кайчә апа! Бу бит мин, Мәүлет Мурзин!

— Күрәм, күреп торам, — диде әби. — Алай да кызларның кайсы янына килдегез? Кайсының этисеме, туган абыйсымы буласыз? Тәскирә шушы көннәрне этисен көтә иде. Аның этисе түгелдерсез ич?

— Юк-юк, Хәдичә апа. Танымадыгыз инде алайса. Мин бит пани Данусяда торган Мәүлет. Геолог егет. Теге, гел тамагы шешеп аптырый торган Мәүлет.

— Ә-ә-ә, исемә төште. Тамак чайкарга чәй содасы сорап керә идең. Ул елларны Данусяда күп егетләр торып чыкты. Барысын хәтерләү мөмкин түгел шул. Ә менә сезне хәтерлим. Сез Викторлар белән бер чорларда укыдыгыз түгелме соң?

— Ие, ие. Болай булгач, чыннан да хәтерләдегез инде. Кызык заманнар ие бит. Кайгы белми, нужа күрми яшәп ятканбыз икән.

Кайчә әби өстәлгә җәелгән шакмаклы эскәртерне кан тамырлары беленеп торган җыерчыклы куллары белән сыпырып-сыпырып алды. Тирән итеп сулап куйды.

— Дәнүсә танкодромга күчкәч тә озак тормады, үлеп китте. Соңгы елларны йөрәгеннән зарлана башлаган иде. Җирләшергә үзем дә бардым. Дус-ишләре белән Виктор да килде. Бик зурлап җирләдек. — Хәдичә әби авыр сулап куйды, күзлеген төзәткәндәй итте. — Җидесигез ел элек булды бу. Торып чыккан егетләре һаман да онытмыйлар әле. — Хәдичә әби шакмаклы эскәтер астыннан ике перевод кәгазе чыгарды. Берсендә ун сум. Икенчесендә — унбиш. Кемнәрдән икәне язылмаган. Әмма адресы төгәл һәм ачык. «Вокзал арты урамы, Фәләнчә йорт. «Фәндәм фондына». Шунда Мәүлетнең дә исенә килеп төште: Себер киңлекләрендә югалып йөргәндә, укыган чакларын, Казанны сагына башласа, үзе дә шулай итә иде бит. Чит илгә командировкага киткәнче дә, аннан йөреп кайткач та, шушы ук адрес белән берничә тапкыр акча салгалады. Әйе, алар бүлмә егетләре белән шушы фондны ташламаска, онытмаска, укып чыккач та аңа ярдәм күрсәтеп торырга ант иткәннәр иде.

— Миндә дүрт кыз торалар, — диде Хәдичә әби. — Авыл кызлары, дүртесе дә акушерлыкка укыйлар. «Фәндәм фондына» акча салучылар шул кызларымны кинәндерә инде.

Сәгать-мазарга карамыйча алар бик озак сөйләшеп утырдылар. Кемнәрдәндер килгән лимон, кемнәрдер үтешли калдырып чыккан тәмле конфетлар белән чәй эчтеләр. Хәдичә әби шунда кинәттән генә:— Бу хәлгә Фәндәм Фәттахович үзе дә аптырый. Минем бернинди дә фондлар төзеп калдырганым юк, ди. — Минем исемдәге нинди фонд икән ул, менә сиңа әкәмәт, ди.

— Чүгез әле, кем ул Фәндәм Фәттахович? — дип бүлдерде аны Мәүлет. — Фәндәм фондын оештыручы әллә табылдымы?

— Минемчә, аның югалганы да юк, — диде Хәдичә әби һәм тагын да ачыла төште.— Ул шушы тирәләрдәге районнарның берсендә әллә райком секретаре, әллә райисполком председателе. Хәер, анықын белеп бетермәссең. Әле үткән атнаны гына кергән иде.

— Ә Виктор? Укып бетергәч тә без аның белән бер-ике генә хат алыштык та, бүтән мин язмадым, ул җавап бирмәде, дигәндәй, берберебезне югалтыштык. Ул да шушы тирәләрдә мени?

— Безнең Виктор Константинович, — дигәч, Хәдичә әбинең авызы ерылып ук китте, — ул хәзер Киров районында мәктәп директоры. — Ике кыз үстерә. Хатыны да бик ачык, бик кунакчыл. Восстание тукталышында торалар. Көзлектәрәк хатыны белән икәүләп килеп кунакка алганнар иде. Туктагыз әле, миндә бит аның эш телефоны бар. — Хәдичә әби утырган җиреннән кутәрелде. Аннары кире утырды. — Юк, бирмим. Сезнең шалтыратуыгыз белән ул чаптырып килеп тә житәчәк. Аннары аның кулыннан бер атнасыз ычкына алмассыз. Ә сез ашыгам, үтеп барышлый гына сугылдым дисез бит.

Мурзин сәгатенә күз төшереп алды. Аңа инде кузгалырга дә вакыт. Хәдичә әби белән бик җылы саубуллашып, Викторга да күп сәламнәр тапшыруын үтенеп, урамга чыкты.

Мәүлет аэропортка менеп җиткәндә, пассажирлар инде шәһәрдән кайтканнар иде. Экскурсия ошаган булса кирәк. Барысының йөзләре шат.

Бераздан аларның барын да самолетка чакырдылар. Пассажирлар төркеменә килеп кушылганчы, Мурзин почта бүлегенә сугылды. Акча күчерә торган кәгазьгә: Вокзал арты урамы, фәләнчә йорт. «Фәндәм фондына» дип язды.

## Мәдинә Маликова

# САРЫ ТЮЛЬПАННАР

ХИКӘЯ



Язның да болытлы, ямансу, шактый күңелсез көннәре була. Шундый бер көннең кичке эңгер-меңгер сәгатендә, кеше тулы троллейбуста, күзлек кигән, пенсия яшендәге бер апа миңа каршы урынга килеп утырды. Кулында бер кочак сары тюльпаннар. Күп иде, эре, матур иде тюльпаннар, эчләрендә кечкенә лампочкалар янган кебек, тирә-юньгә нур сибәләр иде алар. Бөтен кешенең карашы ихтыярсыздан шул чәчәкләргә төбәлде.

Менә троллейбуска кулына зур сумка тоткан урта яшьләрдәге бер хатын килеп керде, тыгызланып баскан халык арасыннан күптән күнегелгән хәрәкәт белән, балыктай шуышып, эчкәрәк, безнең янгарак узды. Аның кыяфәте талчыккан, йөзе уйчан иде.

Аның бәхетенә, чәчкә тоткан апа янындагы урын бушады, сумкалы хатын, җиңел сулап, иркенәеп утырды. Авызыннан кәгазь төргәкләр, полиэтилен капчыклар күренеп торган сумкасын тезенә куйды да, йөзен күршесенә таба борып, күзләрен чәчәкләргә төбәде. Кем белә, бәлки, бу чәчкәләр аның күңелендә матур хатирәләр кузгаткандыр, күзенә ял биргәндер. Кем белә...

Ул шулай керфеген дә какмый карап баргач, чәчкә хуҗасы нидер әйтергә тиеш тапты булса кирәк:

— Бакчабыздан кайтып килүем,— диде.— Алып кайтыр бүтән әйбер юк бит әле, шушы чәчкәләр генә.

— Иллә дә матур икән чәчкәләрегез!

— Чынлап әйтәсезме? Сезгә ошыймы? — дип сорады чәчкәле апа җанланып. Аның күзлек пыялаларында чәчкәләрдән төшкән алтынсу нурлар уйнап алды. Сумкалы хатын тураебрак утырды:

— Ничек ошамасын инде! Эре үзләре, теп-тере үзләре, төсләре дә бигрәк ачык, матур!

— Сез шулай дисез дә бит, күпләр сары чәчәкне яратмый. Сары төс — аерылу төсе, сагыш төсе, диләр. Шуңа күрә мондыйны бүләк итү дә кыен. Ә мин үстерәм менә, тамырларын корытасым килми, яратам.

— Аерылу-сагышлар чәчкә төсле буламыни! — диде сумкалы хатын.— Сары төс — яз төсе, яңа чыккан нәни чебешләр төсе, кояш төсе ул. Галимнәр әйтә: сары төс кешенең күңелен күтәрә, нервысын тынычландыра, — ди.

— Бала чүпрәгендәге таплар да сары, — дип көлемсерәп, ике өлкән хатынны үчекләгәндәй әйтеп куйды минем янда сабыен кочаклап утырган яшь хатын.

— Әйе шул, — диде сумкалы хатын тагын да ачылып. — Сәламәт сабыйның ак чүпрәгендәге таплар да сары була. Тик аларның матурлыгын еллар үткәч кенә аңлый башлыйсың икән шул.

— Сары төс быел модада, — дип сүзгә кушылды утыргыч аркасына тотынып барган түгәрәк битле бер кыз. — Мәскәү белән Ленинградта быел хатын-кызларның бар кигәне шәмәхә дә сары икән.

Күзлекле апа кочагындагы тюльпаннарның берничәсен озын сабагы буена суырып алды да, күршесенә сузды:

— Менә болары сезгә булсын.

Хатын каушап китте:

— Минме? Миңамы? Юк, рәхмәт, мин сездән андый зур бүләк ала алмыйм!

— Нишләп алмыйсыз? Әле генә ошый дигән идегез бит! Безнең бакчада күп алар. Куяр урын юк. Ялгызым яшим бит мин. Боларын да күрше карчыкларына өләшермен дип кенә алып кайтуым.

Сумкалы хатын озын сабаклы, эре чәчкәләрне, ватудан курыккандай, сак кына хәрәкәт белән кулына алды. Яшь кызлардай оялчан елмаю иде йөзендә, бит очлары алланып чыккан, керфекләре дерелди иде.

— Быел миңа чәчкә биргән кеше юк иде әле. Ничек шулай эре, матур итеп үстерә алгансыздыр үзләрен!

— И, аның берние юк! Суганнарын җиргә тыгып куйсаң, үзе үсә ул. Шәһәр өенең баскыч төбендә дә үстереп була. Көзгә таба мин аларның суганнарын да бирә алам сезгә. Тик адресымны гына истә калдырыгыз...

Ике хатын, бер-берсенә елышып, чын ахирәтләр шикелле сөйләшеп киттеләр.

Ә минем күз алдыма аларның сүзләрен каплап, зиһенемне көйдереп, яшьлек дустым Люция килеп басты. Аның язмышы сынуы, өметләре киселүе дә шушындый ук сары чәчкәләр белән бәйле иде бит. Тик аның тарихы юлда барганда җиңел генә сөйләп ташлый торганнардан түгел, авыр, ах авыр ул хәлләрне искә алуы!

Ничек соң әле аның язмышы сары чәчкәләргә барып тоташты?

Моның сәбәпләрен гөлләр чәчәк аткан чакта түгел, гөл орлыклары-ның туфракка төшкән чагыннан эзләргә кирәктер. Ә бәлки аннан да иртәрәк, җирнең гөл орлыгын кабул итәргә әзер булуыннандыр. Чөнки орлык тишелсен өчен, туфракның әзер булуы кирәк.

Ә Люциянең күңелендә мәхәббәт гөлләре чәчәк атсын өчен шартлар әзер иде, күптән әзер иде... Тик аның күңеле буш торды, озак буш торды...

Мин моны көзге кичләрнең берсендә бигрәк тә ачык итеп сиздем.

Дәресләремне бетереп, өйгә кайтырга чыксам, мәктәп капкасы төбендә мине Люция көтеп тора. Бераз гаҗәп тоелды бу миңа: башка чакта, йомышы булса, Люция туры безнең өйгә килә торган иде, мине урамнарда сагалап йөрми иде. Димәк, аның миңа гадәттән тыш йомышы бар!

Ләкин ул миңа үзенең йомышын әйтергә ашыкмады. Безгә хәтле җәяү генә кайттык, юлда гадәти сүзләр сөйләштек: ул эшли торган институт хәлләрен, мин укыта торган балаларны, элекке группадашларны искә алдык — кем кемне күргән дә кем хакында нәрсә ишеткән...

Безгә илтә торган туры юл кечкенә бакча аркылы үтә. Бакчадагы бер эскәмия турына җиткәч, Люция:

— Утырып торыйк әле бераз, — диде.

Сумкасыннан газета алып, юеш эскәмиягә җәйде. Утырдык.

— Кичә тагын театрга бардым. «Сүнгән йолдызлар»ны тагын бер кат карадым әле, — диде ул. — Тагын Мәхдүмгә гашыйк булып кайттым.

— Ни өчен Мәхдүмгә? Нигә егет солтаны Исмәгыйльгә түгел?

— Исмәгыйльгә гашыйк кызлар болай да җитәрлек. Ә Мәхдүм минә охшаган ул. Яратучысы юк аның.

— Нишләп яратмасыннар сине, Люция! Сине яратмый буламыни! Күрмисең генәдер, игътибар бирмисеңдер!

— Ә кем? Кемне күрим мин?

Мин телемне аркылы тешләдем. Люциягә күзе кызып йөргән егетләрне белә идем мин, бар иде андыйлар. Ләкин бит Люция кебек кызга алай күз кыздырып йөрүчеләр генә лаек була алмый. Гадәттән тыш кыз иде безнең Люциябез. Һәм аның мәхәббәте дә гадәттән тыш булырга тиеш иде, ул үзе дә язмыштан зурны — Галиябану белән Хәлил, Ромео һәм Джульетта, Йосыф-Зөләйха мәхәббәте кебек олы, изге, кабатланмас, тугры хис килгәнен көтә, үзенә шундый бөек дәрәҗәдәге хис белән җавап бирерлек пар эзли иде. Моңа аның хакы да бар иде.

Институтта укыганда, ул безнең группабызның күрке һәм мактанычы булды. Биш елда бер генә дүртле дә алмады, гел бишлегә генә укыды, кайбер семинарларда укытучылар белән бәхәскә керерлек гыйлеме бар иде инде аның. Биш ел буе группабызның комсоргы итеп сайланды ул.

Группада аны, исеме белән атамыйча, «Луциус» дип йөртәләр иде. Луциус Корнелиус Суллага — Борынгы Римның шул атаклы гаскәр һәм дәүләт башлыгына тиңләп, көлемсерәү катыш яратып шулай дәшәләр иде аңа: «Луциус!»

Люция үзе дә кушаматка үпкәләми, «Луциус!» диюгә, озын, төз муенын борып, яшь егетләрчә кыска итеп киселгән куе бөдрәләре астыннан акыллы яшел күзләре белән туп-туры синең күзләреңә текәлә, аның түгәрәк мөлаем йөзендә җитди дикъкать һәм таләпчәнлек чагыла иде. Кайгыртучан һәм таләпчән гаскәр башлыгы яисә яшьтән үк кече туганнарын тәрбияләргә күнегеп, иртә акылга утырган кыз бала карашы иде бу.

Һичшиксез, без барыбыз да, шул исәптән егетләр дә, аны ихтирам итәбез, ләкин шул ук вакытта егетләрнең аңа булган мөнәсәбәтендә артык югары күтәреп кую, шунлыктан үзләреннән читләштерү дә сизелә иде. Дөрес, биш ел буе ялгыз торна булып йөрмәде. Икенче курста укыганда физматтан чибәр бер егет белән әйбәт кенә дуслашып киткәннәр иде алар. Кичәләргә, киноларга бергә йөрделәр. Люция бу егеткә бик зур өметләр һәм ышаныч баглаган иде. Ләкин егет укуын бездән алда тәмамлады да, һич көтмәгәндә, мединститут бетергән бер кызга өйләнеп, башка шәһәргә китеп барды.

Люция зарланмады, еламады, хәсрәтен күз карашында да сиздермәде. «Люциянең андыйларга гына исе китми лә, тыштан гына ялтырый иде бит ул егет, ә чынында аның кисеп ташлаган тырнагына да тормый», — дип сөйләштек без группадаш кызлар белән.

Луциус — бездән бер башка калкып торган, нечкә сынына корыч үзәк яшеренгәндәй нык ихтыярлы Луциус — гадәти күз түгел иде, билгеле. Аның язмышы да гадәттән тыш булырга тиеш иде шикелле.

Бер яктан караганда, ул шулай килеп чыкты да. Институтны тәмамлауга Люцияне аспирантурага алдылар, егерме биш яшендә ул фәннәр кандидаты булды, хәзер инде менә докторлык диссертациясе дә әзер.

Тик менә мәхәббәтнең генә аңа лаегы килмәде. Безнең группадагы иң йомыкый кызлар да күптән инде кияүгә чыгып беттеләр, балалар үстерәләр, бер-ике өлгере хәтта икенче кияүгә барып өлгерде инде. Ә Луциус һаман ялгызы.

— Әгәр теләсәң, син әллә кемнәрне таба алган булыр идең,— дидем мин, нихәтле уйлап та, үзем белгәннәр арасыннан аңа тиң кешене таба алмагач.

Бакчада агачлар җан өшеткеч тавыш чыгарып шаулый, кинәт искән дымлы җил безнең өстән юеш яфрак очыра. Люциянең сүзләре исә шул җилдән сагышлырак иде.

— Әгәр мине яратучы булса, гел Мәхдүм төсле бөкре булсын, Квазимодо кебек ямьсез булсын, анысына карамас та идем. Яратсын гына иде. Бары шул гына. Минеке генә булсын иде. Янымда гына торсын иде...

Аңлый идем мин аның хәлен, белә идем, билгеле! Көзнең менә шушындый иртә караңгы төшә торган җилле-яңгырлы кичләрендә ялгызлык кеше күңеленә аеруча авыр итеп сарыла, аны сагыш белән, ялгыз тормышның мәгънәсезлеге турындагы уйлар белән урап ала. Ах, Люция, Люция!.. Ничек кенә ярдәм итим соң мин сиңа! Әгәр үзем егет булсам һәм әгәр дә Әсгатне очратмасам, мин, әлбәттә, үземә синнән башка ярлар эзләмәгән булыр идем!

Кадерен белер идем мин Люциянең! Чөнки мин аның әле беркем белмәгән якларын да сиземли идем. Группадагы иптәшләр арасында ул бераз кырысрак төсле күренә, ә тулай торак бүлмәсенә кайтып, халатын киеп куйгач, ул бөтенләй башка кешегә — йомшак, сизгер күңелле, кайгыртучан, дусты өчен бөтен нәрсәне эшләргә әзер мөлаем кызга әверелә иде. Тик бер нәрсәне — үзен әз генә булса да кимсетүне яисә үзеннән чак кына булса да көлүне һич кичерә алмый. Шуңа күрә мин, аның белән сөйләшкәндә, сүзләрне сайлап кына әйтергә тырыша идем. Бәлки, шул хәтер калучанлыгы аркасында ул үзен корырак, егетләрчә кырысрак итеп күрсәтергә тырышкандыр да әле. Бәлки, шуңа күрә дә ул күңелендәге җәүһәрләрне каты кабырчык астына яшергәндер дә.

Бу юлы да мин аның күңелен рәнҗетмәслек, шул ук вакытта юатырлык сүзләр эзләдем. Эзләдем, табалмадым.

Бакча юлыннан узып барган ике ир кеше безгә таба борылдылар. Караңгыда аларның йөзләре ак тап булып кына шәйләнә иде.

— Сез безне көтәсезме, кызлар?

— Әйдә, китик, — дип минем җиңнән тартты Люция.

Мин аны үзебезгә алып бармакчы идем.

— Рәхмәт, — диде Люция. — Өйгә кайтыйм әле.

Ул бакча коймасы буйлап ашыгып китеп барды. Караңгыда кечерәйгәннән-кечерәеп, сирәк кенә үткән-сүткәннәр арасында күздән югалды.

Кичен мин Люция белән очрашуыбыз турында Әсгаткә сөйләдем.

— Ялгызлыктан интегә, — дидем. — Ичмасан Мәхдүм кебек берәр гарип егет гашыйк булсын иде миңа, ди. Үзенә тиңнәрне театр сәхнәсеннән эзли. Артистка бит ул безнең Луциусыбыз!

— Артистка түгел, антиартистка ул сезнең Люциягез, — дип каршы төште миңа Әсгат. — Һәрнәрсәне артык житди кабул итә. Берәр егетнең үзенә күңеле төшкәнен сизде исә, бу миңа гомерлек яр була алырмы, мәхәббәте чынмы моның, юкмы дип тикшеренә башлый, егетне микроскоп астына салгандай итә. Кемгә ошасын микроскоп астына керү! Мәхәббәттә бераз ихи-михи да кирәк, ансыз булмый!

Мин ирем фикере белән килештем: әйе, Люция мәхәббәткә артык таләпчән, житди карый. Ләкин бу аның җаваплылыгы, күңел сафлыгы турында сөйли ләбаса. Әгәр инде ул берәрсен яр итсә, мәңге аңа тугрылыклы булачак, аңа ярар өчен бөтенесен эшләячәк. Ничек егетләр шуны аңламый! Әгәр аның таләпчән һәм артык житди сыман күренгән кабыгы эчендә нинди күңел яшеренеп ятканын белсәләр, гашыйк булмый түзә алмаслар иде. Әмма Люция үзе ышанмаган кешегә күңелен ачмаячак шул.

Әллә нинди ерып чыга алмаслык хәл иде бу, еллар узган саен Люциянең бәхетле гаилә коруга өмете кими бара иде.

Ләкин көзге яңгырлар үтеп, карлар яуганнан соң, Люция миңа телефон шалтыратты һәм аның элеккегечә кутәренке, дәртле яңгыраган тавышын ишеткәч, минем күңелем сөенеч белән тулды. Әллә инде минем дускаем берәр яхшы кешегә юлыкканмы?

— Сөенечең бар ахрысы, — дидем мин турыдан-туры сорарга яхшысынмыйча.

— Сизеләмени?

— Мин сизми каламмы?

— Бер чакырып таныштырам әле мин сезне!

Дускаемны бәхетле иткән ул кешене, Мәхдүм кебек бөкере, Квазимодо төсле ямьсез булса да, күргәнче үк якын итәргә, яратырга әзер идем мин.

Ул безне сигезенче март бәйрәменә кунакка чакырды. Мин бу очрашу алдыннан шактый дулкынландым. Ни дисәң дә, Мәхдүмне яки Квазимодоны дустым белән янәшә күреп, кәефең кырылмыйча калу ансат булмаячак иде.

Без аңарчы да Люциядә кунакта еш булдык. Аның бер бүлмәле квартиры оҗмахның бер почмагы кебек ямьле, аш-суга да кулы ята, шуның өстенә Әсгат пианино уйнаганда хисле итеп җырлап та ала. Ләкин, барысыннан да бигрәк, аның белән сөйләшүе кызык: дөнья хәлләре һәм фән турында бик күп яңалыклар белеп була иде. Кыскасы, аңа барган саен без рәхәтләнеп ял итеп кайта торган идек.

Мин яңа кеше шушы рәхәтлекне бозмас микән, дип тә шикләндем.

Ләкин егетне күрүгә, бөтен шикләрем юкка чыкты. Гәүдәсе дә төзтуры, буе да Люциядән тәбәнәк түгел, йөзе дә ачык, ак иде аның. Елмаеп кына сөйләшә, Люциянең авызына гына карап тора! Хуҗа булып та йөри шикелле, шул ук вакытта бик үк азынып та китмәгән, үз урынын белә, кечелекле кылана. Һәр сүзендә, һәр хәрәкәтендә Люцияне олылау сизелеп тора. Бер генә кимчелеге бар иде егетнең: ул да булса Люциядән шактый — җиде-сигез яшькә — яшьрәк булуы. Күрәсең, Люциягә бу нәрсә комачау булып тоелмагандыр, югыйсә ул үзенә якын да җибәрмәс иде. Безгә күрсәтәсе иткән икән, димәк, зурдан иде аның өмете, нияте җитди иде. Хәер, нигә өметләнмәскә: егетнең яшьлеге бәрабәренә үлчәүне үз ягына авыштырыр өстенлекләре җитәрлек иде лә аның!

Кыскасы, Люция өчен сөенергә кирәк иде. Мин сөенергә тырыштым да. Ләкин чын күңелдән шатланырга тагын бернәрсә комачаулык итте: ул да булса егетнең текә маңгае астыннан сөзеп караучы күзләре. Сирәк кенә карый иде ул, ләкин шул бер карашы белән сине аркылыга-буйга үлчәгәндәй итә дә куя иде. Караганын сиздермәскә тырыша үзе, син сискәнеп борылуга, елмая башлый, ләкин бер мизгелдә тоелып калган ул караш сине сагайта, күңелне шомландыра иде. Шуның өстенә Әсгат тә минем шатлыгым балына кашык белән генә түгел, чүмеч белән чумырып дегет салгандай итте. Флүн белән — егетнең исеме Флүн иде — бер авыз сүз алышмады. Люция белән аны-моны гына сөйләшкәләде дә, бер-ике чынаяк чәй эчкәч һәм баскычка чыгып берүзе — Флүн тартмый иде — сигарет тартып кергәч, мине кайтырга ашыктыра башлады.

Юл буе башын чайкап:

— Ну артист! Ну артист! — дип кайтты. Ә өйдә:

— Люциягә әйт: ул малайны пропискага кертә күрмәсен тагын, — диде. — Аңа ышанып квартирын пыран-заран китермәгәе!

Горур Люциянең күңелен рәнҗетеп андый сүз әйтеп буламыни! Моны Әсгат үзе дә яхшы белә ләбаса. Өстәвенә Люциянең ялгышканына

һич кенә дә ышанасы килми иде. Шуңа күрә, иремнән дә бигрәк үз күңелемне ышандырырга тырышып, Люция кешеләрне таный ул, малай-шалайдан алданмас дип, чын-чынлап әрләшергә керештем. Ләкин күңелем бер генә дә тыныч түгел иде, ай тыныч түгел иде!

Үзебез укыган чакта шулай үзләреннән күпкә өлкән хатыннар белән бәйләнгән бер-ике студент искә төште. Алар безнең башка егетләр кебек тулай торакта коры-сары белән ничек туры килде шулай тукланып, майка-штаннарын кулъюгыч краны астында юып интекмәделәр — үзләренә әзер оя таба белделәр. Өсләре чиста, тамаклары тук, күңелләре хуш иде. Хәтерлим, Рәниф исемле бер егетебез үзенең шундый кешесен «хатыным» дип йөрткән була иде, бию кичәләренә дә алып килгәләде... Яше егермедән яңа узган егет янында гәүдәсе шактый тулыланган, утызга житкән хатын безгә бик көлке булып тоела иде. Бичара хатын, белде микән почмак саен авыз ерып үзеннән көлеп торганнарын. Ни хикмәттер, бу хәлгә күпләр Рәнифнең бик оста корган хәйләсе итеп кенә карыйлар, дөрес эшли, нигә мөмкин булганда рәхәт күрмәскә дип, аны хуплаучылар да табыла иде. Кыскасы, болай яшәү егет кешенең дәрәҗәсен артык төшерми, әмма хатынны бөтенләй юкка чыгара, аны чутсыз арзанайта шикелле иде. Белмим, андый хатыннар ни уйлап, нәрсәгә өметләнеп асраганнардыр ул студентларны. Бәлки, аларның тасма телләренә ышанып, киләчәктә бергә булуларына өмет саклаганнардыр. Егетне үз яннарында тоту өчен, аларга бар көчләренә ярарга тырышалар иде алар. Әмма мондый «кавышулар»ның ахыры һаман бер төрле тәмамлана иде: егетләр шул рәвешле өч-дүрт ел бал-май эчендә йөзеп яшиләр дә, диплом алгач, канат җәеп, направление кәгазендә күрсәтелгән юнәлешкә очып китәләр иде. Яңа урында үзләренә тиң пар табып, яңа оя коралар. Ә анда, иске ояда, еллар буе күзен аңа төбәп яшәгән хатын нишли, ниләр кайный аның эчендә — егетнең эше юк, әйтерсең, ул кеше белән бөтенләй танышлыгы да булмаган.

Люция дә шундый кадерсез булыр микәнни, ул да шулай адәм көлкесенә калыр микәнни? Булмас, булмас, Люция акыллы, зирәк, ул кешеләрне таный белә, ул үз дәрәҗәсен төшерүгә юл куя алмый, үз кадерен яхшы белә бит минем дустым!

Мин бу хакта бар шикләремне Люциягә әйтеп, ничек булса да аны үз хәленә аеграк карарга мәҗбүр итәрмен, дип бик нык күңелемә киртләп куйган идем.

Ләкин соңгы очрашуларда бөтен уйларымны ачып салырга һич кенә дә җай табылмады. Люция кешеләрнең бу сабакларын оныткан һәм минем сүзләремне дә тыңларлык хәлдә түгел иде. Гадәттән тыш мәхәббәт көтеп яшәгәнгә, ниһаять, килгән бу бәйләнешне мәхәббәтнең зурысы дип үз-үзенә ышандырырга тырыша иде. Ул студент асрап адәм көлкесенә калган хатыннар турында искә алырга да, ишетергә дә теләми, үзенә әдәбияттан, театр сәхнәсеннән мисаллар, үрнәкләр эзли иде.

— Айседора Дункан Есениннан унҗиде яшькә өлкән булган әле. Ә безнең аерма — сигез генә яшь.

Бәхәсләшмим, Люция үз урынында Айседорадан бер генә дә ким түгел, ләкин Флүнне Есенин белән ничек чагыштырмак кирәк! Аннары бит шунысын да онытырга ярамый: ничек тәмамланган бит ул Дункан белән Есенин мәхәббәте!

— Яшь мәхәббәт яшәртә ул, — ди иде Люция. — Йосыф гашыйк булгач, Зөләйха өр-яңадан яшәргән бит әнә!

Люциянең теленнән Флүн исеме төшми иде: «Флүнгә кирәк», «Флүн ярата», «Флүн әйтте». Шуннан гына да аның күңеле бик үк тыныч түгеллеген сизеп була иде. Тигез мәхәббәт белән кавышып, тату гомер иткән кешеләр бер-берсенең исемен кирәк-кирәкмәскә талкып кадерсезләмиләр, ул синең яшәвеңнең табигый бер шартына әверелә.

Люция бер нәрсәне дә яшерә белми, аның Флүн белән булган мөнәсәбәтләрен институтта да яхшы беләләр иде, күрәсең. Болай фаш булу Флүнгә файдага гына, ник дисәң, укытучылар, Люциягә ихтирам йөзеннән, аңа билге куйганда аркылысыннан буен кат-кат үлчиләр. Кыскасы, көнкүрештә генә түгел, укуда да Люциянең ярдәмен күп күрде егет.

Ул соңгы курсларга житкәч, Люция аңа шәһәрдәге әйбәт мәктәпләрнең берәрсеннән урын да эзли башлады. Күрәсең, киләчәктә бергә тормыш итү турында алар арасында күп сүз булгандыр. Миңа барысын да белү кыен, чөнки әлеге сигезенче март кичәсеннән соң минем Әсгатем аларга барып «шома егет» белән очрашудан баш тартты, без гомумән сирәк күрешә торган булдык. Хәер, Люциянең бөтен тормышы Флүн белән мөлдерәмә тулган, аның күңелендә безнең кебек дус-ишләргә урын азайды.

Ничек килеп кергән соң ул шома егет Люциянең тормышына, ничек анда шулай иркенләп урнаша алган?

Мин моны соңыннан, берничә еллар узгач кына белдем. Анда да Люция миңа өзеп-өзеп кенә сөйләде. Ләкин, икесенең дә холкын белгәнгә, мин бу хәлләрне шактый ачык итеп күз алдына китерә алам.

Флүн китап өстендә күз талдырып, ми черетеп утыра торганнардан түгел, үзе утырган тормыш арбасын такыр юлдан шома гына тәгәрәтү җаен белә, үргә менгән чакта, башкалардан эттерү чарасын табарга да оста иде. Андыйларны очратканым бар минем, бу талант аларга тумыштан бирелә бугай, минемчә, аңа өйрәнү мөмкин түгел. Тик алардан ераграк булсаң иде, алар арбасын этәргә язмасын иде, дип теләргә генә кала.

Табигый ки, таләпчән Луциус аңа зачет куймаган. Ике кергән егет, өч кергән — Луциус аны борып чыгара торган: «Укыгыз әле тагын бер кат!» Ниһаять, көтәр көннәр калмаган, деканат студентка шундый шарт куйган: яки син иртәгә зачетыңны тапшыру турында зачеткаңа тамга салдырып киләсең, яисә имтиханнарга кермисең, димәк, институт белән хушлашасың.

Менә шунда инде Флүн беренче тапкыр укытучысының өенә юнәлгән дә. Бәлки, ул юл буе Луциусның җиде бабасын эттән алып эткә салып сүгеп, каһәрләп баргандыр.

Мин аның ишектән ничек килеп кергәнен бик яхшы күз алдына китерәм. Оҗмахның бер почмагы кебек ямьле йортны, ул йортта бары бер генә нәрсә — шушы ямьле, якты урында рәхәт чигеп, кадер-хөрмәт эчендә яшәргә бер ир кеше генә җитмәгәнлеген бер карауда чамалап алгандыр ул, мөгаен. Ах, аның астан сөзеп кистереп карап куюлары! Шул карашы белән квартирны гына түгел, өстенә ефәк халат, аягына йомшак башмак киеп бизәкле келәмнәрдә тавышсыз басып йөргән, ялгызлык кочагында сагышланганы бөтен кыяфәтенә бәреп чыккан, назга сусап олыгаеп килгән кызны да үз бизмәненә салып үлчәгәндер һәм аның бәһасен шунда ук чамалагандыр ул... Өендә чакны Луциус, ядан кайтып, бөтен калкан-кылычларын, тимер күлмәкләрен салган сугышчыга охшап кала иде. Аның хатын-кыз икәнлеген дә, егет бәлки шунда, өендә генә күргәндер.

Ул кичне егет күптән зарыккан «өчле»сен зачеткасына куйдырып чыгып китә.

Китә, ләкин икенче көнне шул ук сәгатьтә тагын килә.

— Гафу итегез, Люция Кадыйровна, мин тагын сезне борчыйм әле. Көн буе вөҗданым тынгы бирмәде. Кичә мин сезгә өчлелек җавап бирә алмаган идем. Бүген көн буе китап өстендә утырдым, ул теманы ныгытып укыдым. Рөхсәт итегезче, мин сезгә зачетны яңадан тапшырам. Билге өчен түгел, вөҗданымны тынычландыру өчен...

Луциус бу салам-торхан алдында ишекне шартлатып ябып куярга тиеш иде. Әмма ул югалып калган. Бер генә мизгелгә, күз ачып йомарлык бер вакытка гына. Ләкин сугышчан маневрны бөтен нечкәлекләренә кадәр алдан уйлап килгән шома егет — ир-ат белән хатын-кыз арасындагы мөнәсәбәтләр фронтында Луциустан чагыштыргысыз зирәгрәк һәм талантлырак Флүн — кызга аңына килергә ирек бирмәгән. Аны этеп диярлек ишектән кергән, керә-керүгә кочагына алып, иреннәренә үрелгән, ә аннары тезләнеп, аның тезләреннән кочып алган:

— Теләсә нишләтегез, тик куып кына чыгармагыз!..

Күп спектакльләрдә кабатланган шушы арзанлы кыланыш безнең Луциус дигән кыябызны җимергән дә ташлаган.

Хәер, гаҗәпмени, ул кыя тыштан караганда гына шулай мәгърур күренә, эчтән инде сагыш сулары юган, ялгызлык хәсрәте саргайткан иде аны.

Ләкин Луциусның горурлыгы, мин җимерелгән кыя шикелле юк җилдән дә ишелеп төштем, дип үзенең көчсезлеген танырга ирек бирми иде. Киресенчә, бу егет үзе минем яулап алган сугышчан хәзинәм, дип үзен дә, башкаларны да ышандырырга кирәк иде аңа. Ул гына да түгел, бу хәзинә мин яуларга лаек, дип тә исбат итәргә кирәк иде.

Мәгълүм булганча, Луциус Корнелиус Сулла вак-төяк белән булышмаган, Римның үзен яулап алып, анда үз законнарын урнаштырган.

Флүн — шома егет тә бу уенны күтәреп алды. Алар икесе дә спектакль уйныйлар һәм ул спектакль тамашачыларга: «Әйе, болар тигез гомер итеп, бер көнне үләргә һәм бер каберг̧ә ятарга дип кенә дөньяга килгәннәр»,— дигән фикерне сеңдерергә тиеш иде. Уйнаучыларның берсе исә моңа чын күңелдән ышанган иде. Шул хәтле ышанган иде ки — үзе белән уйнаган кешенең гарипләеген дә сизми иде. Дөрес, ул гариплек Квазимододагы яки Мәхдүмдәге кебек тышта түгел, ләкин игътибар беләнрәк караган кеше аның эчендә, күңелендә гариплек барын сизәргә тиеш иде. Луциус моны күрмәде, күрсә дә төзәтермен әле дип өметләнгәндер бәлки.

Ләкин һәр уенның бер чиге була. Бу тамашаның да ахыры җитеп килә иде.

Яңа елны каршыларга әзерләнеп ятканда, ялгызы гына безгә Люция килеп керде. Кулында зур гына төргәк, йөнтәс бүреге астыннан бөселеп чыккан бөдрәләрен бәс баскан.

— Син Яңа ел, яңа бәхет көтәсеңдер, ә монда иске дус, иске ваем килде әле, — диде ул.

— Кер, Люция! Ваемнарын бүләрбез — кечерәер, бәхетләрне уртак итәрбез — зураер. Бик дөрес иткәнсең килеп, Яңа елны бергә каршы алырбыз.

— Сез өйдә каршы алмакчымыни?

Әйе, ул кичне без Әсгат белән икәүдән-икәү генә утырмакчы идек. Әни, кызыбызны алып, өлкән апаларга киткән иде — алар анда балалар өчен бәйрәм оештырганнар. Күптән инде бәйрәмнәрне икәүдән-икәү каршы алган юк, яшь чакларны искә төшерик әле, янәбыздагы матур шәһәр чыршысы янына чыгып, бозлы таудан шуарбыз, таган атынырбыз, боз лабиринтында адашып йөрербез, күңел ачып, шау-гөр килгән халык арасында бер тулганырбыз, дигән идек. Алай да үзебезгә бер табын әзерләргә кирәк дип, Әсгат кибеткә чыгып киткән иде.

Безнең бу бәйрәмебезгә Люция чыячак иде. Тик теге Флүне генә килә күрмәсен. Кая икән соң әле үзе?

Мин моны сорарга ашыкмадым. Люцияне чишендереп, кухняга алып кердем, кофе куйдым. Дускаемның йөзе ялгызлык сагышларыннан интеккән чакларындагыдан да караңгырак, ул суырылган, картаеп киткән иде.

«Егет койрыкны бора башлаган, ахрысы!» — дидем мин пошаманга төшеп.

Люция Яңа елга күлмәк тектергән икән, шуны күрсәтергә килгән булып чыкты. Кофене юньләп эчеп тормады, залга чыгып, көзге каршына басып, күлмәген киде. Көрәнсу тукымага эре сары тюльпаннар чигелгән иде: итәк очына да, җиңенә дә. Тегүчесе тәкъдим иткән, быел сары модада, дигән.

Бу күлмәкне тегәргә биргәндә, мөгаен, Люциянең йөзе көләч булгандыр. Ә хәзер аның ямансулыгын көчәйтә генә иде бу сары чәчкәле көрәнсу күлмәк.

— Бөтенләй тегә белми башлады Флера, — диде Люция. — Мин дигәнчә килеп чыкмаган. Картайта.

Хикмәт күлмәктә түгел, Люциянең үзендә иде, әлбәттә. Картлыкяшьлек аршинын Флүнгә һәм аның яшьтәш студент кызларына чамалап үлчәргә кирәк иде аңа. Минем өчен ул һаман яшь, зифа иде, студент чактагыдан бөтенләй үзгәрмәгән дә шикелле. Буе-сыны төз, нечкә, муены озын. Тик бөдрәләрендә көмеш җепләр чагылып китә дә, муенында нечкә сырлар, елмайганда күз төпләрендә җыерчыклар пәйда була. Аерым торганда болар әллә ни сизелми дә, ләкин ул Флүненең күз алдында студентлар белән янәшә тора бит. Янәшә куеп чагыштырсаң, яшь чамасы бик ачык күренә, аңлатып та булмый торган билгеләре әллә каян кычкырып тора бит. Ләкин боларны Люциягә турыдан-туры әйтеп булмый иде. Ул күлмәген салып, тегүчедән зарлана-зарлана бил турысын сүтә дә башлады. Аннары, эшен ташлап, кинәт башын күтәрде һәм:

— Элек син минем өчен утка керергә әзер идең, Зәйтүнә, хәзер дә шулаймы? — дип сорады.

— Әгәр ул утларда син булсаң, сине алып чыгарга тәмугка да керәм, Люция.

— Юк, бу юлы үзең үк кермәсәң дә була. Кулыңны гына суз миңа. Юк, син миңа сузма кулыңны. Телефон трубкасына суз. Шуны ал да менә шушы номер белән шалтырат әле.

— Флүнне сорыйммы?

— Әйе, кырык бишенче бүлмәдән чакырып китерсеннәр.

«Ә ник үзең шалтыратмыйсың?» — дип әйтүдән чак кына тыелып калдым. Билгеле инде ник икәне. Күрәсең, ул анда еш шалтырата торгандыр, тулай торакта аның тавышын таныйлардыр! Я хода, нинди хәлгә төшкән бит безнең мәгърур Луциусыбыз. Улмы инде — студент артыннан ялынып, кимсенеп йөрүче? Улмы — мине дә кимсенергә мәҗбүр итүче?

— Ташла син шуны, шалтыратма, ялынма! — дип әйтергә дип башымны күтәрдем, ләкин аның йөзен күргәч, тыелып калдым: кусәк күтәргән хуҗасына караган көчек баласы шикелле куркып, ялварып һәм чарасызлык белдереп, мөлдерәп карап тора иде ул миңа.

— Ярый, — дидем. — Ни әйтим соң?

— Син чакыр гына. Килгәч үзем сөйләшермен.

Кырык бишенче бүлмә өченче катта ук икән. Шактый озак көтәргә туры килде. Люциянең түземсезлеге кайнар сулышыннан ук сизелә иде. Я хода, килсен иде бу Флүн телефонга, ни әйтсә дә әйтсен, тик килсен генә иде, болай интектермәсен генә иде Люцияне!

Ниһаять,тек-тек аяк тавышлары ишетелде.

— Флүн өйдә юк, — диде бер кыз тавышы.

Люция бөтен гәүдәсе белән өстәл аша миңа таба сузылды, аның хәленә кереп, мин дә аңа таба үрелдем, телефон трубкасының аркасын колагына терәдем.

— Ә кайда соң ул, кайчан кайта? — дип сорадым.

— Без каян белик. Бер... карчыгы бар бит аның, шунда ятадыр, шунда шалтыратып карагыз.

Тавыш «карчыгы» сүзенә басым ясап, ничектер мыскыллап әйтте, кемнәрнеңдер хихылдаганы колакка чалынып китте. Мин корт чаккандай артка тайпылдым. Нигә соң әле бу мыскыллы сүзләрне, көлүне Люциягә тыңлатып торам! Аның җәрәхәтле йөрәгенә тоз сибеп! Ләкин соң иде инде. Люция барысын да ишеткән. Аның йөзе киндердәй агарган, күзләре зур ачылган иде. Аны тораташка әверелдергән нәрсә аннан көлүләре түгел — кем көлә диген бит әле, Люциянең үз шәкертләре, студентлар көлә! — әйе, үзенең адәм көлкесенә калуы түгел, бөтенләй башка нәрсә булып чыкты.

— Ишеттеңме? Ул анда да юк икән бит! — диде ул саташкан шикелле. — Әллә берәр нәрсә булды микән? Мин бит аны шунда ята дип уйлыйм, ә иптәшләре миндә дип беләләр. Кешенең кайдалыгын белүче юк. Ә бәлки ул берәр бәхетсезлеккә дучар булып, больницага эләккәндер. Һушсыз ятадыр, авызына су салучы да юктыр! Скорый помощка шалтыратыйк!

— Ташла, зинһар, — дидем мин. — Ни булсын ул тәти егеткә! Берәр компания белән Яна ел каршыларга йөри торгандыр әле!

— Юк, ул алай итә алмый... — Люция телефонга үрелде.

— Шалтыратмыйсың да, нитмисең дә, — дидем мин ачуым чыгып.

Ул калтыранган куллары белән ян җөйләре сүтелгән күлмәген кире киеп куйды. Җиң очларында, итәгендә сары чәчкәләр янып тора, йөзендә сары сагыш.

— Туктале, нишләп саташып йөрим соң әле мин, — диде ул. — Ул мөгаен кайткандыр инде. Кайткандыр, әлбәттә, мине Яна ел белән котламыйча кала алмый бит инде ул. Ә мин монда тулганам.

— Килсен, көтсен бераз! Артыңнан ялынып йөрсен, кадерлерәк булырсың, утыр монда гына, — дип үгетләргә тырышсам да, ул минем әйткәннәрне ишетмәде. Ишектән чыгып киткәндә, миңа таба борылды да:

— Бик бәхетсез килә бу ел минем өчен, — диде.

Кайтып китте Люция, элекке ялгызлык сагышы өстенә тапталган горурлыгы, кимсетелгән саф хисләре өстәлгән квартирына кайтып китте.

Мәхәббәт җәрәхәтләреннән озак терелә йөрәк, ай-һай, озак терелә. Ә кайчак ул гомер буе да төзәлеп житми, һаман сызлап тора. Әгәр дә аны өсте-өстенә җәрәхәтләп торсалар, бигрәк тә. Люция ул шома егет белән көн саен институтта очрашып тора иде бит, ул аны күрә иде; күргән саен йөрәгендәге ярасы тирәнәя бара иде. Аныңниләр кичергәнен мин күзаллап та бетерә алмыйм.

Бөтен өмет Флүннең тизрәк диплом алып кая да булса эшкә китеп баруында иде. Ләкин бу өметләр дә акланмады. Ул Казанда бик яхшы урынга урнашып калды. Бу очракта да ул үзенә җирлекне шул ук өлкәдә — мәхәббәт өлкәсендә тапкан булып чыкты.

Студентларның дәүләт имтиханнары башланыр алдыннан Люция миңа шалтыратты.

— Иртәгә сәгать уникегә загс янына кил әле, — диде.

— Ни бар анда? Әллә кәләшнең иң якын дусты итеп чакырасыңмы мине?

— Килгәч күрерсең.

— Туктале, алай булмый бит, ул-бу булса, матур итеп киенергә кирәк, чәчәкләр алырга кирәк...

— Киенмә дә, әзерләнмә дә. Карап кына торырсың.

— Тамашачы булыпмы?

— Әйе, шул чама.

Шулай диде дә, мине тәмам аптырашта калдырып, чылт итеп трубканы куйды бу.

Люцияненң сүзен аяк астына салып булмый — мин нәкъ билгеләнгән сәгатьтә загс каршындагы киоск янында басып тора идем инде. Кояшлы җәй башы, шимбә көн, загс тирәсендә бизәлгән машиналар тора, ак күлмәкле кәләшләр белән кара костюмлы кияүләр тирәсендә төркем-төркем булып киенешкән-ясанышкан, шат күңелле кешеләр бөтерелә. Күңелне дулкынландыра торган булса да, загс янында гадәти күренеш. Нигә дип чакырды икән мине Люция?

Бер-бер артлы тагын дүрт-биш машина килеп туктады, алдагысыннан безнең танышыбыз Флүн төште. Әһә, менә ник икән. Кара костюм, ак күлмәктән. Менә ул билен бөгеп, машинадан чыгып килгән озын ак күлмәкле кәләшкә кулын сузды. Тулып пешкән иреннәрен чак кына ачып, дулкынланып елмая иде кәләш, яшь иде ул, чибәр иде, аның Флүнгә төбәлгән йөзендә ярату гына түгел, аллага табынгандай табыну балкый иде. Аларны шунда ук башка машиналардан төшкән кешеләр әйләндереп алдылар. Матур киемнәре, ирләрнең үзләрен горур тотуы белән бу төркем хәтта загс янында да аерылып тора иде. Күрәсең, чибәрлеге, яшьлеге өстенә кәләшкәйнең башка өстенлекләре дә бар иде.

Мин киоск артыннан алгарак чыктым. Нишләр икән шома егет таныш кешене күргәч?

Ул мине күрде, ак йөзеннән күләгә узгандай булды. Ләкин ул күләгәне мин генә сизеп калдым, кәләш йөзеннән балкыган кояш яктысында күләгә шунда ук юкка чыкты. Ул кәләшенең җиргә тияр-тимәс барган челтәр бөркәнчеген төзәтеп куйды, кулындагы ак гладиолусларга кагылмаска тырышып, култыклап алды. Алар загсның биек ишегеннән кереп киттеләр. Тантаналы марш көенә бизәкле келәмнәрдән атларга, үзләрен котларга махсус киенеп килгән могтәбәр кешеләрнең изге теләкләрен тыңларга, кадер-хөрмәт күрергә, балдак алышырга, мәңге бергә булырбыз, дип ант итәргә кереп киттеләр.

Шул вакыт миндә бер теләк туды: йөгереп керәсе иде дә, бөтен кеше каршына басып: туктагыз, сез нишлисез, кемне тәбриклисез, кемне котлыйсыз, ул бит хыянәтче, алдакчы, ул үз йөрәген сатучы, башкаларның хисләрен аяк астына салып таптаучы, дип әйтәсе иде. Ни булыр иде икән? Хәер, андагылар, Флүнгә ияреп тантана залына кереп китүчеләр, аның кемлеген моңарчы белмиләр идемени? Нишләп белмәсеннәр! Бөтен институтта фаш иде бит ул хәл! Аннары төркем арасында да бер-ике таныш чырай чалынып китте әле. Люцияненң танышлары... Яшь парны котларга килгәннәр...

Менә мин олыгаеп киләм инде, әмма бер нәрсәне һич кенә дә башыма сыйдыра алмыйм — ул да булса мәхәббәт өлкәсендә хыянәтнең, ялганның, мәрхәмәтсезлекнең, шәфкатьсезлекнең бернинди җәзасыз калуын.

Әйтик, әгәр син берәрсенең тәнен җәрәхәтләсәң яки яман сүз әйтсәң, — сине хөкем итәчәкләр, суд каршына бастырачаклар, прокурор гаепләячәк, адвокат яклау чарасын эзләячәк, аннары гадел дип табылган җәзаны бирәчәкләр. Ә менә берәүнең иң изге йөрәк хисләрен, иң якты өметләрен, хыялларын, ышанычын урлаган өчен, аны алдаган өчен, аның күңеленә төкергән, газап утларында янган йөрәген аяк астына салып таптаган өчен бернинди суд та, җәза да юк. Киресенчә, мәхәббәттә шул рәвешле җинаять кылып йөрүчеләр үзләрен хаклы, хәтта башкалардан өстен саныйлар, саф хисләргә, тугрылыкка ышанганнарга көлеп кенә карыйлар.

Әнә аларның берсе — шат чырайлы кешеләр төркеме уртасында, мәхәббәт алласының изгелегенә инанган кешеләр генә атлап керергә тиешле ишектән, яшь, чибәр, гөнаһсыз, ышанучан, үзенә гашыйк бер җанны кулына күтәреп чыгып килә. Ниләр язган икән мескен кыз балага ул кеше кулларыннан күрергә? Ә кыз әнә ничек ышанган, ак перчат-

ка кигән куллары белән хыянәтче муенына ничек ышанып сарылган, нурлы йөзе шатлыктан ничек балкый! Белми шул ул, белми язмышын кемгә тапшырганын!

Тукта, нинди күләгә төште соң әле кызның йөзенә? Күзләре нигә болай куркып ачылды, йөзе агарынды? Шома егет тә аптырап калды, кәләшен кулыннан ук төшерде...

Мин артыма борылып карадым. Тротуар кырыена, тасмасыз, шарсыз, бизәлгән машиналар арасында шәп-шәрә булып күренгән кап-кара «Волга» килеп туктады. Ишеге ачылып китте һәм аннан бер хатын... хатын түгел, күңелгә шом салып тере күләгә калыкты. Елтыр-елтыр килеп торган кара күлмәк итәге җирдән сөйрәлә, кара эшләпәсеннән төшкән кара челтәр битен каплап, артыннан җилфердәп килә, кара перчатка кигән озын бармаклы кулларында кара тасма белән бәйләнгән сапсары тюльпаннар... Загс янында түгел иде бу күләгәнең урыны, ничек ялгышып, саташып монда килеп чыккан, нигә ул тораташ булып биек ишек төбендә катып калган төркемгә таба бара?

Беркем берни аңларга өлгермәде. Тере күләгә яшь пар каршына килеп җитте дә, кулындагы бәйләмен егетнең аяк астына ташлады. Сары чәчәкләр сары ялкын кебек җиргә сибелделәр. Кәләш ах итеп Флүннең кочагына ауды. Ул кәләшен тотып алды. Үзе ялтыравык кара ботинкасы белән тюльпаннарга тибә, аларны читкә этәрергә азаплана, ә чәчәкләр типкән саен авыртудан сискәнгәндәй тетрәнәләр, алтын кыңгыраулар шикелле зыңгылдау авазы бирәләр иде шикелле...

Күләгә сын ашыкмыйча гына машинага таба кире китте. Шаккатырлык матур, төз иде бу сын, шул ук вакытта өнсез калдырырлык шомлы иде. Әгәр мәхәббәт дөньясында фаҗигане һәм җинаятьне билгеләүче фәрештә булса, ул шундый булырга тиеш иде.

Менә ул салмак хәрәкәт белән машинага кереп утырды. Хәзер инде кара «Волга» зур тизлек белән урыныннан кузгалып, кешеләр аңына килгәнче, күздән югалырга, кара фәрештәнең биредә булганын раслап, бары тик сары тюльпаннар гына калырга тиеш иде.

Ләкин барысы да син теләгәнчә килеп чыкмый шул. Чаттагы светофор, кызыл күзен кабызып, машинаның юлын кисте. Ул арада ишек төбендәге төркемнән берничә ир, аңнарына килеп, машинага таба йөгерделәр, ишегенә үк барып тотындылар. Мин ашыгып алар артыннан киттем. Каты кычкырып:

— Рөхсәт итегез! — дидем.

Алар көтелмәгән тавышка борылып карадылар. Мин аларны аралап машинага кереп тә утырдым һәм шоферга «кузгал!» дидем. Шул мәлне светофор яшел күзе белән карады...

... Кемдер минем кулыма орынды. Троллейбуста миңа каршы утырган күзлекле апа икән.

— Алыгыз сез дә бераз, — дип, миңа сары тюльпаннар сузды ул.— Алыгыз. Матур бит.

— Юк, юк, рәхмәт, — дидем мин. — Сары тюльпаннар бик авыр хәлләрне исемә төшерә минем...

**Марсель Зарипов**

# МӘҢГЕЛЕК ШӘҺӘР

ОЧЕРК

*
* *

Шәһәрләрнең язмышын юкка гына кешеләр язмышы белән чагыштырмыйлар. Яшьлек чорларын кичергәндә алар да шөһрәт казаналар, берсеннән-берсе зуррак, күркәмрәк эшләр турында хыяллана-лар. Чорлар уза... Кайчандыр тиңсез шөһрәткә ия булган Бүләр, Сарай, Болгар, Тмутаракан, Вавилон, Отрар шәһәрләре хәзер ерак чорлар эзеннән атлаучы тарихчылар һәм археологларга гына билгеле.

Мөгаен, вакытлар узу белән, бу яктагы удар төзелешләр бетәр, элек беркемгә дә билгеле булмаган тып-тын бер урында калкып чыккан Түбән Кама каласында шау-шу тынар, андагы вакыйгалар, озын көзнең чиратлашып килгән көннәре сыман, бер-берләренә охшаш булып калыр. Бу шәһәргә дә яңа яшь калалар күтәрелүен көнләшү белән читтән генә күзәтеп торырга туры килер.

Түбән Каманың роле бүген әйтеп бетергесез зур. Аның әһәмияте киләчәктә тагын да үсәчәк, чөнки без яңа чор — ясалма әйберләр һәм материаллар җитештерү чорына аяк бастык. Түбән Кама тылсымчылары беренчел чимал атомнарыннан һәм молекулаларыннан оештыра торган полимерлар теләсә нинди материалны яңабаштан җитештерү өчен кирәк. Полимерлар — подшипниклар, шестернялар, кабельләр, тормоз кысалары, торбалар, эш кораллары, уенчыклар, чәчәкләр һәм картиналар ул. Аларның массаларыннан мебель, йортларны һәм квартираларны бизәү әйберләре, йөрәк клапаннары, ясалма бавырлар, ванналар, шлюпкалар, баткаклыклар һәм сазлыклар өстеннән сузу өчен юллар, ясалма кәгазьләр эшлиләр. Резинадан башка бер генә машина, комбайн һәм трактор да, бер генә самолет та хәрәкәткә килә алмый. Ә резинаны каучуктан ясыйлар. Күп кенә очракларда пластмассалар металлга караганда да уңайлырак һәм ышанычлырак. Бик кирәк булганда аларны корыч, титан, вольфрам урынына кулланалар. Кешене яңа планеталарга алып очачак космик аппаратларны җиңел һәм юка пластикадан төзиячәкләр. Иксез-чиксез Галәм киңлекләрендә температура 12 мең градуска җитә. Мондый

Ахыры. Башы журналыбызның җиденче, сигезенче саннарында.

эсселеккә нинди генә металл чыдар икән!? Ә бер планетадан икенчесенә очарга тиешле космик аппарат полимердан, ягъни мебель, уенчыклар, автомобильләр ясау өчен файдаланыла торган бер үк материалдан эшләнәчәк. Әлбәттә, аның сыйфаты тагын да яхшырак булачак.

Һәр яңа нәрсә атомнар һәм молекулаларның механик кушылмасы гына түгел. Ул — кешеләрнең өмет һәм шатлыклары, мәшәкать һәм борчылулары, куллары һәм йөрәкләре белән көннең-көнендә ялыкмый, авырсынмый башкара торган эшләре.

Комбинатның баш технологы Г. Җ. Сәхапов белән без нефть-химия индустриясенең киләчәге, шәһәрнең иртәгәге язмышы турында сөйләшеп утырдык. Ул сурәтләгән эшләрдә фантастиканы чынбарлыктан аера торган сызыкны билгеләү бик кыен. Чөнки бүгенге көн инде хәзер үк иртәгәсе көнгә әверелә.

— Без эшләп чыгарган әйберләрнең 86 проценты дәүләт Сыйфат билгесенә ия,— диде Гаяз Җәмикович, гади солдаттан зур белгеч дәрәҗәсенә күтәрелгән гаять тыйнак, эшчән һәм үз-үзенә таләпчән инженер.— Әмма без эшләп чыгара торган продукциягә таләпләр үскәннән-үсә. Берничә елдан соң бүгенге сыйфат беркемне дә канәгатьләндерməячәк. Халык хуҗалыгының төрле тармаклары, фән һәм техника, сәүдә, кешеләргә кирәк әйберләрне эшләп чыгарган заводлар тагын да югарырак сыйфатлы материаллар көтәләр. Алда тагын да зуррак эшләр тора. Алар безгә дә, безне алыштырачак киләчәк буыннарга да җитәчәк.



*
* *

Ә башта ким дигәндә бик мөһим бер мәсьәләне ачыкларга кирәк. Шундый чиксез биеклеккә омтылган шәһәргә бакларда ягулык җитәрме, ярты юлны үткәч, газны киметеп, туктальп калырга туры килмәсме? Ягулык дип сөйләгәндә без барыннан да элек нефтьне күз алдында тотабыз. Түбән Кама территориаль-производство комплексы нәкъ менә нефть эшкәртү нигезендә үсеп чыкты һәм формалашты. Ә аның запаслары, кайберәүләр уйлаганча, чиксез түгел. Белгечләрнең исәпләп каравынча, насослар җир астыннан «кара алтын»ның соңгы тамчыларын суырткач та кешеләр моторларны сүндерергә мәҗбүр булачаклар.

Планетаның киләчәге турында уйлап борчылган галимнәр иртәгәсе көнгә юраулар коралар. Аларның төп асылы кешелекнең чәчәк атуы һәм тормышның дәвам итүе өчен кирәкле җир асты байлыкларының күпме вакытка җитәчәген билгеләүгә кайтып кала. Су, металл, күмер, нефть, саф һава, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясындагы байлыклар күпмегә җитәчәк — барысы да шул хакта баш вата.

Юрауларның исәбе-хисабы юк. Түбән Кама каласын беренче чиратта нефть хәлләре кызыксындыра. Безнең гасырның сиксәненче еллары уртасына ирешелгән 12. 800 миллиард тонна шартлы ягулык запасларының иң зур өлеше —11. 200 миллиард тоннасы күмергә, берничә миллиард тоннасы нефтькә һәм 640 миллиард тоннасы гына газга туры килә. Әгәр егерменче гасыр ахырына энергетик ресурслар елына 25 миллиард тонна тотыла дип исәпләсәк, күмер, нефть һәм газ тагын 150 елга җитәчәк [1].

Ләкин кешеләр, башка барлык ягулыкларга караганда өстенрәк санап, нефть һәм газдан күбрәк файдаланырга тырышалар.

---

[1] Кирилин В. «Энергетика проблемалары һәм перспективалары». «Коммунист», 1975, № 1, 44–45 битләр.

Җир шарында халык саны нибары 2,4 тапкырга артты. Димәк, һәркайсыбызга ата-бабаларыбызга караганда күбрәк байлык, комфорт һәм уңайлыклар, төгәлрәк итеп әйткәндә, җан башына елына 25 тонна чимал туры килә. Бу чималны без һәркем өчен уртак булган табигать коесыннан чумырып алабыз. Без үзебезнең теләк һәм нәфесебезне көннән-көн мулрак канәгатьләндергән саен, хәзинәләр артуга түгел, киресенчә, кимүгә таба бара. Табигатьнең: «Кешеләр, сакчыл булыгыз!» дигән кисәтү авазы яңгырады инде.

Йөз илле елга исәпләнгән юрау — бу әле шактый күтәренке рухлы чик. Күп кенә галимнәр, нефть һәм газга булган ихтыяҗның үскәннән-үсә баруын күздә тотып, бөтенләй башка төрле нәтиҗәләргә дә киләләр. Алар якындагы егерме ел эчендә, ягъни безнең гасырның ахырларына нефть һәм газ чыгару үзенең иң югары ноктасына җитәчәк, ә инде 2035 нче елга җир катламнарындагы байлыкның туксан проценты суыртылып бетәчәк дип раслый [1].

Юраулар һәм исәпләүләр әнә шуннан гыйбарәт. Димәк, Түбән Каманың баһадир йөрәген эшләтүче җир асты елгалары берзаман корып калыр, яшь шәһәрнең гомере әллә ни озын түгел микәнни?

Безнең заман пәйгамбәрләренең табышмак-саннарына нигезләнгән гомуми юрауларга бирелмичә генә, татлы хыяллар, төрле фараз итүләрдән аерылып, реаль җирлеккә төшик, һәм үзләре аша җир маен кудыручы Түбән Кама химик реакторларының һәм аппаратларының нәрсәләр эшләргә сәләтле икәнлекләрен исәпләп чыгарыйк.

Иң элек, әлбәттә, Түбән Кама нефть-химия комплексының төп чимал базасы булган Татарстан промыселларына тукталып узарга кирәк. Дөрес, Татарстан ятмаларының һәркемне таң калдырган күтәрелеш чоры узды инде. Аның скважиналары хәзер елына йөз миллион тонна түгел, ә туксан миллион тонна нефть суырталар. Ләкин монда өметсезлеккә бирелергә сәбәп юк. Бөтенесе дә фәнни нигезгә таянып эшләнә.

Моңарчы нефтьчеләр җиңел һәм бай девон хәзинәләренең «каймагын» җыеп алдылар. Хәзер исә авыр һәм катлаулы җир катламнары белән эш итәргә, элеккеге «үле» ятмаларга җан кертү өчен аларны термик һәм химик ысуллар белән эшкәртү кебек яңа алымнарны киң кулланырга вакыт җитте.

Дөрес, катламнар үзләрендәге хәзинә запасларының яртысын гына бирәләр. Илле процент — бүгенге көндә ирешелгән биеклек. Бу әллә чыннан да соңгы чикме? Әллә инде барлык мөмкинлекләр ахырынача файдаланылып беткәнме? Һич алай түгел. Бары тик күңелне төшермәскә, эзләнүләрне дәвам итәргә генә кирәк.

Татарстан нефтьчеләренең әле моңарчы кул тимәгән зур байлыклары — битум бар. Галимнәрнең исәпләвенчә, Идел буе төбәгендә ул шактый күп. Битум башка өлкәләрдә дә һәм республикаларда да булырга тиеш дип уйланыла. Ул әлләни тирәндә ятмый. Әмма ул үзле һәм сыланучан, аны, скважинадан алган кебек, гадәти ысуллар белән генә алу мөмкин түгел.

Татарстан нефть фәнни-тикшеренү институты галимнәре, тикшеренүчеләрнең, практикларның башка коллективлары белән берлектә, менә ничә еллар инде битум катламнарын эшкә җигүнең җентекле һәм файдалы технологиясен эзлиләр, лабораторияләрдә, катлам модельләрендә тәҗрибәләр ясыйлар.

Һәм менә ул эзләнүләрнең беренче карлыгачы. Мордва Кармалкасы авылы янында, дөньяда беренче тапкыр буларак, битумнардан

---

[1] Ершов Ю. А. «Чимал, игулык, политика» 1975, 18—39—41 битләр. «Курьер Юнеско», 1974, январь, 6 бит.

фонтан бәрә башлады. Андагы мәйданчыкта берьюлы биш скважина борауладылар. Аларның берсендә, җир астындагы битумнарны эретеп, ут яна. Ул ут исә калган дүрт ноктада фонтан бәреп чыгуны тәэмин итә. Гадәттә битум чыганакларын ачык ысул белән эшкәртәләр, чөнки катламнардан нефтьнең үзен бернинди көч тә «кысып» чыгара алмый. Ә монда яхшы үткәрүчән комташ арасыннан аткан кебек шундый ук фонтан бәрә... Компрессор катламга һава өрдерә, ялкынны сүндерми тота, ә калган эшне ут башкара: токымны эретә, нефтьне башка скважиналарга куып китерә. Битум токымнарыннан фонтан бәреп чыккач, ике ай эчендә җир астына 1 миллион 200 мең кубометр һава кудырылган, ә шуның бәрабәренә 600 тонна нефть алынган.

Алда әле зур эшләр тора. Тәҗрибәләрне дәвам итәргә, техника һәм технологияне камилләштерергә, битумнарны башка токымнар шикелле үк үз запасларын юмарт бирергә мәҗбүр итәргә кирәк.

Галимнәрне ашыктырырга теләк бик көчле. Ләкин һәр нәрсәнең үз чираты, үз вакыты бар. Килер бер көн — республикабыз нефть промыселлары яңа сулыш — «битум сулышы» белән сулар.

Шәһәрләр гомере, кешеләрнекеннән аермалы буларак, дистә еллар белән түгел, гасырлар белән үлчәнә. Әгәр сүз Түбән Кама каласының бары тик иртәгәсе көне турында гына бармыйча, ерак киләчәге турында бара икән, әйдәгез, шәһәрнең барлык чимал запасларын исәпләп чыгарырга тырышып карыйк. Табигать хәзинәсендәге нефть һәм газның күләме инде билгеле, күмер хәлләре дә ачыкланган. Ә запаста әле... Җир шарын зәңгәр пәрдә белән чолгап алган, шәһәрләр һәм авыллар, җәнлекләр, урманнар, кешеләр сулый торган һава бар.

Кешеләрнең эшчәнлекләре никадәр кыюрак, активрак булса, табигать хәзинәсеннән алар шул кадәр күбрәк байлык алалар һәм үзләре суларга тиешле һаваны ныграк агулыйлар. Агачларга һәм үләннәргә атмосферага ифрат зур күләмдә тарала торган һәртөрле химик кушылмаларны чистарту кыенлашканнан-кыенлаша. Түбән Кама нефтьче-химикларның эзләнүләре, калдыкларсыз һәм төгәл эшләүләре, табигатьне бозучыларга каршы аяусыз көрәш алып барулары, аларның иң камил фильтрлары һәм иләкләре аша һава кудыруга күчүләре, дөньяда беренче тапкыр буларак, шушы шәһәрдә тормышка ашырыла башларга мөмкин диган нәтиҗә ясарга чын җирлек бирә. Ул чагында берьюлы ике төрле игелекле эш эшләнәчәк. Аларның беренчесе табигатьне саклаудан, икенчесе чыннан да һавага очкан байлыкларны тотып алудан гыйбарәт. Болар чын хуҗаларча тырышлык һәм акыл белән тормышка ашырылгач, Түбән Кама, мөгаен, җирдә һичбернинди торбаларсыз, кап-кара баганалы төтен һәм корымсыз шәһәрләрнең беренчесе булачак.

Билгеле, минем бу фараз итүләрем күпмедер дәрәҗәдә хыялга һәм фантазиягә нигезләнгән. Бу проблемалар хәтта иртәгесе көнгә дә түгел, ә бәлки ерак киләчәккә карый. Әмма ул ерак киләчәкнең — бер гасырга алданракмы яки соңракмы — ишегебезне кайчан шакыячагы безнең үзебезгә бәйле түгелмени? Һәрхәлдә, минем үземне табигать байлыкларының кимегәннән-кими баруы турындагы саннар һәм исәпләүләр куркытмый. Ә менә кешеләрнең галәмдәге байлыклардан кирәгенчә һәм тулысынча файдаланырга акыллары җитәрме-юкмы — бусы инде реаль хәл итүне сорый торган икенче мәсьәлә.

*

* *

Яшь Советлар иленең Фәннәр Академиясе алдында торган бурычларга, галимнәр тарафыннан иң беренче чиратта хәл ителергә тиешле

проблемаларга тукталып, 1918 елда Владимир Ильич Ленин прогресс өчен гаять дәрәҗәдә һәлакәтле булган хосусый милекчелектән азат илнең халык хуҗалыгы программасы күләме һәм үзенчәлеге турында сөйләгәндә «...чималның якын булуы һәм чималны эшкәртүдән башлап ярымфабрикатны эшкәртүнең әзер продукт алуга кадәр булган бөтен стадияләренә күчү вакытында хезмәтне мөмкин чаклы кимрәк югалту күзлегеннән карап, Россиядә промышленностьны рациональ урнаштыру»[1] кирәклеге хакында нигезле итеп, басым ясап билгеләп үтә.

Үзенең уникаль заводлары һәм производстволары, төзелеш базалары, транспорт коммуникацияләре белән Түбән Кама нефть-химия комплексы бер җыйнак кына мәйданда урнашуы өстенә бердәм һәм ныклы технологик бәйләнешкә да ия. Түбән Камадагы гигант промышленность үзәге илнең экономикасын сугыш алды елларында ук элеккегә караганда кызурак темплар белән Урал-Кузнецк комбинатын, башка индустриаль үзәкләрне төзүдән, промышленностьны чимал запасларына якынрак туплаудан башланып киткән үзгәртеп коруларның планлы дәвамы буларак үсте. Бу — халык хуҗалыгын, гәрчә нык үскән булсалар да, аерым предприятиеләр, завод һәм фабрикалар, промысел һәм шахталар төзүгә түгел, ә аларны берләштергән берничә төбәк байлыкларын туплаган өлкә һәм территориаль-производство комплекслары төзүгә йөз тотуның ачык мисалы.

Предприятиеләрне оештыруның актуаль принципларын дөрес хәл итүе — чималны тулысынча файдалануы, куәтле агрегат һәм аппаратларны куллану буенча ныклы уйлап төзелгән технологиягә таянуы, төзелешнең башлангыч чорында күп чыгым тотудан һәм зур көч куюдан куркып калмавы аркасында Түбән Кама феномены төзелә башлавына тугыз ел дигәндә продукция бирүгә иреште. Ә инде унынчы бишьеллыкның урталарында ул елына миллиард сумлык продукция җитештерә һәм өч йөз миллион сум файда китерә башлады. Без үз-үзебезгә карата никадәр генә таләпчән булмыйк, эшләгән эшләребез белән канәгатьләнеп калуны никадәр генә ят нәрсә итеп санамыйк, Бөтенсоюз удар комсомол төзелеше батырлары алдында барыбер башларыбызны имичә булдыра алмыйбыз. Үзләренең дәртле хезмәтләре белән алар кыска вакыт эчендә Түбән Каманы шундый биеклеккә күтәрделәр ки, аның даны дистәләгән еллар һәм чорлар белән исәпләнгән башка индустриаль үзәкләрнеке белән тиңләште.

Халык хуҗалыгы белән идарә итүне камилләштерү, үсешебезнең төгәл маякларын анык билгеләү, бүгенге бурычларны үтәүне стратегик максатларны тормышка ашыру белән бергә бәйләп бару мәсьәләләренә тукталып, КПСС Үзәк Комитетының Генеральный секретаре Леонид Ильич Брежнев партиянең XXIV съездында ясаган докладында ук инде менә болай дигән иде: «Без бик әһәмиятле экономик һәм социаль-политик бурычларны тормышка ашыруның биш ел түгел, бәлки шактый күбрәк вакыт таләп итүенә һаман ешрак очрыйбыз. Бу уңай белән халык хуҗалыгын үстерүне илдә халык саны арту, халык хуҗалыгы ихтыяҗлары, фән-техника прогрессы прогнозларына таяна торган озак сроклы перспектив планлаштыру турындагы мәсьәлә алга килеп баса. Озак сроклы планнарны бишьеллык һәм еллык планнар белән даими бәйләүне тәэмин итә торган шундый караш булганда үсешебезнең төп проблемалары нәтиҗәлерәк хәл ителә алачак».

КПСС Үзәк Комитеты һәм СССР Министрлар Советының 1979 елның июлендә кабул ителгән «Планлаштыруны яхшырту, хуҗалык итү механизмының нәтиҗәлелеген һәм эш сыйфатын күтәрүгә

[1] Ленин В. И. Әсәрләр, 1961, 27 том, 311 бит.

йогынтысын көчәйтү турында»гы карарында «Экономик һәм социаль проблемаларны хәл итүгә, көч һәм ресурсларны иң мөһим гомумдәүләт программаларын үтәүгә тупларга, планнарны эшләүдә вак тармак карашы булдырмаска» кирәклеге басым ясап әйтелә.

Билгеле булганча, Түбән Кама нефть-химия комплексының масштаблары 1958 елда ачыкланды. КПСС Үзәк Комитетының химия индустриясен үстерү турындагы тарихи май Пленумыннан соң планновиклар, экономистлар төпле, җентекле стратегик исәпләүләр ясарга утырдылар. Алар төп максатларны һәм бурычларны ачыкладылар, корылачак заводларның мөмкинлекләрен үлчәүгә салып карадылар, күпме чимал барлыгын, эшчеләрне каян алырга икәнлеген исәпләп чыгардылар, ахыргы максатка ирешү өчен алга барганда кирәк һәм мөмкин булган иң-иң кыска, иң-иң уңай юлларны сайладылар, нинди шәһәр төзергә кирәклеге, анда күпме халык яшәячәге турындагы саннарны игътибарга алдылар. Шунда ук бу зур эшне тормышка ашыруның техник, политик, оештыру чаралары һәм ысуллары хакында сүз барды. Җыеп кына әйткәндә, тиздән нигезе салына башлаячак территориаль-производство комплексының барлык детальләрен башта модельләрдә кат-кат тикшерделәр. (Сүз уңаенда шуны да әйтергә кирәк, «территориаль-производство комплексы» дигән төшенчә тормышта соңрак кулланышка керде. Ул беренче тапкыр КПСС Үзәк Комитетының ноябрь (1978) Пленумында әйтелде). Шуннан соң гына «Җибәрү» кнопкасы илебез экономикасының куәтле машинасын хәрәкәткә китерде һәм менә егерме ел инде ул, көннән-көн көчлерәк була барып, башлап җибәргән эшебезне алдан уйланылган юлыбызның станцияләренә якынайта бара.

Әмма барасы юлыбыз үзе бөтен вак-төякләренә кадәр ныклап уйланып җиткерелгән туры юл түгел. Эш барышында кинәт беренче кысаларның һәм чикләрнең тарлыгы беленде. Нигезе яңа салынган комплекска, ерак араны узучы поездга өстәмә вагоннар таккан шикелле, яңа заводлар һәм производстволар өсти башладылар. Эш шунда, аларның кайберләре тәгәл саный торган машиналарның перфокарта ояларына эләкмәгән икән. Икенчеләренең исә кирәклеге поездыбыз инде тизлек алгач кына беленде.

1969 елда, Түбән Кама төзелә башлауга ун ел вакыт узгач, безнең көнкүрешебезгә, җитмешенче еллар баһадирларының байрагы һәм символы булып, «КамАЗ» дигән яңгыравыклы сүз килеп керде. КамАЗ белән бергә нибары кырык чакрым ераклыктагы күрше мәйданда шин заводы төзү фикере туды. Ул Түбән Кама нефть-химия комплексы технологик чылбырының дәвамы буларак төзелә. Нефть изопрен — мономер — каучуклар — шиннар — боларның әһәмиятлелеге экономик яктан җитәрлек дәрәҗәдә нигезләнә. Беренчесе артыннан шиннар кою буенча икенче заводның корпуслары салына башлый. Алар икесе бергә җирле корылма гына булып калмыйча, бөтенсоюз күләмендәге эре предприятие булып әверелә. Промышленность мәйданчыгында башта билгеләнгән әлеге заводлардан тыш сенаж башнялары һәм техник углерод заводлары төзелә. Эш барышында мономер һәм каучук җитештерү күләме арта, башта уйланылганга караганда куәтлерәк итеп «Этилен-450» комплексы, этил-бензол һәм стирол заводлары төзелә.

Эш монда төзелеш башлангач кына комплекска яңа производстволар китереп «бәйләү»не экономик ялгышлык дип уйлауда түгел. Төрле вариантларны, конкрет саннарны тегеләй дә, болай да үлчәпчагыштырып карау, югалтуларны һәм табышларны бер генә өлкәдә түгел, ә халык хуҗалыгы төзелешенең зуррак күләмендә исәпләгәндә яңа производстволар оештыру өчен Түбән Кама мәйданының

һәрьяктан уңайлырак икәнлеген күрсәтте. Шунысы кызганыч, комплексны барлыкка китерүче төп факторларның үзгәрүе, яңа производстволарның алдан уйланмыйча, ияреп кенә төзелүе үзе белән бергә энергия чыганакларының, чимал белән тәэмин итүнең шундый ук саннар күләмендә артуына, транспорт һәм инженерлык корылмалары челтәренең киңәюенә, шәһәрнең үсүенә — кибетләрнең, торак йортларның, ашханәләрнең, ателье һәм мастерскойларның ишәюенә китермәде.

Комплекска өстәмә рәвештә «тагылган» производстволарны беренче булып Түбән Каманың энергия йөрәге булган ТЭЦ сизә. Шактый вакыт эчендә шәһәр, мөгаен, беренче елларда гына җылыга һәм парга кытлык кичермәде. Монда мин торак йортларга бирелә торган җылылык турында әйтмим. Сүз реакторларга һәм аппаратларга кирәкле, кешеләргә атомнарны һәм молекулаларны таркату һәм кабат кушу өчен шартлар бирә торган технологик җылылык хакында бара. Төзелешнең башланган чорында, комплекс әле проектлаштыручыларның төсле карандашлары очында гына булган чагында ТЭЦны «паровоздан алдан җибәрергә», мәйданда башта ук нефть эшкәртү заводын төзергә, җиңел «парларны» — газларны бүгенге полимерлар химиясенең төп нигезе саналган этилен, пропилен, бензол алу өчен файдаланырга, ә «майсызландырылган» мазутны ягулык итеп тотарга дип тәкъдим итүчеләр дә булды. Госпланда бу фикерне кире кактылар. Аның урынына читтән һәр ел саен өч миллион тоннадан артык кыйммәтле мазут ташырга дигән икенче бер вариант кабул ителде.

Нефть эшкәртү заводын салуга исә шактый вакытны югалтканнан соң гына чынлап керешелде. Алты миллион ярым тонна мазут таләп ителгәнлеге, шул чаклы ягулыкны тимер юл буйлап ташып өлгертү кыенга туры киләчәге ачыклангач, ТЭЦның икенче чираты төзелә башлады.

Унынчы бишьеллыкның беренче яртысында күздә тотылган торак мәйданының 132 мең квадрат метры файдалануга тапшырылмыйча калды. Яңа йортларның югарыгы катларында яшәүчеләр көндез сусыз утыралар һәм төннәрен дә буш кран төбен сакларга мәҗбүр булалар. Шәһәр тә леренә алтмыш мең кубометр су «эчә». Беренче исәпләүләргә караганда бу җитәргә тиеш булган, ләкин суга тәүлеклек ихтыяҗ бер ярым тапкырга арткан.

Ә бит алдан күрелмәгән үзгәртеп корулар аркасында килеп чыккан күп кенә кыенлыкларны булдырмаска да бик мөмкин иде ләбаса! Тормыш дәвам итә. Анда өр-яңа көннәр һәм еллар, планнар һәм эшләр чиратка баскан. Бу язмалар хакында уйланып утырганда мине һаман бер үк теләк тынгысызлап торды. Кама буендагы индустриаль төзелешнең алдагы баскычларында, шулай ук илебезнең төрле өлкәләрендә киң колач белән үскән башка территориаль-производство комплексларында үткәндәге сабаклар искә алынсын һәм эш алдан җентекләп хәзерләнгән генераль схемалар нигезендә башлансын иде.

*

* *

Ә шулай да киләчәктә Түбән Кама каласы нинди булачак соң?

Хыялга бирелгәнгә кадәр куәтле индустрия комплексын һәм, гомумән, мондагы тормышны аннан башка күз алдына китерергә мөмкин булмаган иң әһәмиятле бер нәрсәне истән чыгармаска кирәктер. Мин кешелекнең иң кадерле байлыгы булган җир турында әйтәм.

Башка якларга караганда үсеп килүче индустриаль үзәкләргә

якын тирәләрдә файдаланырга яраклы җирләрнең мөмкинлекләрен арттыруга күбрәк көч куелса, үзеннән-үзе аңлашыла, бу бик табигый булачак. Бу бурычларны тормышка ашыру иген, үлән, яшелчә, бәрәңге һәм җиләк-җимеш уңышын күтәрүгә генә түгел, ит, сөт, йомырка фабрикаларын, димәк, кешеләрне азык-төлек белән тәэмин итүгә дә бик нык бәйләнгән. Беренче чиратта монда минераль ашламаларны мулрак кайтару, күбрәк техника булдыру, сугару системасын ашыгыч рәвештә юлга салу сорала.

Каманың түбәнге агымында куәтле производство-территориаль комплексының тиз үсүе бирегә авыл хуҗалыгы бурычларын да бик нык үзгәртә. Элек-электән иң беренче чиратта ашлык җитештерү белән шөгыльләнгән колхозлар һәм совхозлар хәзер яңа шәһәр-поселокларның заказларын үтәргә тиешләр.

Болар сихерле таяк селтәү белән бер мизгелдә үзләреннән-үзләре эшләнмәячәк. Шәһәр һәм авылларның чын мәгънәдәге гармониясе туктаусыз эзләнүләр һәм тырыш хезмәт нәтиҗәсендә барлыкка киләчәк. Кырларына КамАЗ заводлары килеп тоташкан «Гигант» совхозында иген уңышы унынчы бишьеллыкта гектарыннан уртача утыз центнерга җитте. Мең тугыз йөз җитмеш җиденче елның җәе ифрат коры килде, әсселектән игеннәр шытырдап көйде. Ә икенче елны тоташтан яңгырлар койды, ашлыкны су басып киткән утарларда суктырдылар. Әмма шундый шартларда да бирегә барыбер 26-36 центнер уңыш җыеп алуга ирештеләр.

Дөрес, Кама аръягы хуҗалыклары өчен гектарыннан утыз-утыз биш центнер уңыш алу әлегә сирәгрәк хәл. Монда егерме-егерме биш, хәтта ун центнер белән калган еллар да була. Ләкин «Гигант» совхозының бүгенге күрсәткечләре киләчәктә монда гектарыннан илле-алтмыш центнер уңыш җыеп алырга мөмкин булачагына ышаныч уята. Кама аръягында эшләячәк Зәй сугару системасы Түбән Кама һәм Зәй районнарына дым бирәчәк, 20 мең гектар мәйданда басуларның уңышын арттырачак.

Киләчәктә төзеләчәк сөт һәм ит фабрикаларында елына 2 500—3000 килограмм сөт бирә торган сыерлар калмаячак. Алар урынына 6000—8000 килограмм сөт бирүче «Холмогор», «Бестужев» һәм башка токымлы сыерлар сайлап алыначак.

Без әле балык турында бер сүз дә әйтмәдек, мондагы искиткеч зур хәзинәне — елгаларны, буалар һәм күлләрне, ясалма сусаклагычларны телгә алмадык. Идел, Кама, Вятка, Агыйдел — борын-борыннан балыклы елгалар. Аларда корбан, җәен, чуртан, судак, чөгә, опты балыклары үрчи. Россиянең дүрт зур елгасы бергә кушылган урынга заманында Идел су станцияләре плотиналары корылганчы мәрсин һәм кырпы балыклары күтәрелгән дип сөйлиләр.

Елгалар — табигать-әнкәбезнең зур бүләге ул. Илленче еллардан соң аларга мәйданы ярты миллион гектардан артык булган Куйбышев сусаклагычы өстәлде. Бүгенге көнгәчә ул әле кул тимәгән «зәңгәр чирәм җир». Дөньядагы иң зур ясалма бу диңгезнең һәр гектарыннан җидешәр килограмм балык алына.

Уйлану өчен тагын шуны өстәп әйтергә кирәк: Цимлянск диңгезендә Куйбышев диңгезенә караганда һәр гектар җирдән балыкны ким дигәндә җиде тапкыр күбрәк тоталар!

Унынчы бишьеллыкта Татарстан якларында, Башкортстан һәм Удмуртия республикалары, Пермь һәм Киров өлкәләре җирләрен дә үз эченә алып, тагын бер диңгез — Түбән Кама гидростанциясе сусаклагычы барлыкка килде. Аңа су җибәрү алдыннан, суны бүлеп тору өчен ясалган тоташтыргыч буаны шартлатырга санаулы сәгатьләр калгач, анда матбугат конференциясе үткәрелде. Проектлаштыручы-

лар, төзүчеләр, монтажчылар, энергетиклар илнең 800 дән артык электростанцияне берләштергән энергетик системасында куәтле елгадагы гидротехник корылмалар каскадын төгәлләүче тагын бер гидроэлектр станциясе — Түбән Кама ГЭСы сафка бассын өчен нәрсәләр эшләнүе турында сөйләделәр. Биек плотина һәм станция бинасы төзүдән, хәзерге заман таләпләренә туры килә торган көчле турбиналар монтажлаудан тыш, алар суднолар өчен шлюзлар эшләделәр, 2 850 квадрат километр мәйданны урманнан чистарттылар, 130 дан артык авылны, күп санлы фермаларны, элемтә һәм электр тапшыру линияләрен икенче урынга күчерделәр, скважиналарны махсус дамбаларга һәм утрауларга «күтәрттеләр». Шушы «өстәмә» эшләргә 368 миллион сум, ягъни төзелешкә бирелгән акчаның яртысы тотылды. Кама буйлап 283, Агыйдел буйлап 250 километрга сузылачак бу сусаклагычның мәйданы 2651 квадрат километр тәшкил итәчәк.

Газеталарның, журнал, радио һәм телевидениеләрнең күпне белергә яратучы, һәрнәрсә белән кызыксынучы каләм ияләре биргән сораулар арасында менә мондый сорау да бар иде: «Ә балыкка ни булыр?» «Зәңгәр чирәм җир»не кичекмәстән үзләштерү өчен нинди чаралар күрелә һәм алар ничек тормышка ашырыла?» Бу юнәлештә ул чакта әле берни дә эшләнмәгән иде.

Табигать байлыгы мул булган шундый җирләрне югалту котылгысыздыр инде ул. Бер үк вакытта җирне дә саклап, су станциясе дә төзеп булмый. Куйбышев сусаклагычындагы кебек балыклар үрчетү турында алдан ук кайгыртмау гафу ителмәслек хата эш.

Индустриаль Кама якларында яшәячәк килер буыннарга узгандагы тәҗрибәләргә таянып эш итүе җиңелрәк булыр. Алар үзләренең уй-фикерләрендә тагын да үткенләнә, зирәкләнә, кылган эшләрендә акыллылана төшәчәк. Мин алар кулы белән өр-яңадан торгызылган һәм заман таләпләренә җавап бирерлек сыйфатка ия булган балык промыселларын күз алдыма китерәм. Ул промыселларда, балыкны ныклап тота башлауга керешкәнче, аны башта мул итеп үрчетәчәкләр. Түбән Кама нефть-химиклары хәзер үк инде үзләренең ярдәмче хуҗалыкларын булдырдылар. Алар, кичекмәстән хәл ителергә тиешле башка эшләр белән беррәттән, якын-тирәдәге күлләрдә карп, ак амур кебек балыклар үрчетә башладылар, Зәй ГРЭСы сусаклагычында балыкларны читлеккә ябып асрау белән шөгыльләнә торган махсус хуҗалык оештырыла. Җылы суда елына алты мең биш йөз центнер балык үрчетеләчәк. Бу эштә башлап йөрүчеләргә уңышлар юлдаш булсын!

*
* *

Гомумән, киләчәктә Түбән Кама каласында тормыш илнең башка урыннарындагы кебек үк танымаслык булып үзгәрәчәк. Хыялларыбызга ирек биреп, алдагы ерак елларга узсак, күз алдыбызга менә мондый күренеш килеп басар. Бик күп нәрсә хәзергегә караганда оешканрак төс алыр, көнкүреш шартлары тагын да уңайланыр, бүген әле кешеләрне борчый торган кыенлыклар юкка чыгар.

Шәһәрләр гасырларга исәпләнеп төзеләләр. Әмма бу мәңгелеккә диген сүз түгел. Мин үзем менә болайрак фикер йөртәм. Йортларны проектлаштыручы архитекторлар гомуми, абстракт мәгълүматлар алу белән генә чикләнмәсләр, ә бәлки алар уй-хыялларында ул йортларда яшәячәк һәр гаиләне, аерым кешене күз алларында тотып эш итәчәкләр.

Хәзер без станокларны, машиналарны алыштырабыз, алдынгы техноло к системаларны яңартканнан-яңартабыз, вакытны югалт-

маска тырышып, шахта һәм промыселларга реконструкцияләр уздырабыз. Киләчәктә шундый ук эзлеклелек белән шәһәрләр дә беренче йортыннан алып соңгысына кадәр өр-яңадан төзеләчәкләр. Нефть үзәкләре Әлмәт һәм Лениногорск, революциягә кадәр ук шәһәр булып саналган Чистай, Тәтеш һәм Бөгелмәне узып, гүя бүтән чорга аяк бастылар. Хәзерге заман шәһәр төзелеше алымнарын дәвам итеп, Түбән Кама һәм Чаллы кебек яшь калалар калкып чыкты. Ләкин һәр буын үзенең характеры, гореф-гадәтләре, тышкы күренеше белән архитектура һәм эстетиканың бүгенге көн идеалларына җавап бирерлек шәһәрдә яшәргә теләр.

Иң әһәмиятлесе, реакторлар һәм аппаратлар янында эшләү бөтенләй башкача булачак. Ул вакытта төнге сменалар бетәчәк, кешеләр өчен вахтада автоматлар торачак, куәтле комплекслы заводларда төтеннең әсәре дә булмаячак, соргылт факел телләре тирбәлеп тормаячак. Һәрнәрсә һава һәм сыекча кермәслек итеп капланачак, җиңел һәм нык полимерлар астына яшереләчәк.

Алына торган әйберләрнең артуы комплексның да киңәюен, моның өчен яңа җирләр кисеп бирүне, өстәмә корылмалар һәм аппаратлар булдыруны таләп итәр дип уйламыйм. Килер буыннар бүтән юл эзләп табарлар, әзер системаларны җитештерүчән эшләтү өчен отышлырак технология процесслары уйлап чыгарырлар.

Әйтик, хәзер оста куллы аппаратчылар җир мае булган нефтьне тәшкил итүче углерод һәм водородның тылсымлы ике кечкенә шарчыгын сихерле торган температуралар 800-900 градус җылылык һәм 50-70 градус салкынлык чикләрендә тирбәлә. Галимнәр яңа тәҗрибәләр уздыралар. Биш-ун мең градус эсселектә, икенче төрле әйткәндә, абсолют нульгә якынлашкан шартларда алып барылачак реакцияләр турында җитди һәм төпле сүзләр йөри. Мәсәлән, стирол молекулалары кристалл рәвешендәге тирәлектә югары басым астында бер-берләренә гадәттәге шартлардагыга караганда йөз мең тапкыр тизрәк кушылалар. Гадәти шартларда «Кояш газы» — гелий кайнап чыга торган минус 269 градуста формальдегидның полимерлашуы өчен йөз нульле сан белән исәпләнгән ел кирәк булыр иде. Ләкин тирәлекне үзгәрткәндә һәм басымны арттырганда 1000 буынлы полимер чылбырын барлыкка китерү өчен 269 градус салкынлыкта нибары ун секунд вакыт кирәк.

*

* *

Тирә-якта төн, тынлык, йолдызлар балкышы... Үзенең реакторлары һәм заводлары белән куәтле комбинат сулаган төнге тынлыкта шәһәр көндезге ыгы-зыгыларын, мәшәкатьләрен дә онытмаган. Башыма бер уй килә. Галәм никадәр генә иксез-чиксез булмасын, аның колач җитмәс киңлекләрендә кеше барыбер ком бөртеге түгел. Җирдән киткәннәрнең барлык мәшәкатьләрен һәм борчуларын үз өсләренә алып, аларның эшләрен исәннәр дәвам итә. Халыкларны, барлык кешеләрне — үзара хәтта таныш та булмаган галимнәрне, геологлар, төзүчеләр, игенчеләр, икмәк пешерүчеләр, космонавтлар, итек тегүчеләр, нефтьчеләр һәм химикларны бер-берләренә бик күп җепләр бәйли. Алар барысы бергә һәркайсыбыз өчен уртак булган бөек эш башкаралар — җирдә тереклекнең сүнеп калуына ирек куймыйлар, үзебез яшәгән уртак йортыбыз — зәңгәр планетабыз тагын да матуррак, тормыш итәр өчен тагын да уңайлырак булсын өчен куларыннан килгәннең бөтенесен эшләргә тырышалар. Шулай булмаганда ни өчен яшәргә, көрәшергә һәм хыялланырга соң?!

*Түбән Кама — Казан.*

# КЫЗЛАР ҮЗӘНЕНДӘ

ОЧЕРК

Без — Гайҗан бабай оныклары, китаптан чыккан кешеләр

*Галия Шәймәрдәнова сүзләре.*



Гайҗан бабай... Шагыйрь Шәйхи Маннур уйлап чыгарган герой гына түгел ул. Шушы Олы Әшнәк авылыныкы. Гади колхозчы. Үз илен, үз җирен, үз халкын чиксез яраткан, турылыклы кеше, ил карты.

Олы Әшнәктә күмәк хуҗалык оештырылгач, Гайҗан бабайга колхоз атларын карауны тапшырганнар. Ул чакта бу эш бик җаваплы саналган.

Минем тайлар хәзер карап туйгысыз,
Ялт-йолт килеп тора өсләре,
Су сөлеге кебек буй-сыннары,
Арслан түше күк түшләре,

— ди атлар караучы үз хезмәте белән горурланып.

Поэмадан билгеле булганча, тырышлыгы өчен Гайҗан бабайны, аэропланга утыртып, туган авылы кырлары, болыннары турысыннан очыртып йөртәләр. Җирдән аны бөтен авыл карап тора, намуслы хезмәтнең кешене шундый биеклекләргә күтәрүенә күпләр беренче мәртәбә төшенәләр. Илгә немец фашистлары бәреп кергәч, Гайҗан бабай үзенең хәләл көче белән тапкан акчасына сугыш самолеты эшләтеп, дошманны тизрәк дөмектерү өчен аны фронтка озата...

Галиягә авыл өстеннән очып узган һәр самолетта Гайҗан бабай бар шикелле тоела иде. Аннары ул һәрбер «корыч кошны» шушы игелекле картныкы дип кабул итә башлады. Үзенең дә күккә күтәреләсе, очучы буласы килә. Заманасы башка иде шул, заманасы. Илгә кара кайгы килгәндә хыял белән яшәрлекме соң? Ир-егетләр белән бергә Гайҗан бабай үстергән сөлектәй атлар да сугышка китеп бетте. Әнә, Гайҗан бабабыз да атлар утарыннан чыкты, бригадирлык дилбегәсен үз кулына алды. Син самолет турында хыяллан, ә колхоздагы барлы-юклы тракторлар тик торсын диме?

1943 елның язында, унсигезенче яшендә Галия Шәймәрдәнова, өч айлык курсларны тәмамлагач тракторга утырып, туган колхозы кырларына чыга. Гайҗан бабай атлары сукалап бетермәгән басуларны сөреп, бодай чәчә. Игеннәр каерылып уңа. Арыш-бодай эскертләрен кыш буе суктыралар.

Ә хәзер бүтәнчә инде: очучылар әзер самолетка утырып күккә күтәрелгәндәй итеп, гөрләп эшләп торган тракторга утырдың да киттең. Теге елларны бер дә алай түгел иде шул. Көйле генә барганда, кинәт «пых-пых» итеп трактор сүнеп кала. Ни булганын шайтан белсен! Галия тракторын бер түгел, биш әйләнеп чыга, тик аның сихерен белми. Гарьлегеннән кызның күңеле тула, «лып» итеп җиргә утыра да үксеп елап җибәрә.

— Кирәкми, сеңелем, тор әйдә.

— Ә, Габидулла абый! Синмени әле бу?
— Ни булды?
— Сүнде менәтерә.
— Хәзер карыйбыз аны.

Күрше басуда эшләүче, бу якларның беренче тракторчысы Габидулла Гайнуллин, кызның туктап калуын күреп, килеп тә җиткән икән. Ярдәмчел кеше, бөтен Солтан МТСына билгеле, тикмәгә генә сугыштан бронь белен калдырмадылар инде аны. Казына торгач, өлкән тракторчы тагын телгә килә:

— Искра югалган бит монда, кызый.
— Кайда төшеп калды икән соң ул, Габидулла абый?

Тракторчы авыз күтәреп рәхәтләнеп бер көлеп ала. Майлы кул сырты белән маңгаен сөртеп ала да, тынычлангач, иркенләп эшкә тотына.

— Шөреп кенә төшеп калса, әйтеп тә тормас идем мин аны.
— Ни югалган соң?
— Магнетода гаеп.
— Ә-ә-ә...

Магнетосын да, шәмнәрен дә бакыр акча белән кырып төзәтә Габидулла абыйсы. Галиягә дикъкать белән карап торырга куша, икенче юлы үзеңә шулай ук итәргә туры килер, янәсе.

Магнетоны эшләтеп була икән анысы. Трактор ватылса, алмаштырыр частьлар табуы кыен, алары бөтенләй юк. Хәер, берәү дә моңа үпкә белдерми — сугыш вакыты. Алары самолетларга, танкларга, тупларга кирәк. Һәрбер детальне үзләре төзәтәләр, яңасын ясап куялар. Иң авыры — «подтяжка тарту». Эрегән подшипникны алыштырасың, төзәтәсең, ә тракторны кабызып булмый — яңа куелган подшипникның тыңлыйсы килми. Шуннан соң, берничә тракторчы җыелып, ат дилбегәсе белән «подтяжка тарта» башлый. Сак эшләмәсәң, әйләндергеч ручка кирегә әйләнеп, кулыңны сындырырга да күп сорамый. Яшь кызлар моңа кадәр ирләр көченнән генә килерлек бу авыр эшне дә үзләштерде. Сугыш таләп итте. Хатын-кыз механизаторлар өчен колхоз кырлары фронт сызыгына әйләнде: солдатлар окопта булса, тракторчы кызлар буразнада көн күрделәр. Шунда ашадылар, шунда йокладылар. Торгач тагын «корыч атларына» утырдылар. Сыер, үгез җигеп эшләүчеләр дә шулай иде. Иң авыры тракторчы хатын-кыз җилкәсенә төште.

Галия әнә шул михнәтле елларда чынлыкты, илне, фронтны икмәк белән тәэмин итү, мәкерле фашизм тизрәк дөмексен өчен бөтен көчен биреп эшләде. Җәйге ямьле көннәрдә кичке болынга чыгулар онытылды. Галияләр турыннан сыздырып узган ялгыз гармун да мәңгегә тынып калды. Йокы аралаш ишетелгән тальян моңы — үткәндәгеләрнең кайтавазы гына икән ул. Кырыгынчы еллар яшьлеге, җирдә мәңгелек моң калдырып, ерак-еракларга китеп адашты. Адашсын, адашсын!..

Ә бер дә бер көнне, язгы чәчүнең кызган гына чагында кырлар өстендә таныш моң кабат яңгырагандай булды. 1945 елның 9 мае иде. Гитлер фашизмы җиңелде! Без җиңдек! Кызларның шатлыклы күз яшьләре орлык булып буразнага күмелде. Кайнар күз яшьләре югалган яшьлек булып шыта алмады...

Рәхмәт Гайҗан бабайга, сугыш кырында сөйгән ярларын, кадерле ирләрен югалткан хатын-кызларга әйбәт киңәшче була белде. Ул һәркемнең күңелен дөрес аңлады, аңа юнәлеш бирде, тәмле сүзе белән иркәләде, юатты. Дошманны җиңеп кайткан беренче солдатларны күргәч, Гайҗан бабай кешеләрне яңа батырлыкларга өнди:

— Я, дусларым!
Канатларым минем:
Комсомоллар, кызлар, киленнәр,
Ярман илен кичеп кайткан уллар,
Килеп җитте безнен дәү көннәр.

Сугыш кырында үлеп калганнар өчен дә эшләделәр кызлар. Бары тик хезмәт кенә җиңеләйтә иде кайгы-хәсрәтләрне. Көндезләрен ул шулай, ә кичләрен, хуҗасыз калган буш өй шикелле, ялгыз күңелгә сагыш яңадан әйләнеп кайта торган булды. Андый чакларда тешләр кысылды, иреннәрдән кан тибеп чыкты, яулык читләре дымланды. Кызлар иртән эшкә сагышны капка төбендә калдыру өчен ашыгалар иде.

Һәрьяктан йончыган хуҗалыкны торгызу өчен күп эшләргә туры килде. Галия Шәймәрдәнова шул авыр постта — тракторчы булып калды. Югыйсә, теге елларда кайбер кызлар тракторларын солдаттан кайткан ирләргә калдырып, ФЗӨ мәктәпләренә укырга, Казанга авиация промышленностена, меховойга яки «Спартак»ка эшкә таралып бетте. Галия туган туфрагыннан аерылмады, кайнар тире, сагышлы күз яшьләре тамган басуларны калдырып китә алмады. Әшнәк басуларында җир сөрде, чәчү чәчте, урак урды, утын ташыды, тирес түкте.

Әйләнеп караса, үзе дә шаккатты. Ир-ат арасында бер үзе калган икән ләбаса! Ничек килеп чыкты соң әле бу? Кая китеп беттеләр хатын-кыз механизаторлар? Авылда калганнары да күп икән әле, югыйсә. Тик алар бүтән урын — колхоз фермаларын сайлаганнар, кайберәүләр чүп утауга йөрүне кулайрак күргәннәр. Ул чакта иген арасындагы чүп үләннәрне кулдан утау бар иде әле. Ни әйтсәң дә, тракторда эшләү түгел инде. Әмма Галиягә андый «рәхәтлек» кирәкми. Иткән хезмәтең күзгә күренерлек булсын, җәмгыятькә күбрәк файда китерсен — кыз шулар турында уйланды.

Балык бистәсе районының Олы Әшнәк һәм Кече Әшнәк авыллары бер хуҗалыкка берләшкәч, «Кызыл юл» колхозы тагын да зурайды. Хәзер аның җирләре 6130 гектар. Колхозда алтмыштан артык трактор һәм комбайн, ике йөзгә якын төрле авыл хуҗалыгы машиналары бар. Алар белән югары квалификацияле кадрлар идарә итә. Ә менә хатын-кыз механизаторлар юк.

Җитмешенче елларда Галия тагын бер талпынып алды. Шулай канатлы кош сыман югарыга күтәрелергә, үзенә башкаларны да иярергә ярата инде ул.

— Нәкыя, сеңелем, синдә сүзем бар иде,— дип туктатты Галия бер көнне сыерлар савучы комсомолка Шәйхетдинованы.— Эшеңне яратасыңмы?

— Ник алай дисез, Галия апа?

— Болай гына.

— Кайда да эшләргә кирәк бит инде,— диде Нәкыя, туры җавап бирүдән читләшеп.— Менә сезнең эш кызыклы, ичмасам, Галия апа, бөтен басуларны иңлисез. Безнең ничә карасаң да гел шул ферма.

— Бәйләп куймаганнардыр ич?

— Сыерларны кем савар?— диде кинәт Нәкыя, өлкән тракторчының тел төбен аңлап.

— Табылыр. Әнә, быел мәктәпне утызлап кеше тәмамлый ди.

— Нишләргә икән соң миңа, Галия апа?

Шул чакта Шәймәрдәнова кыз күңеленә очкын сала алды. Кем йөрәгендә ялкын дөрләячәген алдан ук чамалаган иде бит ул. Һәм ялгышмады. Нәкыя колхоз комсомол оешмасының барлык яшьләр катнашкан ачык җыелышында мәсьәләне кабыргасы белән куйды:

укыйбыз, тракторчы булабыз, үзебезнең «Ал яулыклылар» отрядын төзибез. Күпләр аның тәкъдимен якладылар.

— Кайда укыйбыз соң без? — дип сорап куйды кемдер.

— 17 нче авыл профессиональ-техник училищесында.

— Эштән соң дүрт чакрымга йөрепме?

— Анысы бар икән тагын.

Авылда училищеның кечке филиалы ачыла. Училище белән ике арада килешү төзелә. Аннары укулар башлана. Дәресләрне алып бару ТАССРның атказанган механизаторы Габидулла Гайнуллин, Гайҗан бабайның улы, оста тракторчы Хуҗаҗан Газизҗанов шикелле тәҗрибәле игенчеләргә тапшырыла. Көндез кызлар терлекчелектә эшлиләр, кичләрен техника серләренә төшенәләр. Алар белән бергә Гайҗан бабайның өченче буыны — Илдар Газизҗанов та укый. «Үзегез котырттыгыз, өйрәтегез» дип, кызлар Галия апаларының теңкәсенә тиеп бетәләр. Ул аларны трактор йөртергә өйрәтә.

Кулларында өченче классны механизатор таныклыгы. Унбер кыз трактор сорап председательнең «колак итен ашый» башлый. Бер яктан хуҗалык җитәкчесе моңа сөенеп бетә алмый. Ниһаять, ялкау, эленке-салынкы йөрүче, шешә белән дуслашучыларга көн булмаячак. Кызлар — эшчән халык. Ә менә барысына да тракторларны кайдан алып бетерергә? Колхоз җитәкчеләре шул хакта баш ваталар. ТАССР Авыл хуҗалыгы министрлыгына һәм башка югарыгы оешмаларга хатлар языла. Колхозга берьюлы сигез трактор кайта.

Икенче һөнәр үзләштергән элеккеге терлекче Нәкыя Шәйхетдинова, Фәһимә Мифтахова, Мөслимә Исламова, Рәйсә Миңлегалиева, Зәкия Мөбарәкшина һәм башкалар ишекләренә комсомол значогы рәсеме төшерелгән өр-яңа «Беларусь» тракторына утыралар. Сөйләшкәнчә булсын дип, кызлар барысы да башларына өч почмаклы ал яулык бәйлиләр. Галия Шәймәрдәнованы механизатор кызларга җитәкче итеп билгелиләр. Алар үзләренең беренче походларын «Гайҗан бабай» поэмасында телгә алынган «Кызлар үзәненә» ясыйлар.

Менә монда, «Кызлар үзәнендә»
Гөл балчыгы инде,
Беләсез.
Иң югары уңыш мәйданын без
Шунда итсәк? —
Нәрсә диярсез?

— ди Гайҗан бабай.

Әшнәк суы буендагы бу үзәнлек торф ятмаларына бик бай. Озак еллар буе Корноухово спирт заводы торфны ягулык итеп файдаланган. Инде завод юк, торфтан кирпеч сукмыйлар. Әче туфрак өчен кыйммәтле ашлама саналган торф — җир куенында. Галия Шәймәрдәнова җитәкчелегендәге отряд аны кырларга күчерүгә күп тырышлык куя. Туфракны яхшырта бару аркасында «Кызыл юл» колхозында җирнең гектар көче, ягъни уңыш бирүчәнлеге шактый артты. Зур эшләре өчен Галия Шәймәрдәнова хөкүмәтебезнең Хезмәт Кызыл Байрагы орденына лаек булды.

Остаз янында эшләп, кызлар да тирә-якта дан казандылар. Рәйсә Миңлегалиева ТАССР Верховный Советы депутаты булып торды. Нәкыя ВЦСПСның XV съездында делегат буларак катнашты. Мәскәүне, Кызыл мәйданны, Ленин мавзолеен күрде. Ул инде бүген ике бала анасы. Рәйсә, Фәһимә, Мөслимәләр дә берәр бала үстерәләр. Ирләре белән бергә механизаторлар булып эшлиләр.

Колхозчы белә: яхшы туфракка чәчелгән орлык яхшы уңыш бирә. Гайҗан бабай, Габидулла абзый, Галия апа, Рәйсә, Нәкыя һәм Илдарлар әзерләгән туфрак та шундый уңдырышлы, әйбәт шытым

бирә. Моннан нәкъ ике ел элек шушы вакыйганың тагын кабатлануы фикеребезнең дөреслеген раслый булса кирәк.

Иң элек Олы Әшнәк мәктәбенең сигезенче класс укучысы язган бер иншага күз салыйк. «Минем булачак һөнәрем — тракторчы. Чөнки ул авылда иң дәрәҗәле һөнәрләрдән санала. Мин тормышта Галия һәм Рәйсә апаларга охшарга тырышам, алардан үрнәк алып эшләрмен».— Бу юллар Зөфирә Хәбибуллина дәфтәреннән күчереп алынды. Кыз сигез классны тәмамлагач, шушы теләген тормышка ашыру өчен 17 нче авыл профессиональ-техник училищесына укырга керә. Ялгызы гына түгел, әлбәттә. Бөтен класслары белән: унике кыз һәм унике егет.

Без игелекле шытымнарның бик тиз баш калкытуын күрәбез. Монда инде бөтен бер механизаторлар династиясе үсеп килә.

— Абыемның механизатор булуы аңлашыла. Ә менә Нәкыя апага баштарак сәерсенеп караучылар табылды. Ул кыюлык күрсәтмәсә, бәлки, мин дә бу юлны сайламаган булыр идем. Рәхмәт апага, әйбәт үрнәк күрсәтте ул миңа,— ди Фирдания Шәйхетдинова.

Яшь тракторчы Миңлебанат Вәлиева да Фирдания сүзләрен кабатлый. Аның да дүрт абыйсы: Галимҗан, Габдуллаҗан, Хәкимҗан һәм Вәгыйз — механизаторлар. Миңлебанат дүрт күгәрчен арасында бер чәүкә булып калырга теләмәгән — абыйлары һөнәрен сайлаган. Ә абыйлары эстафетаны әниләреннән кабул итеп алганнар. Җепнең очы шулай еракка барып тоташа. Миңлебанатның әнисе — Галия Шәймәрдәнованың элеккеге хезмәттәше. Әтиләре — колхоз тимерчесе. Традиция дәвам иттерелә.

«Безнең Галия апа» дип, өзелеп торучы механизатор кызларны колхозда күпләп санарга була. Галия Шәймәрдәнова — күктәге якты бер йолдыз ул. Яшьләр бу олы йөрәкле кешене үрнәк иткәннәр. Остаз хуҗалык өчен дистәләгән механизатор әзерләгән. Игелекле шытымнар инде алтын бөртекләргә әйләнгән. Озак еллар буе туфракка күмдерелә, тишелә, үсә ул бөртекләр.

Инде менә аның тракторга утыруына нәкъ 37 ел тулды. Ә мин аның җилдән җитез җилдереп йөрүенә карап сокланам. Ел әйләнә гел шулай көпчәкләр өстендә. Ничек ару-талуны белми икән соң бу ил кызы?

— Көнгә уртача йөз чакрым җир үтәдер ул.

— Йөз илледән артмаса,— диләр тәҗрибәле механизаторлар.

Елның язы, көзе дигәндәй, эшнең ялы да, туктап торган чаклар да була. Уртача йөз километрдан да 37 ел буе бик күпкә җыеладыр бит бу? Кушам, тапкырлыйм, исәпләп карыйм. Ахырда үз-үземә ышанасым килми. Тракторчы булып эшләү дәверендә Галия Шәймәрданова Айга барып җиту генә түгел, аны урап кайтырлык юл үткән булып чыга. Менә сиңа космонавт! Ул сызган буразналар белән Җир шарын иркенләп егерме-утыз мәртәбә урарга мөмкин. Мин бу саннарны һич арттырмый әйтәм. Галия Шәймәрдәнова белән очрашканда ир-егетләр кулларын күкрәкләренә куеп исәнләшергә, аңа еракта ук юл биреп калырга, олы рәхмәт сүзләрен әйтергә тиешләр. Дөнья күргән агайлар моны шулай эшлиләр дә. Яшьләргә килгәндә инде — алар өлкән тракторчыга үз рәхмәтләрен хезмәтләре аша әйтәләр.

...Үзенең беренче хезмәт язын һич онытмый Галия Шәймәрдәнова. Ул аның күңеленә авырлык һәм батырлык булып сеңеп калган.

Җир шушындый кешеләр иңендә тора. Аларның гомере — җир өчен.

**ГОСМАН ГОМӘРОВ.**

Балык бистәсе районы.

# БЕЗДӘ КУНАКТА: КОМИ ШАГЫЙРЬЛӘРЕ

РСФСР составында башта (22 март, 1921 ел) автономияле өлкә итеп оештырылган, аннары автономияле республика (5 декабрь, 1936 ел) ителгән Коми АССР 405 мең квадрат километр чамасы мәйданны били, халык саны: барлыгы 806 мең, шулардан коми-зыряннар 217 мең.

Революциягә чаклы комилар кырыс табигатьле төньяк урманнары һәм сазлыклар арасында югалып яшәгән. Хәтта исемен дә коми дип түгел, ә «кысрыкланган, читләштерелгән» сүзе мәгънәсендә «зыряннар» дип йөрткәннәр — чөнки заман аларны теләсә нинди милләтнең нормаль үсеше өчен кирәкле бөтен шартлардан мәхрүм иткән — «читләштергән» була. Моны коминың беренче демократ шагыйре, коми әдәби телен нигезләүче, шул телгә рус, Көнбатыш һәм Көнчыгыш классик шагыйрьләре әсәрләрен, антик поэзия үрнәкләрен тәрҗемә иткән Иван Алексеевич Куратов биографиясе белән бик ачык расларга мөмкин: ул 1839 елда поп ярдәмчесе семьясында тугызынчы бала булып туа, әтисе үлгәч, алты яшендә ятим кала. Аны рухани семинариядә укыталар. Соңыннан үзе балаларга дин дәресләре укытырга мәҗбүр була. Һәм шул ук вакытта караңгы реакция, хезмәт халкының хокуксызлыгы турында политик сатира шигырьләре, туган тел дәреслекләре һәм грамматикасын яза. Шулар өчен эзәрлекли башлагач, 1865 елда Казанга килеп, хәрби суд прокурорлары училищесында укый, аннары Семипалатинск һәм Верный (хәзерге Алма-Ата) шәһәрләрендә хәрби штабта хезмәт итә. Ул 1875 елда Верныйда үлә. Әсәрләре бары тик совет чорында — 1926 елда гына басыла башлый. Күбесе хәтта сакланмаган...

Хәзерге Коми АССР — экономикасы елдан-ел тизрәк үскән, культурасы чәчәк аткан тигез-тиң хокуклы республикаларның берсе. Җәйләр буе саллар аккан чал Печора, Ижма, Вашка, Вычегда, Сысола сулары буенда таш калалар салына, киң юллар сузыла, яңа һәм дәртле хезмәт җырлары шаулый. Тирән җир асларыннан ташкүмер, нефть, газ, төсле металлар, тимер рудасы чыгаручы оста куллы һәм киң күңелле дусларыбызның бөтен илне сөендергән иҗаты әнә шундый.

## Иван Куратов

*1839—1875*

### Игенче һәм кояш

Безгә кояш белән бергә
Бик күп эшләргә кирәк:
Иген уңсын өчен җирдә
Тирләп-пешәргә кирәк.

Юкка без, игенче дусым,
Юкка җирне тиргибез,
Икмәкләр аз булса кышың:
«Җир гаепле, җир...» дибез.

Әйдә күбрәк тирлик кырда —
Кыр ул тирне ярата.
Әнә яз кояшны җиргә
Ничек матур карата!

## Виктор Савин

*(Небдинса Виттор)*
*1888—1943*

### Коми диңгезе

Күпме яшәп, күпме торып
Зәңгәр диңгез күргәнем юк,
Дулкын сикергәнен күреп
Ташлы ярда йөргәнем юк.

Диңгез зур, диңгез киң! диләр...
Диңгез белән эш итмәдем,
Шаулавы җырга тиң! диләр...
Мин ул җырны ишетмәдем.

Чиге юк безнең урманның —
Безнең диңгез ямь-яшел ул,
Җирдәге матур җырларның
Көйли кебек һәммәсен ул.

Акчарлаклар уйнаганда
Диңгез җырлы була, диләр,
Хәтта җилләр булмаганда
Диңгез серле була, диләр...

Безнең якның диңгезе дә
Шундыйларга тиң диңгез ул —
Җыр һәм сер саклый үзендә,
Гүзәл диңгез, киң диңгез ул!

Көн-төн «йөзә» анда халык,
Балта-пычкы чыңлап тора,—
Хәтта кошлар хайран калып
Һәм сокланып тыңлап тора.

Әйтәләр: зәңгәр диңгезләр
Була икән төпсез, диләр,
Кораблар сыза киң эзләр —
Диңгез булмый утсыз, диләр...

Ә безнең яшел диңгездә
Поезд охшый корабларга.
Каравы күңелле бездә
Җырлап торган наратларга!

## Вениамин Чисталев

*(Тима Вень)*
*1890—1939*

### Кыш киткәндә

Явыз карт Февраль яңадан
Төньякка китте.
Бураннар ашмый чамадан,
Андый чак үтте.

Ашыгып Февраль артыннан
Усал Март чапты,—
Кайтмасын диеп салкыннар
Юлларны япты.

Һәм Апрель китте аннары
Карларны алып —
Атлады чаңгы-чананы
Җилкәгә салып.

Каршыла инде, каршыла —
Нурлы ай килә —
Кушылып хезмәт маршына
Җырлы Май килә.

Аннары — печәнле Июнь
Хуш ис таратыр.
Кырларның тынгысыз көен
Һәркем яратыр.

Игеннәр уңар басуда,
Урманда — җиләк.
Эштә тырышлар барсы да
Алыр мул бүләк.

## Николай Фролов

### Аучы җыры

Минем күгем — зәңгәр юрган,
Аннан матур юрган юк,
Урманнарым — асыл урман,
Аннан матур урман юк.

Кышын-җәен матур бу як,
Барча күңел хуш монда.
Һәммә сукмак, һәммә куак
Миңа таныш, дус монда.

Алсу таң булып аланда
Баланнар пешкән як бу,
Хезмәттә ныгып һаман да
Кыюлар үскән як бу.

Җиңәсең барча ерткычны
Булмасаң әгәр куркак.
Җыр дәртле бездә, җыр көчле,
Шатлыклар бездә уртак.

Утырам шалаш түрендә —
Шундый шәп минем урын!
Мин җырлыйм тайга турында,
Күкләргә менсен җырым.

## Василий Елькин

*1912—1942*

### Очрашу

Кояш чыкты. Сибелә нурлар уйнап,
Күмелеп яши балкып нурга яз.
Такыр юллар, матур юллар буйлап
Алып чыкты мине кырга яз.

Башка як бу. Инде башка юллар!..
Карлар ятмый кырда өелеп.
Юл буена баскан яшь каеннар
Чайкалалар җилдә сөенеп.

Бертуктаусыз җырлый зәңгәр урләр,
Бертуктаусыз җырлап тора кыр.
Күкләр түгел, күкри инде җирләр —
Гүләп уза алга трактор.

Мин очраштым шушы күкрәү белән,
Кул болгадым җитез кызга мин.
Йөрәк типте татлы тетрәү белән...
Бик ярлымын икән сүзгә мин...

«Уңыш телим! Нигә туктап калдың?
Елмаюың нигә бик якты?»
Шуны гына бары әйтә алдым,
Шул елмаю мине туктатты.

Шәп елмаю иде ул, чыннан да!
Һәм кыз әйтте миңа аннан соң:

— Куе арыш серкә очырганда
Кил син монда — барсын аңларсың.

Ярсып тибү, яньп тетрәүләре
Рәхәт тә соң кырда йөрәккә...
Ә кыз? Ә кыз җирнең күкрәүләрен
Алып китте тагын еракка.

## Ананий Размыслов

*1915—1943*

### Яшьлек

ӨЗЕК

Йөрәк җырын әйдә тыңлагыз,
Яңгыратабыз аны сафта без:
— Йолдызлардан биек булабыз
Яшьлек белән бергә чакта без!

Дәртле яшьлек — безнең зур бәхет,
Без эшендә, Ватан, уңганнар.
Шаулы океан белән тиңләшеп
Җырлый безнең яшел урманнар.

Җырсыз атлыйк эшкә ничек без!
Безнең җырлар — синең җыр, Ватан,
Картаербыз еллар үтеп без...
Син мәңге яшь, безнең хөр Ватан!

## Иван Вавилин

### Вычегда елгасы

...Болыннарда — кибән көтүләре
Ятьмәләрдә — балык сикерә.
Киң җәелеп агып үтүләрең
Күпме муллык безгә китерә!

Көннәр-төннәр якты булсын өчен
Мохтаҗ идек элек көчкә без,
Синең көчне — ярсу дулкын көчен
Җигәлмәдек ләкин эшкә без.

Без өйрәндек хәзер барсына да,
Хәзер бездә андый җегәр бар! —
Бөтен җирдә көчле машинага
Безнең куллар сине җигәрләр.

Коми синдә элек паром йөртте,
Инде кораб йөртер, кыскасы...
Син, Вычегда, безнең парма күрке,
Син, Вычегда, хезмәт остасы.

## Серафим Попов

# ПАРМА СУЛЫШЫ

ӨЗЕКЛӘР

### Билгесез дуска

Бер миләштә эленеп тора нәни чүмеч.
Туздан ясап нинди аучы элеп киткән?
Әйткән аучы: «Менә чишмә! Син дә су эч!»
Узгынчылар тукталасын белеп киткән.

Туры килер, нәни чүмеч белән суны
Зур урманда бәлки кат-кат эчәрмен мин.
Һәм ышанам, билгесез дус, беләм шуны:
Юлда барлык киртәләрне кичәрмен мин!

Алга китәм. Кала чишмәң һәм чүмечең,—
Шул ук миләш тармагына элеп китәм.
Тырышлыгың яши синең һәркем өчен!
Зур бәхет бу — шуны яхшы белеп китәм.

### Агач кисүче җыры

Җилпи-җилпи куе яшел канатларын,
Кош очкандай ава парма наратлары.

Елан сыман ята кабель кар өстендә.—
Шул көч белән эшли урман бар эшен дә.

Тузыйм дисә, тузан кимен куймый бездә,
Ләкин күбрәк кар тузаны уйный бездә.

### Айюва яры

Тайга буйлап атлыйм поши эзләреннән
Чапкан, ахры, куркып поезд күзләреннән?

Узган саен эчкәрерәк уза барам,
Ә поездлар юл җырлары суза һаман.

Айюваны күз алдыңа шулай китер:
Билбаулы ул, ә билбавы — тимер күпер.

## Эжва иртәсе

Кояш чыга — балкып чыга, янып чыга.
Уңыш теләп нурын суза балыкчыга.

Алтынланып күренә ятьмә пәрәвезе,
Ә бит җеп ул, ә бит хәтта кара үзе.

Очкын булып куна кояш багорларга...
Я суларга бир сәламне, я нурларга!

Эш шәп бара. Җырлап ятьмә ала ирләр.
Һәм ялтырап — бөртек-бөртек! — тама тирләр.

## Күмер

Без шахтада. Никадәрле күмер монда!
Шул хәзинә яткан күпме гомер монда...

Алып булмый аны коры хәйлә белән... —
Кимерә шахтер электрлы кәйлә белән.

Поезд арты поезд китә бу яклардан —
Китә алар шул күмерне төяп бар да.

Утыбызны еракларда балкытабыз!
Шундый безнең ташкүмерле Воркутабыз.

## Сорадым җилдән мин...

Бер көнне сорадым канатлы җилдән мин:
— Ни була җәен дә гел исеп тормасаң?
Әйтте җил: «Яңгырлар яудырам җиргә мин,
Ә яңгыр яумый ул мин болыт җыймасам!»

# Федор Щербаков

## Елгалар кушылган җир

Сысола һәм Эжва — ике сеңел,
Ике елга монда берләшә.
Урман шаулый — җырга кер дә күмел! —
Җилләр белән урман серләшә.

Монда алар ике елга түгел,
Киң колачлы диңгез төслеләр.
Дулкыннарның йөрешләре җиңел,
Юлларында алар көчлеләр.

Карап торам таңга калып ярда:
Ике агым! Нинди дус алар!
Нәкъ шушылай җирдә халыклар да
Үз юлларын бергә кушалар.

## Геннадий Юшков

### Исемсез шигырь

Сукмак та юк, юл да, борылыш та,
Асты ни дә җирнең өсте ни...
Ә трактор — әрсез кырмыска —
Сазлык ерып торба өстери.

Тырпаялар кара түмгәкләр,
Анда-санда кәрлә таллар бар.
Тәнгә ябыша юеш күлмәкләр...
Әйе, монда кыен хәлләр бар!

Күпме ара инде үтелгән,
Әй дөрләтеп учак ягарга...
Сакланырга шушы черкидән
Нинди генә хәйлә табарга?!

Юк, чара юк... Ә саз, саз тирән...
Түзә кеше иренен тешли дә,
Чөнки кирәк — нефть, газ кирәк!
Һәм кешеләр көн-төн эшлиләр.

Металл чыңлый, агач шыгырдый...
Алар тагын алга атлады...
Шушы юлда туган шигырь бу,
Һәм мин аңа исем тапмадым.

## Альберт Ванеев

### Печора көмешләре

Күзне нәрсә, белмим, чагылдыра —
Күк нурымы, әллә ак кармы?
Көмеш төсле чал Печора яме
Кызу куа тәндә саф канны.

Чумып уйный көмеш болытларга
Көмеш калфак киеп алган ай —
Көмеш көртләр арасында — көмеш
Болан мөгезе күренеп алгандай.

Көмеш бәскә төренгәннәр бар да
Көмеш ярда купшы куаклар.
Сәлам сезгә көмеш Кыш-Бабаның
Бәйрәменә килгән кунаклар!

Кошлар бар да елтыр көмеш канат
Кагып оча салмак-сак кына.
Балыкчылар көмеш боз астыннан
Көмеш балык әнә каптыра...

Туган якның көмеш сурәтләрен
Берәм-берәм күздән кичерәм.
Көмеш төсең минем чәчемә дә
Куна инде, гүзәл Печорам.

## Вячеслав Батин

### Туган як

Син безгә кил, безгә кил, дускай,
Сәфәреңә бик шәп сылтау бар:
Якын итсәң безнең якларны,
Ерак йөрер синнән сырхаулар.

Мин бу ярда көтәм, бу ярда,
Йомшак карны, дускай, таптап уз.
Битләреңнән җилләр сыйпасын,
Иркен сулап, әкрен атлап уз.

Тирә-якны, дускай, күр, күзәт —
Күңел күзең белән карап бар:
Күп ул бездә күлләр, елгалар,
Төз ул безнең чыршы, наратлар.

Син безгә кил, безгә кил, дускай,
Бергә сулыйк тайга һавасын.
Бездәгедәй шигъри тылсымны
Тагын кайда күрә аласың?!

**ЗӘКИ НУРИ** тәрҗемәләре.

## ШАГЫЙРЬ ХӘСӘН ТУФАНГА 80 ЯШЬ

### Хәсән Туфан

# УЛ—БЕЗНЕКЕ, БЕЗ АНЫКЫ ИДЕК

ИСТӘЛЕК

А. М. Горький минем күңелгә «Давыл хәбәрчесе турындагы җыр» («Песня о буревестнике») дигән әсәре белән килеп керде. Искиткеч көчле һәм төгәл ритм белән язылган бу әсәр мине бик нык дулкынландыра иде:



**Чал диңгез тигезлегендә**
**Җил болытларны җыя,**
**Болытлар өстендә, күктә**
**Давыл хәбәрчесе гизә,**
**Нәкъ кара яшен сыман...**

Менә шулай башланып китә иде ул — «Давыл хәбәрчесе» (Татарчага тәрҗемә ителгәне — 1936 елларда, яшьләрнең «Атака» журналында бирелгән иде бугай).

А. М. Горькийның Казанда үткәргән яшь егет чаклары күңелендә бик җылы, ягымлы эзләр калдырган. Истәлекләрендә татар халкын үз итеп, якын күреп, иң ягымлы, җылы сүзләр белән искә ала ул. «Мин эчем пошкан көннәрдә, җаныма юаныч эзләп, татарлар яшәгән урамнарга барып, алар арасында йөреп, тынычланып кайта идем»,— кебек сүзләре дә шул хакта сөйли.

Советлар иле язучыларының Беренче съезды буласы елда А. М. Горький, Татарстан язучыларының киңәшчеләре рәвешендә, Казанга олы язучылардан А. С. Новиков-Прибойны һәм Лидия Сәйфуллинаны җибәргән иде. Алар безнең язучылар оешмасын съездга барырга әзерләштеләр.

Мәскәүдә, Колонналы зал бинасындагы съездда тәнәфес вакыты иде. Л. А. Сәйфуллина, меңләгән халык арасыннан безне эзләп табып: «Картыгыз сезне, татарлар, үз янына чакыра»,— дип безне сәхнә артындагы бүлмәгә, Алексей Максимович янына алып килде..

Ул безнең белән куллар биреп күреште, үз кешеләре генә итеп, Казан хәлләрен сорашып, сөйләшеп утырды.

Съезд Максим Горький доклады белән башланды. Икенче доклад — балалар әдәбияты турында, аннан соң УССР һәм БССР, Татарстан Язучылары союзы доклады. Бездән соң — Грузия, Әрмәнстан, Әзербәйҗан, Таҗикстан, Үзбәкстан һәм Төркмәнстан әдәбиятлары докладлары.

Беренче съездда делегатлар саны да бер чама диярлек иде: үзбәкләрдән — 10 кеше, төркмәннәрдән — 7, таҗиклардан — 11, казакълардан — 6, кыргызлардан — 4, Татарстаннан — 12 кеше.

Съезд барышында А. М. Горький безнең делегатлар санын тагын бер кешегә арттырды. Без, телеграмма биреп, Ф. Кәримне китердек.

Бу съезд татар язучылары күңелендә мәңге онытылмаслык күңелле, җылы, тирән эзләр калдырды.

Кыскасы, Алексей Максимович — безнеке, без — аныкы идек.

1936 елның кояшлы, аллы-гөлле чәчкәле, тыныч июне. Мин верандада нәрсәдер язарга җыенам, уйланып утырам.

Веранданы ураган үрмәле гөлләр зәңгәр чәчәкләр аша дөньяны, тыныч тормышны күзәтеп, елмаешып торалар кебек. Чәчкәләрне сыйпап кына, иренеп кенә җил искәләп куя...

Ничектер, яза торган кәгаземнең төсе үзгәрә кебек тоелды миңа. Чәчкәләрнең дә төсләре үзгәрә, тоныклана сыман... Көннең төсе дә, ничектер, үзгәрә бара кебек. Верандадан бакчага чыгып, күккә, кояшка күз салдым... Бәй, кояшның бер чите каралана лабаса! Кояш тотыла лабаса! Бүген шундый хәл буласын ишетмәгән идем микәнни...

Көнне сүрәнләтеп, Җир белән Кояш арасына кереп, акрын гына, ашыкмыйча гына Ай үтеп, узып китте.

Бу вакыйга тәэсиреннән арынып җитмәгән идем әле, Мәскәүдән радио, һич тә көтмәгәндә, авыр хәбәр китерде: А. М. Горький арабыздан китте бүген, мәңгелеккә китте... Бу көн — 1936 елның 18 июне иде.

## Гомәр Бәширов

# ШАГЫЙРЬ БАКЧАСЫНДА

Әдәби әсәр ничек туа? Илһам ничек, каян килә? Шагыйрь яки әдип нәрсә белән рухланып иҗат итәләр? Бу хакта мең еллар буенча язып киләләр, шәт, моннан соң да язудан туктамаслар. Чөнки бу — мәңгелек тема һәм кеше рухының иң мавыктыргыч сере. Дөнья йөзендә күпме әдип, шагыйрь яки композитор булса, шунча ук шәхси үзенчәлек, шунча ук язу алымы һәм дөньяга караш яшәп килә. Әгәр шулай булмаса, әдәбият, сәнгать яши алмас иде. Әмма талантның иҗат эшендә тоткан урынын берьяклы гына итеп, ансатлаштырып аңлатучылар да очрый. Андыйлар, әгәр берәр бәхетле бәндәгә табигать талант дигән шул кадерле һәм тансык сыйфатны бүләк иткән икән, димәк, шул җитте, ул зат үзеннән-үзе әдип, шагыйрь яки композитор булып китә, дигән кебегрәк фикер йөртәләр. Мин үзем талантны нәкъ кирәкле урынында куллану, аның белән нәкъ кирәгенчә идарә итә белү өчен тәпле акыл да, халыкның тарихына, аның тормыш тәҗрибәсенә нигезләнгән бик зур рухи байлык та кирәк дип уйлыйм. Мин моны күз алдында булып торган ачы тормыш хәлләреннән, гыйбрәтле язмыш сабакларыннан чыгып әйтәм. Кыз-

ганычка каршы, кайбер авторларның беренче шигырьдән үк башлары әйләнә башлый, алар беренче китапларының типография карасы кибеп җитәр-җитмәс үк дан шаукымыннан исереп, тормыш сукмагыннан чалыш-чолыш атлап китәләр.

Талант иясе сизгер җан булырга, үз заманының һәр сулышын сизеп торырга тиештер. Тормышның кечкенә генә бер вакыйгасы да, тапкыр сүз дә, күңелләргә рәхәт бирердәй моңлы аваз да аның иҗат дәртен кузгатып җибәрергә мөмкин. Ләкин очкыны дөрләп кабынып китсен өчен, учакта ягулык булырга тиеш бит! Әнә шул хакта — иҗат кешесенә күңел хәзинәсен яңадан-яңа табышлар белән баетып, дулкынландыргыч кичерешләр белән рухланып яшәү кирәклеге турында фикер йөртәсе килә иде.



*Хәсән Туфан һәм Мостай Кәрим.*

Өлкән шагыйребез Хәсән Туфан ифрат та катлаулы, бәрәкәтле тормыш юлы узды. Ул, бәхеткә каршы, сиксән яшенә кадәр иҗат дәртен сүндермичә, һәрдаим әдәбиятыбызның алдынгы сафында бара. Өстә куелган мәсьәләгә шушы бай тормыштан кайбер мисаллар китерергә телим.

**Аксак сыерчык.**

Яз көне кошлар җылы яктан кайта башлагач, Хәсән һәр елны аларны Аккош күлендәге язучылар дачасында каршы алырга ярата. Тәрәзәсе каршындагы куакка берәр ят кош килеп кунуга, биноклен алып, бакчага чыгып китүен дә күргәнем бар. Аннан кергәч, ул кадерле кунагын каршы алгандай куанып, өстәлендәге китаптан әлеге кошның сурәтен күрсәтеп ала:

— Бу тирәдә сирәк очрый. Яз көне төньякка узышлый безгә тамак ялгарга туктый, — дип тә аңлата.

Ул елны бераз сырхап торганлыктан, кошларын каршыларга Хәсән үзе бара алмады. Үтенечен телефон белән миңа әйтергә булган.

— Син минем кошларым-дусларымны күреп, килгән кадәресенә җим салгалап кайта алмассыңмы? Мин аларны бик сагындым,— диде. Нәрсәгәдер уңайсызлангандай, бераз тынып торды да тагын бер-ике сүз әйтеп куйды. — Анңары, ничек әйтергә мөмкин, син анда искәр әле, безнең йорт тумасы аксак сыерчык быел да килдеме икән?

Ярар, иптәшнең үтенечен гамәлгә ашыру — изге вазифа. Ләкин ул нитккән аксак сыерчык? Ул кошның аксагы да буламы икәнни соң? Әгәр була икән, очар кошның аксакмы, түгелме икәнлеген ничек белмәк кирәк?

Хәсән үзе генә түгел, кошлары да аны сагынган икән. Кыш буе аның җимлеге тирәсендә чуалган песнәкләр, тукраннар урынына хәзер көтүе белән еракта кышла-

ган уткойрык, урмәләч, чәберчек кебекләр кайтып төшкән. Әлеге аксак сыерчык та кайткан булып чыкты. Ул башкалардан аерымрак йөри, чыбыкка бер аягы белән чытырдатып ябыша да гарипләнгән аягын сузыбрак утыра икән. Бу сыерчыкның гыйбрәтле язмышын соңыннан гына белдем. Ул бала чагында ниндидер бәхетсезлеккә очрап аягын гарипләндергән дә, бүтәннәр шикелле үзен-үзе туйдыру бәхетеннән мәхрүм калган. Шәфкатьле куллар аны җәй буе ерткычлардан саклап, тамагын туйдырып үстерә торгач, ниһаять, ул көзгә таба тәмам «кеше булып», туганнары белән җылы якка киткән. Менә шуя кошкай туган ягына әйләнеп кайткан да, үзен тәрбияләп үстергән кешеләрне куандырып, шул ук ояда үзе бала-чага үстерергә хәстәрләнеп йөри иде.

Җылы яктан кошлар кайтып оя кора башлаганда, бигрәк тә алар иң дәртләнеп сайраган иртәнге сәгатьләрдә ни җаның белән бу концертка битараф калмак кирәк? Иртән иртүк, агач каүсәләре арасында кояшның алтын-сары нурлары җемелди башлауга, яфракка бөреләнә башлаган хуш исле куаклар арасыннан кошлар үз дусларының чал башын күрәләр. Бу вакытта әле бакчада берәү дә юк, кошлар да ул гына. Аксак сыерчык күгәрчен тамагы төсле матур түшен киереп, өзелеп-өзелеп сайрый. Ул әле яшь колын булып кешнәп җибәрә, әле кеше тавышы чыгарып ай-һай-һай дип куя. Ул да түгел, аның тавышы тау астындагы тынгысыз чишмә чылтыравына охшап китә.

Нәрсә дип сайрый икән сыерчыклар? Юлларыбыз бик озын, җилләр каршы булды, өчтән беребез генә исән-сау кайтып җитә алдык дипме? Әйбәт булса да торган җир, сагындыра туган ил дипме? Хәер, ни генә әйтергә теләп сайрасалар да, алар шагыйрь дуслары белән бик яхшы аңлашалар булса кирәк.

**Гөлләр шигърияте.** Чәчәкләр сөйләшә беләме? Бу сорауга һич икеләнмичә:

— Белә! Әгәр син дә аларның телен белсәң! — дип җавап бирәсе килә. Чөнки Хәсәннең үз теле белән әйткәне бар:

— Кыңгырау чәчәк мине һәр көн иртән, әйтер сүзе бар кебек, күземә карап каршы ала,— ди ул.

Бу хакта аның шигырендә дә язганы бар:

> **Каядыр дәшәләр,**
> **Нәрсәдер әйтәләр,**
> **Мөгаен, матдәнең**
> **Җырыдыр чәчкәләр...**

Ул чәчкәләр аның Аккош күлендәге кечкенә бакчасында үсә. Хәсән Туфан гомере буе яшь шагыйрьләр тәрбияләп үстергән кебек, гөлләр шигърияten дә үз бакчасында, үз кулы белән үстерә.

Әгәр бу бакчага чәчәк вакытында килеп керсәң, нәфис төсләрнең күплегенә, аларның төрлелегенә сокланмыйча кала алмыйсың. Килеп керешкә син үзеңне Көнчыгышның оста куллары чиккән гаҗәеп келәм каршысында торган кебек хис итәсең. Кайсы якка гына күз салма, күзеңнең явын алырлык ал, кызыл, миләүшә төсле, коңгырт һәм зәңгәр чәчкәләр. Менә синең алдыңда ук «беләсеңме без кем?» дигәндәй тәкәббер кыяфәттә иркә Европа кунаклары — мальва, флокс, астра кебекләр чәчәк атып утыра. Болары затлы нәселдән, аларның нәсел-нәсәбе, кайсының кайсы король бакчасында үстерелүе калын китапларга теркәлгән.

Шулар янында ук үзебезнең кырларда, урманнарда әрсезләнеп аяк астында үсеп яткан умырзая, энҗе чәчәк, үрмәле гөл, колмак, кыңгырау чәчәк кебекләр башта гайре табигыйрәк булып күренә. Чөнки гадәттә бу кыргыйларны «культурный» бакчаларга кертмиләр. Хәсән исә үзебезнең йорт тума чәчәкләрне урманнарда, кырларда эзләп табып, үз кулы белән алып кайтып утырткан. Бу хәлне Туфан елмая төшеп кенә үзенчә аңлатты:

— Ничек әйтергә мөмкин... мин биредә аристократияне табигатькә якынайтып, бераз демократиягә өйрәтергә тырыштым. Әйдә, бездән булсын яхшылык! — диде.

Кыргый табигатьнең үз матурлыгы бар. Шагыйрь күңелендә исә гөлләр һәммәсе дә бер үк дәрәҗәдә тигез хокуклы, җылы кояш астында аларның һәммәсенең дә күкрәп чәчәк атарга хакы бар. Алар һәммәсе дә кешенең рухи тормышын гүзәллек, нәфислек, гармония хисләре белән баетып торучы, күңелгә якын табигать бүләкләре. Шунлыктан, шагыйрь аларны якын итеп һәрдаим хәлләрен белешә, кояшлы көннәрдә «күңелләре көр» булуын, һава шыксызрак, салкынрак чакларда «күзләре түбән, күңелләре сүрән» булуын күреп, сизеп тора. Чәчәкләр шагыйрьнең эстетик теләкләрен канәгатьләндереп, күңеле тибрәнүләренә тәэсир иткән чаклар да була. Бер шигырендә ул:

> **Ак гөлләргә тутлар төшә**
> **Сары сагышларымнан,**
> **Гөл гаепсез,**
> **Коткар мине**
> **Гөлнең каргышларыннан,**

— дип яза.

Гомумән, шагыйрьнең чәчәкләр белән дуслыгы ниндидер бер вакытлы, очраклы мавыгу гына түгел. Аның тормышында һәм иҗатында бу табигать гүзәллегенең бик күркәм үз урыны бар. Аның дусларының «чәчкәләрдә төсе, җирдә җылы эзе кала». Кунак кызлар аңа «зәңгәр чәчәк төсле нейлон яулык ябып» киләләр. Ул якын дусларын тәбрик иткәндә аларга, иң кадерле бүләге итеп, чәчәк алып бара, үзенә чәчәк бүләк итүгә чын күңелдән куана. Аның «Чәчәкләр куегыз Тукайга!» дигән сүзләрендә бөек шагыйрьгә тирән мәхәббәте чагыла. Шунлыктан, «Гүзәл» дип исемләнгән шигырендәге мәгълүм юлларны да чын күңелдән ышанып укыйсың:

**Гөлләр сорый миннән: «Нишләп, Туфан,**
**Уйга калдың әле син шулай!»**
**— Белмим, гөлләр, уйга калып шулай**
**Гүзәллеккә сокланам бугай...**

Нәрсәдә икән моның «сере» дигән сорау туарга мөмкин. Күрәсең, шагыйрьнең рухи дөньясының үзенчәлегендә, күңеле һаман да яшь, хисләре һаман да үткен, нечкә булып калуындадыр. Ул тормыш һәм табигать матурлыгын чынбарлыкта ничек булса, шул рәвештә табигый тулылыгы, чикләнмәгән гүзәллеге белән күрә ала, аларга борынгы бабаларыбыз беркатлылыгы һәм сабыйлар самимилеге белән соклана белә. Гомернең сиксәненче баскычына аяк басканда да үзендә сабыйларның күңел сафлыгын саклый алу бик кадерле рухи байлык, сирәк очрый торган бәхет ул.

Минем Хәсәнгә ярым шаяртып, ярым чынлап дигәндәй шундый сорау биргәнем бар:

— Кем син, Хәсән? Сине ниндирәк холыклы кеше дип аңларга мөмкин?

Ул, гадәтенчә, чал чәчен биш бармагы белән тарап, уйланыбрак җавап бирде:

— Мине балалар шикелле беркатлы кеше диләр. Ихтимал, дөрестер ул. Шулай да кайчагында мин усал да була алам.

— Кайчан, ниндирәк хәлләрдә?

— Әгәр дә халыкның йөз суын түксәләр, халык мәнфәгатенә хилаф эш кылсалар.

Бу фикерне әйткәндә, ул сатирик шигырьләрен дә күз алдында тота булса кирәк.

**Шагыйрь өстәлендәге чүкечләр.** һәркемнең әйләнә-тирә мохите, яшәү шартлары аның үзенә генә хас шәхси үзенчәлеген, холкын-фигылен, дөньяга карашын, эстетик зәвыгын чагылдырырга мөмкин. Шәһәрдә булсын, дачасындагы дәрвишләр хөҗрәсе кадәр генә бүлмәсенең язу өстәлендә булсын, шундый бер сәер тәртип яшәп килә ки, Хәсән фәкать үзе генә моның «очына чыга» ала торгандыр. Кем өстәле бу? Орнитолог галимнекеме, слесарь өстәлеме, әллә әдәби иҗат белән шөгыльләнүченекеме? Ниләр генә юк бу кечкенә өстәлдә? Борынгы Эллада шагыйрьләре, Гомәр Хайям әсәрләре, шигырь анталогиясе белән янәшә «СССРдагы кошлар билгеләмәсе» исемле калын китап, тагын шундый галимнәргә кирәкле әсәрләр күрәсең. Шунда ук язылып бетмәгән шигырь юллары, мәктәп баласының «Яшь ленинчы»да басылган өйрәнчек парчалары, иптәшләренең аңа җибәргән яңа шигырьләре, берничә радиоалгыч, зурайткыч пыяла, кесә фонаре, һәм... слесарь кораллары таралып ята. Башта бу мине гаҗәпләндерә торган иде. Ничек була әле бу? Шигырь язганда игәү, эскәнҗә, чүкеч шикеллерәк кораллар да кирәк булмый торгандыр бит?

Эш шунда ки, беренче карауга гаҗәбрәк кебек күренгән шушы «тәртипсез» тәртипнең үз «сере» бар, алар әдәбиятның алтын фондына керердәй мәшһүр шигырьләр язарга һич уңайсызламыйлар. Хәтта киресенчә!

Ул күп вакыт яшел абажурлы өстәл лампасын кабыза да шушы кечкенә өстәленең бер почмагына иелә төшеп, нидер язып утыра. Якыннары, иптәш-каләмдәшләре андый чагына туры килгәндә, аяк очына гына басып, кире чыгып китәләр. Әмма кайчакларны син кергәнне сизеп борылып караса, күрәсең: кулында каләм урынына пинцет-эскәк, күз кабаклары арасына сәгать остасыныкы шикелле үк зурайткыч пыяла кыстырган, ә икенче кулында сүтелгән авторучка, аның нинди дә булса бер аерым кисәге. Каршысындагы калай тартмада бөтен бер арсенал! Инә күзеннән дә үтәрлек вак кына шөрепләр дисеңме, гайкамы, алтынлаган каләм очлары, нечкә пружиналар, төрле төстәге каләм саплары, тагын шундый мең төрле кирәк-ярак. Бәлки анда әле җылан мөгезе дә бардыр...

Хәсән, синең белән сөйләшә-сөйләшә, шул тимер-томыр, пластмасса кисәкләреннән үзе теләгәнчә яза белә торган яңа каләм әмәлләп утыра. Монысын кисә, тегесен игәүли, кай төшендер җаен белеп кенә беләүгә ышкып ала, зурайткыч пыялада бик җентекләп караганнан соң, кайсы урыныидыр бармак башы тикле генә көмеш чүкеч белән «чәк-чәк» иттереп суккалап алган була. Кораллар аның кулында үзеннән-үзе уйнап кына йөриләр. Мин аның җәенке битле йомшак бармакларының шундый тыңлаучан булуларына, шундый җитезлегенә сокланып утырам. Шушылай матур итеп эшли белү үзе шигърият бит! Вак кына детальләрне ул шундый оста итеп тота, шундый иплэп урыннарына утырта, әйтерсең, шушы тимер затының телен белә, әйтерсең, алар аны тыңлыйлар, әйтерсең, ул сиксән яшенә кадәр гомере буе фәкать шушы һөнәр белән генә шөгыльләнгән!

Мондый шөгыль белән мавыгуы бәлки шагыйрьнең кайчандыр Урал заводларында слесарь булып эшләвен исенә төшереп, яшь чагының күңел сусавын басырырга тырышуыдыр?

— Ул гына түгел,— ди Хәсән.

— Бәлки болар белән мавыккан арада шигырьне беразга онытып торасыңдыр, бу үзенә күрә ял була торгандыр?

Хәсән эшен дәвам иттереп башын чайкый:

— Юк, шигырьне онытып торып булмый. Зиһенгә бирәр нәрсә «урала» башлады мы, аны инде өзеп ташларга ярамый. Куллар моны ипләгәндә «югарыгы катта» «тегесе» дә дәвам итә.

Хәсән тагын ниләрдер «сихерле» дә төрле авторучкалардан оешкан кызыл-яшел төстәге яңа каләмгә кара тутырып, язып та күрсәтә. Ак кәгазьгә үрмәкүч пәрәвезедәй нечкә, язгы үлән яфракларыдай сыек яшел төсле нәфис хәрефләр тезелеп китә.

Шундый кызык хәл бит менә: дөнья йөзендәге бер генә заводның да моңарчы Хәсәнгә ошар дәрәҗәдә нечкә итеп яза торган яхшы каләм эшләп чыгара алганы юк икән әле. Шунлыктан, ул теләсә нинди кыйммәтле, яхшы дип саналган каләмне дә үзенә яраклы хәлгә китермичә кулланмый, теләсә нинди кара белән түгел, үзе әйтмешли, «җанга якын, ягымлы кара» белән генә яза.

Чехов врач булган, Лев Толстой сукага үзе ат җигеп, граф башы белән, яланаяк, күлмәкчән җир сөреп йөргән. Болар «кара эш» белән тамак туйдырырга калган затлар түгел. Күрәсең, нинди дә булса һөнәр белүче кеше гади хезмәтнең тәмен тирәнрәк татый, аның кадерен дә тирәнрәк аңлый торгандыр. Андый кешеләр хезмәт иясенең рухи халәтен дә тирәнрәк аңларга сәләтле буладыр.

Бер хатында ул болай дип язган иде:

**Бу кадәр дә юксынырмын икән**
**Илкәемне, алтын ягымны!**
**Бәйрәмнәрне көткән кебек көтәм**
**Казаныма кайтырларымны...**

Туган-үскән якларыңны шундый яратып, шулкадәр өзелеп сагыну өчен, күрәсең, күңел хәзинең бик бай, хисләрең бик тирән булырга кирәктер.

## Сибгат Хәким

# ТУФАН—КҮПЕР...

Туфан — күпер. Поэзиянең өлкән буыны белән хәзерге яшь буынын тоташтырган зур күпер. Минем инде поэзиягә кергәнгә кырык елдан артык. Ул чакта ук минем өчен Туфан өлкән шагыйрь иде. Минем өчен генәме? Үзләре танылып җиткән Әхмәт Фәйзиләр, Муса Җәлилләр, Фатих Кәримнәр дә аңа «Туфан» диләр иде. Шушылай «Туфан» дип эндәшүдә яшь олылыгы гына булды микән? Юктыр, яшь кенә түгелдер. Барыннан да бигрәк поэзиянең олылыгы ишетелә «Туфан»да. Поэзиянең урынын, дәрәҗәсен билгеләүче исем. Поэзиягә зурлык биреп торган исем. Төрле чорлар, төрле еллар булды, бу исем беркайчан да телдән төшмәде. Шагыйрьләрдән, үз чордашларыннан ул бер үзе. Аны чордашлары Такташлар, Кави Нәҗмиләр, Гадел Кутуйлар, Фәтхи Бурнашлар белән бергә күз алдына китерсәң, Туфан фигурасы тагы да зурая төшә. Әгәр аның иҗат юлында Шәехзадә Бабичлар юлдаш булганын искә алсаң һәм укытучылары Галимҗан Ибраһимовлар икәнен дә онытмасаң, Туфан чыннан да күпер дигән фикергә киләсең. Туфан буыннарны бәйли. Мин аның озын авыр чорлар кичеп, бүген безнең арада булуына әйтеп бетергесез шат. Яшәвенә, туктаусыз иҗат итүенә шат.

Туфан миңа иҗаты белән, үзенең рухы белән иң якын шагыйрьләрнең берсе. Мин моңа тагын үзенең кешелек сыйфатлары белән дип тә өстәр идем. Шәхес буларак татар совет поэзиясендә Туфанга охшаган бер генә шагыйрь дә юк. Аңа охшарга мөмкин түгел. Башкалардан аерып куйган төп сыйфаты — фанатиклыктыр, поэзиягә җаны-тәне белән бирелгәнлек. Башкалар өчен дә бу чит сыйфат түгел. Туфан фанатизмы ул бүтән.

Туфан актив. Яшь чагында ул бөтен Урта Азияне җәяү йөреп чыккан, милли әдәбият вәкилләре белән аралашып үскән интернационалист шагыйрь. Шушы яшькә кадәр аның иҗат мәсьәләләренә кагылышлы бер генә җыелыштан, бер генә идарә утырышыннан да калганы юк. Иҗатта көрәшче, иҗатта һәрвакыт үз фикерен әйтеп килә. Шулай да тормышында ниндидер дәрвишлек тә бар аның. Иҗат дәрвишлеге.

Дөнья белән икәүдән-икәү генә кала ала. Галәм белән, материя белән сөйләшә, поэзиядә Гомәр Хәйямнар тирәнлегенә китеп сәяхәтләр ясый. Ашавын-эчүен оныта, барлык дөньяви нәрсәләрдән ваз кичә. Мин аның шушы гомер эчендә кайчан да булса акчам юк дип сөйләгәнен хәтерләмим, белмим. Бу аңа ят, рухы кабул итми, тормышында шуны аңлаган нинди изге җаннар очрагандыр, ул һаман үзенә турылыклы.



*Хәсән Туфан, Сибгат Хәким һәм Туфан Миңнуллин.*

Биографиясенең бер өлешен үзем дә беләм. Мин белмәгән өлеше дә шактый. Үзе язарга яратмый, чыкканнары — кемнәрдер сөйләтеп язып алган биографияләр. Язучыларны күбрәк иҗатлары буенча өйрәнәләр, язылмаган ярты иҗаты үзендә кала. Катлаулы биография — катлаулы иҗат. Мин дә сөйләттем — кенәнә бер сәгать, ике сәгать, ял иткән араларда, кайчакта ачылып китә, туган якларына кайта, әнисенең йолдызлар турында сөйләгән сүзләрендә шигырь яңгырый башлый, шигырь җепләренең очын күрә башлыйсың. Шигырьгә Тукайлар, «Туган тел» килеп керә, тора-бара шигырьдән Урал мартеннары калка, «Башлана башлады», революция... Туфан булган, яшәп, көрәшеп узган урыннарны санау да җитә. Ниндидер әкияттәге кебек зур, романтик җирләр: Урал, Себер, Уралның үзенә хас гигантлар, шахталар, рудниклар, гигант кешеләр, Хабуллар, Чапыйлар... Уралдан Казанга, Казаннан Урта Азиягә. Яңадан Казан. Тора-бара биография кабаттан башлана кебек.

Мин белгән өлеше. Сугыш алдыннан Югары Ослandaгы дачаларда Муса Җәлил, Әхмәт Фәйзи, Әхмәт Исхак, Хәсән Туфаннар бергә «Яшьлек юлы» исемле күмәк әсәр яздык. Сугыш алдыннан минем туйның түрендә Туфаннар, Җәлилләр, Кутуйлар утырды. Туфанның шул туйга багышлаган шигырен мин уналты елдан соң табып алдым. Табулар, югалтулар аша үсте поэзия.

Хәзер дә, яңа шигырьләр туса, мин аңа укыйм. Кайчакта мин аңа телефоннан да укыйм. Туфан — сәгать остасы. Шигырьне ул сүтә, сәгать кебек сүтә. Күзлеген кия, лупасын ала, пинцет белән рифманы сәгать кылын әләктереп алган шикелле әләктерә, яңадан җыеп күрсәтә. Минем бу хакта язган шигырем дә бар. Туфаннан һәрвакыт сиңа шагыйрьлек йога. Мин Туфанга охшаган бер генә шагыйрь дә бүтән юк дигән идем. Бу шулай. Характерында, табигатендә үзенә генә хас нәрсәдер бар. Мәсәлән, ул шигырьне фәкать яшел кара белән генә, каләмнең очы белән генә яза. Башка берәү дә аны таный алмый. Шуннан ләззәт таба.

Туфан — һәртөрле карьера дошманы. Поэзиягә, халыкка турылыкта, намуслылыкта ул яшьләргә һәрвакыт үрнәк булып калачак.

Михаил Дудинның милли шагыйрьләрдән иң яраткан, хөрмәт иткән кешесе — Хәсән Туфан. Дудин белән мин төрле шәһәрләрдә, пленум, съездларда, әдәби кичәләрдә очраштым. Ул башта мине күреп алу белән бер илле адым килеп җитми туктый һәм аннан: «Туфанны саклагыз!» — дип кычкыра. Бу егерме-утыз ел буе шулай. Кайчакта мин Дудинны чорның бер очында, Хәсән Туфанны икенче очында басып торган кебек итеп күрәм. Шагыйрьләр дуслыгы, поэзияләр дуслыгы.

Туфан — күпер, олы чор буйлап сузылган мәһабәт күпер.

## Туфан Миңнуллин

# ШАЯНЛЫК ҺӘМ ҖИТДИЛЕК

Хәсән Туфанга җитмеш яшь тулган көн иде. Шуның хөрмәтенә тантаналы юбилей кичәсе үткәрелде. Кичәдә заманыбызның мөхтәрәм шагыйрен зурлап берсеннән-берсе күркәмрәк мактау, олылау сүзләре әйтелде. Ул сүзләр, тост формасын алып, Хәсән аганың мәҗлесендә дә кабатландылар. Ләкин ни чаклы кабатлансалар да сүзләр ялыктырмады — һәрбер тост әйтүче кыланмыйча, ясанмыйча, төчеләнмичә мактау сүзләренең барысына да шагыйрьнең лаек икәнлегенә ихлас ышанып сөйләде.

Әдәбиятыбызның өлкәннәре җыелган мәҗлескә чакырылуыма эчтән горурланып һәм, әлбәттә, бераз каушабрак утырганда миңа сүз бирделәр. Каушавымны җиңеп, әрсезлегемне эшкә җигеп, шаянрак тост әйтергә булдым.

— Хәсән ага, быел миңа утыз биш яшь тулды,— дидем,— мин туганда сезгә дә утыз биш булган. Сез ул вакытта ук инде танылган шагыйрь булгансыз. Шагыйрь Туфан иҗатына гашыйк әтием миңа Туфан исеме кушкан. Рәхмәт, адаш абый, минем исемемне akладыгыз,— дидем.

Мәҗлестәгеләр барысы да көлделәр. Мәгънәсез шаярып өлкән кешене үпкәләтмәдем микән, дип Хәсән агага карап алдым, ул да рәхәтләнеп көлә иде.

Күпмедер вакыт узгач, Хәсән ага белән Матбугат йорты коридорында очраштык. Шагыйрь мине туктатты да:

— Беләсеңме, энем, теге чакта син шаярткан булып бик җитди сүз әйттең бит...— диде.

Аптырап калдым. Чөнки җитди сүз әйтү башыма да килмәгән иде. Үзеңнән утыз биш яшькә өлкән кешегә, олы шагыйрьгә җитди итеп, исемемне акладыгыз, дияргә мин ул чаклы ук оятсыз түгел, ләбаса.

Еллар үтә тора. Уйланам. Хәсән Туфанның мине туктатып әйткән сүзләре һаман да уйландыра. Шаяру бәлки аерым бер урында килешәдер. Әмма безгә җитдилекне дә онытып җибәрергә ярамыйдыр, күрәсең, уйланырга кирәктер. Без һәм бездән яшь буыннар Илгә, халыкка, Ватанга, иҗатка өлкәннәр кебек турылыклы булып, аларның исемен, өметләрен аклый алырбызмы?

Бүген, гомере буе халыкка хезмәт иткән солтанатлы шагыйребез Хәсән Туфанга сиксән яшь тулганда җитди сүз итеп күңелебезгә шул сорауны салып куйыйк. Ул сорау безне, тынгылык бирмичә, борчып тора икән, шаяруларыбызны өлкәннәр гафу итәрләр. Хәтта кушылып көләрләр дә.

## Альберт Яхин, Флүрә Низамова

# КАЙСЫГЫЗНЫҢ КУЛЫ ҖЫЛЫ

Хәсән Туфан иҗатын өйрәнү мәсьәләсенең куелышы... Бу — күптән көн тәртибенә баскан мәсьәлә. Туфан иҗатының поэтик асылына фәнни аңлатма бирми торып, татар совет әдәбияты тарихын тулаем күз алдына китерү кыен.

Хәсән Туфан иҗатының яңа күренеш икәнлеген таныган хәлдә, аны яңача өйрәнергә кирәклеген дә шик астына алмаска тиешбез. Бу иҗат зур да, катлаулы да. Шуның өчен аны ниндидер уртак нигез табып, махсус төркемчәләргә бүлеп тикшерү уңай булыр иде. Гадәттә аерым язучы иҗатын тикшергәндә күнеккән һәм ярат-

кан ысулыбыз — иҗатны хронологик тәртиптә үсеш этапларына бүлеп карау. Бу юл Хәсән Туфан иҗатын тикшергәндә ярдәм итә алмый. Туфан әдәбиятка җитлеккән шагыйрь булып керә. Еллар үткән саен аның таланты күбрәк ачыла бара. Тормыш, шагыйрь үзе үзгәрә, әсәрләрендәге темалар, стиль алмашына. Төп игътибарны менә шул үзгәрешләргә юнәлтик. Язучының 20—30 нчы, 40—50 нче елларда һәм аннан соң иҗат иткән әсәрләре өч төркемгә бүленә. Бүленешнең нигезе итеп бик гомуми, ләкин мөһим нигез — чынбарлыкка бәя бирү аермасын алабыз. Мондый бүленеш Хәсән Туфан иҗатын бербөтен күренеш итеп күз алдына бастыра. Шагыйрь иҗатының хронологик бүленеше бер үк вакытта бербөтен күренешнең өлешләренә дә әйләнә. Тикшерүнең бу ысулын иҗат чорларын аерым өлешләргә бүлгәләү рәвешендә генә аңлау бик гадиләштерү булыр иде. Сүз бер төркем әсәрләрне үзеннән алда килгән төркем белән бәйләнештә генә аңлату турында, ягъни Хәсән Туфан иҗатын система итеп тикшерү турында барачак.

Беренче төркемгә язучының 20—30 нчы елларда язган шигырьләрен кертәбез. Бу еллар иҗаты тематик байлыгы белән аерылып тора. Шагыйрь әсәрләренә чынбарлыктан яңа типлар, күренешләр эзли һәм шул чынбарлык тудырган хисләрен тасвирлый.

**Эченнән генә әби**
**Догалар укып йөри,**
**Советлар властена**
**Гомерләр тели-тели.**

Иске заман кешесенең яңа тормышка яңача мөнәсәбәтендә шагыйрь заман матурлыгын күрә. Шундый карчыкларга да, үзләрен хуҗа итеп сизә башлаган эшчеләргә дә, елдан-ел арта барган завод торбаларына да, йөк поездларына да чиксез шатлана ул. Бүгенгене үзе күргән, белгән иске заман белән чагыштырып карый. Хәсән Туфан да Такташлар, Җәлилләр кебек, яңа хисләргә исем эзли. Яңа күренешләрне үз хисләре аша бәя биреп аңларга тырыша.

Хәсән Туфанның бүтән бер иш әсәрләре лирик геройның хис тирәнлеген, зурлыгын, куәтен ачуга багышлана. Икенче төркемгә язучының 40—50 нче еллар эчендә язган әсәрләрен кертергә мөмкин. Бу елларда язылган шигырьләрдә тема байлыгы күренми, димәк, хисләр төрлелеге турында да шундый ук сүз әйтергә тиеш булабыз.

Сәнгатьнең иң үзенчәлекле вазифасы, иң авыр эше, язучыларны сыный торган таләбе кеше тойгыларының тирәнлеген, хәрәкәтен күрсәтүдән гыйбарәт. Үзендәге ярсуны укучыга күчерә алу, аны хәтта моңа кадәр кичермәгән дәрәҗәдә хисләндерү, моңа кадәр дулкынланмаган дәрәҗәдә дулкынландыру вазифасы бик четерекле һәм шуның өчен бу эшне фәнни телгә күчерү дә бик кыен.

Инде Хәсән Туфан солдатка китүче кешенең тирән тойгысын аңлап, шуннан туган үз хисләрен генә язу белән чикләнми. Тойгыны, кичерешне бөтен ялангачлыгы белән, кырыслыгы белән күрсәтергә тырыша:

**Туган-үскән туфрагым!**
**Без китәбез, хуш җаным...**
**Яулыгыма төйнәр идем.**
**Кулым җитми — керт калын.**
**Без китәбез, хуш җаным!**

Хәзер туган-үскән якларына кайтучы кеше хисләре күп төсле кырлары белән җемелдәп ялтырамый, бөтен тормышчанлыгы, авырлыгы белән килеп баса:

**Каршыларга чык син вокзалларга,**
**Очрашырга кил син, яшьлегем.**

Сагыну тойгысы кешене бөтен барлыгы белән биләп ала:

**Кемдер шакый тышкы ишекне.**
**— Мин өйдә юк: күңел бүген дә**
**Ерактагы туган җиремдә!**

Сагыну хисен язмаган шагыйрь табуы кыен.

һ. Такташ сагынуның яңа төсмерләрен заманында һичкем әйтмәгәнчә әйтеп биргән:

**Көтүләрдә хәзер кем кәҗәсе**
**Алдан чабып йөри торгандыр...**

Такташ сагынуына беркатлылык, самимилек, балаларча сафлык, шуклык хас.

«Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!.. Сагынган саен сагынасы килә»,— дип яза Гадел Кутуй. Берәү дә хисләрен бу рәвешле белгертмәде. Кутуй сагынуы каршылыклылыгы белән катлаулы, анда хәсрәт белән бергә очрашу шатлыгы да, өметле сагынуның рәхәте дә бар.

Сагынучы кеше халәтен Хәсән Туфанның лирик герое менә ничек күз алдына китерә:

**Яшьләрең юа лабаса**
**Күзеңнең зәңгәрләрен...**

Хәсән Туфанның бу төр шигырьләренә хиснең тирәнлеген ачу мөһим. Кайгы булса — чиктән тыш кайгы, сагыну булса — күз зәңгәрләре юылырлык дәрәҗәдәге сагыну, шатлык булса — башың күккә тиярлек шатлык.

Әйтелгәннәрдән чыгып, Хәсән Туфан иҗатының бу чорын кешенең эчке халәтенә бәя бирү чоры дип билгеләргә була.

60—70 нче еллар иҗатында исә Хәсән Туфан инде яңа туган хисләрен ашыгып сурәтләргә дә, хисләренең тирәнлеге турында элеккечә гасабиланып язарга да омтылмый. Әмма бу чор иҗаты баштагы икесе белән аерылгысыз бәйләнештә тора. Алдагы һәр ике чорның хис байлыкларын, вакыйгаларын саклаган хәлдә аларның дәвамы булып килә. Хәсән Туфанның бу елларда язган шигырьләре, аерым-аерым укыганда да дулкынландыралар. Әмма аларны язучы китабында урнаштырылганча, алдагы томга кергән әсәрләрнең дәвамы итеп карарга кирәк. Шул чакта бу әсәрләр бөтенләй башка яктылык белән яктыра, күп төрле бизәкләр белән уйный башлыйлар. Шул чакта гына бу әсәрләрдә яшь, дәртле Хәсәннең бизәкле хисләрен дә, моңлы Туфанның тойгы-кичереш тирәнлеген дә тоярга була. Хәзер язучы кичергән рухи халәтнең бөтен тәҗрибәсе, тирән эзләре җанлы хәтер рәвешендә шушы шигырь эченә керә. Яңа чынбарлыкның яңа күренешләрен шагыйрь үзенең зур тормыш тәҗрибәсе һәм тойгылар хәтере белән бәяли. Бу бәяләү ахырында фикер сөземтәсе ята. Кешенең фикерләве хәтер төеннәрен үзара бәйләүдән гыйбарәт. Хәтердәге төеннәрдә сурәтләр дә, вакыйгалар да, хисләр дә ята. Шулай итеп, хәтер тормыштагы вакыйгалар уяткан хисләрне бәяләп, аларга үзеннән тойгылар өсти. Хәсән Туфан иҗатындагы лирик геройның чынбарлык күренешенә бәя аермалары шулай итеп, бәяләү эчтәлегенең байый баруы рәвешендә карала ала.

**Гөлләр сорый миннән: «Нишләп, Туфан,**
**Уйга калдың әле син шулай!»**
**— Белмим, гөлләр, уйга калып шулай,**
**Гүзәллеккә сокланам бугай.**

Бу юлларны кешенең гүзәллеккә мөкиббән китүе, дөньясын онытуы дип укыганда да беренчел мәгънә сакланып кала. Кешенең матурлыкны уйланып кабул итүе тойгыларның кызыклы сыйфаты түгелмени? (Беренче төркемдәге әсәрләрдә әнә шул максат күздә тотыла да). Ләкин Туфан иҗатының алдагы чорларын да хәтерләүче укучы өчен бу юлларның мәгънәсе киңрәк, андагы хисләр дә катлаулырак. «Гүзәллеккә сокланам бугай», ди шагыйрь, матур гөлләрне күргәч күңелендә уянган иске хисләренең эчтәлеген сөйләп тормый. Ә бит аның өчен гөл матурлык сурәте генә түгел иде. Гөлләр белән күп кичерешләр бәйле. (Хәтергә төшерик: «Ак гөлләргә тутлар төшә Сары сагышларымнан», яки сугышта адресларын таба алмаган хатлар көлендә үскән ак чәчәкле гөлләр). Матур гөлләр белән лирик геройның гаять бай, тирән, каршылыклы хисләре, истәлекләре бәйләнгән. Матурлык һәм ул тудырган хисләр хәтердәге шуңа бәйләнешле вакыйгалар белән күп төрле бәйләнешкә керә башлый. Тынычлыкта үскән һәм яшәргә башкаларны шатландырырга тиешле матурлыкның бүгенгесеннән бигрәк килачәге күзаллана. Лирик геройның уйга калуы, шул рәвешле, матур гөлнең киләчәге өчен борчылуы белән үзеннән-үзе бәйләнергә тиеш була. Гөл матурлыгының киләчәге өчен борчылу мисалга китерелгән шигырьдә үк тормыш матурлыгының киләчәге өчен борчылу мәгънәсен ала. Мәгънә гомумиләнә, димәк, җитдиләнә, кырыслана, фәлсәфи нәтиҗәгә әйләнә. Бу тема язучының соңгы елларда язган әсәрләрендә еш кабатлана торган төп тема дияргә мөмкин.

Туган авылы башында үскән аккаен турында шагыйрь:

**Әле дә каравыл икәнсең**
**Авылның тышында, түрендә.**
**Сорама, аппагым, сорама.**
**Нәкъ шул ук миссиям минем дә,**

— дип яза. Хәсән Туфанның шулай язуы бераүне дә гаҗәпләндерми.

«Күбәләк» шигырендә әдип матур кызга сокланып карап торуын яза. Бу соклануда да «каравылчы» борчылуы да, матурлыкка бәя дә, борчылып бәяләүнең фәлсәфи эчтәлеге дә бар. Күңелле мәҗлес. Түрдә күбәләктәй матур кыз утыра. Ә кыш шул чак тәрәзәгә гөл-чәчәкләр төшерә. Кышның максаты шагыйрьгә аңлашыла: ул кешеләрне кисәтә, бүгенге матурлыкка үткәннәрнең дәһшәтле көрәше аша бәя бирергә өйрәтә кебек.

**Шул рәсемнәр аша әйтә төсле:**
**— Матур булсын өчен гомерегез,**

**Алгы язның ал гөлләрен, кешеләр,**
**буран аша күрә белегез!**

Гөл матурлыгы, кыз чибәрлеге хәзер шагыйрь өчен хис уятучы чынбарлык күренеше генә түгел. Шагыйрь хәзер матурлыкны күп язмышлар янәшәсенә куеп бәяли. Ил язмышы белән бәйләп фәлсәфи нәтиҗә чыгара. Мондый нәтиҗәне шушы шигырьләрнең дәвамы булып килгән башка әсәрләрендә укыйбыз. «Ни булды сиңа!» шигырендә әдип Илнең символы булган Иделгә турыдан-туры мөрәҗәгать итә:

**Син нигә уйчан бүген!**
**Ни булды Идел сиңа!**
**Яраса, сөйлә миңа!**
**Мин — килмеш турист түгел,**
**Син, никтер, уйчан бүген.**

Хәсән Туфанның шактый әсәре сугыш уты кабызучыларга каршы язылуы бик табигый. Бу әсәрләр — шагыйрь иҗатының буеннан буена сузылган һәм гомумиләшү юнәлешендә үсеп килгән бер үк зур фәлсәфи теманың дәвамы.

«Башлатмагыз!» әсәрендә гөл-чәчәкләр матурлыгы кешеләр үлеме, сугыш дәһшәте белән каршылыкка килү белән генә чикләнми, шуның нәтиҗәсе, башка шартлардагы дәвамы итеп тә сурәтләнә.

**Күпер ватык, юллар ябык...**
**Хатлар кире кайтмады...**

**Каберләрен, хәбәрләрен,**
**Сәламнәрен кем белә!! —**
**Сугыш чоры якларыннан**
**Исә бары җил генә.**

**Сибелә җилдә хәбәр булып**
**Хаттан килгән көл генә.**

Шул көлләрдә гөлләр үскәнлеге әйтелә.

Шулай итеп, бу чорда язган шигырьләрендә Хәсән Туфан тормыштагы гап-гади күренешләрне кешеләр язмышы, ил язмышы югарылыгына менгереп гомумиләштерә. Шагыйрь иҗатындагы фәлсәфилек шуннан гыйбарәт. Фәлсәфи фикер шагыйрь иҗатының буеннан-буена сузыла, чордан чорга күчеп йөри, барлык әсәрләрен кешеләр арасындагы, ил эчендәге зур гыйбрәтле язмыш турындагы поэмага оештыра.

Хәсән Туфан иҗатын бербөтен итеп күзаллау әсәрләргә аерым-аерым анализ ясаганда андагы хис һәм фикер бәйлыкларын түкми-чәчми гомумиләштерергә мөмкинлек бирә. Күптөрлелекне бөтеннең өлешләре итеп җыярга, ягъни гадәти сөйләп чыгу ысулыннан котылып, бер система рәвешендә, тәртипкә салып өйрәнергә ярдәм итә.

Шагыйрь файдаланган сурәт чаралары шулай ук фәлсәфи фикерләүгә китерүче бербөтен система эчендә гомумиләштерелә. 20—30 нчы еллар иҗатында, мәсәлән, поэтик чаралар бәяләү ысулына ярашып килә. Алар чынбарлык тудырган хисләрнең яңалыгын аерып күрсәтергә, ягъни сурәтләнгән объектларга бәя бирүгә тиешләр. Шул максат белән объектлар нәрсәгәдер охшаштырылалар, нәрсәләргәдер якынаялар, керешәләр. Шуңа күрә бу чорның төп поэтик чаралары метафора белән чагыштырулар дип әйтә алабыз.

«Кырын ятып чөлем тартып яткан Урал», «Без күршинең Алсу эсселәрен Алтын итеп өскә киярбез», дип язды Хәсән Туфан бу елларны һәм хис төсмерләрен гаять төгәл, ачык итеп сурәтли алды.

30—40 нчы елларда бәя объекты үзгәрә, хәзер ул — кешенең кичерешләре, рухи халәте. Табигать күренешләре хәзер бәяләнми, бәлки, киресенчә, тойгыга бәя бирү чарасы вазифасын үтиләр.

**Тынма, дәрья, айка, чайка:**
**Күнмәгәнмен тынлыкка.**
**Упкыннарың бирни түгел,**
**Батырма тик моңлыкка...**

**(«Тынма, давыл»).**

**Тәрәзәмне ачып куйдым,**
**Килсәнә, җил, керсәнә:**
**Кадерлемнең хәлләреннән**
**Берәр хәбәр бирсәнә!**

**(«Җилләр исә»).**

Бирелә сүз бөтенләй дәрья, җил турында бармый. Элеккеге чебек тойгылар да яңа туып килмиләр. Алар күптән туганнар хәтта табигать күренешләре белән дә каршылыкка кергәннәр. Бу чорның төп поэтик чарасын халык җырларыннан үзгә буларак, психологик параллелизмның киресе — тойгылар сыйфаты белән табигать арасындагы дисгармонияне күрсәтү дияр идек.

Язучының 60 нчы еллардан соң язган әсәрләрендә чынбарлыкның игътибарга лаеклы күренешләренә гадәти бәя бирелә һәм шунда ук алар хәтер вакыйгалары һәм тойгылары белән кабат бәяләнәләр.

**Йолдызлар да һаман шул да,**
**һәм шул ук та**
**Офыклар,—**
**О, никадәр буйга үскән**
**Халыктагы холыклар!**

— дип яза хәзер шагыйрь. Инде йолдызлар матурлыгына да, кешеләр холкына да хәтер үзенең кулын сала. Бер үк нәрсә төрле вакыт ераклыгыннан, төрле ягыннан карала. Бер үк күренеш үзе белән үзе каршылыкка килә. Бу чорның төп поэтик үзенчәлеге шуннан гыйбарәт тә.

Язучының беренче чор иҗатына метафорик фикерләү хас, дидек. Инде игътибарны шагыйрьнең икенче төркем әсәрләрендәге хисләрнең тирәнлеген, көчлеген сурәтләү чараларына юнәлтик.

40—50 нче елларда язылган шигырьләрдә лирик геройның рухи халәте гаять дәрәҗәдә киеренке. Хис күптән туган, аның көче кимемәгән, даими кичерешкә әйләнгән. Әсәрләрдә бу даимилек үзенчәлекле юл белән күрсәтелә. Кичерешләрме ул, вакыйгамы, уйлануларны — Хәсән Туфан әсәрләрендә барыбер күптән туган, сузылган рәвешендә килә. Хәсән Туфан нәрсәнедер башлап нәтиҗәгә килми, бәлки нәтиҗәдән башлый. Аның сурәте шул сәбәпле алга таба фикерләү белән түгел, бәлки кире якка кайту, чорналган йомгак-сурәтне сүтү юлы белән ачыла.

Берничә мисал китерик. «Вәссәлам» шигырендә солдат атака тынган арада сөйгәненә хат яза. Хатта сагыну хисләре болай белдерелә:

**Карыймсың айларга син,**
**Сорыймсың: «Кайларда син!**
**Иң авыр шартлардамы**
**Бу канлы айларда син!**
**Каныңны койдың микән,**
**Аңыңны җуйдың микән!**
**Яраңны доктормы соң,**
**Яңгырмы юды икән!»**

Бирелә күптән уйланган уйлар, кичерелгән сагынулар икәнлеген исбат итүнең кирәге юк. Хат — шул уй-кичерешләрне хәбәр итү өчен генә.

«Илдә нилэр бар икән» шигырендәге:

**Тышта нилэр бар икән:**
**Юллар зәңгәр кар микән!**
**Боз тәрәзә алсулана,**
**Пожар микән, таң микән!**
**Тышта нилэр бар икән!**

— юлларының мәгънәсен кирегә, фикер-уйларның башына таба чигенмичә, гомумән, аңлап булмый. Лирик геройның рухи халәте дә, физик халәте дә, бу халәтләрнең дәвамлылыгы да шигырьнең язылмаган, ләкин нәтиҗәдән күзаллана торган өлешендә калдырылган.

**Кайсыгызның кулы җылы**
**Бәйлисе бар йөрәкне,**

— дип яза Хәсән Туфан. Бу сурәткә тыгызлап тутырылган тойгы һәм мәгънә бәйләнешләрен шулай ук алдагы, язылмаган өлешләрдән генә абайларга мөмкин: сагыну көчле — ул хәсрәткә әйләнгән — хәсрәт йөрәк яндыра — озак янган йөрәк — яралы йөрәк — ярасы төзәтү өчен бәйләргә кирәк — бәйләү өчен дуслар, якыннар, сак, аңлаучы кешеләр кирәк.

Хәсән Туфанның лирик герое тыштан сабыр кеше. Ул уйласын күптән уйлаган, кичерәсен күптән кичергән. Шундый рухи халәт дәрәҗәсен нәтиҗә аша — хисләрнең янып «тынган» вакытын сабыр сурәтләп, автор шигыренең башында ук укучыда шомлы сагаю тудыра. Лирик геройның тынычлыгы соңга таба битарафлык, гамьсезлек түгеллеген, бәлки түземлек, сабырлык икәнлеген беләсең. Сабырлык бәясен язучы үзе тапкан һәм бик яратып куллана торган башка ысул белән ача.

«Илдә нилэр бар икән» шигыренең дәвамын искә төшерик:

...Инде ул да торгандыр,
Бергә чаклар исенә төшеп,
Күңелләре тулгандыр...

Менә «ул» зәңгәр карны ера-ера, әллә кайтыр, дип, вокзалларга килгәндәр, хәсрәтләрен таратырга тәмәкесе бар микән, дип кайгыргандыр. Шагыйрь әсәренең башыннан ахырынача «аның» турында яза. Ләкин шигырь аның турында түгел, бәлки лирик геройның үз уй-кичерешләре эчтәлегеннән гыйбарәт. Лирик герой сагына. Якын кешесе белән күптән күрешмәгәнгә тилмерә. Сагыну дәрәҗәсен гадәттә шул еракгагы үз кешенең яхшы сыйфатларын күпләп сөйләү, яки арттыру исәбенә күтәрәләр: сагынучы бик якын, бик чибәр, аны күрмәгәнгә күп еллар һ. б. Бу ысул белән тойгыларның туган, ярсыган вакытын сурәтлиләр. Шуның өчен ул Туфанның башлангыч иҗаты өчен генә хас була ала. Хәзер сурәт — нәтиҗәсендә шагыйрь сагынуын язу белән генә чикләнми. Ул сагынган кешесенең үзе сагынуын, борчылганын, хәсрәтләнгәнен яза. Ерактагы үз кешесенең сагынуы өчен борчыла, аның сагыну хәсрәтеннән хәсрәтләнә. «Вәссәлам» шигырендәге солдат хатын искә төшерик: айларга карап илеругә, ярасын кемнәр юды икән, дип кайгыручы хатын-кыз да — солдат сагынуының катлаулы эчтәлеге. Язучы сагынуның тагын бер дәрәҗәсенә күтәрелә. Сагыну тойгысы хәзер сагынучы кешенең тойгылары белән дә яраша. Кичерешләр тирәнлеген сурәтләүче бу алым алда күреп үткән «нәтиҗә» алымы белән янәшә яши, сагынуның соң дәрәҗәсеннән башлавын искә алып, аның үзен дә «нәтиҗә» алымына кертергә мөмкин. Икенче яктан, сагынуның беренче дәрәҗәсен башлангыч иҗатында калдырып, бу алым ике чорның үзара дәвамлы бәйләнешен дә бик яхшы күрсәтә.

«Нәтиҗә» алымының тагын бер конкрет күренеше итеп, әсәрләрдә сурәтләнгән вакыйгаларның урта өлешен төшереп капма-каршы якларын янәшә куюны күрсәтергә була.

— Кайт! — дип хатлар килделәр...
Юллар озын иделәр...
Кайттым.
— Бусы алкалары,
Бусы — кабере...— диделәр.

(«Кайсыгызның кулы җылы!»).

Бу мисалдан күренгәнчә, «алкалар» белән «кабер» гадәти антитеза итеп кенә карала алмый. Антитеза башлыча фикер уйнату өчен кулланыла, нәрсәнеңдер каршылыклы асылын ачарга, аңарга төрле яктан карарга ярдәм итә. Алка белән кабер янәшәлеге — кеше язмышының каршылыклы якларын күрсәтәләр. Матур яшьлек белән үлем фәлсәфи бердәйлеккә һәм каршылыкка куела. Ләкин бу очракта алка таныш бизәк булуы белән истәлекләр уята, кабер нәтиҗәсеннән кирегә кайту юлын күрсәтә, хәтер хисләрен кузгатып югалтуның авырлыгын көчәйтә.

«Бу соңгы таңы аның» шигырендә Хәсән Туфан соңгы таңын үткәрүче егет хисләре белән сандугач сайравын янәшә куя. Яшәү, сөю җырчысы Сандугач егетнең авыр хисләрен бүлдерә, тормыш белән бәхилләшергә комачаулый. Егетнең хәсрәтле тойгылары сандугач тавышына кинәт бүленәләр дә, ялваруга әйләнеп сандугачка юнәләләр:

Бу соңгы таңы аның,
Сандугач сайрый тагын...

Ни була сайрамаса!..
Яңрата әрәмәне.
Ялсана тәрәзәне...

Егетнең соңгы теләге аңлашыла:

«Кил, әни, элекке күк,
Йокысыз күземне үп.
Арала килеп җаным:
Сандугач сайрый тагын...»

Соңгы юл да — егет сүзләре. Ул хисләрен тормыш матурлыгына ияртергә тырышучы сандугачка соңгы мәртәбә ачына. Үлем турында уйларга комачаулаучы сандугачка ачыну хисе — Хәсән Туфанның кичерешне гаять югары дәрәҗәдә сурәтләве түгелмени!

Алка белән кабер, сандугач белән үлем, уен белән югалту, сугыш елларында һәлак булган кешеләрнең сәлам хатлары кулендә үскән аллы-гөлле чәчәкләр... Җил дә, таллар да, яңгыр да, кыш та, каеннар да, тургайлар да 40—50 нче елларда иҗат ителгән әсәрләрдә, кагыйдә буларак, кешенең рухи халәтенә каршы куеләлар.

Хәсән Туфан кешенең рухи халәтендәге өзелергә җиткән, ләкин күпме генә

тартылса да өзелмәгән киеренкелекне сурәтләрлек поэтик алымнар тапкан. Лирик геройның туган якларын, сөйгән ярын, дусларын сагынуы көчәйгән саен аның мәхәббәте зурлыгына, мәңгелегенә инанасың. Хисләр тирәнлеге аша ачылган рухи нык-лык, туган илгә мәхәббәт шагыйрьнең фәлсәфи фикерләве асылда шуңа нигезләнә.

Багышлау рәвешендәге әсәрләрен санамаганда, Хәсән Туфан фактик материалны бәян итүдән качарга омтыла. Шуңа күрә бу шигырьләргә укучы үз язмышын фактик материал итеп сала ала. Күңелендә үкенечләре, сагыну тойгылары сакланмаган кеше буламыни! Кешегә ышаныч, кеше ныклыгына, тугрылыгына горурлану, идеясен Хәсән Туфан укучыларның үз рухи хәзинәләре аша кабул итүенә ирешә.

Ә бит татар халык җырларының системасы да шундый үзенчәлеккә ия. Димәк, халык иҗаты традицияләрен файдалану турында сүз алып барганда, тышкы охшашлыкны күрсәтү белән чикләнеп булмый икән. Ләкин халык җырлары белән Туфан шигырьләренең эчке уртаклыгы, рухи кардәшлеге уртак функциясе барлыгын расладык исә, бу шигырьләрнең дә җырлар кебек гомерле булуын алдан әйтергә нигез табабыз.

Хәсән Туфанның иҗаты зур, катлаулы һәм самими. Халкыбызның бай тарихы лирик герой кичерешләре белән үрелеп, аның нигезе, сәбәбе, сыйфаты рәвешендә шагыйрь иҗатының үзәгендә ята. Бу иҗатта әдәбиятыбызның үсеш тарихы да, аның поэтик байлыгы да бик ачык чагылыш тапкан. Хәсән Туфан иҗаты һичшиксез фәнни нигездә ныклап өйрәнеләчәк. Хәсән Туфан иҗатына җылы куллы бик нәзакәтле, ихтирамлы, сак кешеләр генә мөрәҗәгать итсә иде...

## Рөстәм Кутуй

### Аккош күлендә

...Өлкәнлеге дә, җыры да тик үзенеке,
Ап-ак күбекле чәчләре, чал болыт төсле.

Өендә — песнәк баласы, — уенда торна...
Дөньяда җылы җилләр дә искәләп тора.
Шифалы җир үләннәре, исле үрмәгәл
Айга юл алган шикелле күккә менәдер.
Ап-ак болдырда утыра ак кәгазь кебек.
Ак кәгазьгә сыерчыклар җыр яза кебек.
Алар җырга җим ташыйдыр туган җиреннән,
Шуңа да Туфан мәркәзе җырга күмелгән.
...Аккош күлендә аккош юк. Тик казлар гына.
Алып килә кылдан нечкә авазлар гына.
Кылдай нечкә бу авазлар кылычтай үткен,
Көндәлек борчылуларны өзәләр бер көн.
Кисәләр дә чүп үләнен — калкына гөлләр...
...Җәй уртасы, җиләкле дә, эссе дә көннәр.
Күпме баскычлар менелгән, я санап кара!
Кайда калды сабанга да абынган бала?
Кайда калды Такташлы чор, ялкынлы вакыт?
Беркөн шушы юксынуны, бушлыкны ватып,
Килеп керер үзе кебек Такташлы яшьләр,
Шулар аша гомереңнең дәвамы яшәр.

МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ тәрҗемәсе.

# САЛИХ СӘЙДӘШЕВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Земфира Сәйдәшева

# ҖЫР БИШЕГЕ ЯНЫНДА

Татар профессиональ җырының туу һәм киң таралу тарихы драма театрлары үсеше белән бик нык бәйләнгән. Революциягә кадәр театрда җыр бары күңел ачу өчен генә хезмәт иткән — антрактларда яки тамаша беткәннән соң гына башкарылган. Ә 1917 елдан соң инде ул спектакльнең тукымасына махсус кертелә башлый. Бу юнәлештә татар музыка мәгърифәтчесе һәм композитор Солтан Габәшинең эшен зурлап билгеләп үтәргә кирәк. Спектакльләргә ул язган җырлар каһарманнарның уй-хисләрен, холык-фигыльләрен ачу чарасы булып хезмәт итә. Әмма халык арасында Габәши җырлары киң таралып китә алмый. Алар хосусан театр музыкасы булып калдылар. Ә көндәлек күмәк татар совет җырына нигез салучы дип хаклы рәвештә Салих Сәйдәшев исәпләнә. Ул беренче булып совет заманасы рухына туры килгән, татар халкының яңа хисләрен чагылдырган, аның тормышында һәм көнелендә гаять зур борылышны тасвирлаган җырлар иҗат итте.

Салих Сәйдәшевның беренче җырлары музыкаль теле белән үк бөтенләй яңача иде. Ул бик күп елларга татар совет җырының интонацион юнәлешен билгеләде, үзеннән соң килгән композиторларның җыр иҗатына бик зур йогынты ясады. Егерменче елларда Салих Сәйдәшев иҗатына хас булган интонацияләр һәм жанрлар озак еллар дәвамында (кайберләре безнең көннәргә кадәр) татар җырында өстенлек итеп килде. Композитор, беренче буларак, халык авыз иҗаты традицияләренә генә түгел, татар музыкасы өчен бөтенләй яңа өлкә булган рус революцион җыры (ә аннары совет күмәк җыры) үзенчәлекләренә дә таяна.

Бу күренеш гражданнар сугышы чорындагы халык җырларына да хас: борынгы татар көйләре (күбесенчә, кыска көйләр) яңа сүзләр белән җырланып, төгәл марш хәрәкәтенә буйсыналар, нәтиҗәдә безнең җырларда әлегәчә ишетелмәгән дәртле яңгыраш белән тулыланалар.

Хәлбуки, С. Сайдәшев үзенең иң яхшы әсәрләренә революцион гимннарның марш төгәллеген генә түгел, ә үзенә генә хас көй-интонация һәм ритм шәкелләрен дә кабул итә, аларны халык көй элементлары белән куша.

Бер очракта ул, татар җырларының бөтен көй үзенчәлекләрен (төгәл пентатоника, көй хәрәкәтенең сыгылмалылыгын, секвенцияләрнең күплеген, гадәти кадансны) саклаган хәлдә аларны пунктирлы марш ритмы белән сугара. Шунлыктан бу җырлар бөтенләй яңа төс алалар, аларга гайрәт-дәрт өстәлә. Икенче очракта исә революцион марш һәм гимн элементлары белән җырларның моңы да баетыла. Моны кәйнең кискен талпынуларында һәм өндәү рухындагы кыска, төгәл тәгъбирләрдән күрергә мөмкин. Мисал итеп, Г. Кутуйның «Күк күгәрчен» пьесасындагы «Студентлар җырын» китерергә мөмкин.

Бу җырда бик әсәрле һәм хәтта бераз самими төстә студент хисләре сурәтләнә. Аның көе динамикалы, гайрәтле. Бер-ике тактлык кына, кыска, өзек-өзек тәгъбирләр, бәрәгәйле «фанфаралы» сикерешләр, пунктирлы ритм. Ә кыю һәм катгый характердагы интонацияләре булган кушымта өлешендә аерым тәгъбирләрне һәм авазларны кабатлау ярдәмендә максатчанлык тойгысы белдерелә. Композитор яшьләрнең омтылышларын, үз максатларына ирешүдәге ныклыкларын әнә шулай сурәтли.



Бу җыр сугыштан соңгы чорда да популяр булып калды. Ул инде «Совет яшьләре җыры» дип Ә. Исхак сүзләренә җырлана башлады.

С. Сәйдәшевның мәхәббәт темасына язылган лирик җырлары да яратып җырлана, телдән төшми. Аларда әлеге теманы ике төрле аңлату күренә. Бериш җырларда күбесенчә сагыш-кайгы, назлы үйланулар өскә калыкса, икенчеләрендә якты һәм сөенечле, бәхетле мәхәббәт сурәтләнә. Һәр ике очракта да бу җырларның рухы татар халык лирикасыннан аерылмый.

Халык җыр иҗатына хас сыйфатларны файдаланганда да композитор татар җырларында булмаган күп яңалыклар кертә — пентатониканы диатоник элементлар белән баета, гадәти куплет-период кысаларын киңәйтә һ. б.

С. Сәйдәшевның беренче җырлары ук үзенә генә хас көйгә ия. Шул ук вакытта, аларның фольклорга якынлыгы да бәхәссез (гәрчә халык көйләренә тәңгәл килгән интонацияләре булмаса да). Бу якынлык иң элек татар халык җырларыннан килә торган түбән төшүче секвенцияләр белән бәйле.

Композиторның секвенцияләр белән мавыгуы ул вакытта ук хаклы тәнкыйть ителде. Әмма әлеге алым моңның табигый агышын үстереп, җырның истә калуына ярдәм итә.

Бу җырларның яңалыгы, оригинальлеге — интонацияләрендә. Моңнары белән алар халык көйләреннән генә түгел, башка композиторларның әсәрләреннән дә аерылып тора. Аеруча «Сәйдәш моңы» дип кенә атарга мөмкин булган интонация зур роль уйный. Чөнки ул композиторның соңгырак чор җырларында да очрый. «Сәйдәш моңы»ның нигезендә тәфсилләп, йөрәккә ятышлы итеп нинди дә булса берәр авазны уйнау ята. Беренче җырларыннан алып соңгы җырларына кадәр шушы алым төрле вариантларда файдаланыла. Ритмик һәм интонацион яктан үсеп-үзгәреп, ул кайбер җырларда моңның төп өлешен тәшкил итә.

С. Сәйдәшевның новаторлык чалымнары, бер яктан, татар халык җырларының стиль нигезләренә кыю үзгәрешләр кертүдә һәм, икенче яктан, татар моңнарындагы интонация үзенчәлекләрен яңа жанр элементлары белән кушуда чагыла.

Утызынчы еллар республикабыз музыкаль культурасы тарихына профессиональ иҗатның чәчәк ату чоры булып керде. Уңыш белән барган беренче татар опералары, беренче симфоник һәм хор өчен язылган әсәрләр барлыкка килә. Татар совет җыры да үсешенең яңа чорына керә. 1932—1941 елларда С. Сәйдәшев иҗаты чын мәгънәсендә чәчәк ата. Бу өлкәдә яшь композиторлар Н. Җиһанов, М. Мозаффаров, Җ. Фәйзи, Л. Хәмиди, З. Хәбибуллин, Ф. Яруллин һ. б. лар эшли башлый.

Иҗат көчләренең үсүе һәм мөстәкыйль (ягъни театрга бәйләнеше булмаган) җырларның тууы аркасында Татарстанның җыр сәнгате яңа тормышчан темалар һәм образлар белән баеды.

Хәзер инде татар композиторлары җыр жанрына кыюрак мөрәҗәгать итә башлыйлар. Индивидуаль иҗат стильләренең төрлелеге турында сөйләргә мөмкинлек туа. Менә шул шартларда С. Сәйдәшев иҗаты аеруча нык аерылып тора. Ул үз чорына хас чалымнарны сурәтләде, яшьлек, күтәренке рух, яңа тормыш җырчысы булып китте.

Сәйдәшев егерменче елларда файдаланган җыр жанрлары һәм интонацион чыганаклар соңгырак чор татар совет җыры өчен дә нигез булып тора. Әйтик, халык җыр лирикасына хас сыйфатлар композиторларның күбесенчә мәхәббәткә, туган як табигатенә багышланган әсәрләрендә чагыла. Ә яңа темаларны (Совет Ватанын зурлау, бәхетле тормыш, яшьләр, азат хезмәт һ. б.) гәүдәләндергәндә композиторлар (Сәйдәшев үрнәгендә) татар музыкасы өчен яңа булган жанрларга (марш-җыр һәм вальсларга) мөрәҗәгать иттеләр.

Әйе, интонацион чыганакларга якын килү, аларны үзләштерү һәм баету юллары нык үзгәрде. Татар совет җырына яңа стилистик элементлар — революцион гимннар

гына түгел, 20 нче еллардагы яшьләр җырлары, рус көнкүреш лирикасы, романс, җиңел музыка үтеп керә башлады. Боларның барысы да татар җырларының интонацион төзелешен шактый баетты.

1932—1941 елларда С. Сәйдәшевның җыр иҗаты яңа куәт алды. Бу хәл лирик җырларга караганда, яшьләр марш-җырларында ныграк чагылды. Мисалга К. Тинчуринның «Кандыр буенда» спектаклендәге «Монтер җыры»н алыйк. Аның каһарманнары күп яклары белән «Студентлар җыры»ндагылардан нык аерылалар. «Студентлар җыры»ның дәртле һәм романтик яңгырашы «Монтер җыры»нда тормышка яшьләрчә сөенү, үз көченә ышаныч белән алмашына.

Бу җыр күп яклары белән И. Дунаевский маршларына охшаш. Җегәрле, декламация рухындагы фразалар сузынкы (вакыты белән бер иҗеккә дүрт авазга чаклы) гыйбарәләр аралашуы аңа үзенчәлекле төсмер бирә. Җитез башкарганда алар күңелле, хәтта уенчаграк булып та яңгырыйлар. Җырның икенче яртысында көй фразалары тагын да кыскаралар һәм ахырда «Үсәбез! Үсәбез! Үсәбез!» дигәндәге ачык төгәл эндәшләргә әвереләләр. И. Дунаевскийның «Спорт маршы»нда, «Күңелле егетләр» маршында шундый ук алымнар кулланылуы мәгълүм. Әмма әлеге җыр һич тә И. Дунаевский стилен үзләштерү нәтиҗәсендә язылмаган, чөнки ул 1932 елда — «Күңелле егетләр» кинофильмындагы марштан ике ел алданрак иҗат ителгән.

С. Сәйдәшев нинди чыганакларга нигезләнеп иҗат итә соң? Җырның көендә гадәти бормаларның саклануы, ритмиканың тере, хәрәкәтчән булуына игътибар итик. Икенче яктан, марштагы сыман омтылышлы темп, уенчак эндәшүләр, «Эх!» дип күңелле итеп кычкырып куюлар, ачык оптимизм (мажорлык күренешләре) да татар шәһәр җитез җырлары белән 20 нче еллар рус яшьләр җырлары («Мы — кузнецы», «Наш паровоз» һ. б.) стиле элементларының кушылуы хакында сөйли. Шундый аралашу татар совет җырында яңа күңелле марш жанры тууга китерде.

С. Сәйдәшевның шул ук спектакльгә язган «Фәридә җыры» да утызынчы еллар җыр иҗатында гаять кызыклы күренеш булып тора.

Көйнең моңында кабатланулар белән гармонияләнеп килә торган хроматизм элементлары, җырның яңгырашына күңеллелек бирә торган көчле колоратуралар — болар барысы да С. Сәйдәшевка оперетта стиле якын булуын күрсәтә. Алар, «шәһәрчә җитез» җырларга һәм 20 нче еллар яшьләр маршларына хас үзенчәлекләр белән бергә кушылып, гади марш кына түгел, шатлыклы-сөенечле концерт маршы тууга китерделәр.

Утызынчы еллар татар җырындагы яңа хасиятләр эчтәлектә генә калмыйча, музыка телендә дә чагылыш таптылар. С. Сәйдәшев тарафыннан кертелгән яңа лад формасы көннән-көн ныграк таныла һәм мөстәкыйльлек яулап ала башлый: ул — кереш тоны булган зур терцияле пентатоника. Бу лад җырда күтәренке хисләрне сурәтләү өчен бик кулай. Ул С. Сәйдәшевның оптимистик, күтәренке рухлы яшьләр маршларының нигезендә ята. Әгәр ул утызынчы елларда бер С. Сәйдәшевның гына игътибарын җәлеп иткән булса, сугыштан соңгы чорда бөтен татар композиторлары иҗатында да зур урын алды.

Утызынчы еллар җырларының төп үзенчәлеге — аларның төгәл көй секвенцияләре «әсирлеге»ннән тәмам диярлек азат булулары. Ул ритмикага да уңай йогынты ясап, андагы механик кабатлауларны юкка чыгарды.

Бу чорда язылган җырларның күпчелегендә татар композиторлары теге яки бу жанр чыганагы ритмнарыннан һич тә читләшмәскә тырышалар. Әйтик, рус революцион маршындагы «пунктир» татар марш җырларына да хас, ә гадәти көйләрнең үзенчәлеге булган асимметрик ритмика лирик җырларның нигезендә ята. Әмма инде композиторларның тулысынча халык иҗатына гына ияреү белән канәгать булмауларын, гадәт кысаларыннан чыгарга омтылуларын тоясың.

Әлеге хәл Салих Сәйдәшев иҗатында 20 нче елларда ук күзгә ташлана. Әйтик, Т. Гыйззәтнең «Наемщик» драмасындагы Батыржан ариясенә ул, татар җыр фольклорына хас җөп үлчәүне саклаган хәлдә, вальска тартым ритмнар кертә. Бу юнәлештә композитор утызынчы елларда тагын да активрак эшли. Такмакларга нигезләнгән «Эх, күңелле өмәсе!» җырында синкопа дигән яңа элемент урын ала.

Шунысы кызык, 20 нче елларда татар совет җырына төгәл пунктирланган революцион марш ритмын үзе керткән булса да, 30 нчы елларда Салих Сәйдәшев аны «саф килеш» файдаланудан баш тарта. Чөнки ул вакытта инде башка композиторлар, шушы ритмны бик еш кулланып, таушалган өлге, штамп хәленә китерәләр. Шуңа күрә Сәйдәшев марш ритмын җитез шәһәр җырлары ритмикасы белән бергә куша. Иң яхшы марш-җырларында башка авторлар да аның үрнәгенә иярәләр.

Бөек Ватан сугышы еллары музыкага яңа темалар һәм настроениеләр алып килә. Б[illegible] һәм шатлык җырчысы Салих Сәйдәшев өчен иҗат торгынлыгы башлана. (Рус [illegible] җыр сәнгатендә И. Дунаевский да шундый ук хәләтне кичерә.) Сугышның беренче елында гына аның тарафыннан Кави Нәҗми сүзләренә «Поход җыры» языла, әмма ул да яңа текст белән шатлыклы җиңү көннәрендә генә яңгырый.

Сугыштан соң җырчы композитор буларак, Салих Сәйдәшев әйтерсең лә яңадан т[illegible]. Сәйдәшев иҗатының бу чорында яңа үзенчәлек хасил була: ул театр белән бәйләнмәгән, мөстәкыйль җырлар яза. (Мәсәлән, Г. Хуҗи сүзләренә — «Халисә» дигән лирик җыр, яшьләр җырларыннан М. Садри сүзләренә — «Яшьлек җыры»,

Ә. Ерикәй сүзләренә — «Дуслык җыры» һ. б.) Образлары, стилистикасы ягыннан алар композиторның 30 нчы елларда язылган җырларына якын торалар.

С. Сәйдәшев үзе яраткан юнәлештә эшләвен — драматик спектакльләргә музыка язуын да дәвам иттерә. Бу елларда халыкка яңа җырлар бүләк иткән пьесалар (Т. Гыйззәтнең «Чын мәхәббәт»е, Н. Исәнбәтнең «Мулланур Вахитов»ы, Г. Насрыйның «Кадерле минутлар»ы һ. б.) зур уңыш белән бара.

Салих Сәйдәшевның иҗат юлы халыкка хезмәт итүнең гүзәл мисалы булып тора. Патриот-шагыйрь Муса Җәлил сүзләренә язылган «Җырларым» дигән соңгы әсәре композитор иҗатының көчле аккорды булып яңгырады.

Соңгы елларда татар совет җыры тагын да үсте, камилләште, баеды. Безнең көннәрдә җыр жанрында барлык татар композиторлары да иҗат итә дияргә мөмкин. Һәм бу өлкәдә аларның һәркайсының Сәйдәшевныкыннан аерылып торган юлы бар. Әмма татар профессиональ көй сәнгатенә нигез салган композиторның тиңдәшсез иҗаты һәм традицияләре яңа буыннар күңелендә яши һәм халкыбызның музыкаль культурасын баетуда катнаша.

# Фәридә Салитова

## ЧОРГА АВАЗДАШ

Татар халкының рухи культурасын үстерүгә Салих Сәйдәшев керткән өлешне бәяләп бетерүе кыен. Аның әсәрләре яңадан-яңа буыннарның күңелендә яши. Халык күңелен Сәйдәшев кебек тиз яулап алырга сәләтле сәнгатькярләр сирәк очрый.

С. Сәйдәшев иҗатының чәчәк атуы, зур талантының тулысынча ачылуы Бөек Октябрь социалистик революциясе җиңүе белән башланган яңа бер тарихи чорга туры килә. Бу чор, тугандаш гаиләдәге башка милләтләр белән бергә, татар халкының да социалистик эчтәлекле, милли бизәкле мәдәниятенә тарихта моңарчы күрелмәгән үсеш мөмкинлекләре тудыра. Бу чорда заманының алдынгы идеяләрен гәүдәләндергән бик күп талант ияләре мәйданга килә. Алар яңа, социалистик культураның беренче нигез ташларын салуда катнашалар.

Салих Сәйдәшевның иҗат юлы совет музыка сәнгатендә барган менә шушы үсешүзгәреш, яңару хәрәкәте белән тыгыз бәйләнгән. Казандагы Коммунистик клубта музыкаль-культура чаралары үткәрүне җайга салышкан, Буада үзешчән коллективлар оештырган, кызылармиячеләр өчен концертлар куеп йөргән чакларында ук яшь композиторның иҗат принциплары формалаша башлый. Аның музыкасы халыкны яңа тормыш тантанасы өчен көрәшкә өнди, илне индустрияләштерү һәм авыл хуҗалыгын күмәкләштерү фронтларында җиңеп чыгуга рухландыра. «Без кабызган утлар», «Совет яшьләре җыры» кебек әсәрләрдә шул заман геройларының шигъри эчке дөньясы, тормыш сөючәнлеге бик ачык чагыла.

20—30 нчы елларда С. Сәйдәшев музыкасы белән куелган һәр спектакль республиканың культура тормышында зур вакыйгага әверелә. Моңа композитор һәр әсәренең халык иҗаты белән тыгыз бәйләнештәге музыкаль эчтәлеге, мөһим һәм актуаль темага язылган булуы, сәнгатьчә югары эшләнеше белән ирешә.

Чор кайтавазы булган «Наемщик» музыкаль драмасын гына алыйк. Гади халыкның рухы, көнкүреше аңа гына хас җыр-биюләр аша ачылса, өстен катлауларның тормышы да үзенчәлекле музыкаль сыйфатламасы белән аерылып тора. Гомумән, милли драматургия әсәрләренә язган көйләрендә композитор халкыбызның үткән тормышын реалистик сурәтләү юлына баса. Бу музыканың халыкчан асылы — үз вакыты өчен гади һәм аңлаешлы да, музыка сәнгатенең опера һәм балет кебек жанрларын татар тамашачысына якынайтырлык дәрәҗәдә катлаулы да булуында.

Яңа заманның революцион сулышы халык иҗаты ялкынын да көчлерәк дөрләтеп җибәрә. «Күзгә ачы җилләрдә», «Ком бураны», «Уракчы кыз» кебек җырлардан ук күренгәнчә, халык иҗатына яңа темалар, образлар килеп керә, һәм алар, үз чиратында яңа жанрлар, яңа интонацияләр таләп итә. Менә шул тамырдан яңару процессы — бер яктан, халык иҗат иткән яңа көйләрнең, революцион җырларның турыдан-туры йогынтысы — икенче яктан, Сәйдәшев музыкасына үзенчәлекле төс бирә.

Композитор иҗатының үзәгеннән замандаш күңелендәге хисләрне, аның дөньяга карашын һәм холык-фигыль рәвешен, рухи көчен сурәтләү проблемасы үтә. Ул яңа

эчтәлеккә тиң күтәренке, дәртле ачык яңгырашлы көйләр яза. С. Сәйдәшев тарафыннан иҗат ителгән беренче җыр-маршлар татар музыкасын моңарчы ишетелмәгән ритмнар һәм аһәңнәр белән баета.



Салих Сәйдәшев иҗаты татар сәнгатенең социалистик реализм методы белән кораллануына зур өлеш кертә. Композиторның көн кадагына сугып, актуаль вакыйгалар уңаеннан язылган әсәрләре дә чор куйган идея-политик һәм эстетик таләпләргә туры килә, халыкның сәнгатькә омтылыш-ихтыяҗына җавап бирә. Кызыл Армия төзелүнең 11 еллыгына багышланган атаклы марш, Кәрим Тинчуринның «Кандыр буе» пьесасына иҗат ителгән музыка нәкъ әнә шундыйлардан. Беренче тапкыр күтәрелгән темалары белән үк игътибарга лаеклы, яңа заман кешеләренең кабатланмас музыкаль образларын тудырган бу әсәрләр озын гомерле булды. С. Сәйдәшев иҗатының реалистик асылы һәм гуманистик юнәлеше, социалистик Ватаныбызның зур художникларына хас булганча, чынбарлыкны дөрес чагылдыру, кешеләрне сәнгатьнең илаһи көче белән тәрбияләү һәм берләштерү сыйфатларына ия булуында күренде. Җөмләдән шуны да әйтергә кирәк: татар композиторының һәр әсәре нигезендә яткан әлеге үзенчәлек үзе генә дә буржуаз идеологларның, янәсе, музыка сәнгате сыйныфлардан бәйсез яши, ул аерым идеяләрне гәүдәләндерә алмый, дигән уйдырмаларын юкка чыгарырга сәләтле.

С. Сәйдәшевның заман тематикасы белән кызыксынуы һич тә очраклы хәл түгел, бәлки аның бөтен иҗатына хас, табигый бер хасият. Композитор яңа социалистик культураны тудыру өлкәсендәге катлаулы мәсьәләләрне хәл итүдә җиң сызганып катнаша. Ул татар музыкасының язмышын кайгырта, җыр-көй сәнгатебезнең киләчәген яңадан-яңа чаралар белән баеган хәлдә, совет музыка үсешенең үзәк юнәлешләрендә күрә. Композиторның халык алдында һәм матбугатта ясаган чыгышлары, балаларга һәм яшьләргә багышлап язган күп санлы җырлары әнә шул хакта сөйли. Сәйдәшев музыкаль культура казанышларын меңнәрчә кешеләрнең уртак хәзинәсенә әверелдерү өчен иң дөрес юлны таба — революцион яңарыш чорына авазодаш, халкы күңеленә хуш килерлек көйләр иҗат итә.

С. Сәйдәшев иҗаты халыкчан моңы, тирән лиризмы белән аерылып тора, бу музыканы тыңлаганда без тойгы-настроениеләрнең гаҗәеп эзлекле күчешенә — нечкә-нәфис хисләрдән алып кайнар гражданлык пафосы белән сугарылган образларга кадәр үсешенә тап булабыз. Үзенең шәхси кичерешләре ачылган лирик әсәрләрендә дә композитор субъективлыкка урын калдырмый, социалистик реализм юлыннан читкә тайпылмый, чын демократизм һәм халыкчанлык принципларын тормышка ашыра. Сәйдәшевның халыкчанлыгы милли музыкадагы эчке мөмкинлекләрне үстерү һәм аны яңа сәнгать чаралары белән баетуда күренә. Аның музыкасы халык иҗатыннан ук килә торган һәм шул ук вакытта мөстәкыйль, бик үзенчәлекле фикерләү рәвеше белән аерылып тора. Композитор иҗатында төп урынны биләгән җыр-көй башлангычы, андагы реалистик эчтәлек һәм халыкчан моң киң милли аудиторияне хәзерге заман музыкасына якынайтуга гаять әһәмиятле өлеш кертте.

Салих Сәйдәшев өчен халыкчанлык принцибы һәм милли форма тар этнографик кысалар белән генә чикләнми. Әлеге төшенчәләрне ул киңрәк мәгънәдә аңлый. Әсәрләрнең прогрессив идея юнәлгәнлеге һәм ачык гражданлыгы, халык көйләрендәге сурәтлелектән иҗади файдалану милли музыкага башка халыкларның культура хәзинәсе белән якынаю мөмкинлеге ача, дип саный композитор. Үз иҗатында ул татар мәдәниятенең уңай традицияләре җирлегендә дөнья сәнгатендәге демократик күренешләрне тамырландыруга ирешә. Бу юнәлештә С. Сәйдәшев классик композиторларның иҗат принципларын үзләштерде һәм үстерде.

Бүген, җәмгыять тормышында сәнгать көннән-көн зуррак урын ала барган заманда, халыкка мәдәният чишмәләренең юлын күрсәтешкән шәхесләрне без аерым бер хөрмәт белән искә алабыз. Аларның иҗаты һәм дөньяга карашлары бәһаләп бетергесез тарихи әһәмияткә ия.

Салих Сәйдәшев — әнә шул рәвешле, гомуми культура үсеше, халыкның рухи ихтыяҗлары тәэсирендә чор үзе тудырган художник. Ул тормышта һәм сәнгатьтә барган бөек үзгәрешләр дулкынында, шул үзгәрешләр турында җырлап мәйданга килә. Үзенең иҗаты белән композитор чын кешелеклелек, социалистик гуманизм принциплары җиңүе өчен көрәшнең алгы сафына баса.

Чор һәм талант үзенчәлеге Сәйдәшев көйләренең яңа образлары һәм ачык, ты-

гыз ритмнарында, яңа темалары һәм дәртле-динамик яңгырашында чагылды. Әлеге художество-эстетик сыйфатлар соңыннан татар совет музыкасының асыл билгеләренә әверелделәр.

Композитор мирасы замандаш музыкантларыбыз өчен осталыкка өйрәнү мәктәбе, яңа уйланулар һәм эзләнүләргә җирлек булып тора. Аның үткән гомер юлы, кабатланмас шәхесе — тормышка һәм музыкага чиксез мәхәббәт, халыкка риясыз хезмәт итү үрнәге. Беренче тапкыр Сәйдәшев әсәрләрендә чагылыш тапкан идеяләр, фикерләр, омтылыш-теләкләр һәм иҗади табышлар хәзерге татар сәнгате казанышларында тормышка аша.

# Әнвәр Бакиров

# СОҢГЫ ОЧРАШУ

## ИСТӘЛЕК

Халкыбызның бөек улы Салих Сәйдәшев белән якыннан таныш булуым белән мин бик бәхетле. 1937—38 нче елларда мин аның җитәкчелегендәге Татар дәүләт академия театры оркестрында скрипкада уйнадым. Минем Хәмит абыем курайда, кубызда һәм башка музыка коралларында уйнаганлыктан, алар Салих ага Сәйдәшев белән безнең өйдә дә очраша торган иделәр...

Бөек Ватан сугышының соңгы елында миңа бер татар полковнигы — Мирза абый Ульданов белән очрашырга туры килде. Ул гражданнар сугышында да катнашкан, Салих аганы, «Совет армиясе маршы»н язгач, аларның полкына почетлы кызылармияче итеп кабул иткәннәр икән. Мирза абый белән Салих Сәйдәшевның икенче очрашуы Казанда, Хәмит абыем квартирасында булды. Ул мәҗлестә композитор Александр Ключарев, танылган җырчы Галия Кайбицкая һәм аның иптәше, минем скрипка буенча укытучым, дирижер Ильяс Әухәдиев бар иде.

Сугыштан соң да миңа Салих ага Сәйдәшев белән күп мәртәбәләр очрашырга туры килде. Шуларның иң соңгысына аерым тукталасым килә.

Бүгенгедәй хәтеремдә, Алабуга укытучылар институтын, дәүләт педагогия институты итеп зурайтканнан соң, аның беренче ректоры Габделхак Галиевич Әминев миннән 1954 елның җәендә Салих ага Сәйдәшев белән Алабугада очрашу оештыруны үтенде. Мин бу тәкъдимне үзем өчен бик дәрәҗәле эш дип шатланып кабул иттем һәм Алабугадан Казанга кайту белән, Салих агага алабугалыларның үтенечен җиткердем. Сәйдәшев: «Үземә генә күңелсез булмас микән соң ул районкүләм һәм институтта очрашу? Әнвәр энем, син ул очрашуга башка композитор, язучылар, шагыйрьләр, җырчылар да алып баруны оештырсаң иде»,— диде. Салих абыйның бу теләге аның никадәр олы җанлы булуын, үз каләмдәшләрен, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләрен никадәр якын күрүен тагын бер мәртәбә раслады.

Безнең бу иҗат группасында композиторлардан Җәүдәт Фәйзи, Александр Ключарев, язучылардан Гази Кашшаф, Бари Рәхмәт, Әхмәт Исхак, Әнвәр Давыдов, җырчылардан Мәрьям Рахманкулова, Рәисә Билалова, ул елларда КПССның Татарстан өлкә комитеты культура бүлеге мөдире, хәзер В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты профессоры Камил Фатыйхович Фасеев иптәшләр бар иде.

Шулай итеп, без «Вера Засулич» пароходына утырып, җәйге матур көннәрнең берсендә Алабугага иҗади сәяхәткә чыктык.

Идел өстенә караңгылык төшеп ай калыккач, махсус кечкенә аш өстәле әзерләнде. Табында Салих ага уен-көлке сүз белән күңелебезне ачты.

Салих абыйны чын күңеленнән яраткан, аның иҗатына ихлас күңелдән зур бәя биргән, аның үзе белән дә, музыкасы белән дә горурланган, аны ихтирам иткән кешеләр — иптәшләре, дуслары, танышлары композиторның һәр хәрәкәтендә матурлык, гүзәллек, инсафлык, табигыйлек күрәләр иде.

Алабуга институтында Салих абый белән очрашу кичәсе искиткеч күтәренке рухта үтте. Икенче көнне институт җитәкчеләре һәм укытучылары кунакларны Шишкин урманнарына алып чыктылар. Салих абый урмандагы сөйләшүләрнең дә үзәгендә булды.

Кичен Алабуга район культура йортында зур очрашу-концерт кичәсе үткәрелде. Әлбәттә, бу очрашуда да Салих ага Сәйдәшевнең сәхнәдә күренүе, аның пианинода уйнавы озакка сузылган алкышларга күмелде. Тамашачылар гына түгел, композитор белән бергә килгән кунаклар да Салих абыйга сокланып, кичә беткәнче аннан күзләрен алмадылар.

Бу көннәр һәркайсыбыз өчен онытылмас истәлек булып калды. Иртәгесен Казан кунакларын пароход белән озаттык. Алабуга пристанена озатырга төшкән халык пассажирлардан да күбрәк иде. Пароход кузгалып киткәндә Салих абыйның да яр буенда кул болгап калуын күргәч, арадан кемнеңдер: «Салих Сәйдәшев һәрвакыт халык арасында кала бит ул»,— диюе булды, бу сүзләрне яр буендагы халык алкышларга күмде. Әкрен генә кузгалып китә башлаган пароход палубасындагы кунаклар һәм пассажирлар да шул алкышларга кушылдылар...

Бу чыннан да Салих Сәйдәшевнең халык белән соңгы саубуллашуы иде. Иртәгесен институтның бер төркем укытучылары белән без Салих аганы Яр Чаллыга, улы Альфред янына озаттык...

Шул ук елның декабрь аенда мин, композиторларның иҗат йортыннан кайтып килешли, СССР Композиторлар союзына кердем. Иптәшләрнең мине күрүләре булды, кайгылы хәбәр белдерделәр: «Сезнең өлкән композиторыгыз Салих Җәләлетдинович Сәйдәшев Мәскәү больницасында вафат булды, сезгә Татарстан Композиторлар союзы вәкиле сыйфаты да аның гәүдәсен Казанга алып кайтуда катнашырга туры килер»,— диделәр. Шулай итеп, без Салих аганың улы Альфред, апасының улы Үзбәк (врач) белән Салих Сәйдәшев гәүдәсен Казанга алып кайттык. Аэропортта кара киемнәрдән килгән халык диңгезе, җилсез көнне эре бөртекле кар яуган күренеш миндә көчле тәэсир калдырды...

Академия театры бинасыннан мәрхүмнең гәүдәсен алып чыгып Куйбышев мәйданына җиткәндә, озатырга килгән халыкның соңгы сафлары әле театр бинасы янында иде. Бу хушлашуны чын мәгънәсендә бөек Тукайны соңгы юлга озату көне белән чагыштырырга мөмкин иде...

Сәйдәш тә, нәкъ Тукай кебек, халкыбызның мәңге сүнмәс йолдызы булып калды!

## Мәхмүт Хөсәен

# ТУКАЕ СИН КӨЙЛЕ ДӨНЬЯНЫҢ

Сәйдәшевнең безгә калдырган иҗади мирасы — сүнмәс учак. Йөрәкләрдә гомер буе дөрләп янучы моң учагы! Аның җылысы да, яктысы да, үзе исән чактагы кебек, көчле һәм тылсымлы. Еллар үтү белән ул моң учагының сихри яме һәм шигъри аһәңе арта гына бара.

Бөек шәхесләрнең кайсын гына алып карама, алар, гади җир улы булудан туктап, телдән-телгә, йөрәктән-йөрәккә, буыннан-буынга күчеп, мәңге яшь, мәңге якты йолдызга әверелә. Тукаебыз егерме җиденче яшьында дөнья куйган. Шулай да ул бүген, йөз яшенә якынаеп килүенә карамастан, безнең алга һаман да илһамы сүнмәс дәртле егет булып килеп баса, күңел күгебездә рушан йолдыз булып янтыра. Такташ, Җәлил, Кутуйлар да шулай. Дөрес, мин аларны күреп белмим. Ә менә Салих Сәйдәшевны күреп беләм. Ул чакта мин сугыштан кайткан яшь офицер идем.

...Менә ул, үзенең тылсымлы таягын һавада уйнатып, оркестрга җитәкчелек итә. Сихерле моңнар йөрәкләрне җилкетә. Тамашачы, үзенең концертта утыруын онытып, уйлары белән яшьлегенә кайта, гүзәллек мохитенә чума. Сәйдәшев, үзенең музыкаль үренә баскан килеш, сандугачлар көнләшерлек моңнарын халыкка бүләк итә... Бөек композитор минем хәтеремә әнә шулай сеңеп калган.

Торып-торып куанам: мин бит Сәйдәш кадәр Сәйдәшнең үзе белән сөйләшеп йөрдем. Син яшь, син яшел дип, читкә этмәде. Киресенчә, якын күрде, киңәшләрен әйтте, үзе сорап шигырьләремне тыңлады. «Чебиләр» белән «Буй баласе»н кат-кат укыта иде ул. Аннары, шигырьләр күңелле булгангамы, әллә мин балаларча кыйлан-

гангамы, рәхәтләнеп, күзләреннән яшь чыкканчы көлә иде. Гаҗәеп йомшак табигатьле, сабый күңелле кеше иде ул. Көтмәгәндә Салих абый мине үзе белән бергәләп эшләргә, иҗат итәргә дәште. Минем өчен моннан да зур дәрәҗә, моннан да олы бәхет юк иде ул көннәрдә. Салих абый белән бергә иҗат газаплары кичерү ничектер җиңел дә, күңелле дә, рәхәт тә, шул ук вакытта авыр да, җаваплы да. Җиңел, чөнки шигырьдә кытыршылыклар очраса, ул сиңа каты бәрелмәс, фикерен җайлап кына аңлатыр иде. Күңелле, чөнки эш барышында боегырга, кәефең кырылырга урын калдырмый ул: шаян сүзләр әйтеп, мәзәкләр сөйләп, рухыңны күтәрә. Рәхәт, чөнки аның музыкасыннан һич тә армыйсың, вакытның узганы тоелмый да кала. Авыр, чөнки ул синең алга зур таләпләр куя, тәссез, көчсез юлларыңны кабул итми. Җаваплы, чөнки Сәйдәш кадәр Сәйдәш, ягъни тере классик музыкасына тәңгәл килерлек әсәр тудырып кара.

Салих Сәйдәшев, табигатьнең үзе кебек, даһи да һәм гади дә иде. Даһилыгы аның музыкасында чагылса, гадилеге тормышта, кешеләр белән мөгамәләсендә күренә. Теге, я бу мәсьәлә турында үзара җитди сөйләшү барганда, буяуларны куертмый ул, араларны кискенләштерми. Киресенчә, бер җаен табып, күңелнең киеренке кылларын бушатып җибәрә торган иде. Бер хәл исә истә калган. Без, яшь язучылар, эштән соң радиокомитетта әдәби редактор булып эшләүче драматург Гамир Насрый бүлмәсенә җыела идек. Яңа шигырьләр укыйбыз, пьесалар тикшерәбез, экспромнар язабыз, матбугатта басылып чыккан әдәби әсәрләр турында фикер алышабыз. Кыскасы, безнең иҗади мәҗлес гөрләп тора. Бик еш кына Салих абый да безнең янда була иде. Бер вакытны безнең арада мәхәббәт темасына бәхәс купты. Берәребез сүз алса, бар белгәнен бушата, кызып китеп, бүтәннәргә сөйләргә ирек бирми. Икенче автор да нәкъ шулай кылана. Бәхәс, болай барса, бик озакка сузылган булыр иде. Көтмәгәндә әңгәмәгә Салих абый кушылды. Без бераз аптырап калдык. Олы кеше мәхәббәт турында нәрсә әйтер икән дип уйладык. «Кызмагыз әле, бәгырьләрем,— дип башлап җибәрде ул сүзен,— кайберләрегез әле өйләнмәгән, хатын дигән хикмәтнең ни икәнен дә белми. Ә белү зыян итмәс аларга. Бүтәннәрегезнең хатыннары, бала-чагалары бар. Алар хәзер дүрт күзләп сезне көтеп утыралар. Ә беләсезме хатын-кызның ничә төрле кайгысы бар икәнен? Алты төрле була икән ул. — Бүлмә тып-тын булды, күзләребез Салих абыйда.— Беренче кайгысы: тапкан баласы бик елак булу. Икенчесе: сөйгән иренең аракы яратуы. Яга торган утыны чи булса да кайгыра икән ул. (Бу чорда Казанда бик күпләр мич ягалар иде). Каенанасы усал я рәхимсез булса да зур кайгы икән аларга. Ә бишенче кайгысы: өзелеп көткән кадерле кунагы вакытында килмәү»,— диде дә шып туктады композитор. «Алтынчы кайгысын әйтмәдегез ич»,— дип, Гамир урыныннан ук сикереп торды. «Алтынчысымы? — дип бераз дәшмичә генә өйләнгәннәргә күз төшереп алды да: — Алтынчы кайгысы: яраткан иренең эшеннән үз вакытында кайтмавы»,— дип сүзен очлады. Без барыбыз да тынып калдык. Дилбегәдәй озын бәхәсебез капылт сүнде һәм без мыштым гына өйләргә таралыштык.

Салих абыйның йөзе чытылган, кашлары җыерылган, я булмаса кемнәндер, нәрсәдәндер зарланган чагын белмим. Ваклыклардан, гайбәтләрдән һәрвакыт өстен иде ул. Кайчан гына юлыкма үзенә, чиста киенгән булыр, бик әдәпле генә исәнләшер, саф татарча дәшеп, матур тел белән тыйнак кына сөйләшер иде. Кеше хәтерен калдырган яисә кешене рәнҗеткән чакларын күрмәдем. Зыялыларча спайлык, пөхтәлек, инсафлык, югары культура хас иде аңарга.

Салих абый мине күргәндә сүзен: «Я, бәгырь, әдәбияттан кайсы шагыйрьләрне үттегез? Шуларның берәрсен сөйләп күрсәтмисеңме?» — дип, башлар иде. Бигрәк тә ул Тукай белән Дәрдмәндне ярата. «Ничек алар шулай, кыска һәм аз язып, тирән мәгънә әйтә белгәннәр, бик күпне аңлата алганнар? Тыңлаган саен тыңлыйсы килә үзләрен»,— дип соклана. Шулай ук мин Салих абыйның яшь язучыларның китапларын укып сөенгәнен дә, кайберләренең язмышлары өчен көенгәнен дә хәтерлим. «Әнвәр Давыдов — киң колачлы шагыйрь,— ди иде ул. — Җыр язу серләрен дә өйрәнсә, әйбәт текстлар яза алыр иде, ә Шәрәф Мөдәррисне моңлы һәм озын җырлар авторы итеп күрәсем килә. Менә Зыя Мансурда, үзе шыпырт кына йөрсә дә, эчке аһәң, лирик хисләр көчле. Аның иҗатында вакыт-вакыт Сәгыйть Рәмиев алымнары чагылып китә». Үзара сөйләшкәндә яшь шагыйрьләргә җыр текстлары язу белән генә чикләнмичә, зуррак, катлаулырак музыкаль формаларны да үзләштерергә киңәш итә иде ул. Композитор Җәүдәт Фәйзи белән «Тапшырылмаган хатлар» операсын (Г. Кутуй повесте буенча) иҗат итеп йөрүебезне әйткәч, Салих абыйның йөзе яктырып китте. Ул мине туганнарча кочаклап алды да озак итеп кулымны кысты. Моңсу-ямансу мизгелләремдә Сәйдәш кулларының җылысы әле дә күңелемә канат куя кебек...

Салих Сәйдәшевка илле яшь тулу уңае белән зур музыкаль кичә әзерләнә иде. Бу турыда мин университетта бергә укыган группадашларыма әйттем. «Безне дә алып кер концертка, Мәхмүт. Син бит солдатта булган кеше, бер җаен тап. Без унике бөртек кенә ич. Безнең дә композитор юблиеен күрәсебез килә»,— дип, алар миңа үз теләкләрен белдерделәр. Нишләргә соң? Композиторга багышлап шигырь яздым да юбилей комиссиясе председателенә чаптым. Минем бәхетемә, председатель иптәш, шигыремне хуш күреп, ике чакыру билеты тоттырды. Авыз колакка җитте! Һи, ике билетка уникене түгел, ике йөз кешене дә кертә ул студент! Шулай итеп без бөтен группабыз белән Салих Сәйдәшев кичәсенә килдек.

Концерт дәвам итә. Җырчылар, музыкантлар күтәренке рух белән Сәйдәш әсәрләрен башкаралар. Тылсымлы таяк композитор кулында. Ничек һәм кая кирәк, шунда бора ул үзенең симфоник «сандугачын». Кичәне Казан театр училищесын яңа гына тәмамлаган яшь артист Айрат Арсланов алып бара. Беренче бүлекнең соңгы кешесе итеп мине чыгардылар. Мондый зур кичәдә беренче тапкыр чыгуым булгангамы, шактый дулкынландым. Шулай да, тиз генә үземне кулга алып, мөхтәрәм юбилярга багышланган шигыремне укып киттем.

Солдат булып зур походлар үттек,
Европаның уздык яртысын.
Алга илттек кайнар йөрәкләрдә
«Наемщик»ны — туган як тосен.

Мәскәү аша йотылып тыңлый идек
Окопларда синең моңнарны.
Маршың белән кердек Берлиннарга,
Җиңеп үттек авыр юлларны...

Татарларның Чайковские син,
Тукае син көйле дөньяның.
Рәхмәт сиңа рухландырган өчен
Моң сөюче хезмәт улларын.

Күңелләрне назлап яшисең син,
Арабызда бергә сайрашып,
Халык мәхәббәте лауреаты —
Сөеклебез Салих Сәйдәшев!

# АНЫҢ КҮҢЕЛ ГӨЛБАКЧАСЫНДА

*Мансур Мозаффаров турындагы истәлекләрдән*

...Бер төркем татар композиторлары һәм музыка белгечләре белән мәрхүм Мансур аганы искә алырга барган чагыбыз иде. Зират капкасы төбендә автобустан төштек тә, тар юл буйлап акрын гына эчкә кереп киттек. Шулчак мине таныш түгел бер ир кеше туктатты:

— Бу чәчәкләрне кемгә илтәсез?

— Мансур Мозаффаровка.

Ул, көтелмәгән авыр хәбәр ишеткәндәй, беравык сүзсез торды, аннан, көрсенеп, сөйләп китте:

— Мин аны элек-электән белә идем. Салих Сәйдәшев белән Мансур Мозаффаров минем өчен музыкабызның җанлы гәүдәләнеше булдылар.

Әйе, Мансур Әхмәтович иҗатка җаны-тәне белән бирелгән художник иде. Татар музыкасында «беренче буын профессионал-симфонисты» буларак ул, үз коллегалары С. Сәйдәшев, С. Габәши, Л. Хәмиди, Җ. Фәйзиләр һ. б. белән бергә милли культурага гаять зур өлеш кертте. Аның музыкасы да йомшаклыгы, сафлыгы, эчкерсезлеге һәм гадилеге белән үз тормышына охшаган.

Миңа Мансур Мозаффаров белән әллә ни күп аралашырга туры килмәсә дә, күңелемдә ул үзе турында онытылмас якты хатирә калдырды. Татарстанның аеруча кызыклы композиторларыннан берсе булган бу шәхес турында сөйләми калу гомумән мөмкин түгел: безнең арадан киткән иҗат кешесенең холкын-фигылен, рухи дөньясы, әхлакый йөзен тулыландырырырга мөмкинлек биргән фактларның һәркайсы игътибарга лаек һәм кадерле. Дусларча аралашуыбыз шартларында, һичбер риясыз әйтелгән кайбер фикерләрдә, минемчә, Мансур Әхмәтовичка гына хас сыйфатлар бик ачык күренә.

Ничектер бервакыт, пентатоника турында сүз чыккач, Мансур Әхмәтович болай диган иде:

— Эш күпме «артык» авазлар файдаланылган булуда да, шулай ук пентатониканың «чиста» яки «кушылдыклы» булуында да түгел, ә аның ничек яңгыравында. Әйтик, менә фәлән композиторны алыйк (ул бик танылган бер исемне атады)... Аның пентатоникасы бик «чиста», моннан да чиста пентатоника булырга мөмкин түгел, ә көе ни татар, ни чуваш, ни бурят көенә охшамаган.

Аннан ул йомшак кына көлеп куйды.

— Әйе, аның каравы пентатоникасы чиста...

Мансур Әхмәтович бу темага әледән-әле әйләнеп кайта һәм, беренче карашка, һәрвакыт үзенә-үзе каршы сөйли кебек тоела иде. Ләкин шактый каршылыклы күренгән бу фикерләр, тулаем алганда, бик ачык һәм уйланылган карашлар системасы булып чыкты.

Мансур Мозаффаров гаҗәп киң күңелле кеше иде. Аның бу игелеклелеге кайчагында инде болай да киң булган күңеленең хәтта ярларыннан ташып чыккалый сыман иде. Әле дә хәтеремдә, бервакыт ул бөтенләй таныш түгел кешегә кайнар теләкләр язып, А. Ключаревның сугышка кадәр басылып чыккан, инде бик сирәк очрый торган китапка әверелгән татар халык җырлары җыентыгын бүләк итте. Соңыннан ачыкланганча, кайдандыр ерактан килгән әлеге кеше композиторга «Мин татар җырлары белән кызыксынам» дип әйткән булган һәм Мозаффаровка шул җитә калган...

Мансур Әхмәтовичның искиткеч тиз ышанучан кеше булуы турында мин аның белән танышканчы ук ишеткән идем инде. Композиторның бу беркатлылыгы хәзер, инде күп еллар үткәч, гаҗәеп бер легенда кебек тоела. Бервакыт аңа кемдер бик җитди кыяфәт белән: «Васильевода бер үзешчән композитор Г. Бәширов романы буенча опера язган һәм бу операны Татар дәүләт опера һәм балет театрында куячаклар», — дип сөйләгән. Мансур Әхмәтович бу хәбәргә һичбер икеләнүсез ышанган, чын күңеленнән гаҗәпләнгән һәм шатланган иде. Шуңа күрә дә мин аннан, сез ничек

шулай булдыра аласыз, дип сорарга җөрьәт иттем. Композитор башта сүзнең нәрсә турында барганлыгын аңламады, аннан көлеп җибәрде һәм җавап бирде:

— Ә ничек ышанмыйсың? Музыкада ышанусыз бернәрсә дә эшләп булмый. Көй бит ул һәрвакыт — дөреслек...

Гәрчә минем соравым көй турында булмаса да, Мансур Әхмәтовичның җавабы аның тормыштагы ышанучанлыгы белән табигый рәвештә бәйләнеп китте...

Мозаффаровның кешеләр арасында булган вакытларын искә төшергәндә, ул минем күз алдыма һәрвакыт бер читтә, үзәктән китәргә тырышканрак хәлендә килеп баса. Ул ничек тә кешеләр арасында аерылып тормаска омтыла һәм башкаларның йөзен каплаудан курка иде. Аның бу омтылышы, әлбәттә, түбәнсенүдән, кимсенүдән түгел. Мансур Әхмәтович горур кеше иде! Әмма бу — үз бәясен яхшы белгән, ләкин беркайчан да моны сиздерергә, калку итеп күрсәтергә теләмәгән шәхеснең эчке горурлыгы.

60 нчы еллар башында без казакъ композиторлары белән очрашкан идек. Эшләнәсе эшләр бетеп, бергәләп рәсемгә төшер вакыт җиткәч, Мансур Әхмәтовичның кайбер коллегалары, гадәтләренчә, «фотокомпозиция үзәгенә» эләгер өчен кабалана башладылар. Мозаффаровның шул чагындагы күз карашы, уңайсызлану катнаш моңсу елмаюы әле дә хәтердән китми.

Аның кешеләргә игътибарлылык, үткәнгә ихтирам мәсьәләләләрендә дә үз фикере бар иде.

...Җәйге көн кичкә таба авышып килгән вакыт — Мансур Әхмәтович белән Фукс бакчасында утырабыз. Шунда безнең яннан вәкарь белән генә скрипка футляры күтәреп, шул ук вакытта бу вәкарьлекне бозып, этешә-төртешә бер төркем малайлар-кызлар узып китте. Бу бирердән ерак түгел генә урнашкан махсус музыка мәктәбе — «сәләтле балалар мәктәбе» укучылары иде.

Мозаффаров шау-шулы төркем күздән югалганчы карап торганнан соң бу балаларның язмышыннан көнләшүе турында әйтте. Аның авызыннан «көнләшәм» дигән сүз чыкмаса да, Мансур Әхмәтовичның көтмәгәндә балачак хатирәләренә күчүе әнә шул хакта сөйли иде. Композитор «алардан яхшы музыкантлар чыккан булыр иде» дип, үзенең кайбер яшьлек дусларын да искә алды. Кыскасы, әңгәмә бүгенге көн белән үткән заман тирәсендә әйләнде.

— Аларны бөтен нәрсәгә өйрәтәләр. Бу яхшы һәм монысы өчен рәхмәт, — дип дәвам итте Мансур Әхмәтович. — Ләкин бу укуда халык музыкасына нинди урын бирелгән? Безнең балаларыбыз аны начар беләләр. Монысы куркыныч түгел: белмәсәң, өйрәнергә була. Ә менә яратмыйсың икән, көчләп яраттырып булмый. Аларга халык көйләрен яратырга кем ярдәм итә соң?

Бу сүзләр Мозаффаровка хас булганча тыныч тонда, гадәти интонация белән әйтелгән булсалар да, алар аша әлеге хәлнең композиторны борчуы, күңелен әрнетүе сизелеп тора иде.

Бервакыт ул минем яныма ниндидер саргайган кәгазьләр күтәреп керде. Болар иске афишалар иде. «Без үткәнне хәтердә саклый белмибез, аны тиз онытабыз, — диде Мансур Әхмәтович һәм, дулкынлануын яшерә алмыйча, дәвам итте. — Бүген консерваториягә килешли таныш түгел бер кеше туктатты да, сорый: «Нишләп Василий Иванович Виноградов һәм аның улы Юрий Васильевич Виноградовның әсәрләре бер дә башкарылмый?» — ди. Ул Виноградовларның әсәрләрен кайчандыр тыңлаган булган һәм бик ошаткан. Аның фикеренчә, бу әсәрләрдә татар музыкасының милли йөзе бик яхшы чагыла. Мин бу кешегә нәрсә дип җавап бирим? Ә бит, дөрестән дә, алар нишләптер яңгырамый башладылар. Зур осталык белән язылган бу көйләр, әйтерсең, бөтенләй дөньяда юк — кайдадыр тузан эчендә аунап яталар. Ә бит алар бар, бар!»

Мин инде күптән аның шулай әсәрләнгәнен күргәнем юк иде. Ул сүзен дәвам итеп, башка композиторларны, Козловны, Сәйфуллинны искә алды, Заһидулла Яруллин, аның искиткеч музыкаль интуициясе, Заһид Хәбибуллин музыкасында милли стильнең чисталыгы турында сөйләде, Латыйф Хәмиди иҗатының үзенчәлекләренә тукталды.

Мозаффаров үз иптәшләренең иҗатын яхшы белә, белә һәм ярата иде. Шулай бервакыт аңа сольфеджио җыентыгы әзерләү эшендә катнашырга туры килде. Әзерләүчеләр арасында Ю. В. Виноградов, Б. Н. Трубин һәм мин дә бар идем. Безнең группа бик еш кына җыела һәм җыентыкка тәкъдим ителгән яңа көйләрне тикшерә, сайлап ала һәм, әлбәттә, бәхәсләшә иде. Шундый очрашуларның берсендә группа пентатоника мәсьәләсенә һәм музыканың милли спецификасы проблемаларына әйләнеп кайтты. Без төзегән сольфеджиода пентатониканың төрле формаларына һәм модификацияләренә аерым бер бүлек багышланган булганлыктан, әлеге мәсьәләләр безнең эшебездә төп темаларның берсе иде. Бу сөйләшү хәтергә аеруча нык уелып калган, чөнки бирердә Мансур Әхмәтовичның пентатоникага инде алда берәз телгә алынган мөнәсәбәте тагын да ачыклана төште.

— Мансур Әхмәтович, сез әлеге дә баягы «киңәйтелгән пентатоникага» ничек карыйсыз? — дип сорадым мин Мозаффаровтан.

— Мин теоретик түгел, — дип җавап бирде ул, — һәм бу терминның ни дәрәҗәдә уңышлы булуы турында берни дә әйтә алмыйм. Музыканы тыңлаганда мин, беренче чиратта, аның нинди тәэсир ясавына карап фикер йөртергә тырышам һәм

бу тәэсир кейнең нинди булуы турында сейли. Татар музыкасына килсәк, минемчә аның ни дәрәҗәдә милли булуын хәл итәр өчен пентатоника эзләүнең кирәге юк. Күптән түгел миңа Алабугадан килгән бер һәвәскәр композиторның кульязмасын күрсәттеләр. Аның һәр җырының башында, гадәттә әсәрнең тизлеге күрсәтелә торган урында, пентатоник авазлар рәте тора. Мин аннан нишләп болай эшлисез дип сорадым. Ул күзен дә йоммыйча, бик ышанычлы тавыш белән: «Милли композитор булып калу өчен»,— дип җавап бирде. Шулай итеп, пентатоник авазлар рәте аның өчен миллилек синонимына әверелгән. Ә бит бу кыргый фикерне аның башына кемдер сеңдергән булырга тиеш. Шуңа күрә пентатониканы киңәйтергә мөмкин булуы турында ишеткәндә мондый үзгәртү мөмкинлеге (әлбәттә, миллилектән баш тартмаганда) үзе генә дә миңа ошый. Миңа калса,— дип дәвам итте ул,— татар музыкасының асылы әлеге биш авазга кайтып калудан бигрәк, интонацияләрдән, музыкаль борылышлардан, үзенчәлекле моңнан гыйбарәт. Нәкъ менә алар татар музыкасының төп нигезен тәшкил итәләр. Монда авазлар һәм интервалларның эзлеклелеге, тәртибе, ритмик мөнасәбәтләре бик мөһим. Сүз уңаеннан әйткәндә, татар музыкасында үлчәм һәм ритм нишләптер бөтенләй диярлек өйрәнелми — ә бит, мөгаен, аларда авазлар рәтенә караганда күбрәк үзенчәлекләр табып булыр иде. Мин тагын бер нәрсәгә гел гаҗәпләнә килдем. Татар музыкасында нишләптер мелизмнарга һәм орнаментларга тиешле игътибар бирелми. Шунысын да әйтергә кирәк, татар җырында мелизмнарны нотага салу бик авыр.

Минем «моның өчен махсус билгеләр уйлап табарга мөмкин түгелме соң?» дигән соравыма каршы ул болай дип җавап бирде: «Татар халык музыкасында без мелизм дип йөрткән нәрсәләр чынлыкта мелизм түгел, ә Бетховен «мелизмнары» кебек көйнең аерылгысыз бер өлеше булып торалар. Шуңа күрә нота текстына нинди дә булса билгеләр кертсәк, алар көйдә ялганма кебек булачаклар. Монда нишләргәдер, белмим, әмма ничектер эзләнергә, сынап карарга, татар халык музыкасында мелизмнарның тулы хокукын кире кайтарырга кирәк. Татар җырларының күренекле белгече А. С. Ключарев бөтен гомере буе шуңа омтылды.

Сүз татар музыкасында материалны үстерү мәсьәләләренә күчте. Минем татар көйләрендә вариация принцибы чыннан да төп принцип булып торамы дигән соравыма Мансур Әхмәтович болай дип җавап бирде:

— Әйе, шулай килеп чыккан, татар музыкасында төп үсеш юлларының берсе — вариация, ләкин бу, әлбәттә, үсешнең башка юлларын кире какмый. Мин ышанам, татар халык җырын җентекләп өйрәнгәндә, аңарда вариациялелек кенә түгел, чын симфоник үсеш тә табарга була.

— Кыскасы Мансур Әхмәтович, теоретик булмаса да, татар музыкасы турында бик күп уйланды, бик үзенчәлекле зирәк фикерләр әйтте һәм бу миңа гына түгел, бик күпләрнең фәнни эшчәнлегенә этәргеч бирде.

Без еш кына Мансур Әхмәтович белән шәһәр буйлап йөрергә чыга идек.

Шул чакларда ул миңа күп нәрсәләр сөйләде. Шулай бервакыт Габдулла Тукай һәйкәле янында басып торганда, мәсәлән, болай дигән иде ул:

— Кызганыч, ул чагында шагыйрь әйткән фикерләрне ишетеп, язып баручы булмаган. Миңа Тукайның бер фикерен ишетергә туры килде: ул татар нәкышлары белән бормалы озын татар җырлары арасында охшашлык күргән.

Менә Тукай әйткән тагын бер фикер: төрле халыклар музыкасының бер-берсеннән нәрсәсе белән аерылуын түгел, ә кайсы яклары белән охшаш булуын ачыклау өчен аларны кемнең дә булса чагыштырып караганы бармы?

Бик актуаль булган бу мәсьәләне хәзерге вакытта чагыштырма этномузыкология дигән махсус фән өйрәнә. Шуңа күрә әлеге фикерне ул чагында беренчеләрдән булып күтәреп чыккан бөек татар шагыйренең сәнгатьле фикер йөртүенә һәм аның гүзәллекне, нәфислекне тирәнтен аңлавына сокланырга гына кала.

... Татар халык җырларын скрипка белән фортепьяно өчен эшкәртә башлагач, мин авыр, ул чагында бөтенләй хәл итеп булмаслык кебек тоелган каршылыкка очрадым. Миңа, заманча музыкаль чараларны киң файдалану белән беррәттән, көйнең сафлыгын, моңын саклап калырга кирәк иде. Эшкәртелгән көйләрнең кайберләрен Композиторлар союзында күрсәтеп карадым һәм анда аларга төрлечә бәя бирделәр. Шуннан киңәш һәм ярдәм сорап Мозаффаровка мөрәҗәгать иттем.

Мине игътибар белән тыңлап бетергәч, Мансур Әхмәтович көлеп алды һәм болай диде:

— Халык җырларын ничек эшкәртү турында бәхәсләр инде күптәннән бара. Бу хакта Габәши дә, Хәмиди дә, Заһидулла Яруллин да, Җәүдәт Фәйзи дә, Василий Виноградов та, Ключарев та бәхәсләште, бу бәхәсләр әле дә дәвам итә, ләкин уртак фикергә килгән юк һәм беркайчан да килмәбез төсле. Чөнки барыбер һәркем үзенчә эшли. Башкалар ничек уйлыйдыр, белмим, әмма минем өчен көйне эшкәрткәндә иң мөһиме — җырның рухын, аның кабатланмас үзенчәлеген, милли аһәңен саклап калу.

Мансур Мозаффаров белән очрашканда әнә шулай һәрвакыт күп кенә кызыклы фикерләр ишетергә туры килде. Нәрсә турында гына сөйләмәсен, шатланганда да, борчылганда да аның сүзләре аша бер идея — кешенең төп сыйфаты игелеклелек булырга тиеш дигән идея ачык сизелә иде.

**АБРАМ ЮСФИН,**
**музыка белгече.**

Илдус Ахунҗанов

# ТӘРҖЕМӘЧЕ АЧКАН ТӘРӘЗӘЛӘР

Күренекле язучыбыз Ибраһим Газзи 1962 елның январь аенда Казанда әдәби тәрҗемә проблемаларына багышлап уздырылган Бөтенроссия киңәшмәсе трибунасыннан торып, тәрҗемәчеләр әзерләү — дәүләт күләмендәге мөһим мәсьәлә һәм, димәк, аны кустарь юл белән түгел, ә дәүләт эшенә хас җитдилек белән хәл итәргә кирәк, дигән иде. Хәтерем ялгыштырмаса, шул ук елны М. Горький исемендәге Әдәбият институтында махсус әзерлекле яшь тәрҗемәчеләрнең беренче чыгарылышы булды.

Һәм менә әлеге мәсьәләне дәүләт күләмендә хәл итүнең яңа бер чагылышы — шул ук институтның татар группасында әзерлек үткән тәрҗемәчеләрнең иҗат отчеты сыйфатында дөнья күргән «Запах мяты» исемле хикәяләр җыентыгы.

Биредә без төрле буын әдипләренең әсәрләрен күрәбез. Классик язучыларның хикәяләре белән бергә, башлап язучы яшь каләмнәрнең әсәрләре дә кертелүе җыентыкның кыйммәтен арттыра гына. Ул шушы китапны төзегән Г. Хантимерованың сүз башы белән ачыла. «Рус теленә, милләтләрнең үзара аралашу теленә тәрҗемә ителү — Бөтенсоюз аренасына, алай гына да түгел, дөнья аренасына чыгу»,— дип яза ул. Бик хак сүзләр. Совет тәрҗемә мәктәбенең — ә бездә тәрҗемә эше СССРның җитмеш алты теленнән алып барыла — казанышлары зур, алар интернациональ тәрбия эшенә, бердәм һәм күпмилләтле совет әдәбиятын үстерүгә хезмәт итә. Әмма иҗат юлына яңа аяк басып килгән тәрҗемәчеләрнең хезмәтен бәяләгәндә Г. Хантимерова, анык һәм эшлекле анализ ясау урынына, артык җете буяуларга күчеп, чама хисен югалтып җибәрә.

Эшләр болайга китсә, кайбер яшьләребез үз мөмкинлекләренә артыграк югары бәя биреп, тәрҗемә әдәбиятка кагылышлы гомуми бәяне үзләренә генә кайтарып, нәкъ менә аларның тәрҗемәләре дөнья аренасына чыгарга тиеш икән дигән вәсвәсәгә бирелеп китмәсләрме? Һәрхәлдә, кереш сүздәге үлчәмичә ычкындырылган кайбер фикерләрнең моңа этәргеч бирү ихтималы юк түгел.

Бөтнек исе... Миңа калса, К. Симоновның мәшһүр өч каены кебек үк, бу сүзләрнең дә тирән эчке мәгънәсе, җегәре бар. Ул кешенең туып-үскән җире, аның кече Ватаны образын күз алдына бастыра. Шуңа күрә Рафаил Төхфәтуллинның «Бөтнек исе» хикәясенең исемен китап тышына чыгару бик уңышлы диясе килә.

Инде җыентыктагы кайбер хикәяләргә килик. Менә Фәнис Яруллинның «Олы хәзинә» исемле социаль-тарихи новелласы. Ул фаҗигале вакыйга белән тәмамлана: әсәрдәге нани геройның әтисен, туган җиренә кайтып килүче солдатны, урманда сагалап торып кулаклар үтерә. Ни өчен үтерәләр, нәрсә эзләп җан кыялар? Герман фронтыннан язган хатында солдат үзенең элеккечә фәкыйрь вә мескен бәндә түгеллеген, күптән көткән хәзинәне кулга төшерүен, әйтеп язган икән. Кулаклар шул хакта ишетеп, солдат кешенең хисапсыз мал-мөлкәтен кулга төшерергә ниятләгәннәр. Тик ул кара йөрәкләр әлеге солдатның кесәсеннән үзләре көткән алтын-көмеш урынына тетелеп бетә язган газит кисәге генә табачакларын белмәгәннәр. Җир турында, җирнең мәңгелеккә һәм бернинди түләүсез-нисез крестьяннар-

га бирелүе турында Ленин кул куйган Декрет басылган анда... Җир ул барлык байлыкларның, һәртөрле мал-мөлкәтнең анасы, солдатның сүзләре чынлап та бик хак сүзләр икән шул.

Хикәя балаларга адресланган һәм новелланың үзенчәлекле образлар системасы нәкъ шул максатка хезмәт итә. Вакыйга хәзер инде олы яшенә җиткән авыл тимерчесе Сибгат абзый авызыннан хикәя ителә. Бу алым әсәргә киң колачлылык, мәгънәле ретроспектива бирә. Сибгат абзый, аның ленинчыл хакыйкать өчен башын салган этисе, туган туфрактан аерылгысыз булган Ватан образлары бик ерактан, төптән калкып чыга.

Бу новелланы тәрҗемәчеләрнең әлеге яшь буыны вәкилләреннән берсе Роза Кожевникова тәрҗемә иткән. Р. Кожевникова — шигърияттә дә каләмен сынаган кеше — үз каләменең җегәрлегенә ышандыра. Аның җыентыкта урын алган икенче эше — Габделхәй Сабитовның «Ярсу язлар» хикәясен тәрҗемә итүе бу ышанычны тагын да ныгыта төшә. Г. Сабитов каләменә хас образлылык, хикәяләү рәвеше, күрәсең, Р. Кожевникова өчен якынрак, аңлаешлырак.

Хикәянең матурлыгы, күңелне җәлеп иткән сыйфаты — авторның лирик кичерешләрендә, сүзләр белән әйтелмәгән якты хиссиятендә. Тәрҗемәче әсәрнең менә шушы эчке яктылыгын, хисси эчтәлеген бирә алган. Дөрес, бу — тәрҗемәгә бөтенләй тел тидермәслек дигән сүз түгел әле. Р. Кожевникова оригиналдагы кайбер четерекле тоелган детальләрне читләтеп үтәргә ярата, әсәрдәге теге яки бу сурәтләү чарасына тәңгәл, «синхрон» яңгырардай тәгъбирләрне тәрҗемә теленнән эзләүне хуп күрми. Шулай да аның шигъри сизгерлеге, тоем куәсе үзен сиздерми калмый, хикәя сине барыбер мавыктыра, тәрҗемә эзләрен күрми укыйсың. Бусы исә мактауга лаек сыйфат.

Хикәядә әле «бала-чагалыклары» чыгып бетмәгән ике яшүсмер — Гамил белән Гөлүсә арасындагы беренче ярату — мәхәббәт хисләре, әле үзләре дә аңлап-беләп җиткермәгән кичерешләрнең бөреләнә башлавы тасвирлана. Үзләре дә аңламастан, алар «мәхәббәт законнары» буенча эш итә башлыйлар. Бер-берсен шаяртып алу, чәнечкеле сүзләр әйтешү, балаларча эчкерсез хәйлә белән үзара мөнәсәбәтләрне сынашулар — боларның һәммәсе авторның лирик хисләре белән өртелә. Укучы шулар аша әлеге яшүсмерләр күңелендә шәхеснең формалашуы өчен төп шарт — үзеңнең кешелек дәрәҗәңне тою хисенең канат җәя баруын күрә. Чын сөю хисе ул көрәш дигән сүз бит, мәхәббәтнең бөек көче белән бер-берсенә тартылган ике шәхес арасындагы мәңгелек көрәш... Әнә шуңа күрә дә мәхәббәт темасы — мәңгелек һәм һәрчак үзгә.

Әйткәнебезчә, Гамил белән Гөлүсәнең мәхәббәте әле бөреләнә генә. Хикәянең ахырында автор геройларының эчке халәтен бик мәгънәле табигать күренешендә ача. Әйтергә кирәк, тәрҗемәче дә биредә әлеге фикерне укучыга тирән итеп җиткерерлек сүзләр-сурәтләр тапкан:

«Даже в бабочку, которая лежала недвижно всю зиму меж оконных рам, весеннее солнышко вдохнуло жизнь. Она шевелит своими бархатными крылышками, пытаясь взлететь.

Только, пожалуй, рановато. А пока, видно, трепещет, сквозь сон ощущая пробуждение природы. Она еще проснется, полетит».

Р. Кожевникова тәрҗемәдә компенсация алымын еш һәм уңышлы куллана. Тәрҗемә практикасында бу, гомумән, уйландыра, уңдырышлы фикерләргә этәрә торган күренеш дип әйтер идем.

Реалистик тәрҗемә — әсәрне һәрчак яңабаштан тудыру, иҗади үзләштерү, яңа тереклек бирү дигән сүз. Шуңа күрә дә тәрҗемә теориясе талантлылыкны беренче планга куя. Тик бу талантлылык үзенә бертөрле — тәрҗемәченең автор индивидуальлеген сеңдерә һәм шунда эри алуында.

Әсәр тукымасында һәр нәрсә үзара бәйләнгән. Һәр сүз — әдәби әсәрдә сүз образ микроструктурасын тәшкил итә — тирәндә ята торган гаять бай ассоциатив мәгънәләргә ия. Мәгънә төсмерләреннән берсен генә үзгәртү дә башка элементларга мәгънәви проекция ясауны таләп итә. Нәкъ менә шушындый эчке бәйләнеш тәрҗемә процессында оригиналга яңарак, үзгәрәк сурәт чараларын кертүне таләп итә дә.

Соңгы елларда — тәрҗемә проблемалары хакында фикер алышканда булсын, тәнкыйть мәкаләләрендә булсын — нәкъ менә әсәрне «яңабаштан тудыру», «иҗади хис-фикер аша уздыру»ны яклау өстенлек алды. Мондый мәкаләләрнең авторлары бу карашны еш кына әдәбият белеме өлкәсендәге соңгы казаныш буларак тәкъдим итәләр. Хәлбуки, ул караш чынлыкта

руслар әйтә торган сакаллы самавар булып чыга түгелме соң? Фикеребезне ачыклау өчен кечкенә генә тарихи экскурс ясап алыйк.

Унтугызынчы йөз башында, бөек француз революциясе йогынтысында Германиянең Иена романтиклар мәктәбе классицизм поэтикасына, төгәлрәк әйткәндә, анык абсолют монархия идеяләре белән сугарылган канатына беренче тапкыр кыю һөҗүм башлый. Соңрак исә романтизм агымы француз, инглиз рус әдәбиятларында да үзенә җирлек таба. Рационализм философиясен чигенергә мәҗбүр итеп, шигърият мәйданына хыялга өртелгән ярсу хисләр бәреп керә. Шул рәвешчә, прогрессив романтизм меркантилизм дөньясына каршы бунт рәвешендә дөньяга килә һәм шәхесне рухи богаулардан азат итүне даулый.

Чынбарлыкның сурәтен язучы үзе теләгәнчә, шагыйрьнең илһамы кушканча тудыру принцибы романтизмның типологик (иң гомуми) сыйфатларыннан берсе булды. Инде шул чорларда иҗат иткән романтикларның тәрҗемә өлкәсендәге эшчәнлегенә күз салсак, монда да шул ук принцип хакимлек итүен күрербез.

Романтик язучылар оригиналга тәңгәллекне түгел, ә тәрҗемәченең үз идеалына тугрылыклы булуны өстен куялар. Иң мөһиме, әсәр тәрҗемәченең мәсләгенә, рухына килсен. Үз тавышың, үз йөзең-рухың, индивидуальлегең — романтиклар карашынча, шигъри тәрҗемәнең бәһасен менә шулар билгели. Иҗат процессында романтиклар тәрҗемә ирегеен шул дәрәҗәдә киңәйтеп җибәрәләр, хәтта әсәрнең концепциясе тамырыннан үзгәрә, ә тәрҗемәче мөстәкыйль иҗатчы булып әверелә. Бу җәһәттән романтик шагыйрь Жуковскийның Гогольгә язган хаты бик характерлы. «Минем фикерем чакма кебек — ташка бәрдеңме, очкын чыгуын көт тә тор. Бу, гомумән, иҗатымның холкы: язган нәрсәләремнең һәммәсе дә диярлек я башка кешенеке, яисә башканыкы уңае белән язылган — һәм, хәлбуки, барысы да үземнеке».

Дөньяга романтикларча карау һәрвакыт яшәгән. Әмма дөньяга караш буларак, ул, мәгълүм ки, милләтләр формалашкан, милли-азатлык хәрәкәте көчәйгән чорда барлыкка килә. М. Лермонтовның «Гетедан» дигән даһи шигыре дә, Шекспир трагедияләренең П. Мачабели тарафыннан башкарылган тәрҗемәләре, Г. Тукай, С. Рәмиевнең тәрҗемә әсәрләре дә ул чорларда тәрҗеманең милли культураны баету чарасы булып саналуын раслыйлар. Гомумән, романтиклар тәрҗемәсен сәхнәдә уйнаучы актер белән чагыштырырга мөмкин.

Реализм методы белән эш итүче тәрҗемәчеләр, романтизм юнәлешеннән аермалы буларак, оригиналны башка тел стихиясендә яңабаштан тудыру максатын куялар. Иҗат ирегe монда бөтенләй икенче төрле форма ала, әмма бу — эстетик хакыйкатькә илтә торган юл. Тәрҗемәдә «минем шәхесем түгел — автор шәхесе булырга тиеш!» — диде күренекле язучы һәм тәрҗемәче Н. Евдокимов «Тәрҗемәнең алгебрасы һәм арифметикасы» дигән дискуссиянең йомгаклау утырышында. Бу сүзләрдә дә реалистик методның асылы бик ачык чагыла.

Шулай итеп, әдәби иҗаттагы кебек үк, тәрҗемәчеләр иҗатында да без бер-берсеннән аерылып торган ике юнәлеш, ике типны күрәбез. Әдәбият галимнәре һәм әдипләр, совет әдәбияты белеменең барлык казанышларына таянган хәлдә, технологик бәйләнешләр турындагы теорияне тудырдылар. Аның нигезендә сәнгать күренешләренең кабатланмаучанлыгы турындагы фикер ята. Социалистик реализм теориясе хәзинәсенә тагын бер ачыш өстәлүе иде бу. Әдәбият белемендә яңа сүз әйтү иде.

Боларның барысы тәрҗемә теориясенә дә турыдан-туры кагыла. Чыннан да, илебездә чыгып килә торган тәрҗемә әдәбиятын игътибар белән күзәтсәк, шушы бердәм агым эчендә, күп санда булмаса да, романтик тәрҗемә үрнәкләренең дә яшәвен күрербез.

Без барыбыз да бала чагыбыздан ук К. Чуковскийның «Доктор Айболит» дигән мавыктыргыч әкиятен беләбез. Ә менә ул әкиятнең инглиз язучысы Грю Афтингтан алып язылган булуы һәрберебезгә мәгълүм түгелдер. Алексей Толстой, әйтик, «Алтын ачкыч яисә Буратино маҗаралары» исемле повестен язганда итальяннарның халык әкияте «Пиноккио»не файдаланган. Ә инде әдәбиятның бу корифейларыннан соң иҗат иткән яшьрәк буын әдипләреннән берсе Василий Федоровка килсәк, күптән түгел язылган һәм дәүләт премиясенә лаек булган поэмасында ул бары тик мәгълүм бер теманы гына нигез итеп ала һәм Дон Жуан турындагы сюжетны үзе теләгәнчә эшкәртә. Болар стильләре белән ук реалист язучылар ич диярләр. Әмма ул

ике юнәлешне упкындай аерып торучы чикләр юк бит. Әдәбият тарихында реалист язучы иҗатының кәтмәгәндә романтик юнәлеш алып киткән Пушкин, Куприн, Тукайның кайбер әсәрләре яки, киресенчә, иҗат фантазияләре белән романтик тип вәкилләренең реалистик әсәр тудырган очраклары (Лермонтов, Паустовский, С. Рәмиев) аз түгел. Бу — иҗат психологиясенең әлегәчә ачыклап бетерелмәгән катлаулы мәсьәләләреннән берсе.

Корней Чуковскийның шигъри әкияте дә, Алексей Толстойның «Алтын ачкычы» да, Василий Федоровның яңа поэмасы да — мәреп язу рәвешендә туган әсәрләр. Мәреп язу — үз закончалыклары буенча яши торган мөстәкыйль жанр һәм ул турыдан-туры тәрҗемә теориясе эчендә өйрәнелми. Без бу мисалларны совет язучыларының иҗат колачлары никадәр киң булуын күрсәтү өчен китердек.

Романтик рухлы шагыйрьләрдән Белла Ахмадуллина һәм Вадим Кузнецов тәрҗемәләренә мөрәҗәгать итик. Б. Ахмадуллина грузин, казакъ, балкар, чуваш шагыйрьләре әсәрләрен еш тәрҗемә итә, В. Кузнецов татар лирикасын рус укучысына җиткерү өлкәсендә уңышлы эшләп килә. һәр икесенең тәрҗемәләрендә бу каләм ияләре иҗатына хас үзенчәлекләр, аларның үз почерклары тулы чагыла. Сайлап тәрҗемә итү принцибы бирәдә шагыйрьләрнең үз иҗат йөзләрен, индивидуальлекләрен саклап калу мөмкинлеге бирә. Жуковский, мәсьәләне үткенләтә төшеп, «шигъриятттә тәрҗемәче ул ярышчы» дигәндә, тәрҗемәченең оригиналь әсәр авторы белән ярышка кереп, аның белән янәшә һәм мөстәкыйль рәвештә сәнгатьчә ачыш ясавын күздә тота. Бусы романтик тәрҗемәнең гомуми принцибы. Заманнар агышы совет язучыларына идеалны ачыклауда башка үлчәмнәр бирде, тик шулай да әлеге принцип яши һәм хәрәкәт итә. Язучының иҗат колачын, аның эчке азатлыгы өчен җирлекне киңәйтү турында кайгырткан тәнкыйтьче тормышының үз барышында туган романтик тәрҗемә формаларының күптөрлелеген хуплап каршыларга тиеш.

Мәкаләм, ахрысы, уйлану һәм бәхәсләшү, тәрҗемәнең кайбер хәл ителеп җитмәгән мәсьәләләре турында сөйләшү рәвешен алып бара. «Бөтнек исе» китабына кабат әйләнеп кайтып, Рафаил Төхфәтуллинның шушы исемдәге хикәясенең тәрҗемә ителешен тикшереп карыйк. Бу анализ тәрҗемә проблемаларына берьяклырак карашларның шактый яшәүчән икәнлеген тагын да бер кат раслый.

«Бөтнек исе» хикәясе С. Сафина тәрҗемәсендә бирелгән. Шушы ук хикәя Р. Төхфәтуллинның 1973 елда «Современник» нәшриятында чыккан «Ягодные поляны» исемле китабында Н. Евдокимов тәрҗемәсендә басылган иде. Чагыштырып анализ ясау өчен дә мөмкинлек бар дигән сүз.

Н. Евдокимов, әсәрне тәрҗемәләүгә керешкәнче, аның интонациясен, текст ритмикасын, образлы корылышын җентекләп өйрәнгән, һәм авторның сәнгать реалияләрен үз йөрәге аша үткәргәч кенә, хикәя ясау юлына басмыйча, оригиналның портретын тудыра. Үзенең бурычын ул оригинал нигезендә яңа сәнгать хакыйкате ачуда күрә, шул ачышларын автор белән уртаклаша. Текстологик бер мисал китереп үтик.

Әсәр үзәгендә ике дус, берсеннән-берсе уздырып эшләгән бораулаучы Җаббар белән аның ярдәмчесе Зиннур сурәтләнә. Алар бер-берсенә төче сүзләр әйтүгә күнекмәгән, дуслык хисләрен күңелдә яшереп саклыйлар. Җаббар яшь, куәтле егеттә үзен, үзенең яшьлеген күрә. Зиннур да өлкән һәм тәҗрибәле остазын тирән ихтирам итә.

Н. Евдокимов бу катлаулы мөнәсәбәтләрнең асылына төшенгән, авторның сабыр стиле рухына кергән. Менә бригаданың иртән буровойга баруы күренешеннән өзек китереп үтик.

«Зиннур остановился, поднял упавшую на дорогу вывороченную с корнем рябину, стал утаптывать вокруг нее землю.

— Вот люди,— сказал он,— ни за что погубили дерево.

Джаббар прошел мимо, толкнув его плечом:

— Жалостливый! Возьми домой и спи в обнимку.

— Я о тебе пекусь,— весело ответил Зиннур.— Ты же говорил, Джаббар абый, что рябиновый отвар тебе очень помогает от почек.

— Как нибудь без твоей заботы обойдусь,— сказал Джаббар и бросил в парня комком земли. Зиннур засмеялся и в свою очередь кинул в Джаббара куском засохшей грязи и попал в его помятую кепку.

— Вот как! Руку на старших поднимаешь,— Джаббар схватил Зиннура за пояс, но Зиннур крепко стоял на ногах — не так-то легко было сдвинуть его с места».

Оригиналда эпизод шушында тәмамлана. Тәрҗемәче исә авторның күңеленә үтеп кергәндәй, шул ук саллы стильдә вакыйганы дәвам иттерүен «сизми дә кала».

«Но Джаббар все же одолел — опрокинул парня на спину.

— Вот так, не связывайся со стариками,— сказал, отдуваясь, хотя знал, что Зиннур нарочно поддался ему. Зиннур засмеялся, вскочил и побежал быстро и легко, вприпрыжку, как теленок. Бог мой, как же парень этот всеми подводками похож на него, на молодого Джаббара...»

С. Сафина тәрҗемәсенә килсәк, Җаббар белән Зиннур арасындагы нечкә мөгамәлә, уен-көлке эченә яшерелгән хисләр тоныкланып юкка чыга. Яңа эпизодны башлап, ул болай дип яза: «Буровая как обычно дребезжала, стучала, гремела, грохотала на все лады». Тәрҗемә үзе дә әнә шул буровой кебек, дөбердәп һәм шытырдап колакны тырный. Тәрҗемәче автор текстының музыкаль яңгырашын, ритмикасын башка тел стихиясендә бирә алмаган. Шул ук вакытта хикәянең идея-эстетик эчтәлеген калку итеп гәүдәләндергән күп кенә урыннарны тәрҗемәче кыскарта, шул юл белән авторны «тәнкыйтькә» дучар итә.

Оригиналның хәрефенә турылыклы булырга тырышудан әле Пушкин ук көлеп язган иде. Шактый каты чикләвек булып чыкты ул буквализм, ягъни хәрефкә табыну дигән нәрсә. Изге китапларны тәрҗемә иткән заманнардан башлап, ул Шатобриан, ә аннары Тютчев, Брюсов кебек зур әдипләр практикасында да әледән-әле терелеп, баш калкытып килгән. Күргәнебезчә, бүген дә яшәргә әле исәбе. Хәрефкә табыну хакында грузин тәрҗемәчесе А. Церетели бик матур әйткән: «Хәрефенә туры китереп тәрҗемә итү — тере җан иясен үтереп, тынсыз гәүдәсен өстерәп йөрү белән бер»,— дигән иде ул.

«Тәрҗемәнең алгебрасы һәм арифметикасы» дигән дискуссияне тәмамлаганда Н. Евдокимовның бу хакта әйткән бик мәгънәле сүзләре хәтердә саклана: «Әгәр миңа тәрҗемә эшенә тотынырга тәкъдим итәләр икән, мин үземнең туган телемдә язучының индивидуальлеге, аның шәхесе, сөйләменең музыкаль яңгырашы гәүдәләнүен телим... һәр язучының чәчмә әсәрендә үз музыкасы, ритмы бар һәм мин аны ишетергә, гәүдәләндерергә тиеш»,— дигән иде ул. Моннан аңлашыла ки, проза һәм шигырь тәрҗемәсенең нигезе, асылда бер үк. Тегесендә дә, бусында да чынбарлыкны шигъриятле итеп гәүдәләндерү өчен художникка канатлы хыял эшкә җигәргә кирәк була. Хыялы ярлы булса, тәрҗемәче оригиналдагы чынбарлыкның фоторәсемен генә тудырырга омтылачак.

С. Сафинага килгәндә исә, ул, әлбәттә, әле яшь һәм тәҗрибәсез. Иҗади хезмәткә гаять җитди карап, сәләтен үстерә барганда, ул реалистик тәрҗемә серләрен үзләштерер дип өметләнәбез.

Әлеге китапта без яшь тәрҗемәчеләрнең төрле характердагы иҗат җимешләре белән очраштык. Арада Лилия Гайнанова иҗади омтылышларының киңлеге белән аерылып тора. Ул реалистик новелла остасы Шәриф Камалның «Буранда» исемле әсәрен тәрҗемә иткән. Бу хикәя белән Н. Кәримованың балалар өчен язган кыска хикәяләре тәрҗемәләрен янәшә куеп карыйк.

Тел-стиль чаралары белән дә, эчтәлекләре белән дә бер-берсеннән нык аерылып торган әсәрләр. Л. Гайнанова аларның интонацияләрен тотып ала белә, Г. Хантимерова үзенең кереш сүзендә яшь тәрҗемәченең беренче тәҗрибәләрен бик дөрес бәяли. «Шәриф Камалның кайбер хикәяләре әледән-әле рус теленә тәрҗемә ителеп тора. Менә безнең Л. Гайнанова шул тәрҗемәчеләр белән көч сынашып карарга булды». Чыннан да, Л. Гайнанова тәрҗемәсе классик язучыбызның элегрәк Лев Юдкевич тарафыннан эшләнгән тәрҗемәләреннән калышмый дип әйтә алабыз.

Шул рәвешчә, реалистик тәрҗемәнең колачы, әлбәттә, романтик тәрҗемәдән киңрәк. Безнең әдәбиятта романтик тәрҗемә метод буларак яшәми дә. Мәгълүм ки, ул методның нигезендә идеалистик философия ята. Ә кешелек җәмгыятенең үсеш закончалыклары дөньяга марксистик караш белән билгеләнә. Социалистик реализм әдәбияты, тарихи ачык система буларак, типологик яктан реалистик тәрҗемә методы чикләрендәге стилистик юнәлеш сыйфатында романтик тәрҗемәне дә үз эченә ала.

Тулаем алганда, үз уңышлары һәм кимчелекләре булган «Запах мяты» җыентыгы тәрҗемә сәнгате һәм яшь тәрҗемәчеләребезнең киләчәк иҗаты турында әнә шундый уйлар кузгата.

## РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ



Әдәби тәнкыйтькә Ринат Мөхәммәдиев җитди хәзерлек белән, әдәбиятыбызның бай тарихын тирәнтен өйрәнеп килде. Әле узган ел гына аның М. В. Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетында кандидатлык диссертациясе яклавы да шул хакта сөйли. Ул бер үк дәрәҗәдә яратып һәм үз итеп әдәбиятыбызның үткәне һәм бүгенгесе хакында җитди проблемалар күтәргән фәнни нигезле мәкаләләр белән чыгыш ясап килә.

Ринат Мөхәммәдиев үз мәкаләләренең әдәби камиллеге, мавыктыргыч һәм җанлы тел белән язылуына да зур әһәмият бирә. Аның матбугат сәхифәләрендә даими рәвештә күренә килгән күп кенә чыгышларына композицион бөтенлек, эмоциональлек хас. Мәкаләләрендә үз йөзе, үз дөньясы — шатлык һәм борчулары... Тәнкыйтьче укучыны заманыбызның әһәмиятле проблемалары, четрекле мәсьәләләре хакында уйлануларга этәрә, мавыктыра һәм рухландыра белә. Язучыларга мөнәсәбәте исә, хәерһак булган тәкъдирдә дә, кагыйдә буларак, таләпчәнлек белән принципиальлеген югалтмый. Матур сыйфатлар болар.

1979 елда Татарстан китап нәшриятында аның «Яңа елга күчтәнәч» дип исемләнгән нәниләр өчен хикәяләр җыентыгы дөнья күргән иде, ә быел исә әдәбият сөючеләргә ул «Әгәр без янмасак...» дигән әдәби тәнкыйть мәкаләләре җыентыгын тәкъдим итте. Миңа калса, игътибарга лаек, кызыклы һәм төпле китап.

Җыеп кына әйткәндә, Ринат Мөхәммәдиевның зур киләчәге булган өметле тәнкыйтьче икәнлегенә һич шигем юк. Яшь каләмдәшемә яңа иҗат бәхетләре телим!

ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН.

## РАДИК ФӘИЗОВ



Мин Радик Фәизовның «Яшьлек юллары» дигән повестен редакцияләгән идем. Бу — автор белән беренче танышуым булды һәм күңелдә канәгатьләнү хисе калды. Бу повестен автор балаларның холкын яхшы белеп, алар тормышының эченә кереп, шул ук вакытта укыр өчен күңелле итеп язган иде. Бу — Фәизовның уңышы. Киләчәктә ул бәлки зурлар өчен язар. Аның соңгы елларда күренеп килгән күп санлы хикәяләре шуны күрсәтә. Ләкин ул балалар әдәбиятында үзен иркенрәк сизә, кыюрак эшли, шуңа күрә әдәбиятның бу өлкәсен дә онытмасын иде дип әйтәсе килә.

Радик Фәизов җитди иптәш, тырыш, үз өстендә күп эшли. Әмма белемен тагын да үстерсә, әйбәт булыр иде. Бу аңар зуррак темалар кү-

тәрергә, әсәрләрендә тормышның проблематик мәсьәләләрен чишәргә теләгәндә кирәк булачак.

Иптәш — өметле, яза ала торган, әдәбиятка зур хөрмәт белән карый торган кеше. Мин аны СССР Язучылар союзына членлыкка тәкъдим итәм.

ЛӘБИБӘ ИХСАНОВА.

## МӘГЪСҮМ ХУҖИН



Мәгъсүм Хуҗин, язучылык эше белән күптәннән һәм җитди рәвештә шөгыльләнсә дә, аның язучылар оешмасына әлегә кадәр кабул ителмәвендә, әлбәттә, үзендә дә гаеп бар иде: гадәттән тыш тыйнаклыгы аңа Союзга керү турында уйларга да, Язучылар союзы идарәсенә гариза язарга да мөмкинлек бирмәде.

Миңа калса, прозаик Мәгъсүм Хуҗин инде күптән Язучылар союзы члены булырга тиеш иде. Аның «Ерганак юл ала» (1961), «Хикәяләр» (1966), «Курагай атлары» (1973), «Авылым урамнары» (1978), «Урманлы үр» (1980) дигән китаплары — чын сәнгать әсәрләре. Өстәвенә, әлеге китапларның барысы да фәкать хикәяләрдән генә гыйбарәт. Безнең исә бу жанрга турылыклы язучыларыбыз артык күп түгел.

М. Хуҗинның соңгы елларда язган кыска, тирән эчтәлекле хикәяләрендә авыл тормышы ышандыргыч деталь-образлар аша фәлсәфи планда сурәтләнә, хикәя геройларының уй-кичерешләре, теләк-максатлары заман куйган таләпләргә тәңгәл килә.

Мәгъсүм Хуҗин СССР Язучылар союзына член итеп алынгач, ул хикәя жанрында тагын да активрак эшләр, бүгенге белемле, зирәк акыллы игенченең рухи үсешендәге үзгәрешләрне тагын да кыюрак, тагын да тирәнтенрәк ачып бирер, дип ышанам.

ГАРИФ АХУНОВ.

## Шәүкәт Галиев

### Тургайлар министрына хат

Абый!
Быел бездә тургайлар юк.
Мин аларны һаман көтәм.
Килмәсләрме инде бүтән?

Абый!
Вәли әйтә, дару сипкәч
Самолеттан, качканнар, ди,
Бүтән якка очканнар, ди.

Абый!
Безнең кырга тургай җибәр,
Көн дә чыгып мин көтәрмен,
Килгәч тә хәбәр итәрмен,
Яме?

### Әни, дим, эчмә инде!

Йөрмә кибет алдында,
Кермә кибет артына,
Яратмыйча сөйлиләр
Сезнең ишләр хакында...
Әни, дим,
Эчмә инде!

Ничә тапкыр килделәр
Сине эзләп эшеңнән.
Иреннәрең күгәргән,
Күзләрең дә шешенгән...
Әни, дим,
Эчмә инде!

Сине дә бит таныйлар,
Мине дә бит таныйлар...
Чиркангандай карыйлар,
Әшәкегә саныйлар...
Әни, дим,
Эчмә инде!

Уйла минем хакта да,
Мин дә бит нәни түгел.
Эчкәч син ямьле түгел,
Эчкәч син әни түгел...
...Эчмә инде!!

## Җиңел чана

Уйнап бара бер бала,
Җип-җиңел чана тарткан.
Авыр әйбер күтәреп
Бер әби килә арттан.

Әбине күрә бала —
Чанасы авырая.
Авырая-авырая
Тәмам тукталып кала...

...Төште әби иңеннән,—
Күчте әйбер чанага.
Бик җиңел булып китте
Чана тарткан балага!

## Ике төрле карандаш

Карандашым искиткеч —
Берүзендә ике төс!
Яз теләгән кадәрле,
Менә сиңа — кызылы,
Менә сиңа — зәңгәре!
Болай да була мәгәр:
Менә зәңгәрле-кызыл,
Менә кызыллы-зәңгәр!

— Каян алдың, әтием,
Дусларга да әйтием?

— Шаулап йөрмә кешегә —
Алып кайттым эшемнән...

Яхшы бул, дия иде,
Киңәшләр бирә иде,
Нишләгән бу әтием,
Әтигә ни әйтием?

...Әйбәт иде, искиткеч,
Тоныкланды ике төс...
Карандаш кулдан төште,
Язмыйм мин ике төсле!..

## Ялгыш адым

Трамвайга асылынып
Йөргән чакта шаярып,
Уйлагандыр — егетлек,
Өлгерлек бу, чаялык!

Бер аяк белән баскан,
Бер кул белән ябышкан.
Бик тә хәтәр ярышкан,
Бик тә хәтәр ялгышкан...

Калган ялгыш адымда —
Ялгыш баскан аягы;
Сакланып кына атлый
Хәзер — култык таягы...

## Җир шарыннан атлый бала

Ул кагынып
Алулары,
Тып-тып басып
Барулары!

Утә чак-чак
Атлап әле,
Адымнары
Вак-вак әле.

Әмма эшне
Зурдан йөртә:
— Идән! — диеп,
Җиргә төртә.

Түшәмнәре
Булсын биек,
Үссен башы
Күккә тиеп!

## Малайга эт алдылар

Тәмам тигәч теңкәгә
Эт алдылар малайга.
Кисәттеләр шулай да:
— Режим кирәк маэмайга!

Андый-мондый түгел бу,
Гаҗәп затлы токымлы,
Ашауга да нәзберек,
Капмый такы-токыны.

Иртән иртүк торасы,
Саф һавада йөртәсе,
Кирәкчә сикертәсе,
Тәртипкә өйрәтәсе.

Этка режим булырмы,
Үзең дә санламагач,
Кабат-кабат әйтеп тә
Әйткәнне тыңламагач!

...Ә маэмай шундый матур
Мөлаем карап ала,
Яратканын белдереп
Борынны ялап ала...

Үзе шундый акыллы,
Өйрәткәнне отучан,
Отканны оныτмаучан,
Кушканны кабатлаучан.

Тиде режим файдасы,
Үсте күзгә күренеп.
Малай да бит тәртипкә
Җитте тәмам күнегеп.

Бер-берсенә ике дус
Гаҗәп дәияләнде,
Малай — этне, эт — малайны
Әйбәт тәрбияләде.

Хәтта әле маэмайны
Остарак дип таптылар —
Күргәзмәгә баргачтын
Көмеш медаль тактылар!

## Акыллы телефон

Һаҗәргә туп алганнар,
Безгә якын да килми —
Үзе генә сикертә,
Тотып карарга бирми.

Курчагы да бар аның,
Кулыннан бер дә куймый,
Ашалыр дип куркадыр,
Читкәрәк китеп уйный.

Ә телефон алгачтын
Нишләргә белми бүген —
Үзең белән үзең шул
Сөйләшү мөмкин түгел!

Уйлап баксаң, телефон
Кызык икән ул бигрәк —
Ялгыз булсаң, эшләми,
Телефонга дус кирәк!

Һаҗәр безне чакырды,
Килдек, якын торабыз,
Бераз тәрбиялибез,
Шактый ялындырабыз.

Телефонның булуы
Һәммәбезгә ярады —
Өзелгән араларны
Ансат кына ялгады.

Күңеллерәк ич безгә,
Тамашаны син күр, ә,
Тубы да бит Һаҗәрнең
Сөенечтән сикерә!

## Укучының күңел дәфтәренә

**Осетин мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Кендек сынса — сыныгын ташлама, чәкушкәгә яравы мөмкин.*

*Безнең караңгы йортка да кояш бер карар әле.*

*Яманны эзләп китсәң, яхшылык таба алмассың.*

*Ачы булсаң, төкереп ташларлар, татлы булсаң, чәйнәп йотарлар.*

*Кашыгыннан аш каптырып, сабын күзеңә төртә.*

*Көя киемне тетә, сагыш җанны кимерә.*

*Шаһлар күп була, ә мат бер генә.*

*Әгәр яралый алмасаң ерткычны үтереп булмый.*

*Көлгән чакта һәркем карый, елавымны күрер кеше юк.*

*Әвенеңә ут капса да, ашлык сугучыңны ашат.*

*Күз яшемне түгә алмыйм, кайгырырга кушмыйлар.*

*Шаяртмасана, кодача, сул аяктан биеп киттең бит.*

*Кабызмасаң утын да янмый.*

*Чәчкән нәрсә шытмый калмас.*

*Очкын төшмәсә ут капмый.*

# БӘХЕТЛЕ ИҖАТ

Илләр-җирләр, таныш түгел шәһәрләрне гизеп кайткан сәяхәтчеләр авызыннан шундый сүзләр ишетергә туры килә.

— Күңелгә хуш килә ул шәһәр.

— Әйе шул, яшәргә уңайлы.

Кеше үзенә ниндирәк торак йортлар, урамнар ошавын үзеп кенә әйтә дә алмый. Квадрат мәйданның, мәсәлән, шәһәр халкына уңайсыз тоелуы архитекторларга күптән билгеле. Андый мәйдан кысан һәм йомык булып күренә. Чөнки, кайсы тарафтан карасаң да, квадратның кырлары чикләнгән. Әгәр дә мәйданны бер юнәлештә озайтып җибәрсәң? Бу очракта архитектура ансамбле үзенең җыйнаклыгын, ыспайлыгын югалтачак.

Отышлы урталыкны табарга кирәк. Тик кайда яшеренеп ята соң ул без эзләгән урталык?

Геометрик фигура кырларының иң уңышлы нисбәтен архитекторлар «алтын урталык» дип йөртәләр. Шырпы кабын яки укучылар дәфтәрен мисалга китерергә мөмкин. Ни өчен мондый форма ошый икән безгә — әйтүе кыен. Катлаулы, күләмле төзелешләрдә бу «алтын урталык»ны эзләп табу авыррак, әлбәттә.

Җитмешнең өске ягына чыгып, дөньяның ачысын-төчесен татыгач та, яшәлгән елларыңа әйләнеп карый башлыйсың, тормышыңның «алтын урталыгы» турында уйланасың икән ул. Казан төзүче инженерлар институты профессоры Әхмәт ага Бикчәнтәев белән сүзебез нәкъ шул турыда башланып китте.

Көндәлек эше-шөгыле аның сөйләшүен дә салмакландырган, күңел дөньясын баеткан, тышкы кыяфәтенә ышаныч өстәгән. Заманыбызның атаклы архитекторы Ле Корбюзье да архитектура сәнгатендә дөньяга карашың чагылырга тиеш дигән бит.

Тәрле сораулар белән Әхмәт аганың иң мәгънәле сүзләрен бүләргә кыймыйча утырам. Ул үзенең тормышы, яшәү максаты турында сөйли. Гаҗәп катлаулы да һәм бер үк вакытта бик аңлаешлы да бу шәхес. Гадилек белән олылык шулхәтле ятышып торалар — таң калырлык!

Күңелдә сорау туа: авылыннан ун яшьлек малай чагында ук аерылган кеше үзенең бала чак хыялын шушы зур, ыгы-зыгылы шәһәрдә ничек саклап кала алды икән?..

Сәнгать әһелләренең күбесенә күңелендә йөрткән идеалы белән бала чакта ук очрашырга туры килә. Әхмәткә дә шундый бәхет елмая. Дөресен әйткәндә, ул чын архитектор белән егет булгач кына таныша. Аның өчен остаз ролен тормыш үзе үти.

Ә тормыш Әхмәт ага Бикчәнтәевне нык «өйрәтә». Сәнгать мәктәбендә укыганда көтмәгәндә сырхаулый башлый, мәктәпне ташлап чыгарга мәҗбүр була Әхмәт. Гражданнар төзелеше институтына укырга кергәч, архитектура буенча курсларны тукталар. Аннары егет Ленинградка китә, архитектура институтын тәмамлый. Институттан соң (1939 елда) фронтка китә.

Әхмәт агага сугышта җиде ел катнашырга туры килә. Солдат шинелен Бөек Җиңү көннәреннән соң гына сала. Гади солдат булып каршылый ул Җиңүне.

Егет җимергеч көчләрне үз күзләре белән күрә. Болгария җирендәге мәхшәрләр... Күз камаштыргыч табигатькә илбасарлар вәхшилеге һич кенә дә авазлаш ту-

гел. Әнә теге, борынгы барокко стилендә салынган йортлар тирә-юньдәге агачлар арасында ничек килешеп тора иде бит әле! Бер бомба — һәм матурлык шунда ук юкка чыга. Дөньяга төзер өчен килгән кеше күңеленә нинди җәрәхәт ясалганын белсәгез иде икән!

Архитектор сугыштан төзергә, иҗат итәргә дәртләнеп кайта. Нинди генә авырлыклар кичерсә дә, ул үзен иң бәхетле кеше дип саный. Уйлап карагыз: Әхмәт ага үзе проектлаштырган йортта тора, үзе проектлаштырган институт бинасында эшли.

Сугышка кадәр Әхмәт ага проекты буенча үзенчәлекле генә бер бина салырга керешкән булалар. Кайткач архитектор шул йортны эзләп таба. Төзелеш ярты юлда туктап калган. Хәзер инде, сугыш китергән афәтләрдән соң, кешеләрнең уй-хыяллары да үзгәргән. Чукрак-телсезләр өчен салына торган интернат-мәктәпне төзелеш институты өчен бинага әверелдерергә кирәк. Исеме җисеменә туры килгән Яшел урам буйлап атлый Әхмәт Бикчәнтәев. Сугыштан соңгы юллары нәкъ шушыннан узачагын күңеле белән сизә ул.

Ә менә Әхмәт ага Бикчәнтәев белән Петр Максимилианович Дульский[1]ның юллары ничек кисешкән соң?

Беренче тапкыр алар Әхмәтнең туган авылында — Олы Мәңгәрдә танышалар. Петр Максимилиановичны җирле халыкның милли культурасы кызыксындыра. Әхмәтнең исә рәссам булырга җыенып йөргән чагы. Сәнгать белгече Казан татарларының нәкыш-бизәкләре турында сораша. Әхмәт исә аны озатып йөри. Еллар үткәч алар Казан төзүче инженерлар институтының архитектура кафедрасында яңадан очраша.

Әлбәттә, Әхмәт ага иң беренче чиратта — укытучы, педагог кеше. Аңа булачак архитекторларны иҗат эшенә өйрәтергә кирәк. Шуңа күрә, үз фәненңе белү өстенә, башка фәннәрдән дә бик яхшы хәбәрдар булуың зарур. Фән-гыйлем өлкәсенең үз иҗат газаплары бар шул.

Әхмәт аганың күз алдында ук архитектура юнәлешләре берничә мәртәбәләр алышынды инде.

—... Архитектураның үсү юлларына игътибар итсәң,— дип фикерен дәвам итте Әхмәт ага, — сәнгатьнең башка төрләрендәгегә караганда катлаулырак күренешләргә тап буласың. Архитектура проблемаларын эстетика өлкәсенә генә кайтарып калдыру зур хата ул. Әйтик, ниндидер бер форма безнең зәвыкка туры килде, ди. Моны тиз генә тормышка ашыру мөмкинме? Һич юк. Кайсыларын башкарып чыгу материаль якка «суга». Шуңа күрә дә һәр шәһәрдә очраклы гына төзелгән йортлар очраштыргалый. Алар күңелгә бик авыр тәэсир итә.

Нәкъ шушы вакытта архитекторларның «алтын урталык»ны ничегрәк эзләүләрен, үз проектларын ни рәвешле яна-кюя яклауларын күз алдыма китердем. Бу борчылу Әхмәт аганың тавышына ук чыккан төсле иде.

— Беләсезме, — дип сүзен дәвам итте Әхмәт ага Бикчәнтәев, — безнең белән еш кына килешәләр дә бит. Проектларны производствога кабул итәләр.

— «Объектив» сәбәпләр аркасында кайбер төзәтмәләр кертү шарты беләндер инде?..

— Әйе. Хикмәт шунда, кайчакта төзүчеләр үтенече һәм киңәше буенча архитектор үзе дә үзгәрешләр кертми кала алмый.

Әхмәт ага белән дә моңа охшаш хәлләр була. Дөрес чишелеш табылган да сыман инде, исәбе-хисабы җиренә җиткерелгән. Әмма проект һаман да «җир белән күк арасында» эленеп тора. Төзүчеләрне ярдәмгә чакырмыйча мөмкин түгел, димәк.

Әхмәт ага Бикчәнтәев проектлаштырган күп кенә йортлар хәзер инде Казанның горурлыгы санала. КАИның төп бинасын реконструкцияләү, Казан дәүләт университетының химия факультеты бинасы Н. Э. Бауман һәйкәле, Ленин һәм Степан Халтурин урамнарындагы кайбер йортлар. Һәр бинада архитекторның үз кулы сизелә.

---

[1] Дульский П. М. (1879—1956) — танылган сәнгать белгече, татар халык нәкыш сәнгатен тикшерүче, «Казанның борынгы һәйкәлләре» (1914), «Казан татарлары бизәкләре» (1925), «Татар рәссамнары» (1929) кебек китаплар авторы. 1925 елны Парижда дөнья халыкларының сәнгатенең бөтендөнья күргәзмәсе була. Атаклы язучы, ул чакта Гыйльми Үзәк рәисе, Галимҗан Ибраһимов кушуы буенча, Татарстаннан Парижга җибәреләчәк делегация җитәкчесе итеп П. М. Дульский билгеләнә. Соңгы елларда Казан төзүче инженерлар институтының архитектура кафедрасында профессор булып эшли.

Авылда туып-үскән Әхмәт ага архитектураның авылны бер читтәрәк калдыра килүе белән дә килешми. Безнең архитектура өлкәсендә авыл төзелеше күтәрелмәгән чирәм икән: традицияләре түгел, аның хәтта фәнни нигезе дә юк. Крестьян тәҗрибәсе үзенең тикшеренүчеләрен көтә. Һәм Әхмәт ага Бикчәнтәев шушы эшкә керешә. Илленче елларның азагы була бу. Этнографиягә кагылышлы язмаларда сурәтләнгән йортлар, каралты-куралар бик тә бәхәсле: дөресме ул юкмы — кем тикшереп караган аны? Әхмәт ага башта шунысын ачыклый: иске традицияләргә үзгәреш кертергә кирәк. Шәһәрдәге бөтен уңайлыклары булган фатирны крестьянга тәкъдим итеп кара әле. Гомерендә дә риза булмас. Ул һаман да үз ягына борыр аларны. Гадәт бит. Аннары, бередә инде авылның ни рәвешле урнашачагын да истә тотарга кирәк. Шундый бер сөйләшүне хәтерли Әхмәт ага.

— Бабай, әйт әле, зинһар, — дип сорый ул авыл картыннан, — нишләп сезнең авыл тау битенә урнашкан? Җил оясы бит. Җитмәсә, суы да ерак.

— Бабаларыбыз сайлап алган урын инде, — ди карт. — Хәзер ничек бер сәбәпсез ташлап китәсең? Гореф-гадәткә каршы килү юк.

— Нинди гореф-гадәт, бабай? — дип төпченә архитектор.

— Ничек дип әйтим икән?.. Күрәсеңме, улым, бөтен тәрәзәләр кояш чыгышына карый. Бу бер ышану яки ырым гына түгел инде. Тәрәздән нур сирпелүгә крестьян аякка басарга гадәтләнгән. Сәгать тә кирәк түгел. Тау эргәсеннән яхшырак күренә: юлдан үз кешеме, әллә чит кеше киләме? Кайда кар эреп бетүен дә моннан гына карыйбыз. Җир өлгерүен, җир пешүен чамаларга мөмкин. Аннары, кар эрү дигәннән, тау башында ул бик тиз эри, юл иртә салына, туфрак та кызганыч түгел — тау туфрагы бит, теләгәнчә актар. Менә хикмәте кайда аның, улым...

Үзенең уй-фикерләрен Әхмәт ага кәгазьгә күчерә. Аның фәнни мәкаләләре, язмалары матбугатта басылып чыга. Ниһаять, аның төп хезмәте — «Татарстан авылларында торак йортлар төзү» дигән монографиясе дөнья күрә.

Әхмәт ага Бикчәнтәевнең бу фәнни хезмәтен шатланып каршылыйлар. Әлбәттә, шикләнебрәк карауучылар да табыла. Имеш, хәзер безгә биек-биек йортлар салырга вакыт. Имеш, авылларны заманча йортларга күчереп утыртырга кирәк. Нәкъ шул чакта Әхмәт ага авыл йортларының һәрберсе үзенчә төзелергә тиеш дип чыгыш ясый. Тәвәккәллек бар бит!

Бу юлы да Әхмәт агага бәхет елмая: Татарстан җирендә төзү өчен заманча авыл проектына конкурс уздырыла. Конкурс Бөтенсоюз күләмендә үткәрелә. Бу эшкә кайбер проект оешмалары, архитекторлар коллективы алына. Конкурска Әхмәт ага Бикчәнтәев та катнаша, үзенә иптәшкә Хәбил Ихсановны чакыра.

Урын сайлау иректә була. Менә кайчан кирәге чыга тикшеренүләрнең Әхмәт агага. Күп еллык тәҗрибәсе, белеме, крестьян гореф-гадәтләрен аңлау ярдәмгә килә аңа. Урын дигәннән, безнең Татарстанда күңеленә ятышлы урынны теләсә кайсы төбәктән табарга мөмкин бит. Кайсысы кирәк сиңа — урманмы, елгамы, әллә күлләрме, таулырак тарафлармы — рәхим ит! Ләкин Бикчәнтәев белән Ихсанов һич тә күзгә-башка чалынмаган Шәпше авылына тукталалар. Авылның табигате дә фәкыйрь. Бер өстен ягы бар — Казанга якын ул.

Кыскасы, Әхмәт Бикчәнтәев белән Хәбил Ихсанов һәр ягын уйлап-исәпләп эш итәргә керешәләр һәм зур җиңүгә ирешәләр: булачак Шәпше проекты СССР Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенә куела, авторларга СССР Дәүләт премиясе бирелә.

**МАКСИМ ГЛУХОВ.**

## ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

**Виталий Енеш**

# КЛАССИКЛАР ЭЗЕННӘН

Гасыр тәм-томнары» журналы редакторы минем белән елмаеп сөйләште, әмма «Төнге балкышлар» исемле хикәямне кабул итмәде. Ул да утыра инде, мин сиңа әйтим, редактор булып! Ә менә элек булган ул редакторлар, әйе, элек редакторлар кеше күңелен аңлый белгәннәр. Уйлап кына карагыз! Алар бит Толстой, Тургенев, Мопассан, Чехов, Пушкин, Хемингуэй, Лермонтов, Голсуорси, Гоголь, Дюма, Купер кебек авторларны олы юлга чыгарган кешеләр. Ә менә «Тәм-том» редакторы башка суккандай әйтте дә салды: «Сездә,— ди бу миңа,— бернинди дә оригинальлек сизелми!» Әллә мин санап киткән язучыларда сез оригинальлек булган дип уйлыйсызмы? Ю-у-ук! Байтакка сузылган казынуларымнан соң мин шундый нәтиҗәгә килдем: кайсы бөек шәхесне генә алма, аның язмышы минекенә туры килә. Кыскасы, алар белән минем арада параллельлек бик көчле. Күбесе иң яхшы әсәрләрен минем яшьтә язган. Лермонтов исә минем яшьтә инде танылып та өлгергән. Дөресен әйткәндә, мин үзем дә бит сигез яшьтән яза башлаган әдип. Әйтәсем килгәне шул: болары бөек шәхесләр белән минем арадагы беренче параллельлек.

Тагын шунысы кызык: шул ук Толстой, Горький, Пришвин, Тургенев, Хемингуэй балык тотарга бик хирыс булганнар... Мин дә и яратам инде балык тотуны. Әле күптән түгел генә ике кило кызылканат тотып кайттым.

Өченчедән, бөек шәхесләрнең күбесе сәяхәт итәргә бик яраткан. Мәсәлән, Гарвейны, Декартны, Дизельне, Линней белән Стендальне генә алыйк... Барысы да илләр гизгән. Мин үзем дә сәяхәтләрдән баш тартучы түгел! Быел гына да алты-җиде тапкыр авылга, әти-әни янына кайтып килдем. Ә безнең авыл ерак ул, Казанның үзеннән генә дә ике йөз чакрымлап булыр, мөгаен. Юлы нинди диген әле. асфальты төшкә генә керә!

Минем файдага тагын бер факт: Салтыков-Щедрин, Толстой, Золя, Герцен, Тургенев, Ибсен, Сервантес, Галилей — болар барысы да сакал үстергән. Минем дә сакал бар, югыйсә. Менә Сервантес белән генә безнең охшашлык җитеп бетми: ул сервант уйлап тапкан бугай, ә минем әлегә уйлап тапкан нәрсәм юк. Ну, анысы булыр, уйласаң, табыла ул!

Ярослав Гашек турында шундый сүзләр йөри имеш, булдыклы

солдат Швейк турындагы китабын бастырып чыгаргач, халык сүзенә колак салыр өчен трактирга кереп утырган бу.

— Нindидер Гашек,— ди икән бу янәшә утырган берәүгә,— ниндидер Швейк турында язып чыккан. Чүпнең чүбе инде!

Шунда укучылар моның белән бәхәскә кергәннәр, бәхәсләшә торгач, ачулары кубып, трактирдан типкәләп чыгарып җибәргәннәр.

— Аягыннан селкесәң бер хәреф төшми, шул башы белән Гашекны хурлап утыра,— дип кычкыралар икән артыннан.

«Саескан гыйшкы» дигән хикәям басылып чыккач минем дә укучылар фикерен ишетәсем килде. Киттем кафега. Кереп утырдым яшьләр арасына. «Әсәр яхшы булса,— дим үземчә генә,— мине дә куып чыгарырга тиешләр».

Кафе шыгрым тулы. Ун минут та үтмәгәндер, ишле генә компаниягә эләктем. Үз әсәремне бетереп сөйләргә ничектер кыюлыгым җитмәде. Сүзне болайрак башладым:

— Ниндидер Роман Мальцев шәп кенә хикәя язган! Шундый гыйбрәтле! Автор тормышны белә, киләчәккә кыю карый.

Әңгәмә кызып китте. Тиздән әңгәмә өермәгә әверелде. Һәм мин үземнең урамга очып чыкканымны сизми дә калдым. Үз теләгем белән чыкмадым, анысын яхшы хәтерлим.

— Надан башың белән сүз озайтып утырасың. Күренәсе булма!— дип кычкырулары гына истә калган.

Ә күңелдә ул шатлык, ул куаныч: димәк, мәйтәм, мин дә Гашек дәрәҗәсенә күтәрелгәнмен, тарихка керерлек әсәр язганмын. Мине дә Гашек шикелле куып чыгардылар бит. Тик бу хикәядән соң редакторлар миңа нигәдер кырын карый башладылар.

Тагын шул: берзаманны Бернард Шоудан: «Яхшы әсәрне ничек язарга?» дип сораганнар. Ул гади генә итеп: «Сулдан уңга!» дип җавап биргән. Мин дә сулдан уңга язам лабаса! Мин дә, классиклар кебек, кәгазьне сулдан уңга язып тутырам.

Зур язучылар үзләреннән соң том-том әсәрләрен калдырганнар. Ә мин язганнарны бастырсаң күпме чыгар иде икән? Шигем юк, уртача зурлыктагы бер китапханә чыга да чыга. Тик бер нәрсә аңлашылмый: шул кадәр охшашлык була торып, нигә аларныкын бастырганнар, ә минекен юк?! Ни җитми?

Язган юлларымны укыйм да, күңелемне кайгы баса. Толстойны инде әйтмим дә, минем бит Плутарх хәтле Плутарх белән дә параллельлегем бар! «Параллель язмышлар»ны ул язганмы? Ул язган! Ә мин үзем, хөрмәтле редактор иптәшләр, хәзер нәрсә белән шөгыльләнәм? Ә?!. Барып җиттеме? Менә шул шул!..

Ну, минем «Тәнге балкышлар»ны кабул итәсезме? Юк?! Ярар, хөрмәтле замандашлар, киләчәк барысын да ачыклар.

Чувашчадан тәрҗемә.

# 1980 ЕЛДА ЖУРНАЛДА БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР ИСЕМЛЕГЕ

*КПСС өлкә комитетында һәм Татарстан АССР Министрлар Советында*

**1980 ел өчен Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләрен бирү турында. № 5.**

КПССНЫҢ XXVI СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

Гаффар Ә. **Рәссам.** Очерк. **№ 10.**
Гомәров Г. **Кызлар үзәнендә.** Очерк. **№ 12.**
Гәрәев М. **Каһарман.** Очерк. № 8.
Гәрәев М. **Ташкүмер җыры. № 11.**
Зарипов М. **Мәңгелек шәһәр.** Очерк. **№ 7, 8, 12.**
Ишморат Р. **Замандашым.** Очерк. **№ 9.**
Маркова Ф. **Берьюлы — йөз язмыш.** Интервью. **№ 10.**
Рафиков М. **Ташкын.** Очерк. **№ 10.**
Ступнев Н. **Каен урманының тынлыгын саклап.** Очерк. **№ 10.**
Фасеев К. **Уйдырмалар кемгә кирәк! № 11.**
Фәтхуллин Н. **КамАЗ кешесе: кем ул!** Социолог язмалары. **№ 9.**
Фәтхуллин Н. **Идарә итү: кемнәр һәм ничек! № 10.**
Ш. Хамматов, Г. Ризванов. **Октябрь үстергән дәүләт эшлеклесе. № 11.**

В. И. ЛЕНИННЫҢ ТУУЫНА — 110 ЕЛ

**«Вакыт һәм кешеләр» конкурсына**

М. Гәрәев. **Ильичка хатлар. № 3.**

ДАҺИ ЮЛБАШЧЫ — ИЛҺАМ ЧИШМӘСЕ

Арсланов Н. **Ярдагы һәйкәл.** Шигырь. **№ 4.**
Баттал С. **Поэма тәрҗемә иткәндә.** Шигырь. **№ 4.**
Галиев Г. **Без сикерткән шобагалар.** Хикәя. **№ 4.**
Латыйп Г. **Байрагыбыз безнең Ильичлы.** Шигырь. **№ 4.**
Маликов Ә. **Адашырга безгә мөмкин түгел.** Шигырь. **№ 4.**
Маннапов Ш. **Чигенү юк.** Шигырь. **№ 4.**
Хамматов Ш. **В. И. Ленин татар матбугатында. № 4.**
Хәбибуллин М. **Яктыра кешелек таңнары.** Шигырь. **№ 4.**

ТӨРЛЕ ИЛЛӘРДӘН, ТӨРЛЕ ТЕЛЛӘРДӘН

Вознесенский А. **«Лонжюмо» поэмасыннан өзек. № 4.**
Львов М. **Бөек якташ.** Шигырь. **№ 4.**
Смирнов С. **Апрель.** Шигырьләр. **№ 4.**
Тарва Д. **Бөек кеше.** Шигырь. **№ 4.**

## БӨЕК ҖИҢҮНЕҢ 35 ЕЛЛЫГЫНА

Афзал Г. **Чулман ярында уйланулар.** Шигырьләр. № 4.
Баттал С. **Ярдан очып...** Шигырьләр. № 5.
Гурьев Г. **Лачын йөрәкле егет.** Очерк. № 3.
Гатауллин Р. **Германия.** Шигырь. № 5.
Гәрәй Р. **Туган авылымның туксан батыры.** Шигырь. № 5.
Маликов Ә. **Юлым синдә туктар.** Шигырь. № 5.
Мәһдиев М. **Ут чәчәге.** Повесть. № 4, 5.
Сирай Д. **1418 көн.** Шигырь. № 5.
Әхмәтҗанов Р. **Соңгы монолог.** Шигырь. № 4.
Әхмәтҗанов Р. **Ирләр юк.** Шигырь. № 5.
Әхмәдиев Н. **Солдат хатлары.** Шигырь. № 5.
**Солдат көндәлек яза.** № 2.

## ТАТАРСТАННЫҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА

Белялов У. **Ныгу.** № 2.
Ихсанов Н., Скороходов М. **Йөзгә-йөз.** Повесть. № 4.
Мостафин М. **Җир уллары.** Очерк. № 3.
Рәхим Г. **Табылдыклар өстәле.** Шигырьләр. № 4.
Шакир С. **Баһадирлар юлы.** Очерк. № 1.
Әмирханов М., Кильматов Р. **Юл.** № 2.
Җәләлов А. **Таң атканда.** Очерк. № 3.

## ЮБИЛЕЙГА — ВЕТЕРАН ШАГЫЙРЬЛӘРЕБЕЗ

Ш. Маннур. **Сабыр төбе...** Поэмадан өзек. № 6.
Х. Туфан. **Төрле еллардан.** Шигырьләр. № 6.

## БӘЙРӘМГӘ — ДУСЛАР БУКЕТЫ

Кармеев Г. **Ике Кремль.** Шигырьләр. № 6.
Кузнецов В. **Ташладым мин күкне.** Шигырьләр. № 6.
Ламар. **Казан.** Шигырь. № 6.
Любаев П. **Күпер салыйк.** Шигырь. № 6.
Макаров С. **Искә төште.** Шигырь. № 6.
Нарзуллаев Н. **Татарстан кызлары.** Шигырьләр. № 6.
Рза Р. **Теләгем.** Шигырьләр. № 6.
Сарханлы С. **Ипи-тоз.** Шигырь. № 6.

## ТАТАРСТАН КУНАКЛАРЫ ҺӘМ ДУСЛАРЫ

Оскоцкий В. **Бер сәяхәт турында.** Юл язмалары. № 5.
Санбаев С. **Йөрәгемә кадерле яклар.** № 5.

## ҺӘР ШАГЫЙРЬДӘН БЕР ШИГЫРЬ

Гатауллин Р. **Йокы юк шагыйрьгә.** Шигырь. № 6.
Дәүли Н. **Кызганыгыз йөрәкне!** Шигырьләр. № 6.
Мөэминова Э. **Әлмәт.** Шигырьләр. № 6.
Хисамов Н. **Горурлыгым.** Шигырьләр. № 6.
Хөсәен М. **Тоз турында баллада.** № 6.
Яруллин Ф. **Мәңгелек мирас.** Шигырь. № 6.
Әгъләмов М. **Татарстаным.** Шигырь. № 6.

Булатова К. **Беренчеләр идек.** Шигырьләр. № 3.
Ганиева И. **Шатлыгым.** Шигырьләр. № 3.
Гәрәева С. **Гаҗәп матур бер җәй җәйләдем.** Шигырьләр. № 3.
Ишморатова Р. **Сүз.** Хикәя. № 3.
Рәхимова Б. **Күләргәме, еларгамы!** Шигырьләр. № 3.
Салахов И. **Мәхәббәт картаймы!** Повесть. № 3.

## ПРОЗА

Ахунов Г. **Йолдызлар калка.** Повесть. № 5, 6, 7.
Баянов Ә. **Аргы яр.** Повесть. № 8.
Вәлиев Р. **Яшисе килә!** Повесть. № 2.
Вәлиев Д. **Портрет.** Хикәя. № 5.
Галиев М. **Төнге кыюлык.** Хикәя. № 2.
Галиев М. **Сиңа мин кирәк.** Хикәя. № 12.
Ганиев А. **Иман.** Хикәя. № 12.
Гыйләҗев А. **Җомга көн, кич белән...** Повесть. № 5, 6, 7.
Гыйльметдинов Ф. **Елганың борылган төшендә...** Повесть. № 9.
Камалов Х. **Куян күзе нигә кызыл!** Хикәя. № 1.
Кәрами Р. **Кәккүк тавышы.** Хикәя. № 2.
Маликова М. **Сары тюльпаннар.** Хикәя. № 12.
Насыйбуллин М. **Ярканат.** Повесть. № 9.
Рәкыйпов Ш. **Комбат истәлеге.** Чын хикәя. № 5.
Сарьян Х. **Җәза.** Повесть. № 3.
Сафиуллин Ә. **Гел зәңгәр булмый күкләр.** Хикәя. № 8.
Таһиров Т. **Галия.** Повесть. № 11.
Тимбикова К. **Тәңкәле тау.** Повесть. № 10.
Төхфәтуллин Р. **Ике каен, бер карама...** Дүрт хикәя. № 12.
Фәизов Р. **Күңелле көн.** Новелла. № 8.
Хуҗин М. **Кара күл.** Хикәят. № 12.
Хәбибуллин М. **Яңа өй.** Хикәя. № 12.
Хәсәнов М. **Шөгеровлар.** Романнан өзекләр. № 1, 2.
Хәсәнов М. **Зөбәрҗәт.** Хикәя. № 11.
Хәсәнов А. **Фәндәм фонды.** Хикәя. № 12.
Хөсни Ф. **Бераз бик якын кебек.** Хикәя. № 6.
Хөсни Ф. **Кем гаепле!** Хикәя. № 12.
Шәмси С. **Балконда.** Хикәя. № 8.
Әпсәләмов Г. **Карт мукшы.** Хикәя. № 1.

## ПОЭЗИЯ

Арсланов Н. **Язгы таңда.** Шигырьләр. № 5.
Вәлиева Р. **Ленин туган көн.** Шигырьләр. № 5.
Гатауллин Р. **Феникс — үлемсез кош.** Шигырьләр. № 7.
Гыйззатуллина Ф. **Иделдә өмә.** Шигырьләр. № 7.
Закиров Р. **Шигърияткә.** Шигырьләр. № 8.
Измайлова Н. **Уенчы җыр.** Шигырьләр. № 1.
Кутуй Р. **Аккош күлендә.** Шигырьләр. № 12.
Латыйп Г. **Мин бәләкәй чакта күрдем Димне...** Шигырьләр. № 9.
Мансуров З. **Уйлый белгән йөрәк.** Шигырьләр. № 12.
Рафиков М. **Төрле еллардан.** Шигырьләр. № 8.
Рәкыйпов Р. **Диңгез өсте сыек зәңгәр томан...** Шигырьләр. № 9.
Садә Г. **Алтын бөртек рәхмәте.** Шигырь. № 8.
Синугыл Ә. **Дала җаны.** Шигырьләр. № 8.
Туктарова В. **Кыска шигырьләр.** № 9.
Туфан Х. **Мә, партия, мине!** Шигырьләр. № 12.
Фәйзуллин Р. **Сәйдәш.** Поэма. № 11.
Харис Р. **Йөрәк белән капшап.** Шигырьләр. № 9.
Хәйдәр. **Күзгә булып иңде ак болытлар.** Шигырьләр. № 10.
Хәким С. **Туй итә Казан.** Шигырьләр. № 3.
Шабаев М. **Күзнең якты моңнары.** Шигырьләр. № 10.
Шакирҗанова Л. **Атылмыйча калган ук өчен.** Шигырьләр. № 8.
Юзеев И. **Мәхәббәт китабы.** № 1,2.
Яруллин Ф. **Күңел күзем.** Шигырьләр. № 5.

## ДРАМАТУРГИЯ

Гаффар Ә. **Язлар моңы.** Драма. № 11.
Әминов Ю. **Очрашырбыз, Гөлсылу.** Җитди комедия. № 9.

## КЛАССИК ПОЭЗИЯДӘН ҮРНӘКЛӘР

Б а б у р. **Газәлләр, робагыйлар.** № 1.
К о н а н б а е в А. **Кыран бөркет нәрсә генә алмас,** № 9.

## ДУСЛАР ИҖАТЫ

К а һ һ а р и Г. **Мәңгелек факел.** Поэмадан өзек. № 3.
К о л м ы й Я. **Салават янында.** Шигырьләр. № 4.
К у д а ш С. **Кошлар ашатам.** Шигырьләр. № 4.
М о л д а г а л и е в Ж. **Акыннар агасы.** № 11.
Ә л и б а е в С. **Сигезьюллыклар.** № 4.
**Бездә кунакта: каракалпак шагыйрьләре.** № 7.
**Бездә кунакта: коми шагыйрьләре.** № 12.

## ЧАЛЛЫ ШАГЫЙРЬЛӘРЕ

М а д ь я р о в Н. **Көзге кояш.** Шигырьләр. № 12.
С и б г а т у л л и н К. **Халык җыры.** Шигырьләр. № 12.
Х ө с н у л л и н Х. **Чаллым яктысы.** Шигырьләр. № 12.

## ЯШЬ ЯЗУЧЫЛАР КОНФЕРЕНЦИЯСЕННӘН

Б а т ы р о в Х. **Кыр чәчәге.** Шигырь. № 4.
Д ә ү л ә т ш и н З. **Горурланам.** Шигырь. № 4.
М о с т а ф и н Ш. **Солдат дәфтәреннән.** Шигырьләр. № 4.
Ф ә т х е т д и н о в а Ә. **Гөрләвекләр.** Шигырь. № 4.
Ш ә р и п о в Р. **Чиксезлеккә манып.** Шигырьләр. № 4.

## ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

А к м а л о в Н. **Әгәр ышансагыз.** Хикәя. № 1.
М о р а т о в Г. **Сабан туй.** Шигырьләр. № 9.
Н и з а м о в а Ф. **Кояш нурын эчәр өчен.** Шигырьләр. № 3.
С а д р и е в Ф. **Ә елга һаман ага.** Хикәя. № 3.
Х у җ и ә х м ә т о в а Ф. **Шулай була икән.** Хикәя. № 3.
Ш ә й х и М. **Әйтеләсе уйлар.** Шигырьләр. № 9.

## ЯКТАШЛАРЫБЫЗ ИҖАТЫ

М и ф т а х е т д и н о в А. **Келенеут.** Хикәя. № 10.
М о с т а ф и н Э. **Күңел күге.** Шигырьләр. № 10.
Р ә ф и к о в Б. **Уй белән Уел.** Шигырьләр. № 10.
С а л а х о в И. **Азатлык җырчысы.** № 10.
Х а л и д Р. **Кояшка туры.** Шигырьләр. № 10.
Ш ә р и п о в С. **Кала чыгу.** Хикәяләр. № 10.

## НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

Г а л и е в Ш. **Тургайлар министрына хат.** № 12.
Г о м ә р о в а З. **Бер өйдән сигез кеше.** Шигырьләр. № 6.
М и ң н у л л и н Р. **Йолдызлар.** Шигырьләр. № 5.
С и н у г ы л Ә. **Курчак елый.** Шигырьләр. № 10.
Ш ә р ә ф и Г. **Күрше малае.** Повесть. № 10, 11.

## ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

А ф з а л Г. **Утырышу.** Шигырьләр. № 1.
А ф з а л Г. **Хур кызларың йөрер...** № 11.
Б а т т а л С. **Минем үз каләмем бар!** Шигырь. № 10.

Енеш В. **Классиклар эзеннән. № 12.**
Нури З. **Үлчәве юк...** Миниатюралар. **№ 11.**
Рәхим Г. **Планнарны планлаштырдык.** Юмореска. **№ 11.**
Туктар И. **Җөмләләр. № 9.**
Яруллин Ф. **Мыштым Гайсә.** Юмореска. **№ 1.**
Әхмәдиев Н. **Хәмдениса.** Хикәя. **№ 10.**

## МӘСӘЛЧЕЛӘР МӘҖЛЕСЕ

**Түребездә — белорус классиклары. № 1.**
**Түребездә — рус мәсәлчеләре. № 2, 4, 8.**
**Түребездә — татар мәсәлчеләре. № 9.**

**Укучының күңел дәфтәренә. № 3, 4, 6, 7, 8, 9, 11, 12.**

## «ВАКЫТ ҺӘМ КЕШЕЛӘР» КОНКУРСЫНА

Гәрәев М. **Шамил батыр.** Очерк. **№ 1.**
Кәримов К. **Кайту. № 2.**

## ОЧЕРК, ПУБЛИЦИСТИКА

Абдуллин Я. **Рухи асылыбыз. № 6.**
Зәбиров И. **Ленин шоферы. № 4.**
Зәйнуллин Х., Шәфигуллин З. **Күңелләрдә Тукай моңнары. № 5.**
Низамов И. **Ул кабызган маяклар. № 4.**
Усманов Г. **Мәңгелек бердәмлек. № 6.**
Фасеев К. **Ирек-хокуклар: чын һәм ялган. № 11.**
Әйди Т. **Караңгылык патшасының сердәше.** Очерк. **№ 10.**

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Ахунҗанов И. **Тәрҗемәче ачкан тәрәзәләр. № 12.**
Галимуллин Ф. **Тирән катламнарны ачканда. № 4.**
Галимуллин Ф. **Идел җырчысы. № 8.**
Кукушкин Р. **Яңа шигъри ачкыч эзләп. № 1.**
Маннапов С. **Тормыш үзәннәреннән. № 3.**
Миңнуллин Ф. **Яшьлекне сагыну. № 1.**
Мөхәммәдиев Р. **Шигъри сүзнең җегәре. № 2.**
Мөхәммәдиев Р. **Күңелдәге эзләр. № 10.**
Надиров И. **Лениниананың гүзәл бер сәхифәсе. № 4.**
Нигъмәтуллин Э. **Типиклаштыру турында уйланулар. № 10.**
Сафиуллина Ф. **Татар прозасында хикәяләү. № 5.**
Хәсәнов М. **Ай үсәсен көн үсеп. № 6.**
Шәрәфи Р., Мингалим Р. **Эзләнүләр юлыннан. № 8.**
Юзиев Н. **«Ач, шигърият, серләреңне!» № 11.**
Әхмәдуллин А. **Чын кеше булып яшәүнең серләре. № 9.**
**Күтәрелү һәм яңарыш еллары.** (Татарстанның 60 еллыгы уңаеннан бер төркем татар әдипләре белән әңгәмә.) **№ 6.**

## ЯШЬ ТӘНКЫЙТЬЧЕ СҮЗ СОРЫЙ

Зөлкарнәев Ф. **Еллар чалымы. № 7.**
Хәкимуллина Х. **Яңа язмышлар ачылганда. № 7.**
Хөснетдинов З. **Көннәр язга авышкач. № 7.**
Янов Х. **Матурлыкны күбрәк күрергә. № 7.**

## КЕЧКЕНӘ РЕЦЕНЗИЯЛӘР

Госманов М. **Татар иҗтимагый фикере тарихыннан. Коллектив хезмәт. № 11.**
Литвин А. **И. Г. Гиззатуллин. Защищая завоевания октября. № 8.**
Сафин Р. **Хәсән Хәйри. Язучы һәм тормыш. № 11.**

Сафин Р. **Илдар Низамов. Ул кабызган утлар. № 11.**
Сафин Ф. **Фаил Шәфигуллин. Ак яллы аргамаклар.** Повесть, хикәяләр. **№ 11.**
Урманчеев Ф. **Сибгат Хәким. Халык язмышы — шагыйрь язмышы. Әдәби публицистик мәкаләләр. № 8.**
Хуҗиәхмәтов Ә. **Радик Фәизов. Юлда.** Хикәяләр. **№ 8.**
Яруллин Ф. **Шамил Маннапов. Әти урманы. Нәсерләр, парчалар, хикәяләр. № 8**

## КИТАП КҮЗӘТҮ

Абдуллин М. **Татар тарихы турында китап. № 4.**
Бәширов Г. **Көлкенең хикмәте бардыр. № 2.**
Вәлиев М. **Авыл урамнары буйлап. № 3.**
Галимуллин Ф. **Үсештәге иҗат. № 6.**
Госманов М. **Яңа сәхифәләр ачыла. № 10.**
Кәримуллин Ә. **Культурабыз үсеше елъязмасы. № 8.**
Мостафин Р. **Жанр тойгысы. № 4.**
Мостафин Р. **Табышлар һәм югалтулар. № 9.**
Мөхәммәдиев Р. **Гадиләр, гадәтиләр. № 7.**
Рамазанов Г. **Поэзиядә заман сулышы. № 6.**
Тимбикова К. **Шагыйрәнең яңа ачышлары. № 9.**
Урманчеев Ф. **Үлемсезлек юлы. № 2.**
Фәйзуллин Р. **Олы шагыйрь турында җитди хезмәт. № 5.**
Халит Г. **Язучының әдәби-эстетик фикер хәзинәсеннән. № 1.**
Ханзафаров Н. **Очлы күз, үткен сүз. № 8.**
Хәйдәрова Л. **Озак яшәүнең сере. № 1.**
Хәйдәрова Л. **Күңелгә килгән уйлар. № 7.**
Шакиров С. **Газета һәм әдәбият дуслыгы. № 1.**
Әйди Т. **Тел дигән дәрья бар. № 3.**
Әхмәдуллин Ш. **Адымнар. № 1.**

## ӘДӘБИ МИРАС

Гази И. **Көндәлектән бер бит. № 5.**
Камалиев Г. **Тәҗрибәле журналист, танылган шагыйрь иде ул. № 5.**
Уткин Е. **Мәңгелекнең өне.** Шигырьләр. **№ 10.**
Шакир С. **Мәрмәргә уелган исем. № 5.**
Юзеев И., Сирай Д. **Соңлап килде, чыңлап китте... № 10.**

## ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

Яхин А. **Җыр жанрының төзелеше. № 10.**

## ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Бариева Э. **Бәйләнеш серләрен ачканда... № 1.**
Маннурова М. **Героик симфониягә тиң гомер. № 2.**
Нәфиков Р. **Яңа документлар, яңа бурычлар. № 11.**
Солтанов Ф. **Хөр фикерләү юлында... № 2.**
Хаков В. **«Мәхәббәтнамә» әсәре һәм татар әдәбиятында аның традицияләре. № 3.**
Хамматов Ш. **Идел бөркете, ил бөркете. № 2.**

## ӘДӘБИ ТЕЛ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Низамов И. **Тел байлыгын — матбугат битенә. № 9.**
Әхәтов Г. **Сүзнең хикмәтен табып. № 3.**

## ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

Волков Г. **Татарстанның үз улы. № 5.**

## КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Дәүләтшин Г. **Болгар язма культурасы. № 3.**
Лотфи Г. **Соңгы еллар. № 4.**
Михайлова С. **Татар халкының мәгърифәтче улы. № 2.**
Мәһдиев М. **Рус ориенталистларының эшчәнлеге һәм татар вакытлы матбугаты. № 3.**
Рәхимкулова М. **Юл башында. № 4.**
Әхмәтҗанов И. **Яшьлек һәм шигърият юлдашы. № 5.**

## СӘНГАТЬ

Глухов М. **Бәхетле иҗат. № 12.**
Халитов Н. **Казан татарлары архитектурасында милли үзенчәлекләр. № 9.**
Шәмсетдинова Ф. **Татар симфоник музыкасы үсеш юллары. № 1.**

## ӘБҮ ГАЛИ ИБН-СИНАНЫҢ ТУУЫНА 1000 ЕЛ

Абдуллин Я. **Күренекле фикер иясе, галим һәм әдип. № 9.**
Фәйзуллин М. **Мәшһүр врач. № 9.**

## БӨЕК РУС ЯЗУЧЫСЫ АНТОН ПАВЛОВИЧ ЧЕХОВНЫҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ

Чехов А. П. **Ата.** Хикәя. **№ 1.**

## СӘГЫЙТЬ РӘМИЕВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Садретдинов Ш. **Таң җырчысы. № 2.**

## МӘҖИТ ГАФУРИНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Мәһдиев М. **Шагыйрьнең гомер йомгагы. № 8.**
Әхмәтҗанов Р. **Мирастан ике энҗе. № 8.**
**Мәҗит Гафури турында фикерләр. № 8.**

## А. БЛОКНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Блок А. **Скифлар. Авиатор.** Шигырьләр. **№ 11.**

## ХӘСӘН ТУФАНГА 80 ЯШЬ

Туфан Х. **Ул — безнеке, без аныкы идек.** Истәлек. **№ 12.**
Бәширов Г. **Шагыйрь бакчасында. № 12.**
Хәким С. **Туфан — күпер... № 12.**
Миңнуллин Т. **Шаянлык һәм җитдилек. № 12.**
Яхин А., Низамова Ф. **Кайсыгызның кулы җылы. № 12.**

## САЛИХ СӘЙДӘШЕВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Вәлиева Ф. **Ул яулаган үрләр.** № 11.
Сәйдәшева З. **Җыр бишеге янында.** № 12.
Салитова Ф. **Чорга аваздаш.** № 12.
Бакиров Ә. **Соңгы очрашу.** № 12.
Хөсәен М. **Тукае син көйле дөньяның.** № 12.

## НӘБИ ДӘҮЛИГӘ 70 ЯШЬ

Маннапов С. **Язгы ташулар яктысы.** № 6.

## ҖӘВАД ТӘРҖЕМАНОВКА 60 ЯШЬ

Ихсанова Л. **Зур бакчаның бер гөле.** № 6.

## ГАЗИЗ НӘБИУЛЛИНГА 60 ЯШЬ

Нәбиуллин Г. **Көтәләр кебек.** Шигырьләр. № 2.

## МАНСУР ХӘСӘНОВКА 50 ЯШЬ

**Тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме.** № 6.

## ДИЛӘРА ЗӨБӘЕРОВАГА 50 ЯШЬ

Зөбәерова Д. **Гадел шелтә.** Хикәя. № 8.

## МӘРЗИЯ ФӘЙЗУЛЛИНАГА 50 ЯШЬ

Фәйзуллина М. **Солдат хатлары.** Шигырьләр. № 6.

## ЭДУАРД КАСЫЙМОВКА 50 ЯШЬ

Сафин Ф. **Еллар яктысы.** № 11.

## БАРЛАС КАМАЛОВКА 50 ЯШЬ

Камалов Б. **Актуган Габсаттары.** Повесть. № 1.

## ХӘСӘН САРЬЯННЫҢ ТУУЫНА 50 ЕЛ

Ахунов Г. **Агыйдел егете.** № 3.

## МӘСКӘҮ. 80 НЧЕ ЕЛ ОЛИМПИАДАСЫ

Булатов Ә. **Ленин һәм физик культура.** № 6.
Мортазин Х. **Батыр якташларыбыз.** № 6.

## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Вәлиев М. **Моң чишмәләрен эзләгәндә** (Мәхмүт Нигъмәтҗановка 50 яшь). № 5.
Гәрәй Р. **Абдулла Сәләхетдиновка 50 яшь.** № 4.
Ибраһимова Ф. **Язучы-педагог** (Гали Рәфикыйның тууына 90 ел). № 7.
Максуд Х. **Ил белән бергә** (Мәхмүд Максудның тууына 80 ел). № 1.
Сафин Ф. **Еллар яктысы.** № 11.
Хәйруллина З. **Җыр булып яңгыраган язмыш** (Җәүдәт Фәйзинең тууына 70 ел). № 1.
Хәйруллина З. **Әнвәр Бакировка 60 яшь.** № 7.
Хәйруллина З. **Халкым белән бергә** (Заһид Хәбибуллинга 70 яшь). № 9.
Хәмидуллин Л. **Таһир Нурмөхәммәтовка 50 яшь.** № 4.
Хәмидуллин Л. **Чыңгыз тауларының бөркете.** № 11.
Шәмсетдинова Ф. **Күңелдәге моң чишмәсе** (Исмай Шәмсетдиновка 70 яшь). № 9.
Шәфигуллин Ф. **Кояшлы гөрләвекләр** (Мәгъсүм Хуҗинга 50 яшь). № 5.
Юзиев Н. **Илдус Ахунҗановка 50 яшь.** № 4.
Әгъзәмов Ф. **Ихлас күңелдән** (Хәсән Хәйригә 70 яшь). № 2.
**Г. Галинең тууына 80 ел.** № 7.
**Г. Толымбайның тууына 80 ел.** № 4.
**Кәбир Бәкернең тууына 100 ел.** № 8.
**Халикъ Садриның тууына 90 ел.** № 8.
**Һәрвакыт алгы сызыкта** (Мөхәммәт Әблиевның тууына 80 ел). № 7.
**Резеда Вәлиевага 50 яшь.** № 5.

## БЕЗНЕҢ САФКА

**Равил Вәлиев.** № 1.
**Әхмәт Гадел.** № 8.
**Мәхмүт Газизов.** № 1.
**Марсель Галиев.** № 8.
**Шамил Маннапов.** № 1.
**Ринат Мөхәммәдиев.** № 12.
**Зиннур Насыйбуллин.** № 8.
**Илдар Низамов.** № 8.
**Радик Фәизов.** № 12.
**Мәгъсүм Хуҗин.** № 12.

## ТӨРЛЕСЕННӘН

Вәлиәхмәтов Х. **Ул ачкан дөнья.** № 4.
Сайкин Ш. **Кушаматлар тарихыннан.** № 1.
Шешин А. **Декабрист якташыбыз.** № 11.
Юзеев И. **Чишмәләр кая агарлар!** № 10.
Юсфин А. **Аның күңел гөлбакчасында.** № 12.

**Укучы сүзе.** № 4, № 10.

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары.** № 1 — № 12.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ПАРТИЯ ОТЧЕТ-САЙЛАУ ҖЫЕЛЫШЫ

Татарстан Язучылар союзының башлангыч партия оешмасында отчет-сайлау җыелышы булды.

Партбюроның еллык эше турындагы отчет белән аның секретаре Туфан Миңнуллин чыкты. Ул, һәр жанрга аерым-аерым тукталып, уңышлы һәм кимчелекле якларны күрсәтте, коммунист язучыларның, бигрәк тә урта буын әдипләренең йөкне төпкә җигелеп тартучы көчкә әйләнүләрен, нәтиҗәле иҗат итүләрен билгеләп үтте. Докладчы шулай ук Татарстан Язучылар союзы партбюросының, идарә белән берлектә, әдәби алмаш турында кайгырту буенча шактый эш алып баруына да киң тукталды. Күпчелек язучыларның җәмәгать эшләрендә актив катнашуын, моның иҗатта уңай йогынты ясавын билгеләп үтте. Аннан соң докладчы КПСС өлкә комитеты каршында даими эшләүче иҗат интеллигенциясе һәм Татарстан Язучылар союзы каршындагы теоретик семинарларның язучылар иҗатына уңай йогынтысын әйтеп узды.

Докладтан соң чыгыш ясаган язучылардан Гомәр Бәширов, Сибгат Хәким, Гариф Ахунов, Зәки Нури, Софья Радзиевская, Рафаэль Мостафин, Геннадий Паушкин, Мәдинә Маликова, Разил Вәлиев һ. б. иптәшләр дә язучының гражданлык бурычы, аның җәмәгать активлыгы, совет кешеләрен тәрбияләүдә партиябезнең ышанычлы ярдәмчесе булырга тиешлеге турында сөйләделәр. Җыелышта катнашкан коммунист язучылар Татарстан Язучылар союзы партия бюросының еллык эшен канәгатьләнерлек дип бәяләделәр, аны тагын да нәтиҗәлерәк итүгә юнәлдерелгән карар кабул иттеләр.

Соңыннан партбюроның яңа составы сайланды: Ринат Мөхәммәдиев (секретарь), Венера Ихсанова, Рәфкать Кәрамиев (урынбасарлар), Сибгат Хәким, Гариф Ахунов, Геннадий Паушкин, Илдар Юзеев.

Җыелышта КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев катнашты һәм чыгыш ясады.

## ЛЕЙПЦИГ ЯРМИНКӘСЕНДӘ — ТАТАРСТАН

Россия Федерациясе автономияле республикаларының берсе буларак, дөньяның атаклы сәүдә һәм промышленность оешмалары смотрында — халыкара Лейпциг ярминкәсендә — үзенең казанышларын күрсәтү хокукын Татарстан АССР 60 еллык юбилее, В. И. Ленинның тууына 110 ел тулу елында алды.

Бер мең квадрат метрга якын мәйданда Совет Татарстаны предприятиеләре җитештерә торган промышленность продукциясе, киң куллану товарларының иң яхшы үрнәкләре күрсәтелде.

Татарстан предприятиеләре үзләренең товарларын дөньяның 80 нән артык иленә чыгаралар. СЭВ илләренә озатыла торган продукциянең ассортименты да төрлечә: автомобильләр, исәпләү һәм вакуум приборлары, сәгатьләр, медицина җиһазлары, нефть химиясе промышленносте әйберләре. Киң куллану товарлары бүлегендә Татарстанның Х. Ямашев исемендәге мех производство берләшмәсе әйберләре куелган иде. Казаннан килгән мехларга Парижда, Нью-Йоркта, Копенгагенда, Варшавада һәм башка бик күп шәһәрләрдә тиндәш була алмады. Лейпциг ярминкәсенең алтын медальләренә тәкъдим ителгән әйберләрдән Казан компрессор заводының «МХТМ» суыткыч машинасына алтын медаль бирелде. Ярминкәдә Совет Татарстанының милли көне уздырылды. Анда Казаннан килгән кунаклар концерт куйдылар. Концертта Республиканың иң яхшы иҗат коллективлары һәм башкаручылары катнашты. Бу көнне совет павильонында уннарча мең кеше булды. Күбесе ярминкәгә килүчеләр китабына Татарстанның уңышлары таңга калырлык дип язып калдырдылар.

## ТЮРКОЛОГЛАР ФОРУМЫ

Ташкентта III Бөтенсоюз тюркология конференциясе булды. Анда Мәскәү, Ленинград шәһәрләре, Россия Федерациясе, Урта Азия, Казагыстанның күренекле галимнәре катнашты. ГДР, Венгрия, Польша, Америка, Швейцария, ГФРдан да тюрколог галимнәр килгән иде. Конференциядә төрки телләрне, төрки халыкларының әдәбиятын һәм тарихын өйрәнү проблемалары, киләчәктә бу өлкәдәге тикшеренүләрне үстерү юллары каралды.

Конференцияне оештыру комитеты председателе, СССР Фәннәр академиясе член-корреспонденты Г. Ф. Ким ачты.

СССР Фәннәр академиясе каршындагы Тюркологлар советы комитеты председателе академик А. Кононовның чыгышы илдә төрки тел белеме үсешенең йомгаклары һәм перспективаларына багышланды. III Бөтенсоюз тюркология конференциясенең «Лингвистика», «Әдәбият белеме», «Тарих» секцияләрендә барысы 460 доклад һәм чыгыш тыңланды.

Бөтенсоюз тюркологлар форумы эшендә

СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты, Казан һәм Башкорт дәүләт университетлары, Казан һәм Алабуга педагогия институтлары галимнәре дә актив катнаштылар.

М. З. Зәкиевнең «Борынгы грек тарихчылары төрки халыклар һәм аларның телләре турында» дигән докладны тыңлаучыларда зур кызыксыну уятты. В. Х. Хаковның докладында XIX гасыр татар теленең әдәби үсеше, Ф. С. Хәкимҗанов чыгышында болгар эпиграфик истәлекләрен лингвистик анализлау мәсьәләләре яктыртылды. И. А. Абдуллин кыпчак теле чыганакларына тукталды.

Диалектология буенча да берничә галим чыгыш ясады. Г. Х. Әхәтов Башкортстан АССР территориясендәге татар сөйләше группаларын өйрәнү нәтиҗәләре турында хәбәр итте. Ф. Ю. Йосыпов доклады татар диалектларында исем фигыльнең функциональ семантик үзенчәлекләрен ачуга, Л. Ш. Арсланов чыгышы Калмык АССРның Каспий районында яшәүче алабугат татар теле формалашуда үзбәк компонентының роленә багышландылар.

Ф. С. Сафиуллина, С. М. Ибраһимов, Ф. А. Ганиев, З. З. Заһидуллина докладларында татар теленең кайбер әһәмиятле синтаксик һәм семантик үзенчәлекләре чагылыш тапты.

Г. Ф. Саттаров, А. Х. Нуриева, О. А. Мизин үз чыгышларында татар ономастикасы һәм этногенезы, К. З. Зиннәтуллина, Л. К. Бәйрәмова, С. М. Исхакова, Р. А. Юсупов рус һәм татар телен чагыштырмалы өйрәнү мәсьәләләрен үзәккә куйдылар.

Әдәбият белеме секциясе өч тармакта («Әдәбият тарихы», «Хәзерге заман әдәби процессы һәм әдәбият теориясе мәсьәләләре», «Фольклористика») эшләде.

Тарих секциясендә А. Х. Халиков Идел буе һәм Урал алдының төркиләштерү этаплары, С. А. Алишев XVIII гасырда Казан татарларының Урта Азия һәм Казагыстан белән сәүдә элемтәләре, Ф. Г. Вәлиев Себердәге җирле халыкның Идел буе татарлары белән этнографик һәм тарихи-культура элемтәләре турында чыгыш ясадылар. М. Х. Юсупов татар халкының этногенезы турында Шиһап Мәрҗани фикерләре белән таныштырды.

Татар галимнәре конференциядә тюркологиянең актуаль мәсьәләләре буенча барысы 30 доклад белән чыктылар. Аларның бу өлкәдәге фәнни тикшеренүләре югары бәяләнде.

## ЯШЬ ШАГЫЙРЬЛӘР ФЕСТИВАЛЕ

Август аенда Тува АССРның башкаласы Кызыл шәһәрендә яшь шагыйрьләрнең XI Бөтенсоюз фестивале булып узды. Анда илебезнең барлык республикаларыннан инде беренче китапларын чыгарган 40 лап яшь автор чакырылган иде.

Фестивальдә катнашучылар алдында СССР Язучылар союзы Правлениесе секретаре, иҗат яшьләре белән эшләү комиссиясе председателе шагыйрь Олег Шестинский чыгыш ясады. Ул яшь шагыйрьләрнең гражданлык йөзе, иҗади активлыгы һәм әдәби осталык мәсьәләләренә җентекләп тукталды. Аннары кунаклар республиканың тормышы, культурасы, хезмәттәге уңышлары һәм тарихи урыннары белән таныштылар. Клубларда һәм культура сарайларында әдәби кичәләр үткәрелде.

Фестивальнең төп максаты — илебезнең яшь иҗат көчләрен барлау, тәҗрибә уртаклашу, әдәбиятның актуаль проблемалары хакында сөйләшү иде. Шуңа күрә яшь шагыйрьләрнең иҗатын тикшерү семинарлары аеруча җанлы һәм бәхәсле узды.

Семинарларга илебезнең танылган әдипләре Станислав Куняев, Николай Дамдинов, Вил Ганиев, Аннабирде Агабаев һ. б. иптәшләр җитәкчелек итте.

Татарстаннан әлеге фестивальгә яшь шагыйрь Рашат Низамиев килгән иде.

## ЖУРНАЛ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

16 сентябрьдә язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында «Казан утлары» журналының 1980 елның 1—6 саннарында сөйләшү булды. Һәр жанр буенча докладлар белән Хатип Госман (әдәби тәнкыйть), басылып чыккан материаллар хакында Фоат Галимуллин (проза), Марс Шабаев (поэзия), Равил Вәлиев (очерк һәм публицистика) иптәшләр чыкты.

Соңыннан фикер алышулар булды.

Җыелышта Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов Каракалпакстанда татар әдәбияты һәм сәнгате көннәренең ничек узуы турында сөйләде, аны үткәрүдә актив катнашкан язучыларга Татарстан Язучылар союзы идарәсенең Почет грамоталарын тапшырды.

## КҮРГӘЗМӘ ЗАЛЛАРЫНДА

Татарстан Художниклар союзының яңа күргәзмә залы сынлы сәнгать осталары иҗатлары белән таныштыруын дәвам итәрә. V «Зур Идел» зона художество күргәзмәсеннән соң анда ТАССР төзелүгә 60 ел тулуга багышланган зур экспозиция күрсәтелгән иде һәм менә әлеге мәһабәт сәнгать сараенда республикабыз культура һәм тарихында һәркайсы үзенчәлекле урын алган художниклар — Н. Кузнецов, Б. Альменов, В. Дайчман, Г. Мелентьев, А. Прытков, Е. Старостин, И. Язынин истәлекләренә багышланган күргәзмә ачылды. Бу экспозиция индустриаль пейзаж, графика, портрет һәм башка жанрлар буенча эшләгән әлеге художникларның бай иҗатын бөтен тулылыгы белән күз алдына китерә. Шунысы игътибарга лаек: күргәзмәдә авторларның киң җәмәгатьчелеккә моңарчы таныш булмаган әсәрләре дә тәкъдим ителгән. Мәсәлән, Татарстан сынлы сәнгатендә индустриаль пейзаж жанрына нигез салучыларның берсе РСФСРның һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе

лауреаты Николай Кузнецов, шулай ук графика сәнгатен үстерүгә үзеннән гаять зур өлеш керткән художник — ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Байназар Альменов экспозицияләрендә андый эшләр аеруча күп.

Күргәзмә залында 60 һәм 50 яшьләрен тутырган художниклар Ю. Ананьев һәм С. Неустроевның шәхси күргәзмәләре дә эшли. Бу күргәзмәләрдә әлеге сынлы сәнгать осталарының иҗат үрнәкләренә шулай ук киң урын бирелгән.

## ИЛҺАМЫБЫЗ — ИГЕНЧЕЛӘРГӘ

Авыл эшчәннәренә культура хезмәте күрсәтү теләге белән, Казанның бер төркем сәнгать осталары Горький өлкәсенең Кызыл Октябрь районы авылларында «Татарстан таңнары» дигән әдәби-музыкаль кичәләр үткәрде. М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры солистларыннан Зөһрә Сәхәбиева, Зилә Сөнгатуллина, Хәйдәр Бегичев һәм Рафаэль Сәхәбиев аеруча зур уңыш казандылар.

Марс Макаровның Зиннур Насыйбуллин сүзләренә язылган «Кара шәлең килә сөйрәлеп» дигән җыры газиз аналарыбызның Бөек Ватан сугышы елларында күрсәткән рухи батырлыкларына, алтын сабырлыкларына шигъри һәйкәл булып күтәрелде. Яшь композитор Риф Гатауллинның шагыйрь Фәннур Сафин сүзләренә иҗат ителгән «Хушлашырга ашыкма» җыры да беренче башкарылуында ук үзенә җәлеп итте. Зилә Сөнгатуллина, композитор Сара Садыйкованың «Вальс турында вальс»ын (Мәхмүт Хөсәен сүзләре) зур осталык белән башкарып, игенчеләрнең көчле алкышларына лаек булды.

Чүмбәли авылы егете, яшь җырчы Хәйдәр Бегичевның зур зәвык белән әзерләнгән концерт программасын якташлары бигрәк тә яраттылар. Мәҗит Гафури сүзләренә язылган Нигъмәт ариясе («Эшче» операсыннан) көчле аһәң белән янача яңгырады.

Кичәләрне шагыйрь Мәхмүт Хөсәен алып барды. Ул тамашачыларны Г. Тукай, М. Җәлил, Н. Нәҗми, Г. Афзал, И. Юзеев, Н. Дәүли әсәрләре белән таныштырды.

* * *

Нукус шәһәрендә каракалпак язучыларының VIII съезды булды. Язучы Лирон Хәмидуллин анда татар язучыларының тугандаш әдипләргә юллаган котлавын тапшырды. Съездның икенче көнендә барлык кунаклар Каракалпакстан язучылары белән Нукус дәүләт университетының яңа уку бинасында булдылар, укытучылар һәм студентлар алдында чыгыш ясадылар.

## ШАГЫЙРЬЛӘР СЕКЦИЯСЕНДӘ

Чираттагы утырышта Татарстаннан читтә яшәүче шагыйрьләребез Салисә Гәрәева һәм Булат Сөләйманов иҗатын тикшерү булды. Докладчылар Рәшит Әхмәтҗанов һәм Шамил Маннапов аларның шигырь китапларына анализ белән чыктылар. Чыгыш ясаучы шагыйрьләр Х. Туфан, Н. Арсланов, И. Юзеев, Р. Мингалимов, Р. Гатауллин, Зөлфәт, М. Әгъләмов, Ә. Рәшитов һ. б. бу шагыйрьләрнең поэзиядә актив эшләүләрен әйтеп, иҗатларында үстерәсе уңай якларга туктадылар, киңәшләр бирделәр.

Секция исеменнән С. Гәрәева һәм Б. Сөләйманов СССР Язучылар союзына тәкъдим ителделәр.

## ЧАЛЛЫ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

Мәскәүдә чыга торган «Новый мир» журналы Чаллыдагы яшь авторлар белән тыгыз бәйләнештә тора, аларның әсәрләренә әледән-әле үз битләрендә урын бирә. Әмма журнал редакциясе моның белән генә чикләнмәде, Чаллы шагыйрьләренең коллектив җыентыгын дөньяга чыгарырга булды, бу эшкә журналның җаваплы секретаре Феодосий Видрашку һәм поэзия бүлеге хезмәткәре Арво Метс алынды. Бу күркәм эштән Чаллы язучылар оешмасы да читтә калмый, тиешле булышлыкны күрсәтә. «Орфей» һәм «Ләйсән» берләшмәләреннән егерме бер авторның шигъри әсәрләрен бергә туплаган бу җыентык Мәскәүнең «Известия» нәшриятында 1981 ел башында, ягъни партиянең XXVI съезды ачылыр алдыннан дөнья күрәчәк.

•
• •

Чаллы шәһәре «Энергетик» культура сараенда «Ләйсән» әдәбият-сәнгать берләшмәсенең отчет-сайлау җыелышы булды. Анда бюро председателе Г. Кашапов берләшмәнең еллык эше турында отчет доклады белән чыкты. Соңыннан берләшмә членнары Р. Лотфуллин, Р. Юнысов, В. Хәбибрахманова, Р. Риянов, Р. Фәхразиева, И. Рыскужин иптәшләр доклад буенча фикер алыштылар, берләшмә эшендәге уңай һәм кимчелекле яклар турында сөйләделәр, җитешсезлекләрдән арыну өчен эшлекле тәкъдимнәр кертеләр.

Җыелыш Г. Кашапов, Р. Хәйретдинов һәм М. Сафин иптәшләрне бюро членнары итеп сайлады. Шул ук көнне бюро утырышы булды. Анда бюро председателе итеп Г. Кашапов сайланды.

•
• •

Чаллы шәһәр кошчылык фабрикасында уздырылган укучылар конференциясендә «Якты юл» газетасыннан публицист Рахман Шәфигуллин, «Знамя коммунизма» газетасыннан корреспондент Нәфисә Сафина, «Союзпечать»нең Автозавод районы вәкиле Любовь Попова һәм Чаллы язучылар оешмасыннан Эдуард Касыймов катнашты. Язучы «Казан утлары» һәм «Азат хатын» журналлары хакында сөйләде, конференциягә килгән халыкны кызыклы һәм бай эчтәлекле әсәрләр белән таныштырды.



М. РӘХИМОВ. *Г. Тукай һәм замандашлары яшь С. Сәйдәшевның уйнавын тыңлыйлар*

## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫ!

Журналның киләсе елда чыгачак беренче саны КПССның XXVI съездын каршылау йөзеннән язылган публицистик мәкаләләр белән башланып китә. Тарих фәннәре докторы У. Беляловның «Бүгенге һәм киләчәк хакына», тарих фәннәре кандидаты Ш. Хаматовның «Муса Җәлил — партия солдаты» исемле язмалары — шундыйлардан.

Әдәби сәхифәләрне өлкән шагыйребез С. Хәкимнең «Егерме бишенче август» исемле яңа циклы ачып җибәрә. Шигырьләрдән Ә. Баяновның һәм Р. Юнысовның яңа әсәрләрен дә күрсәтергә кирәк.

Бу журналда без зур-зур юбилейлар билгеләп үттек. Андый бәйрәмнәргә багышланган язмалар 1 нче санда да булачак. Күренекле прозаик, Дәүләт премиясе лауреаты Гомәр ага Бәшировка 80 яшь тулу көне билгеләнә. Бу уңайдан Р. Миңнуллин, С. Поварисов мәкаләләре басыла. Юбилярның иҗатын яратучы укучыларны исә Г. Бәшировның «Сарут» исемле яңа хикәясе шатландырачак.

Һ. Такташның тууына 80 ел тулу көне дә киң яктыртыла. Бу җәһәттән журналда Р. Мөхәммәдиев, Х. Туфан, Г. Иделле язмалары урын алачак.

Бу материаллардан тыш журналда язучы Ж. Рәхимовның «Тәвәккәл таш яра» исемле яңа повесте, рәссам Х. Якуповның «Зур Идел киңлекләре» исемле мәкаләсе бар. «Безнең календарь», «Китап күзәтү», «Төрлесеннән» рубрикалары да шактый бай эчтәлекле.

Журналның соңгы битләрендә, гадәттәгечә, әдәбият һәм сәнгать яңалыклары теркәлгән.


Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210